
# Казан утлары

11
НОЯБРЬ-1973

Эрот Зарипов

# ТУГАН АВЫЛЫМ

циклыннан линогравюралар.



Туган ил турында җыр



Кояш нурлары

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

11

НОЯБРЬ
1973

## Бу санда

Г. РӘХИМ. Неон яктысында уйлану. Шигырьләр . 3
Ш. МАННУР. Агымсуларга карап. Повесть . . 7
Г. АФЗАЛ. Әлмәт яклары. Шигырьләр . . . . 66
Ә. МАЛИКОВ. Яшьлек утравым. Повесть-истәлек 73
И. ӘХСӘНОВ. Бәсле гөлләр. Шигырь . . . . . 92
Э. БАЯНОВ. Һәйкәл. Драматик повесть . . . . 96

ДУСЛАР ҖЫРЫ

В. ГОРЯИНОВ. Моң. Шигырь . . . . . . . . . 123
М. ЯРЕМЕНКО. Социалистик Хезмәт Герое Г. Латыйпов белән сөйләшү. Шигырь . . . . . . 123

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . 124
М. ХӘМИТОВ. Кабат кайтты яшьлек . . . . . 126
Р. МАКСУДОВ. Бүгенге авыл кешеләре . . . 142

Г. КУТУЙНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

С. ЗАКЛАДНЫЙ. Солдат Кутуй . . . . . . . . 149

ХАЛЫК ИҖАТЫ

Ф. УРМАНЧИЕВ. «Ник акмадым дәрьяга боз булып» . . . . . . . . . . . . . . . . 157

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Т. КОРБАНГАЛИЕВА. Совет властеның беренче елларында Татарстанда китап басу . . . . 167

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

## БҮГЕНГЕ ПРОЗА ТУРЫНДА СӨЙЛӘШӘБЕЗ

Язучы. Заман. Герой. . . . . . . . . . . . . 174

## КИТАП КҮЗӘТҮ

Т. ГАЛИУЛЛИН. Әхмәт Фәйзи — тәнкыйтьче һәм галим . . . . . . . . . . . . . . . 181
Р. МОСТАФИН. Романтик омтылышмы, аек акылмы! . . . . : . . . . . . . . . 184

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

З. АКПЕРОВ. Бөек гуманист шагыйрь . . . . 187
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . : . 190

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.

Баш редактор: **Гариф Ахунов.**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

---

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

---

Производствога бирелде 6/VIII-1973 ел. Басарга кул куелды 25/IX-1973 ел. ПФ 09080.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 83200 экз.
Заказ Я-392. Бәясе 50 тиен.

---

ТАССР Министрлар Советының нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинаты, Казан, Бауман урамы, йорт 19.

## Гәрәй Рәхим

### Неон яктысында уйлану

Иң соңыннан кем калыр бу Җирдә?
Берәү?.. Икәү?.. Меңнәр?.. Миллионнар?..
Иң соңгысы булып Син калырсың.
Һәм нәкъ Сиңа тиңнәр, миллионнар.

Син калырсың! Чөнки Синдә генә
Камиллеге якты дөньяның.
Дүрт гүзәлен биргән сиңа Галәм:
Чыгыш, Батыш, Төн һәм Көн ягын.

Һәм тагын да биргән дүрт гүзәлен:
Җирен, Күген, Утын һәм Суын.
Йорт төзергә ташлар биргән тагын,
Иген чәчә торган басуын.

Ә бомбаны бирмәгәндер сиңа,
Бу — тик ялгышыдыр дөньяның.
Куян ясыйм диеп бомба чыкса?
Зыяны бармыни куянның?!

Сизеп торам, куян дигәч синдә
Потенциаль аучы уяна.
Нәсле корсын, халыкара бер ау
Игълан итик бомба-куянга.

Чын куяннар калсын! Калсын ташлар,
Чыгыш, батыш, төн һәм көн ягы!
Җирең, күгең, утың, суың калсын —
Бизәп торсын алар дөньяны.

Күр, урамда неон яктылары,
Ал нурында коена ак каен.
Юк, кайгырма, шулар белән Җирдә
Син калырсың, Кеше дускаем!

●

Малайлыктан уздык бугай инде,
Булмасак та әле ир-ага.
Безнең җилкә, безнең иманыбыз
Кирәк бугай инде дөньяга.

Безнең иман — малайларга иман,
Ә агайлар бездән эш көтә.
Заманага хөкем — безгә хөкем,
Җавап бирми булмый ничек тә.

Безгә инде рөхсәт ителмидер
Чыгарырга уймак уеннан.
Без бит җирдә адәм рәтле тормыш
Дәвам итсен өчен куелган.

Бездән тора бугай инде хәзер
Дәүләтләрнең ничек эшләве.
Түбәнлекнең өскә үрләмәве,
Бөеклекнең түбән төшмәве.

Малайлыклар артта калды инде,
Озакламый без дә ир-ага.
Ә бүгенгә без — утыздагылар,
Һәм җаваплы без дә дөньяга.

●

Читтән генә сиңа карап торам.
Дөнья сиңа шундый килешә:
Көлмәгеңә болын рәсме төшкән,
Ә көлмәгең рәсме — инештә.

Күзләреңә кичке эңгер йоккан.
Мин, зәңгәр күз, диеп җыр язам.
Чәчләреңдә җылы җилләр йоклый —
Алар күчкән сиңа бу яздан.

Сандугачлар сиңа көй биргәннәр,
Җикән-камыш сиңа буй биргән.
Ялгыз казмы, моңлы талмы, әллә
Алсу таңмы — моңлы уй биргән.

Ялгыз гына басып торасың син,
Язгы рәсмең уйный инештә.
Читтән генә сиңа карап тордым —
Дөнья сиңа бик тә килешә.

## Синең иҗат

Мин сокланам синең иҗатыңа.
Синнән, шиксез, бик зур галим чыгар.
Күпме ачыш ясадың син җанда —
Күңлем чыңлый хәзер талир сыман.

Син аңлаттың миңа гади күзгә
Җирнең һәрбер сере күренгәнен.
Язын шомырт чәчәкләргә түгел,
Безнең ап-ак моңга төренгәнен.

Хәзер инде мин кояшка карыйм
Зур бер учак кына итеп түгел,
Аның кебек, шушы дөнья өчен
Мәңге балкыш тели минем күңел.

Болыннарда яна ал чәчәкләр —
Алар, иркәм, безнең саф теләкләр.
Җаныбызның матур уе булып
Очып йөри кызыл күбәләкләр.

Ә бу җилләр тергезәләр булыр
Курганнарда калган батыр җанын.
Офыкларда һаман кызылланып
Янып тора шул батырлар каны.

Күңлем чыңлый талир тәңкә сыман,
Үзгәрттең син мине. Ал рәхмәтем!
Мин сокланам синең иҗатыңа,
Синең иҗат — минем мәхәббәтем.

## Дөнья бөтен

Күрче, иркәм, дөнья безнең өчен
Нинди төгәл булган байлыгын.
Икебезгә нәкъ бер кояш биргән,
Тулы бер ай, киек каз юлын.

Аз да, күп тә түгел — бер җир шары,
Бер зәңгәр күк, ап-ак бер Казан.
Без бәхетле булсын өчен, зурлап,
Бүләк иткән бөек бер Ватан.

Без тиешбез, иркәм, моның барын
Бөтен килеш кенә сакларга.
Юк, бүлешмик. Кыен чакларда да
Гаризалар язмыйк судларга.

Без бүлешсәк, ярты кояш белән
Җылытырбыз кемнең сөюен.
Ай да тулы чакта яктырак бит,
Тулы булса матур җир-күгең.

Ярты Казан халкын кыерсытсаң,
Ни әйтерләр бабаң һәм атаң?!
Кемгә кирәк, әгәр Ватан булып,
Ярты гына булса ул Ватан!

Юк, бүлешмик. Кыен чакларда да
Гаризалар язмыйк судларга.
Дөнья бөтен. Аны нәкъ шул килеш,
Нәкъ шул килеш кирәк сакларга.

## Үзгәрсәк тә

Мәхәббәттә без күпләргә үрнәк булдык,
Бер тамырдан чыккан ике гөләп булдык.
Аерым-аерым уйламадык бер уйны да,
Бер үк хисне кичергән куш йөрәк булдык.

Күпләр бездән көнләште дә бугай әле,
Безгә каршы көрәште дә бугай әле.
Тик без сөю дигән изге ныгытмага
Дошман якын килалмаслык терәк булдык.

Сагышларны, каргышларны санламадык,
Ни ул кайгы, ни ул хәсрәт, аңламадык.
Бер-беребезгә җирдә иң зур бәхет биргән
Идеал һәм иң-иң изге теләк булдык.

Тора-тора без үзгәрдек, нишләп беттек,
Син ул якка, мин бу якка карап киттек.
Еллар безгә шундый кырыс шартлар куйды —
Син ул җиргә, мин бу җиргә кирәк булдык.

Юк, көлмәгез элек бездән көнләшкәннәр,
Шатланмагыз безгә каршы көрәшкәннәр —
Мәхәббәтне сакламасак — вакламадык!
Куш йөрәктән без ике зур йөрәк булдык.

## Оныттың бугай

Сине уйласам, мине моң баса,
Борчылып йөрим инде ничә ай.
Күңелем сизә, назлы язларны
Оныттың бугай, оныттың бугай.

Еракта калды дәртләнеп-ярсып
Без җырлап үткән ул яшел тугай.
Кабатлап булмый торган чакларны
Оныттың бугай, оныттың бугай.

Сөй дип үтенмим, ләкин үкенмим
Яшьлектә сине сөйгәнгә шулай.
Син мине түгел, яшьлекнең үзен
Оныттың бугай, оныттың бугай.

## Соңладык

Уңда ак ай батты, сулда ал таң атты...
Күзгә-күз карарга кыймадык.
Кеше күрер, кайтыйк инде, дидек,
Әллә иртәләдек, әллә соңладык.

Унҗиде яшь иде безгә ул чак,
Кыңгыраулар кебек чыңладык.
Күрешербез әле, дип аерылдык,
Әллә иртәләдек, әллә соңладык.

Бүген менә ничә еллар үткән.
Кинәт тирән бер уй уйладык:
Без сөйгәнбез. Моңа төшенергә
Без соңладык, ахры, соңладык.

Шәйхи Маннур

# АГЫМСУЛАРГА КАРАП

ПОВЕСТЬ

Ай, нинди соклангыч һәм кабатларга да куркыныч сүзләр! Шаккаттым, әнә ничек ялкынланып та китә белә икән ул! Аның бу сүзләре ниндидер сихерле көч белән үзләренә тарта күңелне. Бу — минем өченче дөньям хәзер, зәңгәр хыяллар дөньясы! Әле кайчан гына Юныс байдан да бай булу хыялы — минем канатлы атым иде, ә хәзер ул миңа бик көлке, хәтта хурлыклы көннәрем булып күренә. Гаҗәп, заман сине саз суыннан суырып алып, бөтенләй бер саф агымга кертеп җибәрүен сизми дә каласың икән. Шул ук заман озакламый мәктәп бусагасыннан өченче дөньяга да алып чыгар мине, ул да гади чынбарлыкка әйләнер. Тик хәзергә мин анда хыялым белән генә яшим. Татлы да, газаплы да... Чөнки аның уртасында шул хыяллар төсле ике зәңгәр күз белән алтынсары ике толым да бар бит әле. Миннән бер парта аркылы гына алда ул ике толым. Һәр көнне күрәм, һәр иртәне баш иеп сәләмлим, кулым белән түгел, күңелем белән генә сыйпап куям. Тик ике зәңгәр күзне күрергә генә зар-интизар. Чөнки алар язып-таеп миңа караса, тиз генә үз күзләремне җиргә төртәм, кып-кызыл булып битләрем януын бик яхшы сизгәнгә күрә, читкә китеп барам...

Инде байтактан бирле моңнар-моңаюлар, уйлар-уйланулар ургыла, айкала, чайкала күңелдә. Түгелер дә агылыр күк ашкына. Нишләргә соң, ничек бушанырга? Шәмәк белән Тулбай арасындагы «дөнья уртасын» җырлап та узган булам, үзем белән сөйләшеп тә кайткан булам, юк — эчләр бушанмый, җырлар төкәнми, җанга рәхәт тынлык җәелми...

«Язгыз!..» диде Фарукъ абзый. Күптән эзләнеп тә үзен таба алмаган тылсымлы тартманың сихри ачкычын кулга биргән шикелле яңгырады бу сүз. Үземә-үзем ышанмыйча, кыюсыз гына тотындым мин ул ачкычка. Үз эчендә нинди көч ятканын бераү дә белми. Җир катламына яшеренгән «алтын тамыр»ны яки алмаз бөртекләрен бик күп эзләнүләр, күп көч түгүләрдән соң гына ачарга мөмкин, ә күп кенә очракта ул катламнарның бөтенләй буш булып чыгуы да бик ихтимал. Шуңа күрә

Дәвамы. Башы 8, 9, 10 саннарда.

бәләкәй бер «хикәя» генә язып карадым. Кышкы каникулда әти белән төнлә урман урларга барган идек. Кайтканда котырып буран чыкты да төн буе адашып йөрдек. Авылдан әллә ни ерак та булмаганбыз икән, безнең тавышны урам очындагы Әсәт абый белән Галимулла абзый ишетеп, кулларына шахта лампасы яндырып, килеп алдылар. Әй шундагы сөенүләр! Менә шул «Адашу» дигән хикәя булып чыкты. Фарукъ абзый мактады, журналда да «басылды», ә мин куанмадым. Чөнки хикәя — вакыйганы сөйли, ә күңел тулы уйлар, хыяллар, ургылып агар юл тапмаган үз сүзләрең —әйтелми кала икән...

Беренче санда ук «Яңа юл» дигән шигырь «бастырган» идем инде, тагын яздым: «Яшь күңел» һәм «Язгы җыр» иде бугай болары. Шигырьлекләре, әлбәттә, фәләнчә генә булгандыр, ләкин ул елларда уналты яшь белән бара торган «егет»нең үз сүзләре, үз дөнья тануы, үзенең язгы моңаюлары әйтелгән иде. Фарукъ абзый аларны да кире какмады, журналга да керде... Ни өчендер шигырь миңа, хикәяләргә караганда, ныграк тәэсир итә, күңелне җылыта торганы бер укуда хәтергә сеңеп кала иде...

Шигырь белән маташа башлагач, исем-фамилия мәсьәләсе дә алга килеп баса икән. Моңарчы дәрес дәфтәрләремдә Шәйхелислам Фәрхулла угылы Фазлытдинов йөри идем. Мондый озын, ике этажлы сүзләрдән торган исем-фамилия белән ничек шагыйрь буласың? Исемнең соңгы яртысын кисеп ыргыттым да Шәйхи булып калдым. Казына торгач, ерак бабамның берсе Мәннүр атлы булганын таптым. Моннан да шәп фамилия булуы мөмкинме? Беркемдә юк бу! Һәм мин Ш. Маннур булып киттем...

Үз гомеремдә очраткан әйбәт остазларым арасында иң әйбәте, иң кадерлесе булып, бик яшьли үлеп киткән Фарукъ абзый Билялов калды минем өчен. Чабаталы авыл малаеның гади күңеленә, кара ипигә дә туймаган ул елларда шундый матур, шундый изге идеал салучы, ул малай үзе дә белмәгән, бөтенләй уйлап та карамаган эчкәрге яшерен көчләрен, яхшы хисләрен уятып җибәрүче, авыр һәм татлы шигърият дөньясына сукмак күрсәтүче бу остазыма гомер буе рәхмәт укып яшим мин. Ә ул елларда укытучының үз хәле дә искиткеч авыр иде бит: гөрәнкәле паек такы-токы гына, чәй-шикәр, сабын-тоз, шырпы-керосин берсе дә юк. Чыра яктысында дәфтәр карый, дәрескә әзерләнә, үзенә дә, класска да бер китап. Мәктәп суык, өс киемнәрен салып утыру мөмкин түгел. Хәер, ул чакта суык та гаҗәп түгел, «юк» та гаҗәп түгел, «бар» гаҗәп иде. Әмма Фарукъ абзый үзен кайгырта белә иде микән — әйтүе кыен. Мәктәпкә килеп кергәндә аның башында гади куян бүрек, өстендә яшел шинельдән бозып тектергән пальто, аягында олтанлы киез итек була. Бияләе дә юк бугай аның, күшегеп күгәргән кулларын дәрес биргәндә, үзе дә сизмәстән, шактый озак уып йөри ул. Мәктәптә нинди суык булса да, класска пальтосы төсле үк яшел френчтән генә керә. Ә безнең бишмәтләрне салырга кушмый.

— Менә озакламый утын да күп килеп җитәр, язга таба көннәр дә җылыныр, шунда бишмәтсез утырырсыз,— дип юаткан була ул. Безнең әләмә-сәләмәне дә бик тиз күреп ала һәм нindiдер юлын табып, ярдәм итәргә тырыша. Берничә малайның өс киеме бөтенләй рәтсез, бишмәтләренең кылкасы коелган, минем өченче елны тектергән тегә зәңгәр бишмәт тә шактый кыршылып, курачланып калган иде. Фарукъ абзый каяндыр солдат шинеленнән зурлар өчен тегелгән дүрт куртка юнәтеп, безнең өскә кидерде. Шул куртканы киеп, озын җиңнәрен кайтарып куйгач, өстән ак алъпкыч ябып, билен кысып бугач, әче бураннарда Шәмәк белән Тулбай арасын таптаулар шактый михнәтсез булып китте. Ул безнең өчен укытучы гына түгел, дусыбыз да, киңәшчебез дә иде. Белмим, партиядә тора иде микән Фарукъ абзый, әмма ул минем күңелдә беренче коммунист образы булып, чын кеше булып калды.

## «Түтәй сатып» ат алдык

Без хәзер җирле дә булдык (дүрт имана!), салам-печән дә күбәйде, ипигә дә тиендек дияргә ярый. Башта уртактан чәчтергән булсак та, быел көзен тулысынча үзебезнең арышны чәчтек, киләсе язда сабанга җитәрлек орлык та бар. Бу еллар эчендә урман яклары да рәтләнеп китте. Фартал[1] бирүләре өстенә урлап та кисәргә була. Элекке «өстерилек» дигән газраил «үлде». Агач, салам булгач, каралты-куралар да рәтләнде. Безнең хәзер ике лапас бар, «бер ярым» абзар бар, шуларга амбарны да кушып, түбәләрен тоташтан яңа салам белән ябып җибәргәч, диһи[2] кеше сыман булып күренә башладык. Ничәмә еллар буена «коры куыш» булып яткан амбарга әти үз кулы белән яңаклар куеп, ишек эшләде, сайгак җәйде, иген-тару салырга өч-дүрт лар ясады. Аннары килеп өйгә өстәл-урындык ясады, ян сәке корып җибәрде, өй бөтенләй ямьләнеп киткән сыман булды. «Югары өй»гә идән җәйде, стеналарын чутлап[3] чыкты, ишек борысларын утыртты, тәрәзә яңаклары, рамнар ясап куйды. Әгәр кирпеч табып морҗа чыгартсак, пыяла табып тәрәзә куйдырсак, унбиш ел буена безнең өстә караңгы бура булып торган югары өй киләсе җәйдә чын оҗмахка әйләнәчәк!

Ишегалды коймасы буенда шулай ук унбиш елдан бирле мүкләнеп яткан имән бүрәнәләрне дә кисеп-юнып, шомартып дигәндәй, капка баганалары сыйфатына кертте әти. Димәк, шыгырдавык җил капкадан да озакламый котылачакбыз. Өй артын, «юкагач»тан гына булса да, рәшәткә белән дә әйләндереп алды, мин анда алмагач үсентеләре утырттым.

Үзебезнең эш беткән арада Гатаулла Йосыбы дигән кешегә келәт бурап бирде әле ул. Әйтерсең чын балта остасы! Мин аның бу төрле күп һөнәр белүенә шаккаттым. Бер уйласаң, бер дә аңа, үзе әйтмешли, «шахтада череп» ятасы түгел икән ләбаса, шушы ил җирендә дә үлмәячәк «чыпчык» икән ул!

Эше белән генә түгел, тагын бер егетлеге белән дә таң калдырды әле мине карт: быел сабан туенда безнең авылда беренче тапкыр мәйдан уртасына биек шома колга утырттылар. Башында бик матур «марҗа чигешле»[4] сөлге җилферди. Багана төбендә әйләнеп-әйләнеп йөриләр дә китеп баралар, берәү дә менүче юк. Әти дә килеп карап-карап торды да башын кашыгандай итте. Аннары аягындагы читек-кәвешен салып миңа тоттырды, казакиен җилбегәй җибәрде. Аннан килеп ике табан астын, уч төпләрен төкерекләде дә колга башына үрмәли башлады. Без, малайлар, шундук колга төбен сырып алдык, без генәме соң, җыелды халык, җыелды яшьләр — без мескен малайларга бөтенләй урын да калмады. Мин читкә тайпылып карый башладым: менә дә менә бит әти, бер дә түбән сыдырылмый, колганы ике тез арасына, балтырына кысып беравык тын ала да һаман өскә шуыша. Котларым алынып торам: инде берүк ычкына күрмәсен иде, менеп кенә җитсен иде, менеп җитә алмаса, хурлыгы ни тора бит, күзеңне дә ачырмаслар!..

Шулай бөтен кеше авызын ачып, югары карап, тын да тартмый торганда тәки менеп җитте бит бу, җитте дә сөлгене чишеп муенына салды, аннары ике кулы белән колга башына тотынып, аякларын як-якка ерып уйната башлады — кәмит күрсәтәмени! Бөтен халык берьюлы шау-гөр килеп көлеп җибәрде. Шул шау-шуда, күз ачып йомганчы дигәндәй, түбәнгә төшеп тә җитте әти. Яшь чакта гармунчы булган, көрәшче булган

[1] Фартал — аралап кисәргә бирелгән квартал.
[2] Диһи — ярыйсы ук.
[3] Чутлап — барлык бүрәнәләрне тигезләп юну.
[4] Марҗа чигешле — канва аша аркылы типчеп чигү.

дигәннәрен ишеткәнем бар, әмма колга башына да менә алыр дип башыма да килгәне юк иде!

Ник соң мин шундый булдыклы түгел? Ник берсе дә юк миндә бу сәләтләрнең? Хәер, сәләте дә булыр иде аның, бәлки ул әчтә бөгәрләнеп кенә ята торгандыр. Төп бәлә шунда — кыюлык юк минем. Кеше алдында, мәйдан каршында бер эш башкарасы булса, коелам да төшәм оялудан. Ә безнең әтинең мәйданга чыгып көрәшергә дә, гармунчы булып урамда йөрергә дә, әнә колга башына менәргә дә — кыюлыгы тау хәтле икән. Мин үземнең бу юашлыкны өйдәге канат каергыч тигезсезлектән күрә идем. Алай дисәң, әти үзе дә бәләкәй чакта минем хәлдә булган икән бит әле: үз атасы өендә ул да «үги малай» булып үскән. Мин моны күптән түгел генә Мөбарәкша абыйдан ишетеп белдем.

Безнең Пазый бабай җиде малай үстереп, шактый җир тотып, малтуар асрап, хәлле кеше булып яшәгән. Ә борынгыда Тулбайның җирсуы, урманы-болыны әйләнеп чыккысыз булган, имеш. «Аю күле», «Төлке урыны» дигән куелыкларына авыл кешесе барып та житә алмаган. Заманасында аны Тауиле, Кабыккүпер авыллары да кистереп алган, авыл халкы үзе дә күбәя баргач, хәзерге җир кытлыгы килеп туган...

Ул чакта да кешеләрдә ярату дигән нәрсә булган, күрәсең, Пазый бабайның да йөргән кызы булган, тик аны башка авылдан өйләндергәннәр. Йөргән кыз онтылмаган. Бабай кеше төп йортта үзе хуҗа булып калгач, әлеге яраткан кызы Хәбибҗамалга өйләнеп җибәргән. Билгеле инде, олы хатын Гыйззи әби мондый хәлгә ләббәйке дип тора алмаган. Йортның пумаласы-табагачы, тукмагы да бәләге, иләге дә чиләге дигәндәй, ду күчә дә пыр-туза, дөбер-шатыр шалтырый башлаган. Яшь хатын ике яшьлек Фәрхулла исемле улын калдырып, бу йорттан китәргә мәҗбүр булган. Шунда эт типкесендә үскән малай икән ул. Ә бабай кеше ашау-эчү, фарсит итүне бик яратучан булып киткән. Җәй булса — тимерхут кузласына, кыш булса — чыпталы чана башына бәләкәй Пәрхулланы утырткан да Кабыккүпергә, Тауиленә кабакка чапкан. Иртән китсә, төн урталарында кайту гаҗәп булмаган. Ул фарсит иткәндә әлеге малай чана башында туңып-корышып утырган. Өйдә чакта бөтен йорт эше: мал-туар карау, су ташу, утын яру, мич ягу, бәрәңге әрчү, аш пешерү, хәтта коймак пешерү дә шул малай өстендә булган, Гыйззи әбинең беренче килене төшкәч кенә бу «рәхәтләрдән» котылып, уналтыдан читкә чыгып киткән ул. Бар тапканын шул йортка алып кайткан. Үзе өйләнгәч, тагын ун ел шул йортка икәүләп хезмәт салганнар. Унберенче җәйдә әти читтә чакта безне «Сәләхи өе» дигән ташландык бер йортка башка чыгарганнар. Пазый бабайдан сынык кашык та эләкмәгән. Бу — әтинең йөрәгендә калган тирән бер җәрәхәт булса кирәк, җае чыкканда бу сүзне бик өзгәләнеп әйтә ул.

Менә хәзер, заманнар үзгәргәч, хокукларны даулар көннәр килүен сизептер инде, безнең әти төп йорттагы Мөхлисулла энесеннән шул өлешен кайтармакчы булып йөри башлады. Энесе ике ат тота, революциягә хәтле өчәү иде. Узган ел берсен «киметте».

— Хәзер эләктереп калмасаң, актык атын да «киметер» ул җүнсез! — дип сукрана әти. Ә үзе ил-көн эчендә тавыш кубарып, сутлашып йөрергә дә уңайсызлана. Шулай да бер җае чыкты: кеше әллә кайчан бетергән булса да, безнең көлтәләр басуда утыра иде. Шуларны ташырга дип, Мөхлиснең биясен житәкләп кайтты ул. Көлтәне кертәбез, ат бездә ашый, бездә куна. Атна-ун көн узды, тавыш-тын юк, без дә шауламыйбыз, «үзләштереп» киләбез бияне. Көндезләрен яңа пуҗумдагы[1] үләнгә арканлап та йөртәбез. Әйе, безнең иске пуҗум җиде генә

[1] Пуҗум — ихата.

сажин иде, шуңа өстәмә итеп ындыр юлы дигән бер киң тыкрыкны безгә бирделәр. Киртәләп алдык, ат шунда йөри...

Ә бер көнне биядән җилләр исте: илтеп арканлавыбызга сәгать тә узмагандыр, карарга дип барсам — казыгы ята, арканы ята еландай боргаланып, ә бия юк! Йөгерә-йөгерә тирәдәге бөтен ындырларны, әллә кемнәрнең кибән артларын әйләндем — юк. Елардай булып өйгә кайттым. Чөй белән арканны тоткан килеш, дер-калтырап әти каршында басып торам.

— Ни булган? — диде ул.

Көчкә әйтеп бирдем.

— Каты борын! — диде әти,— шунын эше генә бу...

Аркан белән кыйнар дип бик шөлләгән идем, алай булмады, ашыгып ишегалдыннан чыгып китте. Күпмедер йөреп, буш кул белән кайтып керде. Тик соңыннан гына белдек: әтинең яшьли үлгән туганы Галимулла абыйның Каюм исемле малае Мөхлис йортында үсә иде, шуны котырткан нар икән. Бияне шул урлап китеп, каядыр икенче бер кешегә сараена яшергән. Шулай итеп, без тагын атсыз калдык.

Ләкин башкача атсыз яшәү мөмкин түгел иде, инде күпмегәчә тик ат өчен генә кеше күзенә тилмереп карарга? Әмма ничек итеп ул атны булдырырга соң? Бик күп баш ватты бу хакта әти карт. Шул баш ватып йөргән көннәрдә яучы килде безгә. Кызы бар икән ләбаса соң безнең әтинең, унсигез тутырган кызы! Ул Шәмәк әбиләргә кунакка баргач, шул авылның Асылгәрәй малае Сәетгәрәйнең минем Хөршит түтәйгә күзе төшкән, яраткан, имеш! Үзе инде ике хатын аерырга да өлгергән икән, үзе шулай да мәсьәләне бик каты куя ди: «Чишмә суыннан кайтканда бер генә күрдем, күңелгә керде дә утырды. Шул Хөршитбануны алып бирсәгез бирәсез, бирмәсәгез, бүтән өйләнеп тә маташмыйм, дип әйтә, имеш...

Ә түтәйнең аны белгәне дә, күргәне дә юк икән. Ничек белсен? Унсигез яшьлек кыз ике хатын аерган карт буйдакны каян исенә кертсен? Алай гынамы соң әле: Югары Тәкәнештәге абыйларга сабан урагы бетерешергә баргач, аның белән шул авылның Мәҗит дигән мөгаллиме танышкан. Түтәй моны шул тәрәзәсез югары өйдә бөтен бәйнәсе белән миңа сөйләп, сер бүлешеп утыра, ә түбән өйдә башкода көтәләр.

— И ылан,— ди ул зарлы тавыш белән,— —ниләр генә кылыйм икән инде? Тәки башымны ашарлар күк тия, безнең әтигә карышып буламы соң? Үз анаң булса якларые, ә үги анага нәрсә, килмешәкләр дип атый бит ул безне, аңар тизрәк озату гына кирәк үги кызны... Ә Мәҗит бик ару егет күренгәнне. «Хөршит туташ,— дип кенә тора,— мин сине укытырмын, ди, икебез дә мөгаллим булырбыз, бик матур яшәрбез»,— ди. И аның сөйләүләре — кош сайравы инде менә... Киткәндә бит Урта Тәкәнеш зиратына хәтле озата килде, кулымны үпте, минем билчәнле, солы урып, кытыршыланып-ярганланып беткән шушы кулымны үпте! И алла ходаем, көлсәң — көл, жыласаң — жыла! «Хушыгыз, ди, онытмагыз, ди, хат языгыз, тагын килегез», ди. Аннары менә шушы кәртечкәне бирде...

Түтәй үзенең чөйдәге яңа күлмәге кесәсеннән чыгарып, аны миңа суза. Ул «елына күрә ясмык бәлеше» дигәндәй, тонык кына буяулы бер открытка. «Казанда сабан туе» дип татарча язылган. Арт ягында Мәҗит мөгаллимнең «Сөекле Хөршит туташка гомерлек ядкәрем...» дип башлаган кайнар сүзләре тезелеп китә.

Түтәй сөйләвенә һәм бу открыткада язылган кайнар сүзләргә караганда, Мәҗит мөгаллим аны ярата булса кирәк. Аның түтәйне үзе укытып «кеше итәргә», аңа өйләнеп матур яшәргә теләүләре, әгәр юмалап кына әйтмәгән булса, шул ярату була торгандыр инде. Әмма түтәйнең үз күңелендә чынлап торып, җан-тән белән ярату дигән нәрсә уянмаган бугай әле. Ник дигәндә шул ачык: Мәҗит өчен өзәләнеп торганы күрен-

ми. Ул аны үз буе җитмәслек биек булыр дип уйлый шикелле. Шуның өстенә тегесе мулла малае да икән. Бөтенләй башка тормышта, башка тәрбия алган егетнең мужик кызын яратуына, бигрәк тә «гомерлек яр» итүенә ничек ышанасың?.. Түтәй безнең укый алмады шул. Дөрес, китап таный ул, бәләкәй чакта коръәнгә хәтле барып төшкән кыз, үзлегеннән өйрәнеп сәлам хаты да яза белә. Әмма мөгаллимгә тиң булу — юк, ул монысына ышанып җитә алмыйдыр. Булмас, алса да, ташлар дигән уй аңлашыла тел төбеннән. Шул ук вакытта бу кешегә дә күңеле ятмаганы ап-ачык. Сон мыскалланмаган[1] ефәктәй кызның ике хатын аерган кешегә ничек инде җаны эресен?

Мин тулысы белән аның ягында, аның өчен ут йотып утырам:

— Барма, түтәй, яратмаган кешеңә! — дим.— Башта Мәҗиткә хәбәр салып кара, яз хатыңны, үзем илтеп тапшырам,— дип шәпләнәм.— Ул алмаса да, монысына барма! — дип кабат кисәткән булам.

— Я ылан,— ди ул,— ата-ана сүзенә кем каршы килә алган? Белмисеңмени безнең тормышны? Бар, әйтеп кенә кара риза түгел дип. Күрсәтерләр күрмәгәнеңне, кая керер тишек тапмассың!

— Бер дә курыкма, үзем әйтәм синең өчен! — дип, тагы батыраям мин.— Куып чыгарырлар, дисеңме? Чыгарсыннар, икәү бергә китәрбез, хәзер элекке заман түгел инде, илдә чыпчык үлмәс. Без бит хәзер эшкә ярыйбыз, нижәли тамак туйдыра алмабыз?

Түтәй сүрән генә көлә:

— Малай шул әле син, ылан! — ди.

Ә кодалар килде. Мин эшнең ни белән бетәрен белер өчен «тынчы» булып түбән өйгә төштем. Кече яктан нидер эзләгән булып әйләндем дә кире чыгышлый ишекне әз генә ярык калдырдым. Үзем әлеге балчык идәнле өйалдында таптанам, сайгак булмагач шыгырдамый, рәхәт. «Егет»нең атасы белән анасы килгән кода булып. Асылгәрәй карт олы гәүдәле, олы йөзле, чигәдән үк төшкән сары сакаллы, җирәнчәрәк кеше икән. Ишек ярыгыннан ишетелгән тавышы мөңгерәп чыга, сабыр сөйләшә, кабынып китә торган гадәте юктыр, ахрысы. Карчыгы каратут чырайлы, кара күзләренең янып торуы әле дә сүнмәгән, тавышы да бик тере ишетелә, телгә осталыгы әйткән сүзе саен сизелеп тора. «Йорт тоткасы», «килен зобаные» карчыктыр инде бу...

— Яшермибез, Фәрхулла,— дип башлады ул.— Улыбыз укалы түгел. Ике катын аеруы хак. Вәләкин бу аның усаллыгыннан түгел, әйтергә кирәк, минем әшәкелектән дә түгел. Мин әйттем Сәетгәрәйгә, тимә, дидем, кемдә булмый андый хәл, үзеңә яраса, безгә ярар, дидем. Безнең белән сүз булыр дип курыксаң, башка чык, йорт әмәлләп бирербез, дидем. Теләмәде. «Мин ут эчендә йөргәндә җаман ат чыгарып яткач, булмый инде, әнәй», диде. Аерды. Икенчегә өйләнгән генәе, тагы сугышка алдылар. Ул кайтканчы монысы үзе китеп барды тагы, ошатмады бугай. Вәләкин безнең Сәетгәрәйнең ошатмас җире жук. Шушы яшенә җитеп, ашап-эчеп йөргәнен, ата-анага, туганнарына авыр сүз әйтүен, кешегә тел тидерүен, күрше-күләнгә начар булуын ишеткән-күргәнебез жук. Аллага шөкер, патшасына да, сәвитенә дә туры хезмәт итеп, баш бармагын өздереп кайтты. Җорт-җир өчен үлеп тора...

Аның бу сөйләгәннәрен эти, әлбәттә, белә, күрше авыл ич, хәтта мин дә беләм, йорт-җирләре дә начар түгел, урта тормышлы кешеләр. Мирсалих дигән кече малайлары белән ике кыш бер мәктәптә укыдык. Әни кешенең дә түтәйне бу йортка бик бирәсе килә, ул инде этигә бу хакта төн-көн тукый торгач, аны тәмам күндереп бетерә язганы да билгеле. Эти үзе дә: кыз бала унсигезгә җиттеме, алай-болай яман аты чыкканчы, сазаган кыз булып калганчы, тизрәк урнаштыру яхшы, дигән

[1] Мыскалланмаган — кул тимәгән.

фикердә тора, тик егетнең шул ике хатын аерган булуы гына берхәтле тоткарлаган сыман аны.

Кодагый буласы карчык тагын сүзгә тотына:

— Безгә монда килү җиңел булмады. Хөршитбануның улыбызга караганда шундый яшь булуын, су сөлегедәй зифа кыз икәнен күреп торабыз. Авылыбызга кунакка килгән саен сокланып карыйбыз да, тиңсенмәс ул безне, дип офтанабыз. Вәләкин нишләмәк кирәк, Сәетгәрәемнең шул фәрештә затына үләрдәй булып гыйшкы төшкән бит. Мәхтүмә тутасына сөйли икән: төн җокыларым качты, түтәкәем,ниләр генә кылыйм микән, дип әйтеп әйтәдер ди. Танышырга теләп хат бирсәм, бу карт җүләр диваналанган мәллә дип әйтеп, әйләнеп тә карамас, дип әйтеп әйтәдер ди. Җә син сөйләшеп кара, җә әтәй-әнәйләргә белдер, җаучы булып барсыннар, өйләнсәм — Хөршитбануга гына өйләнәм, бармаса — кәмиссия торам да җаңадан сугышка китәм, дип әйтеп әйтәдер ди. Бала газиз бит ул, ни кыласың — килдек менә каршыгызга, Фәрхулла кода...

Ишеткән колакларыма ышанырга белмичә, көлеп торам. Шул хәтле юма тел, шул хәтле юха тел булыр икән, әллә өйрәтеп җибәргәннәр тагы! Инде «кода» ясап та куйды бит, оялмый да! Ашый бу түтәйнең башын, бер кабуда йота!..

Һәм чәй эчеп бетерүгә шулай булып чыкты да. Түтәйнең үзеннән сорап маташмадылар да. Хәер, шәригать буенча никах вакытында гына сорала бугай ич ризалык. Иске акча белән йөз тәңкә «тарту» алып, туй ашына ит-май, карабодай ярмасы (дөге хәзер юк инде, бездә солы ярмасы гына), тагын ниләрдер турында килешенеп, кыз тарафыннан түшәк-ястык, сөлге-тастымал һәм башка чүпрәк-чапрак китереләсе булып, эшне бетерделәр. Мин уф орып югары өйгә менеп киттем.

— Сатылды, түтәй, башың! Йөз тәңкә Микулай акчасына, ит-майга, карабодай ярмасына саттылар сине! — дип, аның каршына идәнгә килеп утырдым. Берни эшли алмый торган сабыйлар шикелле, икебез дә тик елап утыра бирдек. Ник без шул хәтле тинтәк сарык бәрәннәре булдык икән?

Әйбәт сыйфатларына күпме сокланып, булдыклы эшләре белән күпме горурланып йөри идем мин әтинең, ә түтәйне шушылай сатып җибәргәч, һични аңлый алмый башладым. Нигә кешеләрдә яхшы як та, әшәке як та бергә укмашып яши? Ник кеше холкы көн кебек ачык түгел?..

Бу сорауларга җавап табу кыен иде.

Туй булды. Кеше аты, кеше тимерхуты белән кунаклар ташып йөрдем, аннары барып җизни кешене алып кайттым. Караңгылы-яктылыда басу капкасын узганда кемдер таш җибәрде. Кияүгә дигән ул «күчтәнәч» минем колак төбеннән генә сызгырып узды. Кыз белән кияүне шул түбән өйгә ябып, үзебез Мактый бабайларга куна чыктык. Әти өй тәрәзәсен, ишегалдын саклап төн уздырды. Озакламый Хөршит түтәй туган-үскән бу чокырыннан китеп тә барды. Бик моңсу булды ул көннәр. Кинәт кенә дуссыз, киңәшчесез, сердәшсез ялгыз калдым. Ә Шамил бәләкәй малай...

Микулай акчасы белән «тарту» алуның бик кирәк ягы булган икән: шул Микулай акчасына әти язгылыкта Чистай базарыннан ат алып кайтты. «Балта биреп чөшле алдым, алдаладым татарны» дигән, имеш, берәү. Без дә шундыйрак хәлдә идек бугай. Бу мәкальне әти үзе дә еш әйтә иде, ә бу очракта бер дә исе китмәде. Хәер, кызын сатып ат алган татар — үзен бик бәхетле саный иде ул заманда. Кыз — нәрсә ул, аның җире дә юк, ул барыбер очып китәсе кош кына ич!..

Ул ат озын торыклы, корсагы-башы жиргә салынмаган ыспай гына гәүдәле, кабарынкы йонлы «кызыл туры» иде. Тик ул хайван чамадан тыш үшән булып чыкты. Әйбәт кенә чөңгереп, дилбегә тартып кына әйдәгәнне дә, чыбыркы-чыбык белән сыптыруны да белми, хәтта үрдән төшкәндә дә юыртмый иде. Тик мыштырдый бирә шунда үз җаена. Атка салам белән дә сукмыйча, дилбегә кагып кына юырттыруны яраткан әтигә бер дә килешмәде бу.

— Карале, карале, барган жиреннән йоклый бит, алланың бар иткере! Алды аягын алганчы, арт аягын эт ашый. Нә-әсәнә! — дип, юл буе сукранып йөри иде ул.

Бик нык утыртканнар аны Чистай базарындагы барышниклар. Тик ул ничек алданганын һичкемгә сөйләми, атның шундый черешкән ялкау икәнен кешегә сиздерү була бит, әчтән тына...

Шулай да үзебезнең ат булды бит әле, кече-кара яшьтән хыял иткән ат! Сабан туе саен сөрәнче малайлар безнең турдан узганда күзләрне яндырып, йөрәкләрне әчеттереп, мине кызыктырган ат! Мактый бабайның карт алашасын атланып түгел, җитәкләп кенә сугарып кайтсам да җаннарым рәхәтләнгән ат! Үткән ел Колчакны куып баручы «әрме»ләр авылга туктагач, бездә өч аты белән өч кызылармеец торган иде. Лапастагы ул иярле атлар янында кайнашу, асларын тазартып, өсләрен кыргычлап, тамакларына салып йөрү, хуҗалары күрмәгәндә иярләп Шамил белән сугарырга төшү, шул уңайда ярты гына урамны булса да икәүләп, «гүәрдинчә» җилкә сикертеп, чабып әйләнергә маташу — иң зур бәхеттән иде безнең! Ниһаять, үзебезнең ат бар! Ишегалдына чыксаң, утлыктан печән күшәгәне, пошкырып куйганы ишетелә, ат исе килә. Тик нәрсә булды икән соң миңа? Күңел, горур канатларын җәеп, ат тирәсендә очынмый. Әллә ат белән сихерләнгән малай чаклар узып киттеме? Әллә аның шундый «йөнтәс», шундый үшән булуы, янына кереп ялын сыпырсаң, әйләнеп тә карамавы миндә дуслык уята алмыймы? Белмим, белмим, нидер булды, минем ул атка ис китмәде. Әллә бар ул, әллә юк...

## «Чукып карга булмас...»

Шул язда этине авыл Советына секретарь итеп куюлары билгеле булды. Моңарчы бу эшне Зариф Миңнеханы башкара иде һәм ул авылда бердәнбер дигәндәй русча грамоталы кеше иде, быел аны сайламаганнар. Революция башына хәтле атасы староста булып торган, шул ярамаганмы, бүтән сәбәп булганмы, мин белмәдем.

Ә безнең эти нинди секретарь инде ул? Урысчасы юк бит аның, ә язу-сызуны гел урысча йөртергә кирәк, волость үзеге дә урыс авылында. Мин укуны бетереп кайтып кына кердем, эти шундук кәгазь белән күмде. Түбән өйдәге аш өстәлен югары өйгә менгереп, киләчәктә тәрәзә буласы бәләкәй тишек каршына куйдык та кәнсәләр ачып җибәрдек. Авыл Советы дигән йорт та юк әле безнең авылда! Элекке каравыл өен аңа яраклаштырып булмый, шулай булгач, монда бик «шәп» кәнсәләр инде. Кеше шунда килә башлады: кайсына тегермән талоны, кайсына мүк язуы, кайсына бүтән белешмә. Тегермән инде Сапый кулактан Совет кулына күчкән, кирәк оны казнага китә, талонсыз тарттыру ярамый хәзер.

Авылның бертуган өч бае арасында иң әшәкесе Сапый иде. Ул үзе олы яшьләрдә булса да, төзек буйлы, тук гәүдәле, ыктымат киемле, күркәм чырайлы кеше. Кара сакал-мыегы һәр вакыт килешле итеп кыркылган, байларча камалы бүрке әз генә кырын салып киелгән булыр. Явызлыгы да йөзенә чыкмаган, күңелдә һич салкынлык уята торган түгел. Ә инде «Әйткән сүзен эт җыймас» дигәннәре аңа туры килә тор-

гандыр: «Ач хәерче», «Вак керәшен», «Бетле тәре», «Кеше дисәң — сыны юк, дуңгыз дисәң — йоның юк!» Бу аның Тулбай кешесенә әйтә торган көндәлек сүзләре. Хәер, сүз белән генә калмый ул: башка авыл тегермәнендә тарттырган кешене кабат үз тегермәненә җибәрми, бөягә өлеш кертмәгән кешеләрне күпердән йөртми, ярлы-юаш кешене шул күпер өстендә тотып яңаклый, я башкача мыскыл итә иде. Озак еллар читтә йөреп, революциядән соң авылда яши башлаган «Тәвә Бәтие» (Бәдерттин) абзыйның солы көлтәсе төягән арбасын күпердән түбән яктагы сазга аударып җибәрүен без малайлар үз күзебез белән күреп тордык. Самат исемле кешене аның көлтәсен урлауда гаепләп, каравыл лапасы алдында канга батырганчы кыйнавын да күрдек. Авылның иң үзәгенә үткән явыз иде ул. Бирәләр иде аның кирәген шул чакта, тик авыл кешеләреннән качып котылды дошман!..

Авылда һәр төрле җыем-салымнар да аз түгел хәзер. Йон, йомырка, сөт, май җыю — бар да секретарь өстендә. Югары оч Шәпикъ абзыйларның олы амбарына барып утырам да китергән нәрсәләрне үлчәп алам, кәгазьгә терким. Нindiләре генә булмый ул әйберләрнең! Кайбер җингиләр бик хәйләкәр: сары майга туң май кушып, турта белән изгән бәрәңге бутап китерәләр, йомырканың да тавык астында чебисез черегәннәре, болай бозыклары күп була — кире борырга, сүзгә керергә туры килә. Менә кая китте эшләр!..

Кәнсәләр эше тавык та чүпләп бетермәстәй күп булгач, сабанны әти берүзе сөреп чәчте, тырмага Шамил йөрде. Урак өстендә дә һаман кәнсәләрдә утырырга туры килде, әни кешенең тешләрен шыкырдатып:

— Уттай эш өстендә ул ниткән кәнсә-мәнсә тагы? Йөрсен уракка! Янмас әле кыягазлары! — дигән матур тавышы ишетелә астан. Миңа кыҗырый ул, мин «эшлексез»гә. Үги кызны үткән күз көчләп кияүгә бирдергәч, быел аңа тыгызрак килә, күрәсең. Әти аның сүзләрен җөпләми:

— Белмисең, белмәгәч, тыгылма,— ди.— Әйдә киттек, ат бар, утырт малайларны, булышырлар шунда.

Алар шыгырдавык җил капканы үзләре ябып, ишегалдыннан чыгып китәләр. Бермәлгә тын утырам, әни кешенең җиңә алмавына мыек астыннан гына куанам шикелле. Ләкин әллә ничек уңайсыз булып китә: уттай эш өсте бит...

Бик барыр идем, җәйнең щушындый ямьле көннәрендә басуда рәхәтләнеп эшләүгә ни җитә! Тик ни кылыйм, монда бит ничәмә төрле кәгазь, кәгазе саен ничәмә төрле сорау, ничәмә төрле исемлек — шуларның һәммәсе җавап көтеп ята. Барлы-юклы урысчаң белән ул кәгазьләрдәге яңа сүзләрне, ачык төшмәгән хәрефләрне аңлап бетерә алмый да җаның чыга. «Инвентарь, классификация, социальный состав, образов. ценз, зафиксировать, гужповинность» — боларны мин гомердә ишеткәнем юк, каян эзләргә, кемнән сорарга? Ындыр табагы хәтле була торган «Исемлек-мәгълүмат»ларны ничек төзеп бетерергә? Монда чын оста писер кирәк. Кая ул минем ише танавы кибеп җитмәгән малайга! Ә шулай да тырышкан булам, әтидән сорыйм, оят булса да элекке секретарь Миңнехан абзыйдан сорыйм, ничек тә кәмаләнә китереп, волостька җибәрәм. Кире кайтармыйлар тагы...

Пичәт Сәләх абзый кулында. Ул аны, телен зур чыгарып, ялардай итеп авыз каршында әйләндерә-әйләндерә өрә дә мин әзерләгән кәгазьләргә китереп баса. Беркауымнан соң пичәтен алып, кәгазьне күз төбенә үк китереп карый.

— Булды,— ди,— урак-чүкече әйбәт чыккан, җибәр.

Минем аны үзем белә-белгәннән бирле күргәнем юк иде, хәтта безнең авылда андый кеше барлыгын да белми идем. Ә ул бездән ике өй аркылы гына яшәүче күршебез Җамалый абзыйның олы малае икән, егерме еллап читтә йөргән. Әйтүләренә караганда, Камашаудагы завод-

та «төтен»дә[1] эшләгән, үпкәсе гыжлап тора, нечкә тавышы да карлыгып чыга.

Белмим, язу тануы ничектер, волостьтан килгән кәгазьләрне укыганын бер дә күргәнем юк, шулай да халык аны белми сайламагандыр: холкы-фигыле белән иple кеше, авылның ярлы катлавына ничек тә булса ярдәм итәргә тырыша, бай кутлауның яшергән икмәген табып, рабочий класска (аның сүзе) озаттыру ягын карый. Ул елны авылга беренче тапкыр бугай шактый күләмдә ситсы кайтты. Сәләх абзый, өй борынча диярлек йөреп, кызылармеец гаиләсенә, иң күп бала-чагалыга, иң тетелгәннәргә генә өләштерде аны. Кайсына күлмәк-ыштан, кайсына бишмәт тышлыгы, кайсына казакилык, кайсына чалбарлык тиде. Көтмәгәндә Сәләх абзый миңа да өлеш чыгарттырды.

— Менә, җәмәгать, бу малайны да онытмыйк әле без,— диде ул ситсы бүлү кәмисиясендә.— Көн-төн кәнсәләрски диләә белән утыра, басу эшенә дә чыга алмый, ә жалунҗәсе — аена утыз көн бит аның. Минемчә, әнә шул буйлы материалдан бер чалбар белән бер пинҗәклек бирергә кирәк аңар. Киеп җибәрсен бер җегетләрски иттереп!

Минем эчкә ут төште: башкалар ни әйтер? Юк, кәмисия кешеләре дә каршы килмәде! Хәтта әле: «Кирәк, кирәк, ату сиклэтар җегетебез алача ыштан белән йөри», дигән булдылар.

Баш күккә тиде. Озакламый аны Галәттин абый тегеп бирде. Каразәңгәр-шәмәхә-алсу-кызыл буйлы бик матур әйбер иде ул. Бишмәт җылысы да бирсен өчен пинҗәк эченә теткән чүбек түшәп, эчлеген юан чүбек киндереннән куеп җибәрдек. Нишлисең, мамык та, фабрик эшләгән эчлек тә юк ич хәзер. Хәер, аның эчлеген, эчендәге чүбеген кем күрә? Тышлыгы булсын. Ә тышлыгы менә дигән! Ул яңа киемнәрне киеп җибәргәч, мин хәзер бөтенләй егет сымак тоям үземне. Кәкже, без кешедән киммени!..

Кичке биләмгә дә чыккалый башладым. Тик «егет булып йөргән чакта төрле хәлләр булгалый» икән. Дусай очындагы Майшәкәр исемле кызларда аулак өй сыман нәрсә бар, имеш. Шунда килеп кергән идем, карангы өйалдында ике яктан кысып алдылар да әз генә «кәҗә мае»н чыгардылар. Чыгып качарга ишек тапканчы ничек тә чыдарга туры килде. Соңыннан белдем, Корбый Хуҗасы белән әлеге гыжлавык Зиннәт булган икән: юри генә, безнең оч кызлары тирәсендә кызынмасын дип кенә санаганнар, имеш, кабырганы...

Ярар, йөрмәбез аулак өйләренә: минем хәзер үзем генә белгән яңа бер дөньям бар. Авыл Советы исеменә һәр төрле плакат, брошюралар белән бергә, «Эшченең крәстиянгә җавабы», «Татарстан Шуралар җөмһүрияте» дигән татарча хитапнамәләр, «Җырлар көлтәсе», «Габдулла Тукай шигырьләре», «Садрый Җәлал хикәяләре» һәм тагын байтак исемдә китаплар килә башлады. Кәгазьләрдән әз генә бушандыммы, шулар эченә чумам. Анда миңа әллә нихәтле яңа серләр ачыла.

Шундый почта арасыннан бер көнне «Алтынларым» дигән бәләкәй генә, юка гына бер китапчык килеп чыкты. Чүбек кәгазе тышлыктагы таныш исем кинәт сискәндереп җибәрде. Тукта, гаҗәп бит әле бу: «Хөсәен Абушаев» дигән. Безне Себердә укыткан Хөсәен абый Абушаев микән әллә? Җыентыктагы шигырьләрне йотлыгып укырга керештем, тик алардан Себер турында бер сүз дә табылмады. Җитмәсә, ул шигырьләр кадимче авыр тел белән җансыз һәм сурәтсез итеп язылган иде. Шигырь — сүз көче, җөмлә агышы белән уйнап тормаса, тешкә тия башлый. Шулай итеп, «Алтынларым» дигән бу китапчыктан бер генә бөртек алтын да килеп чыкмады. Бу фамилия үзе дә соңыннан әдәби дөнья эчендә очрамады. Кем булды икән ул?..

---

[1] «Төтен»дә — газда.

Шулай көз житте. Мин тәмам «түрә егет» булып килгәндә генә хәлләр үзгәреп куйды. Җәмәгать эшендә чабып йөри торгач, Сәләх абзый кинәт кенә авырып егылды. «Чихуткәсе ачылган икән», диделәр. Аның элек тә йөткергәләп, гыжлап йөрүе тикмәгә булмаган, күрәсең.

— Бу каһәрдән арынып, әзме-күпме рәтләнү өчен әкаль[1] ике ай срок кирәк миңа, җәмәгать,— дип, урыннан төшерүләрен сорады ул. Безнең эти дә үзен алыштыруларын үтенде.

— Үзегезгә билгеле, минем урысча грамот юк, барлык язу-сызуны малай алып барды, ә малайның хәзер укырга йөрер чагы житте,— диде ул.— Бер жыелганда монысын да карагыз инде, картлар...

Шулай итеп, авыл Советына яңа кешеләр куелды, ә мин яңадан Шәмәк мәктәбенә китәргә җыена башладым. Инде болай да соңга калып барам бугай, сентябрьнең ахыры житеп килә хәзер.

Ләкин көтмәгәндә генә «типте бия тәртәгә» булып чыкты бу эш. Мине укырга җибәрмәделәр. Без җир-сулы, ат-түнлы, мал-туарлы кеше икәнбез хәзер. Йортта эш ишелеп ята: ындыр сугасы, курмы ташыйсы нихәтле икән, урман кисеп, утын китерәсе язга житәрлек итеп. «Хаман-хаман бер карт атасы йөрер микәнни? Үзенә дә белер вакыт житкән, бот буе малай түгел, кыш уртасында уналтыны тутыра. Андыйны инде җүнле кешеләр өйләндереп, башлы-күзле итәләр. Җитәр, күп йөрде селкенеп. Укып мулла булмас, чукып карга булмас!..»

Моны кече яктан әни кеше пырлый. Үзе каба төбендә, тәрәшлесен шытыр-шытыр тарта да орчыгын ачу белән зырлатып җибәрә. Мин олы якта, ишек катындагы бүкәндә чабата тезеп утырам. Эти түрдәге намазлык өстендә эттәзияты белән мәшгуль. Тышта бүген иртәдән бирле пыскак яңгыр сибәли, шуңа күрә без барыбыз да өйдә утырабыз. Шулай итеп, әни кеше минем язмышка «ясыйн» укыды да куйды, «төрҗәгун»ен дә әйтте, этигә дога кыласы гына калды. Белә бит бу хатын, хәйләкәр: куптәннән эчен көйдереп йөргән уйларын картының намаз ахырына гына китереп кыстыра, аллаһәкбәр! Әйтерсең мин юк бу өйдә. Үземә әйтеп, авыз пычратып та тормый!

Этидән мәрхәмәт көткән идем, булмады. Ул нииндидер икеле-микеле җавап тапты:

— Шәйхелислам хәзер югалырлык түгел инде, татарчасы да житәрлек, урысчасы да бар. Әнә бит язу-сызу эшләрен ничек алып барды. Калган ягын, акылы булса, үзе табар...

Минем баш түбәсенә суык су органдай булды. Ничек соң әле бу? Укыр вакыты житте дип, җыенда үзе әйтте ич! Минем бөтен омтылышларыма шулай кисәк кенә көрчек куелды микәнни? Бөтен якты теләкләр белән, Фарукъ абзый уятып җибәргән матур хыялларым белән мәңгегә саубуллашырга микәнни? Юк, мең тапкыр юк! Күңел моңа һич кенә дә риза була алмый. Ул әллә кайларга, үзем дә белмәгән еракларга ашкына. Аңа тау хәтле алтыннарың да кирәкми хәзер. Киләчәктә дә үги бала булып яшәми торган яңа бер дөнья эзли ул. Аны беркем дә туктата алмый инде, чөнки минем эчкә «уку корты» оялап өлгергән. Һичбер әфсен-төфсен, өшкерү-төкерүләр белән дә терелтеп булмый торган «китап зәхмәте» кагылган!

Өйдәгеләрнең бу хөкеменә каршы мин, әлбәттә, бер сүз әйтә алмадым, әйтсәң дә файдасы булмас иде. Әмма шул көннән башлап эчкә усал ният кереп ятты: качарга, качарга!

Тик кая һәм ничек?.. Каян башларга белми аптырап йөргәндә, арыякның Биктаһир малае Бәхти очрады. Үткән ел Шәмәктә миннән бер сыйныф түбән укыган иде, быел аны да җибәрмәгәннәр икән. Сөйләшә киттек.

— Әйдә, Казанга ычкыныйк,— диде бу.

---

[1] Әкаль — әз дигәндә, кимендә.

— Ничек? — Мин аптырап калдым.

— «Ата-анасыз ятимнәр» дип язу алыйк та балалар йортына барып керик. Шунда тик укып ятырбыз...

Бик кызыклы тоелды бу, шәп булачак! Язуын да табып булыр. Үзем әле генә кәнсәләрдән чыктым ич, җайлап сорасам, яңа секретарь каршы килермени? Тик икенче ягы бар: без бит ата-аналы малайлар. Тегендә баргач, безнең ялган ачылса? Кире кайтарып, хур итеп йөртсәләр, нишләрсең?.. Әйбәт түгел...

Шулай итеп, бу ният ябышмады безнең. Инде көзге пычраклар узып, җир туңды. Урманнар кисеп, быел бик күп булган имән чикләвекләрен җыеп йөрдек. Тора-бара ноябрь кереп, чана юлы да төште. Шул көннәрдә Шәмәктән яшь кода Мирсалих килде. Әтиләрне кунакка чакырырга җибәргәннәр аны. Ул да быел укымый икән. Ул миннән ике яшькә олы, буйга да, атасы шикелле, озын, бөтенләй егет булып киткән малаен. Мәктәп турында сөйләшә башлагач, аның авызыннан тагын бер яңа хәбәр төште: Фарукъ абый быел анда укытмый икән, аны Мамадышка күчергәннәр, ниндидер өчьеллык курсларда укыта ди...

Кинәт минем күңел күге яктырып китте: менә кемне эзләп барырга! Ул мине аяктан екмас, ничек тә булса урнаштырыр. План шундук өлгереп җитте, күңел белән мин инде Мамадышта!

Кичләрен каравыл өенә чыккалый торгач, Ситдикъ Шакиренең Мамадышка барачагын ишеттем. Бу — теге өй эче тулы вак малайлы, хәзер биш-алты иманалы, атлы-туңлы булып киткән Шакир абзый. Энгер төшкәндә йортына сугылдым: утыртып барырга булды. Бар бит дөньяның яхшы кешеләре! Юлга чыгуны атна көнгә ниятләп тора икән, монысы да бик шәп, нәкъ безнекеләр кунакта чакта була. Әйтерсең сүз берләшеп эшләгәнбез. Шакир абзыйдан серне үзе генә белүен үтендем...

Шәмәктә безнең якын кардәш-ыру өч йортта хәзер: түтәй белән җизни һәм кодалар, әни кешенең үги анасы, аннары килеп әтинең үз анасы Хәбибҗамал әби дә шул авылга кияүгә барган, шунда балалар үстереп гомер итә. Шулай булгач, безнекеләр өч кичсез дә кайтмаячаклар...

Җомга көнне караңгыдан ук тордым да үзем мәдрәсәгә йөрткән киез белән мендәрне төреп капчыкка тыктым, булган бер пар күлмәк-ыштанны салдым, сөлге алдым, китап-дәфтәрне дә калдырмадым. Аннары чәй эчеп, өс-башны киендем. Җәй тектергән чалбар белән пинжәкне, кыршылганрак булса да, зәңгәр бишмәтне кидем. Теге кыска куныччлы ак итек тишелмәгән иде әле, тула оек белән ул да бик ярап куйды, бер кием яна чабатаны капчыкка салдым. Аннары, киштәдә тезелеп торган арпа күмәчләреннән өч зуррагын сайлап алып, шулай ук капчыкка батырдым. Шактый җыелды болар хәзер. Кирәкле язуларны да кесәгә тыктым. Боларның һәммәсенә дә сәерсенеп карап торган Шамил энекәш:

— Абый, кая китәсең? — дип куйды.

Әйтеп бирергә туры килде, ә ул елый ук башлады:

— Китмә, абый, ник җибәрдең дип мине үтерәчәкләр бит!

— Елама, ылан, сиңа берни дә булмас,— дидем. «Мин әйттем, тыңламады,— диярсең.— Итәгенә ябышкач, сугып җибәрде» диярсең, дип, үземчә юаткан булдым малайны.

Ул арада Шакир абзый капка төбендә иде инде. Капчыкны күтәрдем дә чыгып киттем. Капка ябып маташканда, Шамилнең ян тәрәзәгә үрелеп: «Абый, китмә!» — дип тилмереп кычкырганы ишетелеп калды. Шакир абзыйның үрәчәле чанасы түренә капчыкны сөйкәдем дә күп итеп салынган печән өстенә менеп кырын сузылдым. Чана табаннары тын гына шыгырдап юлга борылды. Көн суык түгел иде, җиле дә әллә ни сизелми, әкрен генә уйнаклап, иртәнге кояш катыш күбәләк кар

төшкәли. Нигәдер күңел нечкәргәндәй булып китте. Каерылып өйгә карадым: җирдән әз генә өскә калкыган ике түр тәрәзәсе белән, өстәге әле һаман эшләнмәгән «күзсез» бурасы белән монсу гына утырып калды ул. Урам буш, курше-тирә буш. Гыйльми дә күренми, ичмаса, Һади да юк... «Сау бул, туган өй! Сау бул, Тулбаем! Тагын китә сездән бу малай...» дип әйтәсе килде.



## Ярты ипи

Әкрен уйнаклаган кояшлы кар тора-бара туктап калды, без Күчәнгер тавына килеп житкәндә көн бөтенләй ачылып киткән иде инде... Икебез дә чанадан төшеп, ат артыннан атлый башладык. Ни дисәң дә кыш бит: әзме-күпме тәнгә йөгергән суыкны тау менгәндә коеп калдыру, укмаша төшкән буыннарны язып җибәрү үзе бер рәхәт. Чакрымнан артыкка сузылган сөзәк үрле бу тауның исемен яратам мин: «Күчәнгер». Эчендә нindидер сере бар шикелле. Аңлашыла да, аңлашылмый да. Бәлки шуңа күрә матур ишетелә торгандыр. Мин аның мәгънәсен күп мәртәбәләр сораштырып карадым, белүче булмады. «Шүләңгер», «Битләңгәр» дигән авыл исемнәре дә билгесез. Борынгылар безгә күп табышмак калдырганнар...

Күчәнгердән соң Комазан урманын чыгып, ун чакрым тип-тигез кардиңгезе белән баргач, Мамадышка килеп кердек. Безнең авыллар двор тотучы Шәмәк Ганигә туктала. Без дә шунда борын төртеп чәй эчтек тә, Шакир абзый атын карый калды, мин педкурсларны эзләп киттем. Якында гына икән, Фарукъ абзыйны табу да кыен булмады. Хәлемне сөйләдем. Ул мине курслар мөдире янына алып керде: Зиннуров дигән тәбәнәк, юан гәүдәле, кара чырайлы бер кеше икән.

— Ай-һай, егет, соң булыр бит, башкалар ике ай укый инде,— диде ул. Эчкә шундук курку төште: кире борса, нишләрсең?.. Ләкин Фарукъ абзый мине коткарырга ашыкты: «Тырыш малай ул, куып житәр», диде. «Качып килгән шәкерт бит, узып та китәр әле», дип өстәде әйбәт кенә көлемсерәп. Мөдир абзый артык карышмады. Иртәгесен миңа ана теле, рус теле һәм математикадан имтихан ясадылар. Уздым, уздым! Шул көнне үк курсантлар яши торган тулай торактан урын да бирделәр. Капчыкны җилкәгә асып, Шакир абзый белән саубуллашканда әйтергә туры килде:

— Мин монда укырга калам инде, Шакир абзый,— дидем,— әтиләр сораса, әйтерсең...

— Ярый, агай-эне,— диде ул,— тырыш, әйдә, тырыш. Укый торган замана килде...

Шулай итеп, курсант булып та китте абзагыз хәзер. Элек калаччы булган Белов дигән бай йортының югары катындагы бер бүлмәгә урнаштым. Без анда алты малай, барысы да миннән ике-өч яшькә олырак, авыллары таныш: кайсы Акчишмә, кайсы Өскебашы, тик үзләре генә таныш түгел. Түрдәге олы бүлмәдә иске танышым Шәһит Кәримовны очраттым, без аның белән Дусайда бергә укыган идек. Бик яхшы булды әле бу: сабакташ һәм «табакташ» булып киттек. Әйе, табакташ, йортның аскы катындагы ашханәдә көндез бер тапкыр безгә кайнар аш пешә. Савыт-саба житмәгәннәндер инде, аны ике кешелек итеп, табак хәтле олы бер бадыян белән мөлдерәмә тутырып бирәләр. Кипкән балыктан пешерелгән ул яшькелт-соры төстәге сыек шулпаны без Шәһит белән «ялт» итеп кенә куябыз. Шуның өстенә безгә әле бер кадак ипи дә бирелә, иләми генә пешерелгән солы күмәче...

Укулар авыр булып чыкмады. Беренче курс хәтта мине канәгатьләндерми дә, чөнки күбесе узган ел без Шәмәктә укыган дәресләр кабатлана иде. Берәр ай узгач, шәпләнеп китеп, Фарукъ абзый ярдәме белән

икенче курска күчкән идем, «тугызлык» җитми башлады, еш кына «чөгендер сатарга» туры килә хәзер... Укытучылар табылмауданмы, белмим ни сәбәптәндер, ана теленнән башка бөтен фәннәр рус телендә бара, ә үзебез татар мәктәпләрендә укытучы буласы кешеләр. Тактага чыгып, хисап мәсьәләләрен дөрес чишәм, шуны сөйләп бирергә тел җитми: ык та мык. Менә шунда ике битең — ике олы чөгендер: кадагы бер тиен! Башкалар да шул чамадарак. Ушма авылыннан тәбәнәк буйлы, юан тавышлы Харрас дигән бер малай бар. Укытучы сөйләгәндә берәр сүзне аңламый калса, парта арасыннан тора да: «А што такой сиблизация?» дип сорый. Укытучы, дәресен бүлеп, аңлатырга мәҗбүр була. Озак та узмый: «А што такой самодержавия?» дип кычкыра теге. Дәреснең тәме китә, укытучының эче поша башлый. Мондый юл белән русча өйрәнергә маташу да әйбәт түгел, күрәсең.

Фарукъ абзый өч курска да ана теленнән керә, аның дәресендә рәхәтләнеп утырасың. Ул һаман шулай: кагыйдә аңлатып кына калмый, еракларга алып китә сине, әллә ни хәтле яңа мәгълүмат бирә. Ләкин ул атнага өч кенә тапкыр керә, Шәмәктәге шикелле киң аралашып булмый. Ни өчендер быел ул безне әдәби мавыктырулар белән дә шөгыльләнми, журнал чыгару белән дә кызыктырмый. Вакыты җитмиме, белмим.

Монда минем бер юл шигырь язып караганым юк әле, хәтта онытып барам бугай инде. Хәер, язардай сәбәп тә юк, кирәге дә күренми шикелле. Гомумән, дәрес сәгатьләреннән тыш безнең белән кызыксынучы юк, кантон комсомол оешмасыннан да һичкем килми. Без — үзагымга куелган үсмерләр. Шулай да китапханәгә йөргәлибез, гәзитләр укыштырабыз, тәмәкегә урлап та кайтабыз, акча булганда кино да карыйбыз.

Монда мин беренче мәртәбә татарча театр күрдем, «Галиябану»ны куйдылар. Я алла, булса да булыр икән матурлык! Саф авылча гүзәллек белән тулган җырлар, уен-көлкеләр, сөю сагышлары, ирешә алмый калган өметләр! Дивана малай шикелле гел «балавыз» сыгып, Исмәгыйльне үз кулым белән буып үтерерлек булып утырдым. Шул кичтән башлап минем бәләкәй дөньяма Мирхәйдәр Фәйзи дигән олы шагыйрь, авыл кешеләрен яратучы нечкә күңелле һәйбәт язучы килеп керде...

Озакламый кышкы каникул килеп тә җитте. Миңа бу бигрәк тә тиз тоелды. Безгә ул көннәр өчен дә «паюк» тия икән, барысын бергә исәпләп унсигез кадак солы оны бирделәр, тик кая куярга аны һәм үземә кая барырга? Әле генә качып киттем, кайтсам — кертерләрме?.. Күпме уйлама — башка юл юк. Онлы капчыкны аркага йөкләдем дә авылга юнәлдем. Буш кул белән кайтып керәсе булмауга сөенеп атлыйм, уку җиреннән дә ризык китерәм, янәсе!

Кичке караңгы төшүгә ишекне юаш кына ачып өйгә кердем. Лампага яңа гына ут элдереп, куык сөртеп йөри иде әни кеше. Әти сәке түрендә ахшам намазында утыра, вак малайлар кече якта тавышсыз гына кайнашалар. Учакта гөжләп торган күмер шәүләсе уртадагы олы сандык башына төшкән, казанда пешеп килә торган ашның тәмле исе өйгә таралган... Караңгылы-яктылы ишек катында басып калган беренче мизгел бик кыен булып китте. Берәү дә көтми иде мине өйдә. Хәер, кем көтсен? Әнә бит малайлар да күрми, әти инде намазы белән мәшгульдер, әни кеше дә күрмәмешкә салына. Ә бит мин ишектән керүгә үк күз кырыен төшереп алды, югыйсә; шулай да түзмәде ул:

— Бәрәч, әнә бит, кайтып та кергән качкыныгыз! — дигән булды.

Кайчандыр читтән кайтып кергәндә дә шундыйрак сүз белән каршылаган иде ул мине. Шул чакны уйлый-уйлый, капчыкны салып идәнгә куйдым да, берни дә булмагандай, мөмкин хәтле йомшак тел белән юри аңа эндәштем:

— Әни, бу капчыкны кая куярга икән? Әзрәк он алып кайткан идем, күп түгел ул — ярты пот кына...

— Ниткән он тагы? — диде ул зәһәрсезрәк тавыш белән.

— Мамадыштан биреп җибәргәннәр иде, каникул вакытында аласы паюк өчен...

— Ник, амбарда урын бар ич,— дип куйды, тагын да җылымсарак итеп.— Бар, Шамил, чыгарып куй.

Кая инде ул Шамилгә кушу, үзем чыгарам, мондый шәфкатьле тавыш ишеткәч, җир читенә илтеп куярга да була! Алла рәхмәте, ипеки дигән нәрсәң ташны да йомшартуы мөмкин икән! Ул аның атка сибәргә генә яраклы икәнен белсә, «Башыңа капла кибәгеңне!» дип кенә ычкындырыр, ярый әле, анысын әйтмәдем. Иртәгесен үзе күрер әле...

Шулай итеп, әз генә боз эрде. Өс-башны чишенеп, бит-кулны юып табын кырыена утырдым. Олы табак белән аш килде: бәрәңгесе тулы, токмачы тулы каз шулпасы! Мондый ашның тәсен күрү түгел, исен дә татымыйча ике ай «ураза» тоткан үсмер малайның башы әйләнеп китсә, гаҗәпмени?.. Башны түбән иеп сыпыра бирәм токмачны! Әтинең тузынып китүеннән кот чыгып утырам. Аннары ашау онытылачак. Ләкин түзем булды, ачуын эченә йота белде.

— Ата-ана өйдә юк чакта йорт ташлап чыгып китмиләр аны,— дип башлады ул суыграк тавыш белән.— Вак бала-чага ни белә ул, ут-күз чыгарып, йорт-җиренне көлгә очырса, ни кылырыең?.. Примиргә ерак барасы түгел, әнәтерә Сөләйман малайлары нишләде? Үз күз алдында бит!..

Әйе, бик килешәм әти сүзе белән. Бигрәк тә пыр тузып дуламыйча, сабыр гына әйтүенә бик риза мин аның. Мине дә әрли, янәсе, тегеңә дә сөяк ташлый.

Ә Сөләйман абзый малайлары, чынлап та, моннан ике ел элек бик зур бәхетсезлек тудырдылар. Әле көз башы гына иде. Ата-аналары авыл белән бергә урман кискән чакта бу ике малай лапасларына ут ягып уйнаганнар. Ут бик тиз арада шундагы салам-печәнгә, түбәгә үрмәли һәм урамның бер очын җил искән якка ялмап та чыга. Халык урманда, сүндерер кеше юк: унлап хуҗалык кыл-бөртек әйберсез кала.

Шулай итеп, минем «качкын»лык хәлләре артык тавыш-гауга кузгатмый гына узып китте. Өстәмә язык алып булса да ялган белән ялгаштырдым:

— Фарукъ абзый быел анда укыта икән бит... Ул чакырткан мине, энесе Мирзаһит артыннан әйтеп җибәргән... Аның сүзен аяк астына саласы килмәде. Ә сезгә әйтергә йөрәк җитмәде... Ачуланырсыз, дидем...

Ышандылармы? Белмим. Хәер, ышанулары да мөмкин: мин ялганчы малай булып танылмаган бит әле. Аннары шул ягы да бар: эти аның яхшы укытучы икәнен белә, аны мактап күп сөйләгәнем бар. Шундый укытучы аның малаен Мамадыш хәтле җиргә чакырткач, ни дисен? Малаена гына түгел, үзенә дә дәрәҗә!

«Яхшы якка ялган да ярый» дигән сүз ишеткәнем бар. Белмим, дөрестерме ул, әмма бу очракта минем өчен бик ярап куйды...

Ә каникул бик шәп узды. Аның шәплеге шунда: безнекеләр ат суйды. Әйе, әйе, кырык сигез яшенә хәтле атсыз яшәгән Пәрхулла ат суйды! Теге карт, үшән аттан котылмакчы булганнар икән. Үзләренчә симертеп суйсалар да, хәтта поттан артык мае чыкса да, сап-сары сеңгер булып каткан итенә безнең яшь арысланныкыдай тешләр дә үтәрлек түгел иде. Шулай да ат сую — байлык галәмәте инде ул, амбарында дүрт аяк ит эленеп торсын әле! Үпкә-бавыры, эчәге-картасыннан пешерелгән бөккәннәр, шулпалы бәлешләр, баш-аягыннан әзерләнгән койкалар көндәлек ризыкка әйләнеп китте.

Икмәк мәсьәләсе шулай да кысынкырак иде. Мал-туарга имән чикләвеге оны сибәләр, ул он ишлерәк семьялы кешенең хәтта ипиенә дә

кушыла. Шуның өстенә хәзер һәр өйдә житен кумәче. Элек житен орлыгын базарга чыгарып саталар иде, хәзер аны алучы юк. Ул орлыктан май сыгып, керосин урынына яндыралар, коймак майларга да тоталар. Онын тарттырып, төче кумәч пешерәләр. Чәй эчкәндә кетердәвек бер кумәчне ашап була, ә икенчесе тамактан үтми, күңел болгана башлый, бик «бәрәкәтле» ризык...

Каникулдан киткәндә миңа да әни кеше шул ризыкны бер дә жәлләми төяп жибәрде. Әллә житен кумәчен бик ярата, әллә мине? Икмәк бирәү генә әләкте, ә инде ит-май дигәне капчыкка бөтенләй кермәде. Хәер, үзем гаепле түгел микән: «Безгә анда көн саен сарык итеннән пешерелгән обед ашаталар», дип мактандым бугай. Шулай булгач, карт алаша ите тыгып, мине мәшәкатьлисе килмәгәндер...

Шуның өстенә, өйдә булган ун көн эчендә шәһәр хәтле шәһәр жирендәге «зур уку»дан кайткан «кунак шәкерт» булыбрак йөрдем. Ул мине бик «тешли» алмады. Чынлап та, безнең авылдан моңарчы шәһәргә китеп кем укыган. Андыйны белгән-ишеткән кеше юк, мин үзем дә белмим. Әти моны сизә һәм горурлана иде булса кирәк. Шулай да ул мине илтеп куймады, юлаучы да эзләмәдек, жәяү кайтып кергән шикелле, аркага капчык асып, жәяү чыгып та киттем.

Белов бай йортына тагын жыелып, китаплар эченә янадан чумдык, кыш тавының кояшлы ягына төшә башладык. Килгәч тәрәк дөньялар матур иде, дәресләр дә борчымый — кешедән ким укымыйм, күңел күтәренке. Белмим, кыш уртасында уналтыны узып киткәнгәме, борынга кызлар исе дә керә башлады шикелле. Тәкәрлек күкәе төсле чуп-чуар битле, елтыр күзле, тәбәнәк кенә буйлы бер йомры кыз белән кинода танышып, караңгыда кулын кысып утырдым. Уч төпләре бик тә жылы иде, өенә дә озатып куйдым, тагын очрашырга сүз дә бирештек. Әмма берәр ай узуга кикрикләре шактый шиңә төште егетнең. Каткан кыерчык та жибәрмиләр өйдән. Үзем белән килгән бер ипине юка-юка телемләп кенә тотсам да, беткәнен сизми дә калдым. Ашап булмый торган «бәрәкәтле» житен кумәче дә юкка чыкты. Көннәр озыная барган саен тамак ачыга бара. Чиле-пешле бер кадак солы ипие, йодрык хәтле генә булгангамы, кече телгә дә йокмый кала. Күпме теләсәң шул чаклы чөмерергә мөмкин булган кипкән балык шулпасын тутыргач, корсак каптай булып кабара да шарык-шорык килә, берәр сәгатьтән шиңеп төшә, эчтә шайтаннар яңадан утын кисә башлый.

— Шайтан түгел,— ди Шәкүр,— анда ач жылан кереп яткан, шул суыра безнең карын төбен.

Көлешкән булабыз. Шәкүр Вятка арыягыннан килгән, каеры тунлы, бозау бүрекле, карсак кына буйлы малай. Аның да минем шикелле «ачка тук» булып йөргәне әллә каян ук сизелеп тора. Тагын шундый биш-алты малай бар. «Балыкчы балыкчыны...» дигәндәй, без дә ничектер бер-беребезне ерактан күрәбез. Сәлим дигәне «кәжә боты»н суырасуыра безнең янга килеп баса.

— Эч эзләнүгә иң яхшысы менә шушы аның,— ди,— чуваш тәмәкесе. Илла майлы да соң: берне тартып жибәрсәң, симез каз ите ашагандай гел кикереп кенә йөрисең...

Ул тәмәкене Мамадыш базарыннан мин дә чыгып алдым. Гәзиткә төрнап, тартып жибәрүгә башлар әйләнеп, күзләр урыныннан купкандай булып китте, тын юлларына кинәт дегет тулган шикелле тончыгып йөткерә башладым. Шулай да нәләндем, чыннан да, ашыйсы килгәнне басып жибәргән төсле ул. Кяшки шулай булсачы! Юк шул, ялган юанычкына, чын ипи ашаган чаклар барыбер төшкә керә. Көн саен бер тапкыр Шәмәк Ганиләр дворыннан авылдашлар күренмәсме дигән өмет белән әйләнеп кайтам, берәүне дә очрата алмыйм. Бер көнне Максутова фамилияле бер кыз миңа үзе өчен кухняда кизү торырга кушты. Ул, бер аягы аксак булу сәбәпле, Вятка ярыннан су ташый алмый. Бик рә-

хәтләнеп риза булдым. Ичмаса, туйганчы бәрәңге ашадым. Өстәвенә, ул әле миңа өч-дүрт чәйгә житәрлек сохари бирде. Әх, шундый кызлар күбрәк булса! Булмый шул, һәркем үзе тора, үз кизүем дә ерак әле... Минем табакташ Шәһит Кәримовка икмәгедер, бәлештәй зур орлык бөккәнедер һәр вакыт килеп тора. Кайчакта ул миңа да бирәр сынык сузгалый, ә кайчакта, оялудан бурлаттай кызарып булса да, «әҗәткә» сорап алам.

— Кызыл кар яугач бирерсеңме? — дип көлә ул. Мин дә тапкыр телләнгән булам:

— Язган булса — яз көне, кушкан булса — кыш көне,— дим.

Ә февраль ахырларына таба инде бөтенләй рәт китте: баш әйләнә, күзләр әлҗе-мөлҗе килә башлагандай булды. Ичмаса, житен күмәче булса да җибәрсеннәр иде. Әллә теге чакта аннан борын чөергән булуның киялеге килде микән?.. Сатар әйбере дә юк, сатып икмәк алыр урын да юк... Ташлап кайтып китәр идең, уку жәл. Хурлык: шәпләнеп качкан бул да кайтып кил — жир тишегенә кер аннары!

Астагы ашханә залына узганда уң якта чолан бар. Барысының да әйбер капчыклары шунда тора, минем капчык та шунда — эчендә вактөяк чүп-чары бар, ипие генә юк, ә башкалар алай түгел... Көннәрдән бер көнне бик тамак өзелгәч, кеше юк чакны туры китереп, ишекнең тимер эшергечен тарттым да шул чоланга кердем. Ялт-йолт каранугa бер симез капчыкны күреп, тиз генә авызын чиштем: олы-олы өч түгәрәк ипи! Дүртенчесе бүген генә башланган булса кирәк. Калай саплы бәләкәй пәкем белән шуннан бер телем каерып кистем дә кесәгә тондырдым, өстенә бияләйне тыктым, капчык авызын бәйләдем, аннары сак кына чолан ишеген бикләп, чыгып тайдым. Аллага шөкер, берәү дә күрмәде! Кая барганымны абайламыйча, урамнар буйлап жәһәт-жәһәт атлый бирдем. Әйләнә торгач, югары очтагы базар жыела торган мәйданга килеп чыктым. Кояшка караган бер йорт кырыена утырып, тирә-якны күзәтә башладым. Мине танырдай кешеләр булмавына тәмам ышангач кына кесәгә кулны тыгып, урлаган телемне урлап кына сындырып алдым да урлап кына авызга каптым, урлап кына чәйнәп йоттым. Тагын кабатладым, шулай чәйни торгач, телем бетеп тә китте, кесәгә жыелган валчыгын да кырып-себереп, чүп-чардан да аермыйча ашап бетердем, ә тамак туймады. Оятсыз тамак!.. Бирән тамак!..

Шулай да бу кәсеп белән мин атна-ун көн чамасы маташып йөрдем. Хәтта кай көннәрне ике кесәгә ике капчыктан ике телем салып чыккан чаклар да булгалады. Бөтенләй комсызланырга тотынды кеше! Торабара күңел төбенә әллә нинди корым утырган сыман була башлады. Әллә каян гына ямьсез уйлар килеп туа: «Үзең укып йөр, хәтта качып килеп укы, үзең караклан, кеше әйберсенә кул суз. Үзең гаделсезлекне бер дә яратмаган буласың, үзең шуны ук эшлисең. Юк, курсант түгел, вак бур гына син!..» Бу инде: мин әле ул чакта ачык белмәгән вөждан газабы булгандыр, шул әрләгәндер. Ә шул ук вакытта эчтән икенче бер тавыш мине акларга, хәтта бу оятны «сыйнфый жәймә» белән капларга тырыша: «Син бит юкнықын түгел, барныкын гына аласың. Аларның капчыклары тулы күмәч тә бөккән, тәбикмәк тә күзикмәк, ит тә май. Алар бай да мулла баласы, алар тук булып, син ач булыргамы? Юк, синең бер телемең генә бик хәләл ризык ул! Тотылма гына! Тотылмаган — карак түгел!..

Баксана, юатучы да бик шәп сөйли бит. Кайсы шайтан, кайсы фәрештә боларның?.. «Тамак тәмукка кертер» дигән сүз бар бугай. Озакламый минем башка да шундый хәл килә язды. Кичләрнең берендә торакның түрдәге киң бүлмәсенә малайлар, кызлар жыелды. Гайшә Насыйбуллина дигән кыз елый-елый сөйли башлады:

— Бездә ипи караклыгы китте. Бүген чоландагы капчыктан минем ипине урлаганнар. Нәрсә булып чыга инде бу?..

— Кемнән шикләнәсең? — дип сорадылар.

— Маннурдан гына... Аңар икмәк килмәгәнен барыгыз да күреп тора...

Яшен суккандай булдым. Коелып төшкәнемне сиздермәскә, кызармаска тырышам. Башны югары тотып, туп-туры карап утырган булам. Нишләргә инде миңа хәзер? Харап бит эш, харап!

— Күргән кеше бармы? — дип сорады кайсыдыр.

— Күргән кеше булса, бугазыннан буар идем мин ул каракның!

— Күпме урлаган? — дип кычкырды кемдер.

— Капчыкта ике бөтен, бер ярты ипием бар иде, әнә шул яртысы юкка чыккан,— диде Гайшә, һаман әле күзен җебетеп.

Кинәт минем эчкә җылы кереп китте. Димәк, бу мин түгел! Минем беркайчан да ярты ипи урлаганым юк. Аны чоланнан ничек алып чыгасың да кая яшерәсең? Капчыгыңа тыгар идең, тенти башласалар — хәзер эләгәсең. Күрәсең, миннән шомараклар да бар икән әле монда. Тордым да:

— Юк, минем урлаганым юк! — дип кычкырдым.

— Урламаган булса, коръән үбеп ант итсен! — диде Гайшә. — Тольно белеп торам — шул гына.

Менә кайчан көрчеккә килеп эләктем! Нишләргә миңа хәзер? «Юк, мин урламадым», дип бу малайлардан котылу юлын эзләсәң дә коръән үбеп ходайны ничек алдыйсың? Ул бит минем урлаганны күреп, белеп тора. Нәкъ ялган сүз белән корьән үпкәндә генә авызыңны чалышайтса, я китап тышына ябыштырып катырса — нишләрсең? Хәер, ул рәхимшәфкать иясе бит. Тиз генә ходай тәгаләнең үзе белән сөйләшеп алмакчы булдым: «Минем ул телемнәрне тамак ачлыктан гына алганны да, берьюлы ярты ипи чәлдермәгәнне дә син яхшы беләсең... Шулай булгач, «ярты ипи урлаганым юк!» дип ант итсәм, ярлыкарсыңмы мине, ходаем?» дип сорадым эчтән генә. Ходай эндәшмәде. Аның дәшмәвен үз файдама юрадым да:

— Китерегез, ант итәм,— дидем мин батыраеп.

Тарих мең дә тугыз йөздә егерме беренче елның язында, совет властеның дүртенче елы барганда, Мамадыш каласындагы педкурсларда укучылар арасында коръән табылмас дип уйлаган идем, хата булып чыкты, бик тиз табып китерделәр. Һәм мине аягүрә бастырып (ярый әле, тәһарәт алдырмадылар), ике кулыма коръән тоттырдылар. Түшәмгә табарак карадым да:

— Минем ярты ипи урлаганым юк, ходай шаһит! — дип, коръән тышын үбеп алдым. Мин моны чын күңелем белән эшләдем, чөнки ходайга бик нык ышана идем. Ләкин бик нык ышансам да, телемләп урлауларым йомылып калды. Монысы өчен мин алла каршында гына түгел, кешеләр каршында да ап-ачык гаепле идем. Нишләргә соң? «Ярты ипи алмавым хак, ә телемләп урлаштырганым бар, иптәшләр...» дип әйтсәм, ничек булыр иде?.. Иптәшләр генәме соң монда?.. Әйтеп кенә кара. Шул ук Гайшә — Биләтле авылының калаччы Әскәр бай кызы бит ул, шул ук Акчишмәнең бай малае Шәңгәрәй, шул ук кара коелып утыручы бүтәннәр — хәзер изеп ташлап, җаныңны алачаклар!..

Шул җан саклау инстинкты буенча, дус-дошман алдында дигәндәй акланып калдым. Әмма бу хәл мине җәйгә тикле газаплап йөртте. Җилкә өстемдә ниндидер кара козгын утыра, һәм шул козгын көн саен йөрәкне чукып тора кебек иде. Теге «сипкелле сөйкемле» белән кабат киногa барырга да туры килмәде, аның Рәйханә дигән апасы бездә укый иде. Әлбәттә, житкерми калмагандыр бу тәти егетнең хәлләрен...

Гарьлекнең соңгы чигенә җиткән башны җиргә салындырып, ашханәгә узганда чолан ягына бөтенләй карамас булып йөри башладым. Каешны ныграк кысып, тәмәкене сузыбрак суыргач, түзеп була икән...

## «Ырыйстан» эти

Бу хәлләр басылуга берәр ай узган иде бугай. Кояшлы көннәрдә карның күзгә күренеп сыза барган чагы, түбә читләреннән тамчының чат-чот тамган чагы һәм гөрләвекләрнең ага башларга юл эзләп маташкан чагы иде. Шәмәк Гани дворында Мәхмүтне очраттым, житен маена тоз алмакчы булып килгән, чәй эчтек. Имән чикләвеге оны кушылган булса да, ипи белән чәй эчтек! Хәлләрен сораша башлавым булды:

— Пәрхулла абый да монда әле...— дип куйды бу.

Ничек инде? Эти монда, ә миңа кермәгән дә... Бик гажәпләндерде бу мине.

— Өтермәндә утыра ул,— дип өстәде Мәхмүт...

Күз алларым кинәт карангыланып китте.

— Әтекәем-әнекәем, монысы нинди сүз тагы, уйнап сөйлисеңме? — дип аның күзләренә төрәлеп каттым. Ул аңлатып бирде:

— Трутпобиннес буенча урман кисәргә бармаган өчен бугай. Инде жибәрелгәненә бер атна бардыр...

Менә сиңа кирәк булса-а! Нишләргә хәзер? Мәхмүт тә рәтле киңәш бирә алмады. Хәер, кем монда акыл өйрәтә алсын? Төрмәнең капкасы кая таба ачылганын да белүче юктыр безнең нәселдә. Янынннан узганда да кеше куркынып китә бит аның... Ничек итеп этине күрергә соң, хәле ничек икән аның, чирләп ятмый микән?..

Бер киңәшчем дә юк, төрмә турында теләсә кем белән сөйләшеп тә булмый. Уйлый торгач, Фарукъ абзый янына киттем. Оятымнан бутала-бутала хәлне сөйләп бирдем.

Ул да бик аптырап утырды. Суд беләнме, срогы күпме икәнен сораштырды. Мин ул якларын белми идем. Шуннан ул бер кәгазь язды да мөдир иптәш Зиннуров янына кереп китте. Байтактан соң чыгып, пичәтле, штемпельле һәм имзалы кәгазьне минем кулга тоттырды.

— Төрмә начальнигының үзенә күрсәт,— диде.

Курка-курка гына төрмә капкасы төбенә килдем. Янда гына бәләкәй тәрәзәле будка бар икән, шуны кагып кәгазьне суздым, этине күрергә теләвемне әйттем. Эчтә утырган хәрби киемле кеше язуга күз йөгертте дә:

— Атаң кем? — дип сорады.

— Фәрхулла Фазлытдинов,— дигәч, олы бер кенәгәдән карап алды да бәләкәй капканы ачып, ишегалдына кертте, аннары төрмә ишеге янына китереп, шуннан эчкә узарга, беренче каттагы алтынчы камераны сорарга кушты.

И дөнья! Шушы башымнан төрмә эчләрен күрермен дип кем уйлаган? Китаплардан уку буенча ул бит иң куркыныч йорт булып, катылык-шәфкатьсезлек урыны булып, пычрак, сасы бер пәри оясы булып күңелгә сеңгән. Аяклар калтыранып атлый, күз-колак бик нык сагаеп, абайламаганда гына бер әшәкелек булуын көтә...

Ә төрмә эче нигәдер пычрак түгел, борынга сасы ис тә бәрелми. Киресенчә, коридорның бөтен идәннәре сап-сары итеп юылган, бер почмагында да чүп-чар күренми. Стеналары да чиста, ә мин кан таплары күренер дип уйлаган идем. Шуның өстенә коридор тәрәзәләренең челтәре аша язгы кояш кереп, бу михнәт йортына әз булса да сөенеч сибәргә теләгәндәй яктылык чәчеп, идәннәрдә, мич кырыйларында уйнап яткан була. «Нәзерәтел» дигәне дә мин көткәнчә тупас телле, төксе йөзле булып чыкмады. «Сиңа кайсы бүлмә, энекәш?» — дип сорады да алтынчы камерага кертеп жибәрде. Бу да бик гажәп тоелды миңа.

Ә камераны ачып керүгә ишек катында тукталып калдым. Авыл

өендәгечә тоташ сәке түренә намазлык җәеп, бер карт шуның өстендә утыра. Кайда булса да — шул икән бу этинең. Төрмәдә дә намаз калдырмый, имеш! Калган биш-алты кеше йөзлек буена тезелгән. Монда да көлеп торган чисталык, идән-сәкеләр әле генә юып чыгарылган төсле, дымлы сыман булыбрак күренә, камера эче җылы, кешеләр кулмәкчән генә. Ә түрдәге бердәнбер тәрәзәдән төшкән кояш бу бүлмәгә дә күңелле бер ямь өсти. Кинәт төрмәнең минем уйга сеңгән бөтен куркынычлыгы, бөтен әшәке шыксызлыгы югалып китте, өшеткеч бозы эреде. Элек тә шушылай булды микән соң бу? Китапларда арттырып язылды микәнни?..

Эти намазын тәгәлләп, җәймәсен төргәндә мине күреп алды, йөгереп килеп ике кулымны суздым:

— Исәнме, эти, саумы? — һәм, күз мөлдерәп, тавыш сынып китте.

Ул минем малай баштан төрмә хәтле төрмәне ачтырып керүгә шактый гаҗәпләнгән иде бугай, күзләрен җемелдәтеп озак карап торды, аннары гына:

— Аллага шөкер әле, улым, ничек киләсе иттең? — диде.

Мич тирәсендәрәк урнаштык та, ярым пышылдап дигәндәй, сөйләшеп утырдык. Кайсылары тартырга дигән булып коридорга чыкты, кайсылары сәкегә сузылып ятты. Аларның гади авыл кешеләре икәне күренеп тора иде. Этинең биле кузгалган булган икән. Аның сирәкмирәк кабатлана торган шундый өянәге бар. Катырак салкын-фәлән эләктерсә, чамаламыйрак авыр күтәрсә, шул биле тота. Читтә чакта ул аны «киндер бәлсәне» дигән нимес даруы белән майлый-сыпыра иде, авылда — мунча пары, мәтрүшкәле себерке. Менә шул билсез чагы туры килеп, урман нәрәтенә бармый калган.

— Ә менәтерә хәзер таш капчыкка ятап белән китереп тыккач, язылды да китте җүнсез бил! — дип көлгән була карт.— Төрмә дигәч, кот чыга бит,ниләр күрәм инде дип әйтеп, курыкканыем, ярый тагы, хода рәхмәте белән мондагы бәндәләр миһербанлы икән, алай кагыпсугып йөртмиләр. Кар түгәбез, урам-ишегалды тазартабыз, утын кисәбез, идән-сәкеләрне үзебез юабыз бик шәплэп. Хәерле булсын, егерме көн күп түгел, исән булсак...

Минем монда килеп керүгә Фарукъ абзый ярдәм итүен белгәч, аңа күп итеп рәхмәт әйтергә кушты.

— Бик әйбәт кеше булса кирәк, аның сүзеннән беркайчан да чыкма син, улым, тырышып укы,— диде.

Бик һәйбәт сүзләр әйтте, ә минем ничек яшәү турында һични сорашмады. Сәер кеше безнең бу карт. Бер карасаң — алтын, бер карасаң — чуртым дигәндәйрәк. Малаеның монда телемләп кеше ипиен чәлдерүен һәм ярты ипи урлауда гаепләнүен белмәсә дә, ачлы-туклы йөрүен чамаларга тиеш иде бит ул. Мин күтәреп кайткан шул ат онынннан ук хәлне аңларга була ич. Ә ул күрми. Хәер, өйдә дә шулай иде бит: уттай эш өстендә бер ипине берүзең сугардай булып кайтып керәсең, табынга утырсаң — алдыңа бер телем ипи куялар. Дөрес, бик үк юка телем булмый ул, шулай да бер чынаякка бетми, ике чынаякка җитми. Ике каптың — бер йоттың дигәндәй, кече телгә дә йокмый кала. Нишләргә белми утырганнан соң авызыңнан чыгар-чыкмас кына тавыш белән: «Әнәй, ипи кис әле...» дисең. Иң элек ике күз кадала сиңа, аннары потнуска бәрелгән пычак шылтырый, аннары бәләкәй генә бер телем «дык» итеп алдыңа ята, яртысы чынаягына түгелгән чәй килә. Болары инде тамакка таш булып утыра...

Шуларның барын да күреп түр башында утырган эти: «Кис күбрәк итеп, ашасыннар туйганчы — эштән кайтканнар бит!» — дип әйтә алмый. Әллә курка микән ул яшь хатыннан?..

Һич югы, житен күмәче яки бәрәңге җибәрсәләр дә рәхмәт укыр идем. Бәлки үзем дә җебегәндер инде мин: менә күпме утырдык, ә шул

хакта бер сүз әйтә алмадым. Хәер, тоткындагы кешедә ул кайгымыни?..

Чыгышлый мине төрмә башлыгына алып керделәр. Котым чыкты. Нәрсәгә икән дип куркудан тешләрем шак-шок килгәне мине алып керүче нәзерәтелгә дә ишетеләдер кебек иде. Бик шәп мыеклы, олы юаш күзле, урта яшьләрдәге кеше мине үз каршына утыртып хәл сорашты, аннары:

— Стало быть, сез инде укып бетергәч кем буласыз? — диде.

— Исән-сау укып чыксак, укытучылар булабыз инде,— дидем мин тартыныбрак.

— Стало быть, үзебезнең яшь советски педагоглар булып, авылларда просвещение таратасыз инде? — дип елмайды ул.

Сүзенә русчаны еш кыстыручы бу абзый шулай ачылып сөйләшкәч, эчкә җылы керде, баягы куркулар юкка чыкты. Гади кеше булып тоелды ул, халык эченнән чыкканлыгы күренеп тора иде аның. Әйбәт кеше икәнен сизгәч, чишелебрәк киттем: үзебезнең гомер буе бер имана белән ат-тунсыз яшәгән ярлы катлаудан булуны, картның бил белән җәфаланганда урман кисәргә бара алмый калуын сөйләп бирдем. Тел төбем билгеле инде: этине йолып булмасмы, янәсе.

— Так, так,— дип утырды ул мин сөйләгәндә. Аннары, бик ашыгыч бер эше барлыгы исенә төшкәндәй, кинәт кенә кузгалды да:

— Ладны, брат, апдумаем, күмер юк, утын юк, мәктәпләр суык, больнислар суык, ә мужик бик кыймылтамый,— дип миңа кулын сузды. Аның көрәк хәтле учында минем малай кул югалып калды.

Ачык кына ничек дип уйларга да белмәстән, чыгып киттем. Төрмә хәтле төрмәгә шулай ансат кына барып керүем дә, бу кешенең мине үз янына чакыртып, сөйләшеп утыруы да бик сәер иде. Тагын да сәеррәге ике көннән соң булды. Ике көннән соң әти төрмәдән котылып, безнең торакка килеп керде.

Ни дияргә белмичә, шаккатып калдым.

— Кәбинетенә чакыртып алды,— ди әти. «Бар, бабай, кайтып тор, моннан ары сәвит быласы сүзенә ныклабрак колак сал», дип әйтте,— ди.

Картның бик күңеле булган, шөкерана кылып бетерә алмый. Ә безнең торакта самавар кайнату мөмкинлеге дә юк иде. Шәмәк Ганиләр дворына киттек, картның төрмәдән чыккан ипие белән туйганчы чәй эчтек тә, мин аны озатып җибәрдем. Буш корсакта бакалар чурылдавын тагын әйтми калдым. Хәерле булсын, түзәрбез...

Гөрләвекләр әллә кайчан агып бетеп, Мамадыш урамнарында беренче үләннәр баш төртә башлаганда Вятка иделе ташыды. Аргы як болыннарына күз күреме житмәс булып су җәелде. Астан ике катлы ап-ак пароходлар менә башлады, без гел пристань тирәсендә чуалып, аларны озатып калабыз. Шуларга утырып, әллә кайларга китәсе килә. Хәер, бик әллә кайларга булмаса да, җыйнаулашып Соколкага хәтле төшеп тә мендек. Безне Казанга экскурсиягә алып бармакчылар иде, булмады. Казанда тиф котыра, имеш, кире бордылар.

Укулар унбишенче июньдә генә тәгәлләнде. «Педкурсларның ике курсын тәмамлады» дигән язу алып, өйгә кайтып киттем.

Ә кайтым керсәм — шаккаттым дә калдым: безнекеләр пыр тузып Себергә китәргә җыенып ята! Әйе, әйе! Ачлык буласы икән, яз башыннан бирле бер тамчы яңгыр төшмәгән, кырдагы бөтен уҗым көеп беткән, ә сабан тишелмәгән дә, имеш. Мамадышта ятып, шундый афәт куркынычы барлыгын мин бөтенләй белмәгәнмен дә. Ә бу хакта өйдәгеләрдән миңа ләм-мим бер хәбәр килмәде. Минсез генә китеп бармакчы булуларына бик нык хәтер калды. Түзмәдем, үпкәмне авыздан чыгардым.

— Мине шунда ташлап калдырмакчы булгансыз икән,— дидем үги анага.

Бер дә исе китмәде.

— Ник, үзең качкынныкка чыгып киткәч, без инде ата-ананың кирәге җуктыр дип уйлаганыек,— дип кенә куйды...

## Михнәт юлы

Икенче көнне басуларга чыгып киттем, үз күзләрем белән күрәсе килде. Юл буйлап «Түбә өсте», «Үзән асты», «Гөбердәвек башы», «Аю куле», «Төлке урыны», «Кызлар елгасы» дигән урыннардан бара торгач, урман читендәге «Янык» басуына менеп җиттем. Ышанмаслык берни дә юк икән шул: арышлар нечкә генә булып ике буын чыгарган да саргаеп каткан. Хәтта Яныктагы кара балчыклы тигез җирләрдә дә күз кинәнер нәрсә күренми. Мондагы кара туфрак, табада кыздырган төсле, ярмаланып тора, борынга китергәч, көек исе аңкыта.

«Борын түбәсе» ягындагы сабан басуларында бөтенләй өмет юк икән: солы белән борайның бармак буедай беренче кыяклары ук көеп ята. Ясмык-борчак, карабодайның да берәм-сәрәм зәгыйфь яфраклары күмкә өстенә шәлпәеп төшкән. Нинди дер могҗиза белән бүген үк яңгыр башланып, ике атна буена көн аралаш явып тормаса, бу игеннәрдән бер генә бөртек ризык та әдәм авызына керәчәк түгел...

«Шылангыр» чишмәсенә төшеп су эчтем дә тау кашындагы межа куаклары төбенә утырдым. Кая гына карама, күз күреме җиткән җирдә ялангач кызыл балчыклы ямьсез таулар да сыртлар, үрләр дә түбәләр. Шулар белән аралаш басуларны аркылы-торкылы ярып, язгы сулар вакытында иген җирләренең бар маен агызып китә торган коры елгалар. Бөтен тирәдә шәрәлек-шыксызлык. Сусаган күзләрең белән урман әзли башласаң, җиде-сигез чакрым киңлектә нинди дер бер кызның шәльяулыгы төшеп калгандай бәләкәй генә яшел билге күрәсең. Фәкыйрь безнең бу яклар, фәкыйрь... Авыл кешесенең йөдәү-җитмәүчелектән башы чыкмый. Бармаклар белән санап утырам: безнең авылның ун гаиләсе балчык өйдә тора икән. Ә тәрәзә аслары, почмаклары бүселеп, туксан тераү терәткән, борыны белән җиргә чуккән, аксак Пәхерттин абзый күк бер якка кыйшайган йортлар, түреннән бәләкәй генә «сыңар күз» караган өйләр күпме?! Ил җире шулай җимсез-имсез булгангадыр инде, читкә агылган безнең бу як. Мәгәр анда казганып та мантый алмаган. Күпме читкә йөреп, сыңар тиенен дә күз карасыдай саклап тота торган безнең әтинең «югары өе» дә әнә уналты ел инде сукыр карачкы булып тора ич. Тәки эшләтеп керә алмадык шуны.

Себергә китәсе булу, дөресен генә әйткәндә, сөендерде мине. Болай төп-тамыр белән йолкынып киткәч, кабат кайтмабыз инде, җиргә, урманга бай Себердә нигезләнеп калырбыз дип уйладым. Сагынмабыз да шикелле тоелды...

Кайтуга атна тулганда әзер булдык. Күченеп китә башлагач, үзен белән сөйри алмый торган әйбер-сәйбер дә дөнья хәтле була икән. Сатылырдаен хак белән озатып, сатылмастаен агай-эне, күрше-күләнгә таратып бирдек. Сату дигәннән, кайсыдыр сүз чыгарган: Себердә Микулай акчасы йөри, имеш! Безнең әти тагын ышанды моңа. Теге вакытта түтәйне Микулай акчасына кияүгә биргән шикелле, үзебезгә юллык ризыкны әзерләгәннән калган бер капчык онны да (иң газиз, иң кыйммәтле нәрсәне) шул иске акчага сатып җибәрде. Дөньяны бик белгән, бик акыллы саналган кешенең дә шуңа ышануы искиткеч сәер иде!

Иртәгә атна кич. Җыен бәйрәме башланасы көн.

И жыеннар, жыеннар,
Су буйлары, болыннар,
Шаулый-гөрли уеннар,
Сайрап туймый гармуннар...
Ак чабата, ак оек,
Әйдә, бергә атлыек,
Китик озын уенга,
Кер, жаныем, куенга...—

дигәннәрен такмаклыйсы килә... Ә безнең як жыеннарын санап бетергесез. Җәйнең беренче матур көннәре дөньяга җәелгәч тә Комазан җыенына китәләр. Аннары Янбай җыены, безнең Туктамыш җыены, Кукчә җыены, Төенчек җыены булып уза. Иң соныннан, арыш урагына төшәр чак җиткәндә генә, Казанский җыены башлана. Сабан туйларыннан да күңеллерәк була ул җыеннар. Яшь-җилкенчәк өч көн буе болыннарда, чишмә башларында уйнап, җырлап, туйганчы көлеп дигәндәй ирек ачып, үз җыенын уздыргач, башка авыл җыеннарына да бармыйча калмый әле. Берәүләр чуклы-чачаклы атларда чаба, ә берәүләр «пишкун»га утырып китә...

Без дә барган идек ул җыенга... Әле кайчан гына Хөршит түтәйнең кыз чагы иде бит. Яңа Мәкчем авылындагы Гөлбану түтәйләр үтереп кыстап чакыргач, әтиләр безне Казанский җыенына җибәрделәр. Бер дә барасым килмәде, картлар көчләп дигәндәй түтәйнең каравылчысы итеп җибәргәч, нишли аласың? «Назлы кәҗә» булып маташу түгел бу, бик мөһим сәбәбе бар: минем кәзәки юк. Ә кәзәкиең дә булмагач, биш минуттан егет булып өлгерәсе унбиш яшьлек сәмрәүгә башка авыл җыенына баруның нинди кызыгы бар?..

Тыз да быз килде әни кеше һәм җаен тапты: күрше Һадиулланың кара сатин кәзәкиен гозерләп алып чыкты да өскә кидерде. Артын тартты, алдын тартты да:

— Менә бит, коеп куйган күк! — диде.

Яхшылык эшләде ул, рәхмәт әйтергә кирәк иде аңа, ә мин авыз турсайттым, ник дисәң, кеше киеме бер чакрымнан кычкырып тора бит инде ул. Җитмәсә, култык асты кыса, якасы тар, тагын әллә кай төше әллә ничек шунда. Әти дәшми, ачуланмый да. Олы малайның кәзәкисез булуы шәп түгеллеген үзе дә сизә, күрәсең.

Киттек без шулай итеп пишкунга утырып, Яңа Мәкчем авылына. Басу капкасын чыгу белән кәзәкине салып кулга тоттым, авылларны узганда гына киям дә тагын салам. Кеше киеме кылчыклы, гел чәнчеп тора тәнне. Минем хәзер чалбар да бар, югыйсә, оек-чабата да яңа, әйбәт укыган өчен мәктәптән бирелгән күлмәклек тә сабан туена гына тегелгән, башта кырпулы бүрек тә бар, ә кәзәки юк менә, юк кәзәки!..

Шыя буендагы киң болында була икән җыеннары.

Шау да гөр, уен да җыр, әллә ничә авыл яшьләре җыелган, әллә ничә урында уен бара. Болыннары бер дә рәхәтләнеп йөгерерлек түгел икән — гел түмгәк кенә. Беренче көн ярыйсы гына узды, ә икенче көнне багана буйлы бер егет «озын уен»га өстери башлады түтәйне. Иген арасына, урманга таба алып китәргә исәбе. Күрәм, түтәйнең ул белмәгән-күрмәгән егет белән һич кенә дә барасы килми, һаман артка тартыла, ничек тә ычкынырга тели, ә йөзеннән — коты очкан. Килдем дә араларына төштем. Тиз генә егетнең кулын аерып ташлыйм да түтәйне алып китәм, янәсе.

— Туктале, кайнеш,— диде егет авызын ерып.— Безнең әз генә сүз бар, әнә шул тирәләрне генә әйләнеп кайтыйк, мишәйтләмә. Ука чуклы, алтын чигүле кара хәтфә түбәтәй синең башта буласы, онытма шуны!..

— Әй, такылтык! — дип, мин яңадан ташландым. Ә ул мине, нихәтле генә тыпырчынсам да, култык астымнан эләктереп, йомычкадай гына читкә чөйде. Елардай булып, тагын килеп тарткалаша торгач, тәки түтәйне аерып алдым. Дөньяның яме сүнде, болыннан ук кайтып киттек.

— Нәрсә булды, гөлкәйләрем,— диде Гөлбану түтәй,— ник иртә кайттыгыз?

Сөйләп бирдек, аннары чәйгә утырдык. Эссе булгач, кәзәкине салып элим дисәм, уң култык асты умырылып чыкканын күрдем. Түтәйгә суздым. Икебез дә телсез калдык. Ул аны кич буе ямап утырды. Ни пөхтәләп ямаса да, гаеп барыбер сизелә иде шул.

Икенче көнне иртүк кайтып киттек... Кәзәкинең ертылган булуын барыбер күрделәр. Шул нәләт кәзәки аркасында күршеләр белән әчелешле булдык, ә һади мине тотып кыйнарга йөрде. Әй ул кәзәки!..

— Ничек яшисең, бик җәфа чикмисеңме, бик җәберләмиләрме? — дип сорадым. Тормышы бик начар булса, «Әйдә, безнең белән китик, анда баргач, икебез дә эшләрбез, этиләрдән аерым торырбыз, ничек тә үлмәбез», димәкче идем.

— Юк, ылан,— диде түтәй,— бик әйбәт яшим. Җизнәң бик яхшы кеше булып чыкты. Ул мине ярата. «Синнән башка бер көн дә яши алмыем», ди. Мин дә ярата башладым аны хәзер. Бәхетем шулдыр дип куанам. Карчык та начар түгел: үзе дә какмый, кызларыннан да каты сүз әйттерми. «Балам» дип кенә торган була...

Менә сиңа, аңла бу дөньяны! Ике хатын аерган кешегә көчләп кияүгә бирелгән кыз — нәрсә сөйли? Юк, минем малай башка сыймый бу. Әллә яшерә микән? Төпченеп карыйм, барыбер түтәй үзенекен сайрый.

— Юк, ылан, юк,— ди.— Синнән яшермәсием инде. Күз генә тимәсен, бик әйбәт торабыз! — ди.

Ярар, бирсен ходай. Шушындый озакка аерылган чакларда, ул бәхетсез тормышта тилмереп калса — нишләр иде?..

Эңгер төшүгә Мөбарәкша абый ат белән ишегалдына килеп керде, аның артыннан Мактый бабай да үз аты белән кереп җитте. Әйберсәйберне төягәч, алдагы арбага ике кечкенә малай белән картлар менеп утырды. Мактый бабай арбасына Шамил белән Лотфулла кунаклады, мин дә шунда утырып барасы. Ишегалдына күрше-күлән, агай-эне тулган. Хушлашу, кул бирешү, хәерле юл теләү сүзләре озак дәвам итә. Ниһаять, җил капканы шыгырдатмый гына күтәреп ачу һәм атлар чыгып киткәч ябып, аратасын тыгып кую минем өскә төшә. Озата чыгучылар җәй уртасының сыек караңгысында соңгы мәртәбә кул изәп, соңгы теләген укып кала. Арбалар артыннан без өчәү атлыйбыз. Түтәй шулай бәхетле булгач, җизни хәзер миңа якын булып китте. Мин аларның уртасыннан барам, миңа рәхәт. Туган авыл кала, туган йорт кала, суын эчеп үскән Олы чишмәләр кала. (Ә Себердә чишмә юк, су тәмле түгел.) Аунап-тәгәрәп каз көткән, җырлап йөргән болыннар кала, күз аллары күк төтен булганчы су коенган дугайлар кала. Ничәмә тапкыр җиләкләрен-гөлҗимешләрен ашаган зиратта ничәмә тапкыр сабый яше түгелгән әни кабере кала, аның Мактый бабай белән Гаптулла абый ясаган гади генә бура чардуганы эчендәге ялгыз каены, без барган саен моңсу гына җилбердәп каршылый торган ак каены кала. Бары да кала... Ә мин нигәдер тыныч, түтәйләр белән сөйләшеп баргангамы, бер дә артык уйланмыйм. Әллә сәфәр йөрүләргә, аерылышу-кавышуларга күнегеп киткәнме бу күңел, әллә яшьлек барын да шулай җиңел генә кичерә белә микән?..

Тегермән күперен узгач, арыкның югары очына менеп, Кечти Шакир абзыйлар тыкрыгыннан басу юлына чыкканда без инде егерме бер олау булган идек. Кечти Шакир абзый үзе дә, кияве Галимулла да,

әни кешенең биш балалы тутасы Гөлфаныйттәй белән ире Мөхәммәтгале җизни дә, Җәләли Фәезтине дә, теге усал Зиннәтләр дә, гражданнар сугышында күп йөргән һәм бик шәп шлем киеп кайткан «камисар» Хәйбәрәхман абый да, көтүче Галәү дә һәм тагы бик күпләр ачлыкның беренче качаклары булып, туган авылдан китеп барабыз...

Басуга чыккач, әз генә төн салкынчасы беленсә дә, аяк астындагы тузан һаман коп-коры, җил булмаса да, «пырак оны»[1] шикелле үзеннән-үзе күтәрелеп, борыннарга тула. «Бирге елга»га җитәрәк җизниләр алгы арбадагы әтиләр белән саубуллашып килде. Безнең янда түтәй елый башлады, аерылышасы килмичә балавыз сыга ул. «И ыланнар, сездән башка нечекләр яшәрмен инде...» дигән була.

Ә безнең истә дә юк. Арбадагы әйберләр өстенә атланып утырган унике яшьлек Шамил: «Җылама, түтәй, без бит читкә китәбез, читкә!» — дип көлә.

«Бирге елга» күперендә түтәйләр «хәерле юл!» дип кул изи-изи туктап калдылар. Без күперне чыгып үргә күтәрелүгә, алар инде күләгә булып кына күзгә эленәләр иде. Болай төнлә чыгып китүнең дә бер әйбәт ягы бар икән: туган авыл да, чәчәкләрендә аунап үскән болыннар да, җанга якын урыннарның берсе дә ачык күренми, үзәкләрне өзеп калмый — онытуы да җиңел булачак. Кыска төн яктыра башлаганда Тулбай инде үрләр артына күмелгән иде. Көн буена күп авыл кырларын уздык. Һәркайда бер үк хәл: саргаеп каткан игеннәр, басу өсләрен күксел сөрем төсле рәшә сарып алган һавадан көек исе килеп тора.

Җитмеш чакрымдагы Бүрсет тамагына без икенче көннең кичке ягында гына килеп җиттек. Әйберләрне бушатып яр буена өйгәч, фатир кереп чәйләр эчкәч, атларын туйдыргач, Мөбарәкша абый белән Мактый бабай кайтыр юлга чыгасы булдылар. Белмим ни өчендер, Мактый бабай белән аерылышып калу бик читен булды миңа. Мөбаракша абый үз туганыбыз, бик әйбәт кеше, аның тугыз баласы янында без тагын өч бала — үзенекеләр шикелле үк тигез булып яшәгән чакларыбыз булды, бер авыр сүз ишетмәдек, кырын күз күрмәдек, әмма шулай да Мактый бабай миңа тагын да газизрәк, тагын да үзрәк. Ихтимал, кече-кара яшемнән үк аның һаман күз алдында булуы, әти читтә чакларда безнең ишегалдында утын ярулары, баһадирларча олы гәүдәсе белән кизәнеп селтәнә торгач, нинди бөгәрләнеп-чукмарланып беткән чаеры төпләрен дә чәрдәкләп ташлавы, җиде төн уртасында чыккан янгын вакытында безне йомшак кына тавыш белән уятып, югары очка меңгереп куюлары, каешланып беткән олы уч төбендә чалгы пәкесен янап, бер дә авырттырмый гына чәчне кырулары, үсәрәк төшкәч, мине алашасына атландырып сугарырга җибәрүләре мәңге онтылмас булып күңелгә сеңгәндер. Әнә бит, хәзер дә онытмаган ул, атын җиккәч, яр буена, без әйбер саклап утырган җиргә саубуллашыр өчен килгән. Шамил белән икебезне бөркет канатларыдай ике кул астына кертеп, дөньяның күпме авыр эшләрен күтәргән авыр учларын җилкәбезгә салды.

— Җәгез, балалар, сау булыгыз инде,— ди ул картларчарак калын тавыш белән.— Ил-җирләрен дә онытып бетермәгез, исән-сау барып җиткәч тә бер хат язып салыгыз. Без дә хәлләрегезне белеп торыйк...

Артык бер сүз дә әйтмәде. Җылы, ягымлы учлары белән башлардан сыйпады да китеп барды.

— Сау бул, бабай, Гаптулла абыйга, Гадел җиңгигә сәләм әйт! — дип кычкырып калдык.

Күз чылануын энекәш алдында күрсәтәсе килми, капчыкларның икенче кырыена чыгып утырдым. Мактый бабай шул сыйфатлары

[1] Пырак оны — тегермән стеналарына мамыктай булып куна торган вак он, тузан.

өстенә әкияттәге батыр шикелле булып та күз алдында тора минем. Күптән түгел белдем монысын: китәр алдыннан өйләренә кереп утырган идем, сүз иярә сүз чыгып, бабайның ни өчен «Мактый» дип аталуын Гаптул абый белән Гадел җиңги көлә-көлә сөйләп бирделәр.

Безнең яктагы элекке «өстерилек»ләр усаллык белән дан тотканнар. Русча стрелок сүзенең «өстери»гә әйләнеп китүе дә юктан гына килеп чыкмаган, күрәсең. Сапа өстерилек, Шыяп өстерилекләрнең кансызлыгын авыл телендә яман әкият итеп сөйлиләр иде. Озак еллар буена Александр патша муштрасында телен дә, кешелеген дә җуйган Сапа солдат өстерилекләрнең иң әшәкесе булган. Кышкы озын төн уртасында утынга барган кешеләрне дә сагалап торып, балта-пычкысын алып кала, тәртәсен чапкалый, я булмаса атның колак төбендә генә мылтык атып җибәрә икән. Җәен булса: җиләккәме, себеркегәме барган хатын-кызның савыт-сабасын, башындагы яулыгын алып кала, кайберләрен урман төбенә таба өстери, имеш...

Көч ташып торган таза, озын гәүдәле Газизулла исемле егет атасы белән таң алдында урман төяп ятканда да өсләренә шул Сапа өстерилек килеп чыккан.

— Аха, урман каракларыǃ Давай балта, давай пычкы! — дип, мылтыгын төзәгән, имеш. Егетнең атасы кинәт куркудан балта-пычкысын аның аяк астына китереп салгач, Сапа тагын да котыра төшеп:

— Вәләй сани! — дип, чаналарын да бушаттырмакчы булган.

Моңарчы сабыр гына торган егет:

— Була ул, бушатабыз,— дигән дә, яшен тизлегендә өстерилек өстенә ташланып, тегенең ике көпшәле мылтыгын каерып та алган.— Матри, якын киләсе булма, ату «пук-пук!» үзеңне! — дип, куш көпшәне төзәп тә өлгергән.

Әле генә мыекларын ата мәчедәй тырпайтып, яман да зәһәрләнеп торган Сапа солдат шыпан-шыпан гына урман эченә таймасынмы! Ә егет белән атасы, балта-пычкыларын да югалтмыйча, чананы да бушатмыйча, мылтыкны да ташламыйча, Тулбай юлы белән сыздырта биргән. Иртәгесен үк Сапа өстерилек авылга төшеп җиткән. Староста-фәләнне дә эзләмичә, туп-туры егетнең өенә килгән. Кешегә әйтүе дә гарьлек бит: авылның шундый бер мескен бүрекле «чабаташ-ниге», Әләксандр патша кулында ничәмә еллар служкбыда булган, ничәмә сугышлар пурыхын йоткан гаярь солдатның, атчайнилеге белән тирә-якка дан тоткан Сапа өстерилекнең корулы мылтыгын тартып алсын, имешǃ Моны нәчәлстуа белсә, алла сакласын, «смисте далой!» диячәк бит. Менә шуңа күрә дә бу урман бүресе егетнең өенә килеп керүгә үк бүреген салып, солдат җирендә озак йөрүдән яртылаш оныт-тып бетергән татарчасы белән аны юмалый башлаган:

— Маладес, маладес! — ди икән башын чайкап.— Син шипке храбрый йөрәкле икән, никак курыкмый син, даже миннән дә! Мактый мин сине, мактый! Давай, брат, на мировай: мылтык минеке, патша урманы синеке. Мин сине күрми, син мине белми, кисә бир!

Идән уртасына нараттай баскан егет әйтә моңар:

— Ашыкма, — ди,— смирны бас, аннары әйт: әби-бабаңа, ата-анаңа, җиде буын балаңа урман юлы ачык булыр, зыян салсам, кулым корыр! — диген.

Теге кабатларга мәҗбүр булган. Шуннан соң, егетнең аталары аны кунак итеп, чәй эчертеп, мылтыгын кулына тоттырып, чыгарып җибәргәннәр. Бу хәбәр бик тиз авылга таралган һәм егетнең Газизулла дигән исеме онытылган. Ул — «Мактый» булып киткән...

Әнә шул баһадир Мактый бабайдан аерылып калдык. Мин аның үз мәнсезлегем аркасында, ничә яшьтә икәнен дә белмим, болай әле бик нык сыман күренсә дә карт инде ул. Күрешүләр тагын насыйп булырмы?..

Бүрсет тамагында без озак ятмадык, иртәгесен төш турыларында пароход килде. Моннан китүче халык әллә ни күп түгел иде, безне кешечә урнаштырып йөрделәр, теге чактагы төсле хәтәр тавышлы кондукторлар да күренмәде. Пароход эчен беренче тапкыр күрүдән ис-акыллары киткән малайлар арасында мин инде «карт чыпчык» идем, машина бүлекләрен, үзем белгән почмакларны — барын да күрсәтеп йөрдем, хәтта өске палубадан да ялтын-йолтын гына әйләнеп төштек.

Пароходлар олырак пристань саен палубаларына хәтле яшел усак утыны тутыралар икән хәзер. Әле генә урманнан чыгарылган шул чи усак белән тартса да, без артык озак бармадык: дүртенче тәүлектә Пермьгә килеп төштек. Менә монда инде хәлләр катлаулана башлады: төрле яклардан килеп тыгылган халык белән Пермь вокзалы һәм аның тирә-ягы мәхшәр көнендәге шикелле иде. Әйтерсең бөтен дөнья урыныннан купкан һәм бар да Себер тарафына агыла. Ә вакытында озатырга эшелоннар, паровозлар җитми икән. Атна буена таш вокзал төбендәге эсседә, тузанда, чебен эчендә ята торгач, бала-чага арасында эч китү, кызылча, кызамык шикелле чирләр тарала башлады, ризык капчыклары да шактый бушый төште. Бары тик унынчы тәүлектә генә озын бер эшелон булып сузылган кызыл вагоннарда Пермьнән чыгып киттек. Төялгәндәге ашыгычлык арасында кем кая өлгерсә, шунда утырды. Без Вятка аръягындагы Мурт һәм Дөм-Дөм авыллары белән туры килдек. Урыныбыз әйбәт: өстәге сәкедә, кыйбла як тәрәзә буенда. Җәйге җиләс җил белән җилләп кенә барасы. Юлдашларыбыз да әйбәт кешеләр булып чыкты, бик тиз аралашып киттек. Ләкин тора-бара хәлләр авырлаша барды. Аскы сәкедәге Минһаҗ абзыйның алты яшьлек кызы төн-көн эч китү, туктаусыз косу белән изалана башлады. Бер төрле дә «тышка чыгу» җайланмасы булмагач, аның бөтен тәрәте идәнгә ага, анасы җыеп өлгерә алмый, вагонда тын алыр хәл калмый, дәвалау чарасы да юк. Берничә көннән соң Ишимгә килеп җиткәч кенә ул балада холера табып, лазаретка алып киттеләр, башка вагоннарда да мондый хәлләр булган икән. Безнең эшелонны бер тупикка кертеп, кат-кат дезинфекцияләр ясап, атна буе тоттылар. Үзебез дә шул вагоннар тирәсеннән беркая йөри алмыйбыз, җибәрмиләр. Ә ризык капчыклары буш, каяндыр ашарга табасы бар. Дөрес, кайбер станса-ларда безгә манный болгаткан шулпа белән җан башына яртышар кадак чамасы ипи биргәлиләр. Бер көнне шундый ашны алып кайтың, без малайлар ашарга гына тотынган идек, ап-ак манный ашы бик тәмле дә тоелган иде, көтмәгәндә табактан бәләкәй бер кисәк дуңгыз мае килеп чыкты, тиресендәге шитинасы да өтелеп бетмәгән. Нишләргә дип торганда, әти күреп алмасынмы!

— Ниткән нәҗес бу! — дип кычкырды ул.— Барыгыз, бар, хәзер үк чыгарып ыргытыгыз!

Җылы аш бик кызганыч булса да, чыгарып җиргә капларга, чиләген «кипәтүк» белән кат-кат кайнарлап юарга туры килде. Озаграк торылган җирләрдә һәркем ризык табу ягын карый. Монда да берничә кеше, сандыгында яткан берәр кадерле нәрсәсен кыстырып, төнлә белән якын тирәдәге бер авылга качып барды. Таң алдыннан бер яшьлек тай нәртеп, капчыкларына бодай ипие төяп кайттылар. Безнең әти дә Микулай акчасы күтәреп барган иде алар белән. «Син, князь, иске бай мәллә?» — дип, буш борганнар үзен. «Авызларын корт чаккыры!» дип, кешеләр тай суйганда сукранып йөрде ул.

Ниһаять, без тагын кузгалып киттек. Еш кына берәр тәүлеккә тук-тала-туктала бара торгач, Омски янындагы Коломзино стансасында тагын тупикка сөрделәр — эшелонга тиф кергән иде. Монда без әни кешенең Нәкыйп исемле бер яшьлек имчәк малаен җирләп калдырдык, Муртның Минһаҗ абзый да гүр иясе булды. Тагын дезинфекция, мунча кертүләр, бет көйдерүләр китте. Безнең вагоннан тагын бер җиңги

юкка чыкты. Ул бер бәләкәй стансада поезд туктау белән төшкән дә вагон астына кереп үз йомышына утырган. Шундук поезд кузгалып китә башлагач, ашык-пошык чыгарга маташканда, уң аягын сыйрагыннан вагон көпчәге кисеп узган. Аны шундагы медпунктта калдырдылар. Муртның Бәдри абзый вак-төяк дүрт баласы белән ялгыз калды хәзер. Кайчан да булса бер-берен табышыр микән алар? Мондый хәлләр көн саен диярлек булып тора...

Бу михнәт юлы кырык биш тәүлеккә сузылды безнең. Арттырырга мөмкин булган кием-салыммы, башка әйберме — бар да тамакка кереп бетте. Эшелон халкының бик күпләренә өрәк төсе кергән иде инде. Бик күпләр билгесез стансалардагы больницаларда, бик күп бала-чага вокзал перроннарына чәчелеп калды. Бишенче августта гына Анжерка шахталарына килеп туктадык. Эшелонның бер өлеше тагын да еракка, Өркет тирәсендәге Черемхово шахталарына китеп барды. Монда калганнар унбиш көн карантин узганнан соң эшкә урнаша башлады. Юлдашларыбыз Анжерка, Судженкадагы төрле шахталарга таралды. Авылдашларның күпчелеге белән бергә безнең әтиләр дә Андреевский дигән яңа рудникка җибәрелде. Унсигез тулмаган үсмерләрне шахтага төшермиләр икән, мина Анжеркадагы хозотделда кара эшче булып калырга туры килде. Бер көнне кокс төйибез, икенче көнне электр стансасында шлак түгәбез, өченче көнне тимер юлда ком таратабыз. Шундый «шәп» эшләр табылып кына тора. Озакламый спецовка да бирделәр: соры парусин күлмәк белән шундый ук чалбар киеп җибәрдем. Аякта — бродни. Күн кунычлы, йомшак олтанлы бик җиңел бер әйбер ул. Шулай оек-чабатаны ташлап, алача ыштанны каплап дигәндәй, мондагыча йөрим хәзер. Баштагы киез эшләпә генә калды. Яшәр урын да бар: Мехәмәтгале җизни мондагы җиденче шахтага керешеп калган иде, алар шул ук шахтада күптән эшләүче Зәйнулла забойщикның бәләкәй генә бер алачыктай өенә фатир керделәр, мин дә аларда тора башладым. Гөлфаниттәйнең биш баласы бар, дүртесе кыз, төпчеге малай. Алар берсе дә эшкә ярарлык түгел — ваклар. Җизни — аңгы-миңгерәк бер юаш кеше. Русча сыңар авыз сүз дә белми. Ул үзе сәүдәгәр Гатаулла малае, тук тормышта үсеп, дөньяның әчесен-төчесен татымаган, аны күрше авылның әнә шул уңган һәм акыллы кызы Гөлфанигә өйләндергәннәр, бай йортыннан башка чыгарганнар. Үзенә тигән бер иманасы өстенә атасы аңа әвен корып биргән. Җизни кеше авылда әнә шул әвен кую белән моңарчы бала-чагасын туйдырып килә иде. Ачлык җилләре аларны да кубарып, монда китерде. Шахта эшен ул авыр кичерә, сменадан кайткач ыңгырашу-сызланулар бик күп була. Алты сәгать эшләп чыкса, унике сәгать йокы кирәк аңа.

Забойда эшләүчегә пот та ун кадак он бирелә, гаилә әгъзаларына да ун-унбиш кадак чыга. Җиде тамакны туйдырыр өчен бу, әлбәттә, җитми. Тормышның бөтен авырлыгы, кайдан бер умачлык он табу кайгысы, бала-чага хәстәре бары да шул хатын өстенә төшә. Җитмәсә, ул балаларның өчесе шулай ук аталарына охшап туган, акылга зәгыйфь булып үсәләр. Әмма Гөлфаниттәй аларның берсен дә араламый, тигез карый, тигез ярата. Шулар өстенә ул бер тиен түләүсез мине дә тәрбияли, өс-башымны юа, алып кайткан егерме биш кадак онымнан ипи пешерә, ярма-токмач бирелгән чакларда аш пешереп ашата. Үз балаларыннан яхшырак карый ул мине. Бу әйбәтлегенә шаккатарсың аның. Мин бит аңа сеңелесенең үги малае гына. Шул яхшылыгы белән ул миңа үз анам шикелле кадерле хәзер.

Без килеп озак та тормастан, кура җиләге пешеп җитте, урманга йөри башладык. Анжерка тирәсендәге янынкта котырып куралык үскән, аның җиләген җыеп бетерә торган түгел иде ул елны. Мин эштән кайтуга Гөлфаниттәй белән кызларын ияртеп урманга китәбез. Ике сәгать эчендә зур-зур ике кәрзин җиләк җыела. Без аны, күрше-тирәдәге

электән торучы хәллерәк өйләргә йөртеп, онга-ипигә, бәрәңгегә алмашабыз, аш янына куш була. Үзебез дә туйганчы ашыйбыз, киптерәбез, как коябыз, шикәр бирелгән чакларда хәтта вареные кайнаткан булабыз. Җиләк бетүгә искиткеч күп булып шомырт та өлгерде. Агач төбенә килеп ботакларын иясең дә яфрак яшеллеген күмәрдәй чем-кара булып сыгылган эре-эре шомыртлы тәлгәшләрне кәрзингә кул белән сыдырып кына төшерәсең. Шомырт шул хәтле өлгерән — кул тиюгә чөменнән кубып, изелми-сытылмый үзеннән-үзе коела башый. Урманнан кайтканда авызлар кап-кара була. Шомырт безгә бигрәк тә ярап куйды: бер котелогына бер котелок он бирә маржа түтәйләр. Алар шомырт оныннан пешергән пирожкины бик яраталар икән. Гөлфаниттәй дә пешергәли башлады аны: шикәре дә күбрәк булса, телеңне йотарсың! Үзе бик туклыклы була икән тагы. Ә безгә иң кирәклесе — шул ягы!..

Шулай да Себер хәтле Себергә килеп тә ачлыктан качып булмады бугай. Ул безнең ишек төбендә генә сагалап тора. Умач белән көлчәдән узып булмый.

## Уңмады кәсепләр

Көзен Нукай (авылдагы кушаматы) җизни белән минә тиф бәреп екты. Икебезне бер арбада Судженка больницысына алып киттеләр. Шайтан алгыры, михнәт юлларын кечкәндә эләкмәгәнне, монда килеп урнашкач чирләп ят, имеш! Дөрес, мин озак юанмадым, яшьлек алдыргандыр инде, унбиш көн эчендә терелеп тә чыктым, ә җизни кеше өч айсыз котыла алмады. Гөлфаниттәйнең кече малае белән кече кызы да эч китүдән җәфаланды. Өйдәге тормыш бик тә начарланып китте. Юк, минеке түгел, минем хәл, киресенчә, элеккедән уңайлырак иде хәзер. Терелеп эшкә йөри башлагач, көннәрдән бер көнне мине «материальный отдел» дигән конторга рассыльный итеп җибәрделәр. Төрле урыннарга пакет ташый башладым. Дәрәҗә күтәрелде, мине хәзер «Старший куда пошлют»[1] дип атыйлар. Кыш кергәч, өс-баш та үзгәреп китте: аякта көрән киез итек, сырма чалбар, ~~өсте~~ кыска кайры тун, олылар өчен тегелгән булса да, җиңнәрен кайтарып, билне каеш белән буып куйгач, тап-таман гына. Башта да кәҗүнни колакчын бүрек. Хәер, барысы да кәҗүнни — эш киеме итеп контордан бирделәр.

Гөлфаниттәйгә бик авыр. Җизнинең бальничнига чыга торган оны потка да тулмый хәзер. Шул чирләләр аркасында Гөлфаниттәй кешегә кер-фәлән югалаудан да туктарга мәҗбүр булды, бәрәңге-чөгендер-торма казу, кәбестә кисү шикелле эшләргә дә чыга алмады, шулай итеп, ай ахырларында умачка да туймый башладылар. Чирдән арынып килүче балаларга да рәтлерәк ашатырга, җизни кешегә дә өстәмә илтергә кирәк. Ә тифтән терелә башлагач, үзем беләм, шул хәтле ашыйсы килә, күршең коры ипи генә чәйнәгәндә дә авызыңнан сулар килә. Тик каян алсын соң Гөлфаниттәй? Алмашырдай әйберләре дә калмаган, кайчангыдыр зур яшел кияү сандыгының эче дә шып-шыр. Нәчә генә ачып, ничә генә актарса да, ертылып беткән иске күлмәк, иске чүпрәктән башка бер нәрсә дә килеп чыкмый аннан. Шулай да ул зарланмый, эчтән тынарга тырыша. Миңа бик уңайсыз: ничек булышырга белми аптырап йөрим. «Ылан, бер умачлык кына онына керик әле...» дигән чакларында җаннар тетрәп китә. Талонга килгән ярма-токмач ише әйберне дә биргәләгән булам, тик андый вак-төяк белән генә берни дә үзгәртеп булмавы көн күк ачык.

[1] «Старший куда пошлют» — «кая җибәрсәләр, шунда чабучы башлык» дигән мәгънәдә көлеп әйтелә торган сүз.

Шул чакта гаепле бер эш эшләп ташладым. Нәкъ ай ахыры иде, яңа эшли башлаган җиремә берәнче тапкыр азык-төлек карточкасына баргач, «әни белән энем бар» дип, курка-курка гына өстәмә ике карточка яздырдым. Ышандылар, бирделәр. Иртәгесен кибеттән, шулай ук курка-курка гына, үземә егерме биш, «әнигә» унбиш, «энекәш»кә ун — барлыгы илле кадак он, тагын әллә нихәтле токмач-ярма, бәрәңге күтәреп кайттым. Юл буе як-ягыма карандым: менә-менә килеп тотарлар шикелле тоела. Ә инде өй ишегеннән исән-сау узгач, бер дә галәмәт юмарт кешеләрчә:

— Гөлфаниттәй, менә бу онның утыз кадагы сезнеке! — дип кычкырдым.— Ярмалары да сезнеке!

Ә кем кесәсеннән юмартландым?..

Хәзер дә аңлый алмыйм: яхшылыкмы бу, әшәкелекме? Күз алдындагы мохтаҗларга булышыйм дип, кемнедер икенче берәүне өлешсез калдыру дөресме? Юк, дөреслек минем якта түгел иде бугай... Дәүләт исәбенә яхшы атлы булучылар барыбер казна каракларыдыр инде ул...

Ярый әле, бу хәл озакка сузылмады, егерме икенче елның февраль айларында базарлар ачылып китте. Авыл кешеләре Анжеркага ит-май, бәрәңге, иген-тару китерә башлады. Талонга шактый шикәр, тозлы чуртан, тәмәке, шырпы бирелә, азмы-күпме мануфактура да чыккалый, шуныңише нәрсәләрне онга алмаштырга мөмкин, акчаң күп булса, сатып алырга да була. Бу инде безнең хәлне берхәтле җиңеләйтеп куйды...

Ял көннәремнең берендә этиләргә бардым. Себергә килгәннән бирле аларда булган юк иде әле. Әни кеше кунак итеп чәй эчертте, аннары мине котырта башлады:

— Сабын җук бит, күзгә кырып салырлык та җук, бөтен рутник катыннары интегә,— дип тотынды ул.— Ә Тумскидә тулып ята ди. Кеше дигәнең тик тормый, шуннан җук кына хакка алып кайта да монда әллә нихәтле он каера икән! Ә без монда төче көлчә кимерәбез...

Китте бу, китте тезеп. Юкка мин йөрим икән малайлыкта чабып, бушка гомер уздырып, чабата туздырып. Шул Томскидан сабын алып кайтып онга сата башласам, күр дә тор, бөтен дөньялар ал да гөл булачак икән, үзебезнең дә тамак туячак, рудник хатыннары да сабынга рәхәтләнәчәк, һәм тагын әллә ниләр, әллә ниләр булачак! Һәм мин котырдым. Дөрес, үземнең «сабын мелианеры» булуыма бик ук ышанып җитә алмадым, чөнки бер тапкыр «Юныс байдан да бай булдым» бит инде мин, мәгәр бу йөрү шулай да кызыклы булыр сыман иде. Бердән, мин малай чакта ук этинең Томски дә Томски дип күпме мактап сөйләгәне бар, ә мин Себергә икенче рәт килеп тә аны һаман күргәнем юк. Икенчедән, анда берәр укуга эләгеп булмас иде микән, бу кыш тәки әрәмгә узды бит, ни мәгънәсе бар ул курьер булып йөрүнең? Өченчедән, иптәш тә бар: күршедә генә торучы Мәснәви дигән кордаш малай анасы белән шунда сабынга йөри һәм нindидер табыш та итәләр икән. Шулай итеп, җир-сулар кипкәч, әни кеше малайларының авызыннан өзеп әзерләгән бер пот онны аркага асып, киттем мин тегеләр белән Томски каласына. Анжерка стансасында кача-поса гына күмер пульманына кердек тә, капчыкларны антрацитка күмеп, бер почмакка сыенып утырдык. Капчыкчылар бер без генә түгел икән, шуңа күрә проводниклар күзенә чалынсаң, хәзер үк куалар да төшерәләр. Бик озак күмер эчендә утырганнан соң поезд кузгалып китте. Егерме җиде чакрымдагы зур гына Тайга стансасына ике сәгать килеп, шулай ук кача-поса гына вагоннардан төштек. Томскига поезд төн уртасында гына буласы, көн буе перронда «кызындык». Монда әллә нихәтле беспризорник малайлар җыелган иде. Миннән олыраклар да, бәләкәйләр дә бар, һәммәсе дә безнең яктан килгән татар, чуаш, урыс, мукшы

малайлары. Юк, алар бер дә бозык, усал түгелләр, кеше әйберсенә дә тимиләр. Вокзалда яки перронда берәр ашап утыручы күренсә, аның тирәсен сырып алалар, үзенә түгел, ипиенә карыйлар. Тик ул кешенең дә ипие бер сынык! Ә инде тәмәке тартучы тирәсеннән аның тәпчеген алмыйча китмиләр. Һәм ул бичара төпчек, унлап малай «бер генә, бер генә!» дип суыра торгач, кайсыныңдыр иренендә ябышып сүнеп кала. Байтагысының янбаштан кигән бәләкәй капчыгы бар, ләкин соранчылык билгесе түгел, «хуҗалык» капчыгы. Аның эчендә агач кашык, калай кружка, тагын ниндидер тимер-томыр кисәкләре, төрле искемоскы барлыгы күренә. Алар перронның бер башыннан бер башына чапканда, шул капчыклары шылтырап, үзенә бер оркестр тудыра.

Ерактан килүче «курьерски»лар[1] дә Тайга стансасында шактый юанып китәләр. Менә шунда инде бу егетләрнең бәйрәме булып ала. Һәр тәрәзә турында диярлек урысча, татарча, чуашча көйләү башлана. Миннән бәләкәйрәк буйлы, шактый зур алача капчыклы, тез күзләре авызын ачкан һәм каешланып беткән «күн» ыштанлы, олы соры күзле Сапешка дигән татар малаеның тавышы моңлы гына яңгырый икән:

Безнең иләр кай якта, дип,
Кыр казыннан сорадым.
Кыр казлары гаңгылташкач,
Бер утырып җыладым шул,
Бер утырып җыладым...—

дип җырлый иде ул. Бер урында бирмәсәләр, икенче вагон каршына килеп тагын дәвам итә:

Китә казлар, китә казлар,
Теләмиләр калырга.
Атам да юк, анам да юк,
Белмим кая барырга шул,
Белмим кая барырга...

«Международный» дигән вагон янында карлыккан юан тавышлы рус малае Пашка: «И никто не узна-е-ет
Где могилка моя-а»ны суза. Күршедәге тәрәзә турында Пилатка дигән бәләкәй генә, сипкелле генә чуаш малае тутыгып-яньчелеп беткән җиз подносны каралып беткән сабый бармаклары белән дөңгелдәтә. Бу беркатлы зәгыйфь кенә тавыштан ниндидер бию көе чыга шикелле. Пилатканың үзе шикелле үк чандыр, сары чәчле мукшы иптәше, ыштан кылкасын күтәрә-күтәрә, шул көйгә биеп маташкан була. «Акмаса да тама» дигәндәй, боларның «тырыш хезмәтен» күргәч, юлчылар я ак күмәч кисәге, я колбаса, я акча, я конфет сузалыйлар. Поезд кузгалып киткәч, бермәлгә малайлар да югалып тора. Алар җимерек вагоннар арасындагы үз «оя»ларына китеп, табышларны бер-берсенә күрсәтешәләр икән. Моны безгә Сапешка әйтеп бирде. Аның чын исеме кайчандыр Сафиулла булган, Кукмара тирәсендәге Мәчкәрә авылыннан килгәндә ата-анасы холерадан шушы Тайгада икесе бер көнне үлгәннәр, бер көнне күмелгәннәр. Сафи шулардан аерылып китә алмый йөри икән. «Әр көнне бер барып кайтам яннарына»,— ди ул.

Кичкә таба алар вокзал артындагы йортларга таба йөгерешә башладылар: анда «эвакопункт» дигән мәрхәмәтле урын булып, боларны көненә ике тапкыр тары өйрәсе белән сыйлый икән...

Томски поездына төнге бердә генә «куян» билеты белән утырып киттек, капчыкларны түбәнге сәке астына түргә үк яшердек тә үзебез иң өскә сәндерәләргә постык. Бөтен вагонга бер шәмле «сукыр» фонарь яна, караңгылык безне бик әйбәт саклый, тотсалар — шәфкать юк, чөнки бездәйләрне спекулянт дип атыйлар икән. Исем шәп! Таң яктыр-

---

[1] Курьерски — ул чакта шул исемдә поездлар бар иде.

ганчы вокзалга килеп төштек, бу да әйбәт узды: кайсыбыз ишектән, кайсыбыз тәрәзәдән чыгып, тотылусыз котылдык. Капчыклар күтәреп, әллә ничә урамнар үтеп, базарга килеп кергәндә иртәнге алтылар булгандыр — базар мыж кайный иде инде. Әйтерсең элекке заман базары. Ончылар рәтендә озак юанмадык: кулга ничәдер миллион «совзнак» тоттырып, «товар»ны алып та киттеләр. Сабынчылар рәтендә сайлана башладык. Сабын заводтан чыкмаган, һичбер клэймә-фәләне юк, аны шушы сатучылар үзләре кайната, имеш. Яртышар аршинлы борысларны такта өсләренә тезеп куйганнар, җаның ниндиен тели. Мәснәвинең анасы ниндиен алса, мин дә шундыйны алырга тырыштым. Сабынны хатын-кыздан оста кем белсен? Он акчасына тигән ничәдер борысны капчыкка төреп, сүс белән бәйләдек тә кире вокзалга юнәлдек. Беркая йөреп, бернәрсә күреп булмады. Ярар, икенче килүдә мин үз сукмагымны табармын әле. Шундый ук мең мәшәкать белән, кергә-пычракка батып кайтып кердек.

Менә без хәзер элекке «вак товар бае»ннан «сабын бае»на әйләндек. Иөрим рудник буйлап, сабын тутырган кәрзин күтәреп. Бер дә алай бик ябырылып төшмиләр. Он һәркемнең үзенә такы-токы. Ә сабын дигәнең, юньсез, көннән-көн кибә бара. Өстенә су бөркеп, идән астына куеп саклаган да булам, юк, барыбер кипшенә. Иртә беләнгә өстен балык тәңкәсе төсле елтыравык тоз каплаган була. Аны кырып ташламасаң, сабының әйләнеп тә карауччы булмый. Атна-ун көн дигәндә көчкә иллә-алла сатып бетереп, утыз биш кадак он җыйдым. Ай-яй, зур табыш! «Алтыга ал, бишкә сат, атың булсын сәүдәгәр»...

Карточкаларга килгән ул бер пот онны балалар авызыннан өзеп биргән иде бит әни кеше. Шулай да ул, дулый-дулый булса да, тагын биш кадак өстәп, тагын җибәрде мине. Тагын киттек Мәснәвиләр белән. Тагын шулай таң алдында Томскига барып җиттек. Вокзалга туктавыбыз гына булды, «облава!» дигән куркыныч сүз таралды. Вагондагы капчыкчылар ду-кубып әрле-бирле чапкынлый башлады. Кайсыларыдыр арт кырыйдагы тәрәзә рамнарын төшереп, шуннан ике юл арасына сикерергә тотынды. Мин дә, капчыкны аркага киеп, берсе артыннан сыдырылып түбәнгә төштем. Төшүем генә булды, эләктерел тә алдылар. Мылтыклы, хәрби киемле юл сакчылары: «А, паразиты, попались!» — дип, әйдәп тә киттеләр безне. Кая алып баруларын уйлап та өлгермәдем, төрмә ишегалдына китереп тә керттеләр һәм камераларга тутыра да башладылар. Белмим нилектәндер, мине беренче каттагы бәләкәй генә камерага берүземне тыктылар. Авыр чуен биклә-вечләр «шалт-шолт!» итеп кенә калды. Башка суккандай миңгерәп торганнан соң капчыкны салып, таш идәннең бер почмагына куйдым да өстенә утырып елый башладым. Яшьне туктата торган түгел: әйтерсең маңгай астыннан чишмә бәреп чыга. Куркып елыйм, гарьләнеп-хурланып елыйм. «И ходаем, яшь кенә башларыңнан төрмәләргә килеп кер инде. Ристан булуларым шушы микәнни?.. Суд ясап, әллә ничә елларга олактырсалар, нишләрсең!» дип, тагын да мөлдерәбрәк китәм. Ике-өч сәгать узгандыр, берәү-бер килүче, сораучы юк. Агасы яшь агып бетте бугай, күз төпләре әчетеп кипшенә башлады, үзем дә тынычлана төштем шикелле. Хәтта:

Ничә еллар бу бинада ялгыз утыра башым
Бер савыт су, бер телем икмәк ирер бәнем ашым,—

дигән бер җыр да искә төште. Мин аны кайчандыр «Тәфтиләү» көенә үземчә бик шәп итеп җырлый да идем. Үземне озак еллар төрмәдә ялгыз утыручы, тәрәзәгә карап шул җырны җырлаучы итеп күз алдыма китердем. Һәм... көлеп җибәрдем. Ишектә тимер челтәрле бәләкәй генә тәрәзә бар, шунда карыйм, кемдер килеп шуннан кычкыруын көтәм. «Судсыз гына балалар йортына җибәрсеннәр иде, рәхәтләнеп укып ятар идем...» дип телим ходайдан.

Көндезге уникеләрдә тәрәзә түгел, ишек үзе ачылды, аннан кергән кеше документ сорады. Педкурслардан алган белешмәне бумажник төбендә йөртә идем, шуны күрсәттем. Файдасы тиде бугай: каталажкадан чыгардылар. «Бүтән болай йөрмә!» дип, каты кисәтү дә ясадылар, әмма детдом дигән сүз авызларыннан чыкмады. Мин тагын капчыкны асып, базарга юнәлдем. Үзем табып, кая да булса урнашу юлларын эзләргә тагын йөрәк җитмәде. Шул каһәр тигән сабыннарны төяп, Мәснәүләрне дә тапмыйча, тагын кайтып киттем. Өйдәгеләргә барын да сөйләп бирдем, бүтән йөрисем килмәвен аңлатырга да тырыштым. Шулай да, алып кайткан сабынны күтәреп, рудникны тагын күпмедер тапкыр әйләнергә туры килде әле. Сабын сатуның бу юлы да рәте чыкмады, җыйган он утыз кадакка төште. Әни кешенең дә дәрте сүрелде бугай, мине артык кыстамады...

Ул арада хатын-кыз, яшүсмер якын-тирә авылларга эшкә тарала башлады. Әни кеше моны шундук абайлап алды. Гөлфаниттәй белән мине ияртте дә, өчәүләп уракка чыгып киттек. Бу тирәдә генә эш табылмас дип ерактагы Итат стансасына хәтле «куян» булып барсак та, урак өсте әле җитмәгән булып чыкты. Әниләр кайтып китте. Ә мин бер хәлле генә кешедә тамак хакына печән чабарга калдым. Ипие бодайныкы булса да, ашы яшел суган тураган квас похлебкасы гына булгач, кысыр басудагы каты печәнне аюдай таза «чалдон» агайлар белән берәттән чабып бару «кәҗә майлары»ның чыгара икән. Атнадан артыкка чыдап булмады. Юлга бер ипи белән өч-дүрт кыяр бирделәр, атналык эш хакы шул булды.

Мин кайтканда арышлар өлгереп килә иде инде. Берничә көннән кабат чыгып, Ижморка районындагы бер авылда уракка ялландык. Хуҗабыз бай кеше түгел, гадәти генә йорт-җирле, ике генә атлы яшь бер крестьян. Хатынының, берсе бишектә, берсе итәктә дигәндәй, өч-дүрт баласы бар, шуңа күрә генә кеше ялларга мәҗбүр икән. Үзләре әйбәт кешеләр, тамак ягын кысмыйлар, дисәтинә башын да унике пот онга килештек. Ә дисәтинәләр Себердә иңгә дә, буйга да йөзле икән, урак белән кырка-кырка башына барып чыкканчы күзләрең күгәрә, билләрең таш булып ката, кулга кан төшә. Шулай да кышлык икмәк эшләп каласы килә. Гөлфаниттәйгә генә читен, ялгызы гына булгач, аңа инде бермә-бер ким тиячәк, ә өендә биш бала!

Ике атнадан артык казганып, аркаларга икешәр пот он асып, кайтыр юлга чыктык. Кубрәген дә күтәреп булыр иде, тик вагон баскычларында, буфер өсләрендә шыкыеп йөрүче «куяннарга» кинәт кенә сикереп төшәргә, вагон асларыннан кача-поса чыгып, икенче бер тамбурга йөгерергә туры килә. Бу юлы без Владивостоктан Мәскәүгә йөрүче «скорый»ның «международный» вагонындагы киң баскычларга эләгеп, исән-аман гына кайтып җиттек. Калган оннарны, кабат барып, шундый ук мәшәкатьләр белән ташырга туры килде.

## «Миндә бар, синдә юк»...

Ул елны әрбет чикләвеге бик шәп булды. Август ахырларында рудникның төп халкы ат-тун белән барып, куна-төнә тайгада ятты, капчык-капчык чикләвек ташыды. Чүлмәкчедән күрмәкче дигәндәй, без дә киттек Шамил энекәш белән тәпи-тәпи генә. «Пихтач» разъездыннан нихәтле эчкә керсәк тә, башкалар коеп киткән җирләрдән уза алмадык. Без соң әле кедр суккан малайлармы? Шулай да үзебезчә маташкан булабыз: махсус ясалган тимер тырнакларны аякларга беркетеп, зифа буйлы әрбет агачының таҗына хәтле менәм дә ботак очларында калган «күркә»ләрне таяк белән бәреп төшерәм. Шамил аларны куе үлән арасыннан җыеп капчыкка тутыра. Ләкин ул түзми, икенче бер агач

табып, ялан тәпиләрен сагызлый да әскә менеп китә, үзе коя, янәсе — егетлек күрсәтә! Ә үлән арасына, төп куышларына поскан борындыклар шуны гына көтеп торалар икән: без төшкәнче әллә нихәтле «күркә»не кимереп эштән чыгаралар, куышларына ташып бетерәләр. Йөри торгач, өч тәүлек узды. Зур итеп учак ягып, тайга төбендә кунган төннәр, аркаларны утта җылытсак, күкрәк туңган, аяк туңган чаклар, шылт иткән тавыш ишетелгән саен янывызга таяк таянган «аю хәзрәт» килеп чыгуын көтеп яткан шомлы һәм татлы минутлар истә калды. Икебезгә ярты капчык чиста чикләвек алып кайттык, бу инде коры йөреп буш кайткан эше түгел, картлардан да оят булмас, өйдәге малайларга да «эш» табылачак.

Озак та үтмәде, тагын тиф белән егылдым. Бусы «возвратный» дигәне икән. Тамырга кан җибәреп, унбиш көндә терелтеп чыгардылар. Кан бирүче кыз — шундагы Рита исемле санитарка иде. Терелә башлагач, ул миңа елмаеп йөрүчән булып китте. Урта бармакта илдән үк киеп килгән бик шәп «тульски» балдак бар иде. Ялтыратып җибәрсәң, гел чын көмеш төсле булып китә иде ул, шуңа күзе төште. Терелеп чыккан чакта ул шәп балдакны шул сөйкемле кызга истәлек итеп биреп калдырырга туры килде...

Себернең иртә көзе тиз узып, беренче кар җиргә ятканда мин инде тәмам савыгып җиткән идем, каядыр эшкә урнашырга кирәк иде. Сәер безнең бу әни кеше. Һич аңламассың, каян гына уйлап таба: бер карасаң, мине Юныс байдан бай итә, икенче карасаң, укудан туктатып йорт ялчысы итә, өченче карасаң, «сабынчы» итә, ә хәзер нәрсә ди?

— Әнә, кеше юк бит безнең Әндриескидә, бала-чага укытырга керсең, гыйлеме тулып аркылган ич,— ди.

Шаклар да каттым, кеше әйткәнме, үзе уйлап тапканмы ул моны? Ә минем башыма да килгән нәрсә түгел! Әти дә аны куәтли тагы:

— Барып сөйләш, булдыра алырга тиеш син хәзер,— ди.

Мин, ахры, кеше сүзенә бик тиз бирелә торган малай бугай — шундук бу эш мине кызыктырып та куйды. Чынлап та булдырып булыр микән? Эх, шәп тә булыр иде соң! Юк, барып чыкмас. Рудникта утызкырык бала бардыр, алар ничә класска бүленәчәк, ничә төрле холыкфигыль бар аларда. Малай гына башыңнан тыеп кара син ул ташбашларны! Ике көн уйланып йөрдем. Үземнең әйбәт укытучыларым күз алдыннан кичте. Бер уйлаганда Хөсәен Абушаев булдым, икенче уйлаганда Хөсәен Габитов булдым, өченчесендә Фарукъ абзый булып карадым. Шулар шикелле укыта алсам, эшләр барып чыгар төсле күренә. Тик менә минем тәртә кыскарак: тыңлаусыз малайларны чәпәп ташламам микән? Гыйлемне «куллап бирү» заманнары узды бит хәзер. Ә өйдәгеләр һаман котырта: «Бар да бар! имеш, ычкындырма урынны, калырсың авыз ачып». Иң элек файданы күздә тота торган әни кеше «жалунҗәсе» белән дә кызыксынмый. Тамакка җитәрлекме — белгән кеше юк.

«Хөсне хат» дәресендәгедәй бик тырышып, пөхтәләп гариза яздым да Судженкага киттем, анда хәзер район үзәге. Мәгариф бүлеген табып, «нацмен» [1] инспекторы бүлмәсенә кердем. Керүгә ис-акылларым китте, күргән күзләремә ышанмагандай, бир мизгелгә тукталып калдым: китаплар, плакат-карталар шикелле әсбаплар өелгән олы бер өстәл артында миңа бик таныш кеше утыра!

— Гайнеттин абый, сезме бу? — дип йөгереп килдем дә ике кулымны аңа суздым. Ул да кинәт калкынып:

— Тукта, тукта... Шәйхелислам, син түгелме соң? — дип, мине кочаклап алды. Өстәл аркылы килеп чыкты бу эш. Шулай да һәйбәт минут иде бу. Мин дә, туган абыемны күргәндәй, аңа сыенып калдым.

---

[1] Нацмен — азчылык милләтләр.

Әйе, моннан җиде ел чамасы элек шушы Судженкада бер баракта яткан һәм төннәрнең берендә юкка чыккан Гайнеттин абый иде бу.

— Кара әле, брат, син полный егет булып житкәнсең хәзер! — дип гаҗәпләнде ул.— Әле кайчан гына ялан тәпиле ярканат идең бит!..

Ә мин аның элекке матур чәчләре чал белән чуарлануына, сөйкемле генә сирәк шадра сибелгән маңгаена шактый тирән сызыклар ятып, сизелерлек олыгая төшүенә гаҗәпләндем. Тагын да бигрәк, аның монда, Судженкада, булуы гаҗәп иде. Ә мин шушы ук тирәдә инде бер ел торып, аның хакында кешедән дә ишетмәгән идем, үзем дә күрә алмадым. Беренче сүзем шул хакта булды.

— Гаҗәп түгел, дустым,— диде ул.— Дальний Востокта актык сугышлар беткәнче тоткарланырга, аннары госпитальдә кабыргаларны ремонтлатырга туры килде. Мин әле монда яңа кеше...

Шунда гына күзем төшеп, тагын бер шаккатып калдым: аның яшел постау «френчеге» түшендә... әллә ялгыш күрәм инде... юк, чын үзе бугай... Минем әле аны чын тере кеше түшендә күргәнем дә юк... шул микән соң?.. Һәм мин кыюлыкны җыйдым да:

— Гайнеттин абый, бу... ни... чын үземе? — дип, бармак белән төртеп сорадым.

— Үзе инде...— дип көлемсерәде ул, башын селкә-селкә, бәләкәй малайларга аңлатканчарак итеп.

Кинәт Гайнеттин абый миңа бик югары булып, бик зур кеше булып күренә башлады. Ник дисәң, аның түшендәге кызыл лента өстендә: сугышта зур батырлык күрсәткән кешеләргә генә бирелә торган Кызыл Байрак орденының чын үзе беркетелгән иде. Сокланудан нишләргә белмичә, күзләрне һаман шуннан ала алмыйм. Хәтта үземнең ни йомыш белән килгәнне дә онытып, әдәп саклауны да истән чыгарып, сорашырга тотындым. Бер сөйләшә башлагач, барына да кагылырга туры килде. Теге вакытта үзен тотарга киләселәрен алдан сизеп, Красноярга качкан икән ул. Мәгәр аннан барыбер озакламый тотып алганнар аны. Революцияне «Иркутский централь»дә каршылаган. Чыгарылгач, Черемхово шахтерлары арасында эшләп, Колчак кузгалуга, тагын «идән астына» кергән, аннары актык атышка хәтле Ерак Көнчыгыштагы ак генераллар белән сугышып йөргәндә ике кабыргасыз калып, госпитальдә яткан...

Боларны ул бик кыска итеп, хәтта бик коры гына сүзләр белән әйтеп узды, ордены турында бөтенләй телгә дә алмады. Малай чагымда ук яраткан кешемнең шундый соклангыч юллар узуы күңелдә горурлык тудырды һәм үзем дә шунда йөргәндәй рәхәт булып китте...

Хәзер инде ул сораштыра башлады. Баштан үткәннәрне сузмый гына сөйләп, әтинең Андреевка шахтасында эшләвен, шунда яшәвебезне әйтеп бирергә туры килде.

— Үзең ничек соң? — дип сорады ул аннары.— Эшлисеңме, укыйсыңмы дигәндәй?..

Шунда гына үз йомышым искә төште. Ык-мык итебрәк тордым да, кесәмдәге гаризаны чыгарып, аңа суздым.

— Монда килүем менә шуның өчен иде...— дип өстәдем.

Кәгазьгә күз йөгертеп чыкты да гаҗәпсенебрәк миңа карады: «Айһай, бик югары үрелмисеңме соң?» — дигәндәйрәк иде бу караш. Белем яклары белән кызыксынды. Икенче баскычта алты класс бетерү өстенә педкурсларда укуымны да әйтеп бирдем. Теге вакытта мине коткарган белешмәне дә гаризага теркәгән идем. Ул әле миңа, әле шул кәгазьләргә карап-карап торды да:

— Практикаң бармы соң синең? — дип сорады.

Коелдым да индем: мондый сүзне беренче тапкыр ишетүем, мәгънәсе ничек икәнен дә белмим. Инде ничек җавап бирергә? Нәрсә икән ул? Шунсыз укыту мөмкин түгел микәнни? Нинди дә булса берәр доку-

менттыр инде, күрәсеңме?.. Башка тай типкәндәй, һич нәрсә шәйли алмый тик утырам. Ничек дип җавап бирергә соң? «Бар» димме, «юк» димме? «Юк» дип әйтсәң, алмаячак инде ул. Ә бу эшкә мин күңелне тәмам беркетеп җиткергән идем инде, бик әйбәт булыр төсле күренә иде. «Бар» дияр идем, «Күрсәт, алайса», дип сорый калса, нишләрмен? Каян чыгарып күрсәтим мин аңа ул практика дигән нәрсәне? Ялганың тотылгач, синә кем ышансын аннары? Ни диярга белми икеләнеп, бурлаттай кызарып, башны түбән ук иеп, шактый утырганнан соң: «Әзрәк бар инде ул», дип пышылдадым. Күзләргә карап ялганны тотмагае дип куркам үзем.

Гайнеттин абый үзе дә минем хәлне аңлап алды бугай, яңа сораулар белән артыгын төпченмәде. Укытучылар җитмәвен әйтеп, тырышып эшләргә кушып, гаризама резолюция салды. Аны күрше бүлмәдә рәсмиләштергәч, бер атнадан балалар исемлеген төзеп, ничә класска бүленәчәкләрен билгеләп, күпме дәреслек һәм башка әсбап кирәк буласын чамалап, җигүле ат белән яңадан килергә кушты.

Баш күктә! Биш атлыйсын бер атлап дигәндәй, өйгә кайтып барам. Мин — укытучы! Әйтерсең йөз ел теләгән теләгемә ирешкәнмен! Ә ничек укытырмын икән? Ул хакта әле уйлап бетерә алмыйм. Анысы әле ерактагы яшен шикелле генә тоела — куркыныч түгел.

Шулай да теге нәләт сүз һаман баш миен кыргычлап тора. Беренче очраган кешедән сорамый түзмәдем.

— Практикамы? — диде шитина мыеклы бабай.— Практика — кыш көне бәкедә коену!

— Ә-әй! — дип кул селтәдем дә китеп бардым. Уйламый авыз ачсаң, әллә ниләр ишетерсең...

— Дөресе шул! — дип кычкырып калды карт.— Менә үзең коенып кара!..

Кайткач этидән сорадым.

— Прахтикәме?..— диде ул уйлангандай итеп. Аннары күзләрен шаян җемелдәтеп кенә әйтә куйды: — Миндә бар, синдә юк!.

Менә әкәмәт, ул да табышмак уйный бит!

— Нәрсә, әллә тегендә сорадылармы? — дип куйды әти бераздан. Мин әйткәч, аңлатып бирде:

— «Укытып караганың бармы?» дип сораган синнән Гайнеттин абыең,— диде.— Син соң, күпме укып йөреп, шул сүзне дә белмисеңмени?..

Үтерде дә салды! Юк шул, үземне бик белдеклегә санап йөрсәм дә, (хәер, анысы инде аның бик ансат!) шул гади генә сүзне дә белмим икән!..

Әйтелгән көндә ат белән барып, дөнья хәтле китап-дәфтәр, карандаш-каләм, кара савытлары һәм башка кирәк-яраклар төяп кайттым. Китаплар барысы да яңа, быел гына Казанда басылып чыкканнар. Алардан буяу исе белән бергә туган як исе дә килгән шикелле. Дәреслекләрдән тыш Г. Тукай, Ф. Бурнаш шигырьләре, Г. Камал пьесалары һәм Г. Ибраһимовның аерым-аерым китап итеп чыгарылган әсәрләре бар иде. Баштан арык мәктәп һәм китаплар эченә чумдым. Өйгә бары тик ашарга һәм кунарга гына кайтам. Балалар «нуль» класстан алып дүртенчегә хәтле. Шуларны утыртырга ике бүлмә бар. Иртән «нуль»ләр белән беренче, икенчеләр укый. Әлеге «практика» дигән нәрсә шунда кирәк икән инде. Бер бүлмәдән икенчесенә чаба-чаба шактый әлсерисең, методик кулланма юк. Күбесенчә, Хөсәен Абушаевны искә төшерәм, аның бер бүлмәдә дүрт классны ничек укытканын күз алдыма китерергә тырышам. Төштән соң «өч», «дүрт»ләр укый. Алар белән җиңелрәк һәм авыррак та: күбрәк шаярырга яраталар, аның каравы, хәреф таныту белән чиләнәсе юк. Иң соңгы дәрес — физкультура. Белмим, кайда өйрәнгәнмендер, үзем белгәнчә тырыштырган булам, һәм

ул «димнастика» уйнауны балалар бик ярата. Ниһаять, класста берүзем калып, төн уртасына хәтле дигәндәй китап, дәфтәр белән утырам. Баштарак дәреслекләрне ятлый-ятлый диярлек укып чыгарга туры килде. Аннары матур әдәбиятка тотындым. Галимҗан Ибраһимовның дистәләп хикәясен беренче тапкыр шушында укып, таң калдым, аның канатлы сүзләрен кабатлап йөри башладым. Кемнәндер аның «Безнең көннәр» дигән романы барлыгын ишеттем. Эзли торгач, унбиш чакрымдагы Судженка китапханәсеннән аны да табып алдым. Бит почмаклары ашалып, төпләре кат-кат ябыштырылып беткән бер китап иде ул. Бу романны укып чыккач, аны язган кешегә бөтенләй гашыйк булдым. Ул үзе дә шул зур көрәшләр эчендә йөргән батыр булып күңел түремә кереп утырды. Аңа багышлап шигырь яздым.

Шигырь дигәннән, шушы мәктәптә көн-төн ятканда, яз башлары белән күңелдә тагын шигырь туа башлады. Ул өч елга якын каядыр югалып торган иде. Унбиш яшьтә шигырь язып маташуны Фарукъ абзый «котыртуы» аркасында бала чакның очраклы бер очынуы гына булгандыр дип уйлый башлаган идем инде, ялгышканмын икән. Унсигез яшьлек егет язгы ашкынулар канатында хыялланып йөргәндә, ул ниндидер сайрар кошчык сыман һәр хисемне, уйларымны көйләргә керешә, дөнья үзем дә аңлап бетермәгән яңа төсләре белән күренә башлады. Мәктәптә эшли башлау, гомумән, минем вакланып-керләнеп бара торган күңелгә яңа сафлык өрде, кайчандыр Шәмәк мәктәбендә уянган олы теләкләрне тергезеп җибәрде. Бөтен искедән, чорнап алган вак тормыштан тизрәк арыну, тизрәк олы юлга таба атлау омтылышы туды.

Балаларның олыраклары белән Ф. Туйкә дигән язучының бер пәрдәлек пьесасын куйдык, рудник халкы безнең бу эшне яратып кабул итте. Билгеле, безнең әти дә, әни дә «тиятер» карый торган кешеләр түгел инде, алар килмәде. Мәгәр «тиятер» уйнап йөргән өчен сүз дә әйтмәделәр. Шуннан соң без, рудниктагы яшьләр җыелып, драмтүгәрәк оештырдык та зурлар өчен дә спектакльләр куя башладык. «Әртис» булу да кызык икән: рудник кызлары минем исемне дә белә башлады хәзер. Рольләрне иң оста уйнаучылар забойчы Закир абзый Шакиров белән Җәмил Хатипов булып чыкты. Боларда сәхнә таланты барлыгы күренеп тора. Ә Җәмил абый шуның өстенә бик оста гармунчы да иде...

Минем күптән инде комсомолга керәсе килә, иптәшләр дә кыстый. Тик чишүе ифрат кыен булган бер проблема бар: ходай проблемасы! Безнең барак каршында гына Комитет бакчасы. Кичләрен шунда чыгып ак кар өстенә ятам. Башта колакчын бүрек, өстә кыска кайры тун, аякта сырма чалбар белән киез итек: төн буе ят, туңарлык түгел. Күккә карыйм, йолдызлар белән сөйләшәм, галәм һәм яшәеш турында уйланган булам. Берсе дә җавап бирми... Китаплар, брошюра һәм журналлар укыйм. Берсе дә алла юклыгын исбат итеп күрсәтми, шулай да шактый нәрсә аңлыйм. Бөтен диннәр иң борынгы яһүд диненнән төрле тармакка аерылган икән. Барысы да кешене «кол» дип атый. Мөселман дине «алла колы» ди, христиан дине «раб божий» ди. Ә минем кол буласым килми. Бөтен ирекләрдән мәхрүм ителгән мескен бер җан иясе булып чыга кеше. Юк, мин моңа риза түгел. Бөтен ирекләрем үз кулымда булган, берәүгә дә табынып яшәми торган азат кеше буласым килә минем!..

Белмим, миңа хәтле комсомолга кергән миллион санлы яшьләр бу «проблема»ны үзләре өчен ничек хәл иткәннәрдер, мин үземчә болай уйладым. Ленин белән Маркс, дөньяның иң бөек акыллары, әдәм баласының ирекле өчен бөтен гомерләрен сарыф иткән шундый әйбәт кешеләр, әгәр чынлап та алла дигән абсолют көч булса, аны танымаслар идемени?.. Әдәм баласы аллаларны үзе уйлап чыгаруы бик табигый хәл булып калды хәзер...

Шулай итеп, яшь комсомолец булып киттем. Бу инде бала акылының үткән көннәреннән — ягъни аң богавыннан котылуның беренче сикереше иде. Шуннан соң комитет ишеге өстенә зур хәрефләр һәм төсле буяулар белән: «Бетсен дин, яшәсен фән!» дип язып куюда артык куркыныч булмады.

«Комитет» дигәнебез — рудник уртасында бер бина. Партия һәм комсомол ячейкалары, профсоюз оешмасы, русча, татарча көтепханә шул йортка урнашкан. Мәктәптә булмаган китапларны һәм татарча газитләрне шунда барып укыйм. Хәзер инде «Азад Себер» газитенә үзем дә хәбәр язгалый башладым, кайберләре басылып та чыкты, ә шигырьләрне җибәрергә куркам әле, көләрләр генә, басмаслар...

Язның сирин гөл суы йөгерткән кечке офыклары, әйтеп биргесез бер гүзәллеккә төренеп, әллә нинди серләр яшергән төсле булып күренә. Шул офыкларда янган йолдызларны барып алып, кемнеңдер алдына учлап сибәсе килә... Мине кызарта торган мондый хисләр каян туа соң әле? Җылы җилләр алып килдеме, әллә кыр казларымы? Тулбай өстеннән узган кыр казларын бала чактан бирле күпме каршылаганым, күпме тапкыр кул изәп калганым бар. Алар Себер өстеннән дә узалар икән! Һәм узганда: «Исәнме!» дип кенә түгел, «Әйдә безнең белән!», «Син көткән куанычлар безнең юлда!» дип тә кычкыралар икән. Юк, дусларым, булмый шул, беркая да китә алмыйм, минем «бала казларым» итәгемә ябышкан әле. Гаҗәп хәл, шул утыздан артык бала белән уртак тел таптым бугай, ахры. «Абый»да «абый» дигән булып, яннан китмиләр. Шукларга да ачкыч табып була, тик менә «нуль» класстагы аңы-зиһене ачылып җитмәгәннәр кыен икән. Алар бит әле, күп өйрәтә башласаң, елап та җибәрәләр. Юат аннары син аларны! Ә инде зиһен күзләре ачыла төшеп, хәрефләрдән сүз тудыра башлагач, аларның шатлыгы тау хәтле зураеп китә, сөйләп сүзләре бетмәс була, кайда язу күрсәләр, шунда хәрефкә хәреф куша-куша, ничек тә укымыйча китмиләр. Мин үзем дә нәкъ алар шикелле сабый, ахры: шуларның урамда хәрефләрдән сүз ясап маташуына куанып йөрим. Тик рудник зур түгел, язулы такталар җитми дә кала безгә...

Ул чакта мәктәпкә реформалар кертү чоры булганлыктан, язгы имтиханнар бетерелгән иде. Шулай да укулар тукталыр алдыннан безгә Гайнетдин абый килеп чыкты, дәресләрдә утырды, баланың җавап бирүләре, дәфтәрләре белән кызыксынды. «Гаебем» табылмады, хәтта:

— Ярый, ярый, болай булгач,— дип, хуплап куйгандай итте. Аннары көлде дә: — Ничек, практикаң бармы инде хәзер? — дип сорады. Мин дә көлеп җибәрдем һәм үземнең ул чакта «практика» дигән сүзне белмәвемне әйтеп бирдем.

— Сиздем мин аны,— диде ул,— коелып төшүеңнән үк күренеп тора иде.

Әйдә чәй эчтек, әти белән теге чактагы барак тормышын, уртак танышлар язмышын сөйләшеп утырдылар.

Сүзләре күбрәк Тәхфәт абый тирәсендә булды. Былтыр без аның белән бер дә көтмәгәндә генә күрешеп куйган идек. Тифтән терелеп больнистан чыккач, өйгә кайтышлый тимер юл күпере аркылы узганда, бәләкәй генә будка төбендә бер сакчы күрдем. Әллә кай төше генә мин белгән әллә кемгә генә охшаган сыман тоелды. Мин аңа карыйм, ул да миңа карый. Өс-башын хәрбиләрчә ыктымат киенеп, киң каеш белән гимнастерка билен артка бөрештереп кыскан, күн итеген көзгедәй итеп чистарткан, ә башындагы зур йолдызлы шлемын әз генә кырын салып кигән, нечкәрәк кенә бөтеркә мыек җибәргән, ә үзе мылтыгыннан чак кына калку вәүдәле, чандыр йөзле бу кеше кем икән соң? дип таный алмый аптыраган идем. Кайдадыр күргәнем бар, югыйсә,

ә хәтергә һич килми! Караша торгач, әз генә елмаешкан да булдык. Шуннан соң әйтә куйды бу:

— Әллә Шәйхылислам инде?..

Шундук тавышыннан танып алдым:

— Төхфәт абый, синме?!

Мылтыгы-ние белән кочакларга туры килде. Үзгәргән ул, бик нык үзгәргән, олыгаеп та киткән шикелле, шул ук вакытта, күзләреннән элекке моңсулык шәүләсе каядыр чигенеп, ниндидер наян, яшь чаткылар да сибелә төсле иде. Очрашуыбыз гаҗәп түгел, аның мондый киемдә булуы гаҗәп тоелды миңа. Ул бит патша сугышына да алынмаган кеше иде.

Сүз иярә сүз китте. Унҗиденче елны ук Кызыл Гвардиягә язылган икән.

— Шуннан бирле мылтыкның җилкәдән төшкәне юк әле, малай,— диде ул.— Безнең бу тирә шахтеры партизанга агылды бит. Тайга эчендә ята торгач, Колчакның койрыгын кисеп кулына тоттырдык, аннары Өркетскидә үзен дә «оҗмах»ка озаттык... Үги анада гына түгел икән, дускай, әдәм баласының бәхетсезлеге...

Менә шул Төхфәт абый хәрби хезмәттән бушангач, янадан шахтага төшкән, Гайнеттин абый аңа кыз яучылап, өйләндерешеп йөргән. Ә ул кыз Нәфисә атлы икән, ә ул Нәфисә без китәсе елны Мәгъмүрәттәйнең баласын караучы үсмер Нәфисә булып чыкты. Гыйшыклары Нәфисә уналтыга җиткәч тә башланган, имеш. Ә туйларында туксан өченче баракта чыккан бар кеше дә катнашкан. Нәфисә хәзер үз баласын карый икән. Ә Гайнеттин абый Төхфәт абыйны бик ныклап «арба-чана» китабына утыртып, наданлыгын бетерткән дә күптән түгел генә Томски партшколасына җибәргән.

— Бер ел булса да укысын,— ди Гайнеттин абый.— Төхфәт шикелле кешеләр бик кирәк безгә хәзер...

Шуннан соң Гайнеттин абыйны тиз генә күрә алмадым мин. Аның үзен дә Томски губкомына милләтләр эшенә алганнар булып чыкты.

Тормышлар шактый рәтләнеп китте хәзер, ризык карточкалары бетерелде, умачлы көннәр онытыла башлады. Базарда, магазиннарда товар дигәнең каерылып ята, ал, акчаң гына булсын! Ә инде акча дигәнең алтын белән тәэмин ителгән червонец хәзер. Чыңлап торган саф көмеш таңкәләр дә бар. Әле кичә генә мең таңкә торган бер кап шырпы бер тиенгә төште. Мин хәзер червонец белән егерме өч таңкә эш хакы алам, егермесен картларга биреп барам. Алар моңа бик шат: малай тәүфыйклы, тапканын әрәм-шәрәм итмичә, йортка кайтара, янәсе. Ә «тәүфыйклы» малайның эченә иблис кереп утырган, котырта да котырта: «Өстендә җилкәсе салынып төшкән кайры тун, ботында өч тиенлек зәңгәр тышлы сырма ватник, аягында олы шахта ботинкасы. Боларны синә курьер чакта биргәннәр иде, ә хәзер кем син? Шул кыяфәттә йөрергә тиешме укытучы? Шундый буламы үнсигез яшьлек егет? Ник алмыйлар алар синең өс-башыңа? Син биргән акчалар кая китә?..» ди. Әгъвәли, эчкә пошаман сала. Чынлап та, мин хәзер бу кылка белән йөрергә ояла башладым. Җитмәсә, көннәр һаман җылыта, тунны салыр чаклар бик тә җитеп килә. Ә картлар нигәдер бер дә ашыкмыйлар, бу хакта тавыш-тыннары да юк. Дөрес, эти үзенә эш киеме өчен шахтадан бирелгән күн итекне кечерәйтеп, олтан читләрен бик матур сырлап, өр-яңа итек тегеп куйды: миңадыр дип уйлыйм, тик өс-баш кына һаман юк. Тагын ун-унбиш көн көтеп тә булмагач, апрель получкама буй-буй кара материалдан френч белән кепка, күк тастәге сырлы драптан галифе тектереп җибәрдем, эти теккән күн итекне киеп алдым. Бу башбаштаклыкны картлар, әлбәттә, яратмады, мин тектергән нәрсәләрне яманлап, гел юкка чыгаргандай иттеләр. Әйдә, хәерле булсын, авызлыкны читкә бер чөйгәч, яңадан кабасы килми, бәйсезрәк

кылана башладым: чәчне дә кешенекечә житкереп җибәрдем, кичләрен кызлар-яшьләр белән таган атынырга, киноларга да йөргәлим.

Рудникта актык зимагур булып калган карт егет Гыйльманша абзый бар иде, шуның бер иске гармунын сатып алдым. Барак каршындагы абзар башына менәм дә печәнгә чумып гармун кычкыртам, эти моңа да сүз әйтми әле. Хәер, үзе дә кайчандыр гармунчы булган ич. Гармунны минем үз гомеремдә өченче тапкыр тотуым. Беренчесендә, Төхфәт абый гармунын урлап «уйнап» хур булган идем, һаман онытылмый. Икенчесе: Дусайда укыган елны Шакир дигән дус малай үзенең «гыж-гыж» килә торган бер искесен биреп җибәргән иде. Шуны, югары өйнең түбәсенә үк менеп, җәй буе кычкыртсам да, көй бөтенләй чыкмады, ә бичара гыжлавык, түбәдә ята торгач, тәмам таралып төште. Өченчесе менә бу печәнлек башы: уйныйм, көй дә чыгарам, тик ул агылып бармый, үзем бирергә теләгән моң салынмый көй эченә. Бары да акыл кушуы белән генә эшләнгән шикелле. Бармаклар да шома гына йөрми, телдән телгә дырык-дырык сикерә. Моны мин үземнең сулагайлыктан күрәм, сул бармаклар үзләреннән-үзләре биеп торалар. «Эх, бу гармунны сул кул белән уйный торган итеп ясасалар, сайратыр идем!» — дип куям. Астын өскә әйләндереп, сулагай кул белән уйнап карыйм. Алай бигрәк хәтәр икән: шүрәле елаган, кәҗә көлгән авазлар чыга шикелле... Юктыр, ахры, гармунчы булу хыяллары бушка гынадыр минем...

Язгы пычраклар кибәр-кипмәстә үк безнең михнәт юлы белән килгән якташларның байтагысы киредән илгә җыена башлады. Исәпләре — бәрәңге утыртырга кайтып житү. «Бәрәңге утыртсак — ач булмыйбыз», диләр. Анжерка стансасындагы кызыл вагоннар эшелоны бер атна эчендә төялеп тә бетте. Безнекеләр кузгаласы итмәде, гомергә төпләнергә бугай исәпләре. Мехәмәтгале җизни дә үзенең биш баласы белән бер вагонның аскы сәкесенә урнашты. Тик Гөлфани түтәй генә кайта алмый. Шул мокыт иренең, шул биш баласының тамагын ач итмәс өчен үзе ачлы-туклы торып, бар көченә гомер буе казганып, ашказанын тәмам рәттән чыгарган ул. Авыр хәлендә аны больниска илтеп салырга туры килде. Бөтен шахтер арасында атаклы доктор Новицкий үзе операция ясаса да, мантымады. Рәтләнеп килә дип өметләнгәндә дөнья куйды Гөлфани түтәй. Бу изге ананың, бу саф күңелле яхшы кешенең бер өем туфрагы ерак җирләрдә ялгыз калды...

Бу эшелонда күгәрчен тамагыдай күгелҗем күзле, сары сандугачтай мөлаем йөзле Мөфәрри дигән бер кыз да китеп барды... Кулымдагы бүләк яулыгын аңа җилпедем. Аның соңгы елмаюы булып язгы җилдә озак җилфердәде ул...

Күп тә узмастан, минем тормышта да кәмит кенә бер үзгәреш булып куйды. Анжер базарыннан кайтып, френч белән кепканы ишек катындагы чөйгә элдем дә чәйгә утырдым. Шахтадан кап-кара булып кайткан эти кухняда озаклап юынгач, шул ук ишек каты чөйдәге сөлгене алып сөртенә башлады. Ул сөртенеп бетүгә, мин тамак туйдырып табыннан кузгалуым булды, эти тып-тын һәм тиз генә олы яшел сандык артыннан беләк юанлыгы шомырт таяк тартып чыгарды да «шарт-шорт!» минем аркага, билгә тондыра башлады. Һичнм аңламыйча тик торам күзләрне шарадай итеп: күләргәме, еларгамы? Тагын бер-ике селтәнгәч, телгә килде бу һәм сүзләрен теш арасыннан гына чыгарып тезәргә тотынды:

— Оятсыз, ыштыр бит! Чәч житкереп, башыңа сыер дучмагы киеп, урыс булып, тәмәкегә сасып йөрисең! Камсамул булып иманыңнан ваз кичеп, кәмитет ишегенә динне мыскыллаган язу язып, әдәм актыгы мәртәт булып киттең! Җир күтәрмәс сине, яхшыдан яман туган нәрсә!..

Ни кылырга белмичә мыгырданган булам:

— Ни бит... тәмәкене... Хәйберәхман абый сорагач кына алып кайткан идем...
— Ялганнама, ахмак! — дип кычкырды эти.— Кешегә дип алгач, кабы ачык булмый аның!..— Һәм тагын кизәнә башлады.

Иман заты булмаслыгы күренеп тора. Тиз генә ишек катына килдем дә френч белән кепканы кидем. Шунда гына күрдем: түш кесә ачык калган һәм башланган папирос кабы күренеп тора икән! Башка сүз катмыйча, җәһәт кенә өйдән чыгып тайдым. Бу — актык чыгып китү булды.

Анжеркада Уфа ягыннан килгән Бәкер Альфин дигән организатор бар иде, хатынлы кеше булгач, аңа квартир биргәннәр. Аларның чоланында җәй уздыру миңа да бик яхшы булды. Альфин иптәш, «комсомол башлыгы» булудан бигрәк, сәхнәне ярата иде. Җаен без аның тырышлыгы белән Анжер-Судженск шахталарында байтак спектакль куйдык. Ул мине сәхнәдә чын артистча уйнарга, кыйный-кыйный дигәндәй, өйрәтә иде. Ә үзе «Җөйче Гайшә»дә карт ролен, «Галиябану»да Бәдрине уйнаганда сокланмаган кеше калмый, «бис»кә чакырып «җанын алалар» иде. Түгәрәк шактый үсеп китте. Аның Бәдәр һәм Банат Асманова, Закир Йосупов, Әптери Әптерәхманов, Сафа Гобәйдуллин, Гаптерәшитов шикелле оста уйнаучы артистлары барлыкка килде...

Альфин мине галстук тагарга да өйрәтте әле. Хәтта үзенең бик матур сыек зәңгәргә ялтыравык бизәк төшкән бер галстугын, искерәк булса да, өч кенә тәңкәгә миңа «бүләк» итте. Шуны тагып Судженкага бер-ике тапкыр «вечер»га барган идем, «Андреевка мөгаллиме өч тиенлек муенчак тагып, кызлар әлбумына «шыгырлар» язып йөри» дип, стена газитенә чыгардылар. «Муенчак»ны тиз генә салып атарга туры килде...

Август урталарында уку йортларыннан разверстка килеп төште, шахта яшьләре укырга китә башлады. Минем бәхеткә дә өлеш тиде: Свердлов каласына җибәрделәр.

## Беренче омтылыш

Малай чакта вокзаллары аркылы берничә тапкыр килеп сарып узган «Кәтримбур» каласына мин хәзер студент булып килдем. Гаҗәп тә, куанычлы да бу. Дөрес, мине әле Халык мәгарифе институтының хәзерлек курсына гына алдылар, урта белем юк, шулай да студент! Барыбер студент!

Укучы яшьләр шактый күп икән монда. Татбашпедтехникум, партия мәктәбе, рабфак, тау техникумы, медтехникум һәм бүтән уку йортларында бик күпләр белем ала. Шуның өстенә татбашклуб, балалар йорты, мәктәпләр, китапханә һәм өлкә совет-партия оешмаларында эшләүчеләр бар. Спектакльләр, концерт, әдәби кичәләр белән мондагы мәдәни тормыш үзенчә гөр килеп яши. Болардан тыш бөтен Урал өчен чыгарыла торган «Коммунист» газите белән «Шәпи агай» журналы да бар бит әле. Тот та чум бу күлгә һәм батмый йөзә генә бел!

Себердә чакта ук «Коммунист» газитен яратып укый идем, аңа хәбәрләр язгалый башладым һәм алар миңа рабкорлык билеты да җибәргәннәр иде. Килгән көннәремдә үк редакцияне табып, кешеләре белән таныштым. Газитнең талмас эшчесе Нәкыйп абзый Бәхтигә күңелдә иң җылы хисләр урнашты. Кайчандыр патша солдаты булган, соңыннан Смольныйда «Правда» газитен таратып йөргән бу аксак кызылгвардеец без яшьләрне һәр вакыт үз итеп, кече күңел белән сөйләшеп, һәрберебезне хәбәрче, шагыйрь, хикәяче, фельетончы итәргә

тырыша, «үткен язарга, үткен тешләргә» өйрәтә иде. Ул «Коммунист» гәзитен әйбәт мәгънәсендә кызыклы итүгә, күп таратуга, Урал эшчесенең туры үзеннән хәбәрчеләр хәзерләүгә зур көч куйды. «Шәпи агай» журналы да аның тырышлыгы белән чыга башлады. Аның фатихасы белән күп кенә каләм тибрәтүче яшьләр бу гәзит һәм журнал битләрендә көч сынап, беренче тапкыр мәйданга чыктылар. Шулар арасыннан оста фельетончы булып киткән «Җамакай» иптәш редакциягә китерелде. Ак чехларның «үлем эшелоны» белән Себер түренә хәтле «сәяхәт» кылса да, гомер буе яшь күңелле, җор телле булып калган бу егет — Идрис Туктаров булып чыкты. Монда эшләгәндә ул фельетончы гына түгел, нечкә күңелле шагыйрь дә, хикәяче дә, соңрак повесть һәм романчы да булып китте. Гражданнар сугышы белән килгән Апуш Гатауллин да шигырьләре белән шушында дөньяга күренде. Газиз Иделле белән Абдулла Әхмәт дусларны да шул ук Нәкыйп абзый редакциягә тартты. Минем дә беренче өйрәнчек язмалар аның яхшылыгы аркасында шул «Коммунист» белән «Шәпи агай»да урын тапты. Унике юллык беренче шигырем чыккан көн (1923, ноябрь) беренче бәйрәмем булды.

Ләкин безнең арада әдәби әсәрләре белән танылганрак, шигырь, поэма, хикәя, драма язуның төп законча лыкларын белә торганрак кеше берәү дә юк иде әле. Барыбыз да фәкать эчке сиземләү яралгылары белән, күңелгә тулган теләк-омтылышларны әйтергә ашкыну белән сукыр рәвештә генә хәрәкәт итә идек. Арабызда төп курс студенткасы Таһирә исемле бик талантлы бер шагыйрә бар иде. Ул безнең шикелле кычкырмый, яңгыравык лозунглар тезми. Аның шигырьләре җылы дулкын бәреп, эчке бер моң белән агылып тора иде. Ә без аны «пессимист» дип, «үзеңне генә җырлыйсың» дип әрлибез һәм төрлечә көләбез. Әгәр үз вакытында өйрәтүче-юнәлтүче булса, Таһирәнең бик әйбәт шагыйрә булырга мөмкинлеге бар иде.

Бүтән байтаклар да шул җитәкләүче булмаудан тынып калдылар. Нишлисең бит, ул чакларда без язылган әйбернең иң элек сыйнфый ягын, сәяси дөрес яңгыравын бик берьяклы гына тикшерә идек. Бу хакта бик күп бәхәсләр, бик әче тәнкыйтьләшүләр, «тетмәсен тетү»ләр була. Ә инде әдәби әсәрнең сәнгатьчә югары сыйфаты турында фикер йөртә белмәгәнгә, «әйбәт язылган», «йомшак чыккан» дию белән генә чикләнә идек. Ихтимал, шуңа күрә дә ул елларның бик күп шигырьләре белән бик күп шагыйрьләре туар-тумас үлә баргандыр.

Үз «тәнкыйтебез» үзебезгә шундый мәрхәмәтсез яшеннәрен атып торса да, шигырь язуның барыбер үз тәме, үз рәхәте бар иде. Тулай торакның кайсыдыр бер почмагына кешеләрдән качып, бер бит кәгазь өстендә дөньяны онытып, яңакка таянып, еракка карап хыяллану, күңел түреңнән серле сүзләр, көтелмәгән рифмалар эзләп утыру, беренче дүрт юлны тудыруның иң авыр газабын кичерүдән дә татлы берәр нәрсә тагын бар микән дөньяда! Дан турында да уйлый белмисең әле, кая ул! Шагыйрь дип атасалар, бурлаттай кызарып каласың. Сәхнәгә чыгып укуы да мең бәла — каушаудан бугалып бетәсең, нәкъ сабагын белмәгән малай хәленә каласың. Ә шул ук вакытта укыйсы да килә! Акчасына кызыгыр урын да юк. Әгәр дә мәгәр берәр шигырең басылып чыга калса, аның өчен барыбер гади хәбәргә түләгән шикелле генә түлиләр. Шуңа да гаҗәпләнәсең, чөнки бу шигырьне басып чыгарган өчен син үзең редакциягә акча түләргә тиешсең кебек тоела, чөнки сиңа бик зур яхшылык эшләде бит ул. Юк, акча шикелле вак-төяк нәрсә турында кем уйласын ул чакта! Шигырь сүзе — изге сүз. Йөрәгең тавышы дөньяга яңгырый! Менә нәрсә мөһим, менә нәрсә бөек! Син үзең дә, күңелең дә пәйгамбәрдән сафрак, югарырак булырга тиеш! Аннары безнең тамак ягы тәэмин ителгән ич! Ә инде бик килеп терәлсә, тимер юлга төшеп утын бушатасың, бер дә ис китми! Юк, ул чакта безнең буын ниндидер югары пафос белән, үзе дә ачык аңлап

бетермәгән мавыктыргыч романтика белән, дөньякүләм революцион омтылыш белән яши иде. Болар бар да сабыйларча беркатлы, читтән караганда бик наив тоелса да, барыбер матур иде, кызык иде, ләззәтле иде, бөек иде һәм чын иде безнең өчен! Бәлки шуңа күрә дә көненә икешәр-өчәр шигырь язылгандыр, һәр көнне берничә урында әдәби кичә булып торгандыр һәм аларда шигырь, җыр, музыка яңгырагандыр...

Мин башта Таһирә шигырьләренә яшертен гашыйк булып йөрдем. Юк, үзенә түгел. Белмим, ни өчендер, кыз кеше буларак, ул минем кызыксындырмады, яшькә дә миннән зуррак иде бугай, бәлки буй җитмәс чәчәк булып күренгәндер... Ә менә шигырьләренә чын күңелдән мөкиббән идем. Ике арадагы бүлмә тактасы ярыгыннан пышылдап кына шигырьләрен сорап алам. Гади дәфтәрне урталай бөкләп тегелгән тар озынча кәгазьгә вак кына энҗе бөртегедәй хәрефләрдән тезелгән сүзләр, юллар... Никадәр хис аларда, ялкын, моң, кичереш, сөю. Иясез сөю, җавап тапмаган сөю, берәүгә дә ачылмаган күңел кизләвеннән тик дәфтәргә генә түгелгән мәхәббәт! Алдагы Билгесезне юксыну һәм тын моңаюлар, үзенчә әйтсәк, «йөрәк аһылары» ничектер миңа да уртак шикелле һәм алар миңа да йога башлады. Үзем куркам, чөнки сизеп торам: болай язу«гөнаһлы» эш, «пессимист»лыкка китү булачак, ә шулай да кызыктыра, йогынты ясый!..

Син исәнме, Таһирә? Еллар, язмышлар агышында никтер тынып, дөнья күрми калган нечкә хисле шагыйрә! Саклыйсыңмы син ул яшьлек моңнарыңны? Синең ул дәфтәрләрне ничек табып, тагын бер кат ничек укырга?..

Шулай итеп, мин Тукайдан башлап Таһирәгәчә, алар арасындагы Гафури, Дәрдмәнд, Рәми, Бабич шикелле һәрбер көчле шагыйрьгә гыйшык тота идем. Көчсезләр һәр вакыт шулай була диләр бугай. Ихтимал, бу дөрестер дә... Ләкин «көчле дә көчледән көч ала» дигән сүз дә бар бит әле...

Ә шул көннәрдә, һәр яңа китапны йотлыгып йота барганда, «Җир уллары» дигән бер җыентык кулга килеп эләкте. Бу минем өчен искиткеч бер ачыш булды. Һади Такташ дигән бер шагыйрь бар икән. Ул үзенең шушы китабы белән минем аллаларым тезелгән гыйбадәтханәдәге барлык гыйшык шәмнәрен сүндереп ташлады да иң югарыдагы урта бер җиргә яңа бер көчле ут яндырып куйды. Һәм мин, һич аңсыздан, бары тик шул утка гына табына башладым. Ул ут мәңгелек булып калды, сүндерә алырдай бүтән бер көч тә табылмады...

## Өркемәгән кошлар иле

Безнең институт гомерле булмады: ике-өч ай укыдык микән — яптылар. Төрлебез төрле уку йортларына таралдык. Мин берничә иптәш белән партшколаның татар-башкорт бүлегенә эләктем. Шулай итеп, өч айлык «студент» булып кына калдым. Тагын үз теләгәнемчә тирәнгәрәк чумып булмады, чөнки монда укулар бер генә еллык. Бу бүлекне тәмамлагач, безне төрле җиргә эшкә җибәрәчәкләр...

Минем өлешкә дөньяның төньяк читендәге Тобол округына иҗбач булып китү бәхете эләкте. Патша заманында кешеләрне монда сөргенгә куа торган булганнар. Миннән дә «кәтер китәсең икән» дип көлде иптәшләр. Әйләнә-тулгана аккан тар гына Тура суы буйлап бәләкәй генә бер катлы пароходта Төмәннән Тобол каласына егерме дүртенче ел җәендә бер атна сәяхәт кылгач, тагын йөз егерме чакрым әчкәре саз ягындагы Тукыз авылына ат белән килеп төштем. Юлым уң булды: әйбәт каршыладылар. Авыл Советы рәисе Алиш агай Садыйков үз квартирына урнаштырып, табыны түреннән урын бирде. Шул ук авыл

укытучылары ирле-хатынлы Рагачуриннар да беренче очрашудан ук һәйбәт дуслар булып китте, чит-ят җирдә ялгыз моңаеп калырга туры килмәде.

Бу авылда элек волость үзәге булган, хәзер аның бинасында авыл Советы. Шул бинаның элекке «каталажка» бүлмәсендә уку өе урнашкан икән. Ат башыдай чуен йозагын ачып эчкә уздым. Аның бердәнбер тәрәзәсенә куш бармак юанлыгы тимер челтәр корылган. Бердәнбер өстәлдә аунап яткан брошюралар, вак-төяк китаплар әллә кайчан саргаеп, тузанга батып калган. Стеналардагы берәм-сәрәм плакатлар да үз төсләрен җуеп, пәрәвез оялары белән уралып беткәннәр. Шундый ук хәлгә төшкән кепкалы Ленин рәсеме дә, «менә бит, энекәш, тагын әләктем мин тимер читлеккә...» дигәндәй, акыллы күзләрен кыса төшеп, моңсу гына елмаеп тора. Бу хәлләрне күргәч, миңа да моңсу булып китте. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән җир булса да, үземчә дәрт белән, әллә ниләр майтарырдай ялкын белән килгән булган идем бит... Күрәсең, бу бүлмәгә бик күптән аяк басучы булмаган, мин дә кайсы баштан тотынырга белмичә аптырап калдым. Бу тимер рәшәткәле шыксыз бүлмә кинәт кенә күңелне суытып җибәрде, ничек кенә итмә, төрмәне хәтерләтә ич ул. Атна буе тузанын-пычрагын тазартып, берхәтле рәткә китергән булдым, «ыспа-читалнай»ны ачып җибәрдем. Килүче булмады. Бөтен бәлане шул тимер челтәрдән күреп, Алиш агай белән Гали Рагачуринга (икесе дә коммунистлар) үземнең зарны сөйләдем. Алар, партячейкага куеп сөйләшкәннән соң, уку өе өчен авыл Советының утырышлар бүлмәсен бирергә булдылар. Тукызда биш-алты кешелек комсомол ячейкасы да бар иде, алар якын-тирәдәге өч-дүрт авылга сибелгән, егерме өчтән күптән узып (ул чактагы комсомол яше), өйләнеп җибәргән «егетләр». Авылларына йөреп чакыра торгач, беренче җыелышны уздыру мөмкин булды. Моннан соң бик шәп эшләргә булып, бик шәп карарлар чыгардык.

Алдагы атнада тагын җыелып, яңа бүлмәне тазарту өмәсе ясадык. Ватык-җимерек өстәл-урындыкларны төзәтү, чүп-чар түгүдә ирләр эшләсә, стеналарны агарту, идән-тәрәзәләрне юып чыгару, гөлләр табып китерүдә бу иптәшләрнең җәмәгатьләре күп ярдәм итте. Шулай итеп, без хәзер якты, таза бүлмәле булдык, өстәлгә җәяргә авыл Советы искерәк бер комачын да кызганмады. Аның өстенә булган кадәр китап шикелле нәрсәләрне тезеп салдык. Ләкин алар тышлары белән генә түгел, эчтәлекләре белән дә бик искергәннәр иде, ә гәзит-журналлар бөтенләй алынмый икән. Җитмеш биш чакрымдагы район үзәгенә ике тәүлек олау белән барып, андагы политпросвет аша китаплар алдырырга, үзем белгән редакцияләргә хатлар язып, гәзит-журналлар сорарга туры килде. «Яңа себерке яхшы себерә» диләр бугай, мин дә шулай бик кыдырынып йөргән булам. Районнан кайту белән стена гәзите чыгарырга керештем. Тик мәкалә-хәбәр каян алырга соң? Комсомолларым кул гына куя беләләр, укытучылар җәйге ялга китте, Алиш агай кул селкеп кенә куйды: «Әйдә, үсең пулаштыр инте», диде. Уң кул белән шигырь язам, сул кул белән мәкалә-хәбәр язам, өченче кул белән рәсемнәр ясыйм, дүртенче кул белән редакциялим, бишенче кул белән гәзитне зур бер кәгазьгә язып чыгам, алтынчы кул белән стенага элеп куям. Уку бүлмәсенә тагын бер ямь өстәлгәндәй булды. Ләкин аның бер почмагы барыбер китек әле: анда Ленинның яңа рәсеме кирәк, тегесен бөтенләй әләрлек түгел. Районда да эзләп карадым, хәтта исполкомның бер бүлмәсендәге портретны, теләнеп-теләнеп тә бирмәгәч, йолкып алырга маташкан идем, булмады, үземне әрләп кенә чыгардылар. Каян табарга соң? Ник күбрәк итеп чыгармыйлар икән аны?..

Шул бүлмәдә кич буе ялгыз утыра торгач, бер уй килде башка. Һәм мин эшкә керештем: шактый зур гына бер дүрт почмаклы ак

кәгазьне дәфтәрдәге шикелле вак кына тигез шакмакларга нечкә генә карандаш белән бүлеп чыктым. Аннары Ленинның теге иске рәсемен дә шундый ук шакмакларга бүлдем. Һәм рәсемдәге сызыкларны шакмаклар санынча ике тапкыр арттырып, ак кәгазьгә күчерә башладым. Иң элек кепка сызыклары, аннары йөз чалымы, каш-күз билгеләре килеп чыкты, борын, авыз барлыкка килде, сакал-мыек, янак күләгәләре төште, яка-галстук булды... Ике көннән соң эшемне тәмамлап, сабый баладай сөенә-сөенә, түр стенага элеп куйдым. Ишек катына ук китеп, ерактан карыйм, уңнан карыйм, сулдан карыйм — охшаган бит, валлаһи, охшаган! Гомердә рәссам булганым юк, бәләкәй чакта мәчет сурәте ясаудан, мәктәптә укыганда дәрес буенча әрҗә-чүлмәк ясаудан узганым юк иде. Инде килеп үзем дә шаккаттым: башыңа төшсә, чынлап та башмакчы булырга мөмкин икән! Алиш агайны, бик яшерен серем бар кешедәй эшеннән аерып, уку бүлмәсенә алып кердем дә тантаналы рәвештә кулны сузып стенага күрсәттем. Ул башта берни дә аңламыйча минем кәефне җибәрде. Тик сернең нәрсәдә икәнен төшендереп биргәч кенә, мыегын кыймылдатып:

— Тучнай үсе! — дигән пичәт сукты. Әйтерсең ул Ленинны күреп белә. Минем баш тагын күккә тиде...

Килгәнгә ай тулып бара. Хәзер инде уку өенең якты, чиста бүлмәсе дә бар, стена гәзите дә эленеп тора. Ленин рәсеме дә бар, ай башыннан «Коммунист», «Азад Себер», «Эшче», «Игенчеләр» гәзитләре дә, «Шәпи агай», «Яшь эшче», «Безнең юл» журналлары да килә башлады. Яңа китапларның да беренче төргәге килеп житте — бар да бар, тик «ыспа читалнай»га килүче генә юк. Юк! Кызларны әйтәсе дә түгел инде, егетләре дә аяк басмый. Күпчелегенең укый-яза белмәве билгеле. Ичмаса, болай кызыксынып, сүз тыңларга булса да кермиләр. Ә кызлары шактый караңгылыкта һәм шактый кыргый карыйлар мондый нәрсәгә. Авылда баерак кешеләрнең кызлары да бар, әзме-күпме укымыш яклары да юк түгел, имеш. Мәгәр аларны да кымшатып булмый. Андыйлар килсә, бүтәннәре дә нярер иде бәлки. Менә бит гармунчы булмауның бәласе кайчан суга икән тез астына! Күпме маташтым шуны өйрәнергә, тәки барып чыкмады. Менә хәзер гармун белән шушы җәйге кичләрдә бер-ике тапкыр урам әйләнгән идең, кәтүе белән синең арттан йөрерләр иде. Егетенә кызыгып булмаса, кызык итеп, яңа нәрсә итеп нярерләр иде. Ник дисәң, монда гармун юк, бу Тукызда гына түгел, бүтән авылларда да юк. Бу якларда гармун уйнау гадәте гомумән кермәгән. Скрипка уйныйлар да курай тарталар...

Инде мин килгәндә үк сүтелгән иске мәчет бүрәнәләреннән клуб укмаштырып яталар иде. Бер көнне Алиш агай, авыл башлыгы буларак, өмә ясады. Мәчет бүрәнәсеннән клуб салу шикелле «көфер эш» булса да, байтак халык килгән иде. Әзер сайгак һәм такталардан файдаланып, түшәм, идән җәйдек, түбә яптык, хәтта сәхнәсен дә әмәлләп ташларга, түшәм өстенә балчык менгерергә дә өлгердек. Клуб әзер, ишек-тәрәзәләр генә куясы калды. Бу минем өчен бик уңайлы булып чыкты. Авыл Советы җыйган җыелыш саен, хәтта бик кыенлык белән булса да яшьләр өчен аерым җыелыш та җыеп, хәзерге «текушчи момент» турында, дөнья буржуазиясенең, Чемберлен, Клемансоларның этлеге турында «бик шәп» докладлар ясый башладым. Ул докладларның һәрбере тиздән булачак мировой революция белән һәм Тукыз яшьләренең шуңа җиде төн уртасында да әзер булырга тиешлеге турындагы кайнар сүзләр белән тәмамлана иде. Озакламый шул ишек-тәрәзәсез клубта ниндидер бер спектакль дә куеп җибәрдек. Әйбәт чыкты. Тагын куегыз дип йөдәтә башладылар. Бик куяр идек, безгә яраклы пьеса юк. Хатын-кызыбыз бер Камилә апа гына. Карчык булып уйнарга тагын бер егетебез бар — шуның белән вәссәлам. Ә кызларны сәхнәгә тарту турында уйлау да мөмкин түгел.

Тукызга орынып кына торган Җукәвылда ярым шаман сыманрак бер мулла бар иде. Аның кәмит кыланышларын миңа сөйләп күрсәттеләр. Тиз арада «Хәсән мулла» дигән пьеса барлыкка килде һәм без аны сәхнәгә куйдык. Афишада мулланың үз исеме ачыктан язылган булгач, клубка халык сыймады, пыяласыз тәрәзәләр дә кеше белән капланды. Шулар арасында качып-посып кына караучы Хәсән хәзрәт үзе дә булган, имеш. Нишлисең бит. Ул чакта муллалардан көлү бик модада иде шул...

Монда мин моңарчы белмәгән-күрмәгән үзгә бер халык эченә килеп кердем. Бу як кешеләре татар, башкорт, казакъ, үзбәк, монгол, остяк сүзләреннән укмашкан үзгә бер «тамыр шивә»дә сөйләшәләр икән. Аларны яхшы аңлар дәрәҗәгә килү өчен ике-өч ай күнегү кирәк. Үзләре бик кече күңелле, ачык чырайлы, уен-көлкене, җыр-такмакны, мәзәкйомакны бик үз күрәләр. Ә безнең ише «Казанның»ларны искәртмәстән генә исәр итеп, «әвәрә кылып», туйганчы бер көләргә яраталар.

Аларның көнкүреш гадәтләре дә бик үзенчәлекле иде ул чакта. Өйләренә килеп керсәң, мич күрмисең. Мич казнасы урынына киң ачык авызлы итеп учак ясалган, аның морҗасы туп-туры түшәмгә менеп китә. Көз-кыш көннәрендә ул учакта ут өзелми: өч аяклы казан белән шул учак каршында аш пешә, табада балык кыза, әләвә[1] пешерелә, бүтән ризык әзерләнә, шул ук учак өйне дә җылыта. Ә инде икмәк мичләре — тышта. «Кыш көне ишегалдында ипи пешерәләр»,— дигән сүз көлке яңгырый. Бу як кешеләре өчен моның бер дә көлкесе дә юк. Шактый биек итеп мич казнасы корганнар да өстенә чуманнан олырак итеп озынча бер балчык куыш койганнар, мич авызы калдырганнар һәм бөтен җирен үзле балчык белән сылап-шомартып чыкканнар. Аңа бер ат йөге утын ягалар. Ул өлгерүгә өйдә әвәләнгән ипиләрне яссы җилпучка тезеп чыгаралар да тиз-тиз генә шул мичкә озаталар, авызын каплыйлар...

Урман аларның өсләренә авып тора. Җәен әзерләп куйган утыннары шунда саклана, кышын аны, иртә саен барып, бер көнгә җитәрлек алып кайталар. Печәнне дә шулай бер көнлек итеп кенә ташыйлар, чөнки аларның абзар түбәләре, сарай башлары юк, кайбер атлы-тунлы кешенең дә хәтта өй түбәсе дә ябылмаган була. Бу аларның ялкаулыгын күрсәтә дип әйтмәс идем мин, чөнки алар үзләренең төп эшләрендә бик өлгер һәм бик житезләр. Табигать байлыгы шулай мул булган урыннарда әдәм баласы үзенең иртәнге көн хәстәрен бүген кайгыртуны артык кирәксенми, күрәсең...

Күп авыллар урман, саз арасындагы ачык җирләргә «бойдай» чәчкәли, «бойдай» ашый. Ләкин иң яраткан эшләре аучылык белән балыкчылык. Төз атучы мәргәннәр өй борынча диярлек. Тиеннең күзенә, аюның маңгай уртасына гына ата торган Корман әкә бар иде. Шул үз нугәрләрен[2] тыкрыкка алып чыга да ярыш башлый. Ул иске бер каңсаны[3] уң кулы белән югары күтәреп тора, икенчесе аңа кырыкилле метрдан «сыңар ук» белән атып җибәрә. Тими. Башкаларның уклары да шәпшә булып чыжлап уза. Шуннан Корман әкә, «кана!» дип, үзе тотына һәм нәкъ чокырына тидереп чилемне атып төшерә.

Агач башындагы тиеннең фәкать күзенә генә тидереп ату да юкка гына килеп чыкмаган икән. Башка урынга тисә, тире бозыла, хакын югалта, имеш. Аюга, аңга[4] йөрүчеләр дә шулай ук гадәти хәл. Аюны, гадәттә, атна буе дигәндәй тайгада ятып, ике-өч кеше бергә «чыгара» монда. Берүзе йөрүче дуамал башлар да була. Шул ук Корман әкә турында әллә ялган, әллә чын булган хәлне сөйлиләр иде.

[1] Әләвә — бездәге борынгы әлбә.
[2] Нугәр — иш, дус.
[3] Каңса — чилем, трубка.
[4] Аң — болан.

Имеш, Корман әкә шулай аю хәзрәтләре белән бергә-бер очрашкан да, унбиш метрга тикле якын җибәреп, чәнчә бармакның яртысыдай булырлык үзе койган сыңар укны нәкъ тегенең уң колагы эченә генә батырып, «шалт!» егып салмакчы булган. Ә мылтык атылмаган: әллә нәрсә генә булган — әллә дары дымыккан, әллә пистон бозылган, әллә чакма чакмаган. Ул арада камытаяк-йөнтәпи үрә баскан да: «Кер куеныма, җаныем!» дигәндәй, мамык кочагын җәеп, моның өстенә килә дә башлаган. Куныычындагы сугым пычагын чыгарырга да өлгермәгән Корман әкә, аю патшага капланып та куйган моңа! Киткән алыш та тартыш, әүмәкләү дә тәгәрәү, бер аска да бер өскә. Ничек тә үзен бу олы тинтәктән издермәскә, үткен тырнаклары ерткалаудан сакланырга тырыша торгач, тар бер чокырга килеп төшкән аучы. Шуны күрү белән аю «ха-ха-ха-а!» дигәндәй шашкын бер тавыш белән бөтен урманны үкертеп җибәргән дә аяк астында яткан чытыр-чытырманны кубарып моның өстенә өяргә тотынган, хәтта бер иске төпне умырып алып та китереп каплаган, аннары үзе шунда сакка яткан, имеш. «Петте паш!» дип ята икән Корман әкә, ә үзе хәйлә эзли икән. Бу тар гына чокырда, өстенә өелгән төп-тумран астында нәрсә генә уйлап табарга соң? Келт итеп исенә төшә: аның көзге-кышкы суыкта ауга йөри торган бу туны яшь аю тиресеннән ич! «Тукта, файдасы тимәсме?» дип уйлый һәм тиз генә тунын, бүреген йонлы ягы белән әйләндереп кия. Ул үзе дә аю төсле хәзер! Шуннан ары куныычындагы олы пычагы белән чокырның теге кырыен киңәйтә дә өскә чыга башлый. Кыштырдауны ишетү белән үк аю аның каршына ташлана! Һәм кинәт артка чүгә: бу ниткән хәл? Аның каршында кеше түгел, ә ниндидер бәрән башлы яшь бер аю тора! Корман әкә, карт аюның шул аптырау хәленнән беравыкта файдаланып, пычагын күрсәтми генә елыша да, эчен ярып җибәрә тегенең. Гөрс итеп җиргә ава тайга патшасы. Туный аны Корман әкә. Ут яга, аю итенең иң тәмле җирләрен генә кисеп пычагына тезә дә шашлык кыздыра, тамагын туйдыра. Ник дисәң, бу куркыныч тартышта бик ачыккан, бик алҗыган була ул...

Аучылар үз хикәяләрен: «Сиңа ялган, миңа чын», дип башлыйлар. Ихтимал, бу да чын белән ялган арасындадыр. Болай караганда, каңсасын бер дә авызыннан төшерми торган Корман агай бик гади кеше, һич тә искитмәле батырга охшамаган. Коңгырт калын кашлары бар да, ике сыңар уктай янып торган ике күзе бар. Аннары шунысы да бар: үз батырлыгы турында ләм-мим бер сүз әйтми ул. Андагы аучыларның тагын да экияттәгечәрәк егетлекләрен ишеткәнгә күрә, Корман агайның бу хәленә дә чын итеп ышанасы килә.

Аю ите, аю мае белән алар мине дә сыйлады. «Әләвә» дигән бик тәмле ашларын аю мае белән ашаганда телләреңне йотарсың! Юк, аю мае гына түгел, миңа алар «ау чире» дә йоктыра яздылар. Чүлмәкчедән күрмәкче дигәндәй, кооперативтан бер берданка алып чыпчык-каргалар атып йөрдем дә, көзен, аларга ияреп, озанга[1] киттем. Кайтып кергәндә алар биләндә ун-унбиш көртлек булса, минем кулда бер мескен була иде.

Белмим, хәзер ничектер, әмма ул елларда мондагы урман-суларда киек-җәнлек, кош-корт, җиләк-җимеш һәм балык исәп-хисапсыз иде. Нарат җиләген, торнакузне[2], козыкны[3], карагатны ат йөге белән ташыйлар, шомырт, миләш, баланны сангa тыккан кеше дә юк. Һәм шул җиләк-җимешне Ишим-Павлодар базарларына алып чыгып, йөге-йөге белән бодай төяп кайталар. Сезонга ике-өч йөз баш тиен ату, берничә дистә кызыл төлке, ак төлке, кеш һәм башка киекләр ату да

---

[1] Озан — көртлек.
[2] Торнакуз — мүк җиләге.
[3] Козык — әрбет чикләвеге.

табигый эш санала. Хисапсыз күп вак күлләрдән җәен-кышын балык тарту да аларның төп кәсепләреннән берсе булып тора...

Август урталарында булса кирәк, Шәрәф Мәхмүт дигән бер иптәш килеп төште. Ул үзе Тобол шәһәре янындагы Затылган авылыннан чыккан җирле кеше булып, Казанда ТКУ бетергән һәм, футурист язучылар төркемендә торып, сәхнә әсәрләре яза икән. «Гаскәр» дигән бер пьесасын хәтта бастырып та чыгаралар, имеш. Минем әле тере футуристны бер дә күргәнем юк иде. «Айны аулап, кояшны бораулап» дигәндәй, ул замандагы матбугатта шактый көлке шау-шу кубарулары карганда, алар үзләре дә шактый хәтәр егетләр булырга тиешләр иде. Ә бу озын буйлы, җилкәсенә төшкән озын чәчле, чак кына шадра йөзле, шушы як кешеләренекечә хәйләкәр очкын күзле һәм йомшак елмаеп сөйләшүчән егетнең андый куркыныч яклары бер дә күренмәде. Без аның белән бик тиз аралашып киттек. Ул мине юлга, «кызыклы сәяхәткә» котыртты һәм без, Алиш агай ярдәме белән оста бер каекчы табып, «әҗәл тагарагы»дай бәләкәй һәм сай көймәдә, Тукыз уртасыннан уза торган Агыт суы буйлап өскә үрләдек. Саз һәм күлләрдән башланып тын гына, ялкау гына ага торган бу суның өсте кайбер урыннарда тоташтан төнбоек чәчәкләре белән капланган. Чын охшашын табу мөмкин булмаган шул ак фарфор чынаяк чәчәкләр арасыннан ярып бару, таррак урыннарда яр буенда ук сыгылып пешеп утырган кура җиләге, карлыган, шомырт, миләш тәлгәшләренең башларга тиеп калуы, камыш төпләре, төнбоек яфраклары астына ышыкланган чумга үрдәкләрнең, су тавыгы һәм тагын әллә нинди кошларның көтмәгәндә ишкәк астыннан гына дигәндәй очып китүе нинди дер сихри бер әкият дөньясын хәтерләтә. Юк, әллә кая качмый ул кошлар, егерме-утыз атлам артка гына күчеп төшәләр. Шулай бара торгач, унбиш чакрымдагы Уат авылына килеп җиттек. Бу авыл шул исемдәге күлдән балык тоту белән көн күрә икән. Күл буенда утын шикелле өеп киптерелгән балык әрдәнәләрен беренче тапкыр күрү миңа бик сәер тоелды. Кышкы юл төшкәч, алар бу әрдәнәне Тубыл торага[1] чыгарып, потребсоюзга тапшыралар, ә аннан азык-төлек һәм ау кирәк-ярагы кайта икән.

Без карт коммунист Абайдулла агайга тукталып, кунак булып, кунып чыктык. Үзе дә, малае Мокка да унтугызынчы елдан ук партиядә булып, егерменче елдагы сәнәкчеләр фетнәсенә каршы сугышканнар. Кече уллары Шәкә — уналты яшеннән комсомолец. Ярлы гына тормышлы булсалар да, бай һәм саф күңелле кешеләр иде болар. Безне мин күрмәгән-татымаган балык ашлары белән сыйлап, иртәгесен юлга озатып калдылар. Без, кояш белән кузгалып, тагын шул бормалы-сырмалы, чәчәкле-тугайлы Агыт белән кырык биш чакрым өскә күтәрелеп, кояш баеганда Агытбаш авылына килеп җиттек. Бу да әз-мәз генә иген чәчә торган балыкчылар авылы икән. Мондагы авыл Советы рәисе Аетбаев дигән олы яшьләрдәге кеше, авылда партияле бер үзе генә булганлыктан, безнең ячейкада тора. Без аңа тукталдык. Бу абзый ярыйсы гына тормышлы урта хәлле кеше булса кирәк. Әйбәт кенә җиткерелгән каралты-курасы бар, ике катлы өе бар, ике өендә ике хатыны бар. Мин шаккатып, кычкырып көлдем. Мондый хәл минем малай башка, «искелеккә ут урләтүче» комсомол башка, сыя торган нәрсә түгел иде. Менә сиңа вәт: үзе коммунист, үзе авыл Советы башлыгы, үзе ике хатың белән тора!

— Нимә кылаен, нөгәр,— ди ул.— Микулайски заманда алып куйган, гуй! Хәзер инде икесеннән дә әллә ничә бала бар. Ничек аераен, кайсын аераен? Икесе дә яман түгел, икесенә ике ысба, икесенә дә пулнай тигез права! Тора ятсыннар!

---

[1] Тубыл тора — Тобол каласы.

Ул безне олы хатын өендә дә, кече хатын өендә дә кунак итеп, алгы юлга көймә һәм көймәче биреп, озатып җибәрде. Ун чакрымлы бер күлне аркылы кичкәннән соң аргы ярындагы тар гына канау авызына килеп туктадык. Алдагы күлгә көймә сөйрәп йөрмәс өчен моны Аетбаев казыткан. Без ярга чыгып җәяү атлый башладык, ишкәкчебез көймәне шул тар канаудан алга этәрә. Монда мәңгелек торф сазлыгы. Болай караганда болын шикелле тигез җир яшел кыяк үләне белән капланган, сирәк-мирәк әрәмә өемнәре, анда-санда карсак каен, кәрлә нарат, ялгыз зирекләр дә тирбәлеп утыра. Ә инде баскан түмгәгеңдә озаграк торсаң, күз алдыңда ул югала, быжыр-быжыр күбекләнеп чыккан җирән су итек кунычын күмә башлый. Ярый әле, кулга күсәк алдык, шуның ярдәмендә тиз генә алга сикергәләп, андагы куак төбенә барып басасың, ул ныграк була икән. Безнең «Букырлы» чишмәсе янында да мондый урын бар иде, малай чакта без аны «төпсез кое» дип атый идек.

Шәрәф Мәхмүт җор телле кеше булып чыкты: көлке сүзләрен яудыра-яудыра, озын аяклары белән һаман алга сикерә. Бу як кешесе булгач — аңа нәрсә, бәлки ул йөзенче тапкыр узадыр мондый юлны! Ә мин анын артыннан өлгерә алмыйм. Җитмәсә, шул чакта нәкъ юл өстендә елан пәйда була. Кайбере чем-кара, кайбере балчык төсле соры, кайбере үләнгә тартым яшькелт төстә: күз аермый, табигать битлеге кигәннәр. Яннарына ук килеп җиткәнеңне сизми дә каласың. Ә миңа алар барысы да аждаһа булып күренә. Чөнки барысы да «әби авыз»ларын ачып, җәплекә телләрен чыгарып, сихерле күзләрен чекерәйтеп, «йотам!» дигән шикелле сиңа карап тора! Курку дигән нәрсәне белми дә. Аяк белән тибеп очырырга — тешләр дип куркам, әйләнеп узсаң — төпсез коега төшеп китәсе. Тотам да кулдагы тәртә буе күсәк белән муенса буе еланга җан ачудан кизәнеп, «шап!» итеп китереп сугам. Әллә кайларга пычрак чәчрәп китә, ә елан күзен чекерәйткән килеш һаман тора бирә шунда! Чебенгә туп белән аттырган батыр патша искә төшә, әллә кайсы экияттә генә иде әле ул!.. Бата барган итек кунычыннан су керә башлагач, елан аркылы җан-фәрманга алга сикерәм, ул ысылдап кына кала. Баксана, йота алмый икән ләбаса!

Биш чакрымга сузылган шушындый «рәхәт» юлны узып, алдагы күл ярына килеп җиткәч, янадан көймәгә утырып, утраулы-түмгәкле, карабаш камышлы һәм тагын төнбоеклы күл эченнән бара башладык. Я ходаа, күргән күзләремә ышаныймм, юкмы — ярты чакрым да китмәгәнбездер, ундагы бер бәләкәй утрау итәгендә, бездән якында гына аккошлар төркеме йөзә! Шунда ук кыр казлары сибелгән. Аларның безгә исе дә китмәде — ике якка аерылып, юл биреп кенә калдылар. Әз генә ары киткән идек, ике түмгәк башында озын нечкә аяклы, нечкә муенлы ике челән басып тора. Болары да безгә баш кыйшайтып кына карап калды.

— Алар монда бала чыгарад, кара көз йиткәнче тораллар,— диде ишкәкчебез.— Ич берәү атмайды...

Нинди сизгер кыр үрдәкләре дә төнбоек чәчәкләре арасында йөзеп йөргән җирләреннән, безне күргәч, һавага күтәрелмәде, каядыр яфраклар астына чумып кына калдылар.

Бу — «Оллы күл» дип атала икән. Анын иңе ундурт чакрым, буе кырыктан артык, имеш. Булса да булыр, чөнки ул якка карасаң яр күренми, күл суы күк чите белән тоташа. Анын дулкыннары да башкача, безнең «әҗәл тагарагы»н йомычкадай уйната башлады, авылга җиткәнче ярга сыенып кына бардык.

Бу күл буена вак-вак авыллар утырган, алар барысы да балыкчылык белән көн күрә. Монда урман да саз арасы, сабан тәрәне борын төртер урын юк икән. Шул авылларның берендә безне Барый исемле егет өенә алып кереп кунак итте. Тукызда укытучы Гали Рагачуринның

комсомолец энесе иде ул. Яңа гына күлдән чыккан симез табан балык ухасын, оста кыздырылган чабакны ашамаган кешеләр, нихәтле мактасаң да, бу ашларның ләззәтен барыбер тоя алмаячаклар!

Балыктан соң кайнар куе чәй килде, чәй табынына ак он камырыннан майда куырылган сап-сары бавырсак өелде. Аның һәрбере балалар такыясы төсле кабарып, түгәрәкләнеп пешкән. Авызга капсаң, шундук кетердәп эреп бетә. Бу як халкының традицион ашларыннан берсе икән ул. Табын түбәсеннән бавырсак булмаса, мәҗлес тә, туй да булмый, сый да булмый, имеш.

Монда без ике-өч көн торып, Оллы күлдә җылым тартканнарын карап, җыелышлар уздырып, мировой революция турында сөйләп, җырчылар һәм курайчыларны тыңлап, кире Тукызга кайтып киттек.

Шәрәф Мәхмүтнең бу якларга килеп чыгуы сазламыклар эчендә сәяхәт кылу өчен генә түгел икән. Егерменче елны бу якларда (Түмән — Тобол, Ишим — Тара буйлары) сәнәкчеләр фетнәсе дигән фаҗигале көннәр булып узган. Ак офицерлар, кулаклар коткысы белән шактый киң җәелгән ул суkыр стихиягә каршы сугышта бу тирәләрнең барлык коммунистлары, комсомоллары, алдынгы яшьләре катнашкан. Шәрәф Мәхмүт үзе дә, минем Гали Рагачурин дустым да, юлда әлеге без туктаган коммунистлар да, кулларына корал тотып, шушы сазламыкларны «тарап» узганнар. Шәрәф агай әнә шул хакта әдәби әсәрме, истәлек китабымы язмакчы иде. Кызганычка каршы, матбугатта андый әсәр күренми калды. Чөнки, шулай түбәннән күтәрелеп, соңыннан Мәскәүдә ИКП[1] да укыган, аннары Башкортстанда политбүлек начальнигы булып эшләгән бу иптәшнең үз язмышы шәхес культы елларында күп авырлыкларга дучар булды. Шулай да әле ул соңгы елларда янадан канатланып китеп, шул әсәрен тудыру өчен Мәскәү архивларында казынуы турында язган иде миңа. Мәгәр озакламый икенче бер хәбәр — аның көтелмәгәндә вафат булуы турындагы кайгылы хәбәр килеп төште...

Бу якларда күргән-белгәннәрем хакында ниндидер бер әйбер язу теләге миндә дә шул чакта ук уянган иде. Чөнки мондагы халыкның көнкүреш, гореф-гадәт, тел, фольклор, тарих, этнография үзенчәлеге минем өчен бар да яңа, бар да кызыклы булып тоелды. Әйтик, бу як халкы Күчүм хан заманында гына (16 йөз) ислам диненә кертелгән. Аларга дин өйрәтү өчен Бохара әмирлегеннән өч йөзме, биш йөзме гаилә «укымышлы» үзбәкләр китерелгән. Болар авылларда үз заманына күрә мәдрәсәләр ачып, дин тарату гына түгел, халыкка әзме-күпме уку-язу да танытканнар, үзләре дә сизмәстән, бәләкәй генә мәгърифәтче булып киткәннәр. Икенче яктан, алар күпме тырышмасын, ислам дине әллә ни тирән тамыр җәя алмаган. Хатын-кызның ирләр алдында тел яшерүен, яулык чите белән генә булса да бит каплавын күрмәдем мин. Авыруларны өшкертү, чынаяк яздырып эчертүләр урынына шабыр тиргә батканчы, тәмам хәлдән тайганчы скрипкага биетеп «чирен куу», тагын әллә нинди им-томнар белән шаманчылык итү йолалары тулып ята. Өченче яктан исә, бу як кешесенең өендә тәбәнәк кенә сәкс, сәке өстендә кыска аяклы өстәл булу, шунда аяк бөкләп, я кырын таянып ашаулары, алда әйтелгән учак һәм ипи мичләренең шулай сәер корылуы — һәммәсе дә әлеге «бохарлык»лардан кергән булуын хәтерләтә иде.

Шул ук вакытта, мине Чурнайга[2] алып барганда ат башына утырып, борынгы көйләрне бер дә ашыкмый гына бормалый-боргалый сузып, «ди торган»нарны кат-кат кыстырып, бик моңлы «айтып» бирә торган Касук бабай шикелле оста җырчыларына, Хәмзә Мәннапов

[1] ИКП — Кызыл профессура институты.
[2] Чурнай — район үзәге Черняковский.

шикелле оста курайчыларына гашыйк идем. Казанлы авылындагы бай хәзрәт үлгәннән соң игенчелек итә башлаган варис улы «коммунист» Абушахмаевта яшь кенә башыннан батрак булып эшләүче комсомолец Ярукның (Ярулла) халык башыннан узган сәнәкчелек фаҗигасе турындагы бәетне авыр бер моңлы көй белән:

Иртә торып аулар салдым
Агынлы күл балыккау,
Бу партизун сугышлару
Айбрат булсын халыккау...—

дип җырлавына, аннары кинәт уен-көлкегә күчеп:

Эскрипкәм-сорнаем ти,
Сикереп төшеп уйнаен ти,
Сикереп төшеп уйнамаен,
Бандит кызын урлаен ти! —

дип, жилкенеп биеп китүләренә дә гашыйк идем мин.

Менә шуларны язасы килгән иде.

Аннан килеп, бу як халкы кышкы ау сезоннары сүрелә төшкәч, туй ясарга тотына. Мина өйләнешү туенда түгел, Уат авылындагы урта хәлле коммунист Корманалиевның сөннәт туенда булырга туры килде. Әйе, бу якта малайларны мәктәп яшенә житкәндә генә сөннәткә утырталар һәм ике-өч көнгә сузылган туй ясыйлар икән. Туйга үз авылы гына түгел, тирә-яктан да киләләр — чакырылган да, чакырылмаган да. Иртәдән башлап төн уртасына хәтле табын өзелми. Бу туйның иң кызыгы — ат чаптыру. Озын колга башына тиен, төлке, ас, хәтта кеш һәм бүтән тиреләр эленгән була. Урман арасындагы тар гына кышкы юлдан ат чаба. Хәер, монда җәен ат чаптыру мөмкинлеге дә юк — күл дә сазлык. Шушы ат чабышы белән сабан туена охшаган бу бәйрәмне алар, ихтимал, шуңа күрә дә кыш ясый торганнардыр...

Тагын бик күп үзгәлекләре бар бу якларның. Шуларны төплерәк өйрәнеп, киләчәктә ни дә булса язарга дип йөргәндә генә Тукыздан мине алып киттеләр.

Нибары сигез-тугыз ай чамасы эшләп калдым микән, Тобол каласына чакырып, округ комсомол комитетының милли инструкторы итеп куйдылар. Шулай итеп, мин дигән малай «белтеки» генә түрә булып китте хәзер. Мондый кыен эшкә иртә күтәрүләрен, көче житеп бетмәячәген сизсә дә, каршы килмәде. Ник каршы килсен, ерак саз арасындагы избачны Тобол каласына күчерәләр ич! Мәскәүгә күчерү белән бер бит ул! Белемсез дә, тәжрибәсез дә, сары авызлы чыпчык баласыдай яшь тә икәнлек берни түгел хәзер, дингез тубыктан аңа! Өс-башны да хәтәр бөтәйтеп җибәрде ул: җәйге чөлләдә кара постау френч белән шундый ук постау галифе киеп, шабыр тиргә батып, коп-коры көнне аягына сары күн итек өстеннән резин галош киеп, Тобол урамнарындагы такта тротуардан дык-дык басып кына окружкомолга килә. Чеховның «Футлярдагы кеше»сен дә укыганы юк әле аның! Сыек булса да кара бөдрә чәче жилкәсенә төшкән, бусы инде шагыйрьлек галәмәте. Хезмәтенә килеп утыргач, андый-мондый тәжел эш кушмасалар, шигырь язарга керешә ул. Дөрес, әле аны берәү дә шагыйрь дип танырганы юк, ләкин ул аңа карамый, һаман яза бирә. «Азад Себер», «Коммунист», «Эшче», «Крәстиян гәзите», «Яшь эшче», «Шәпи агай», «Кечкенә иптәшләр» журналлары баскалап тора аның язганнарын: кайсы шигырь, кайсы хәбәр, кайсы хикәя сыман нәрсәләр шунда. Хәбәрчеме, шагыйрьме, хикәячеме, бу — аның өчен барыбер. Хәер, юк! Алай дисә, ялганчы була. Шагыйре аның өчен барыннан да артыграк! Ни өчен? Ул моны үзе дә белми, әйтә дә алмый. Тик ниндидер рәхәт пешерә торган ялкын шикелле булып, яшерен бер куаныч кына яши эчендә...

Шулай шигъри хыяллар белән мәмрәп йөргәндә эш сорый башладылар аннан. Әллә ничә губернадан зуррак булган Тобол округындагы авылларда берәм-сәрәм яшәүче татар-бохар комсомоллары белән ниндидер эш алып бару мөмкинлеген күз алдына да китерә алмады ул. Эшләгән кадәре эшеннән исәп-хисап язып бирә белү дә килмәде аның кулыннан. Шул сәбәпле эштән «азат иттеләр» ул тәти егетне. Егерме алтынчы ел язында килгән беренче пароходта Тобол каласыннан «кәҗә билеты» белән китеп барырга туры килде аңа. Февральдә командировкага чыкканда гына кырык сигез сумга алган бөрмә билле җылы туны һәм чалбарлык отрезы бар иде. Шуларның икесенә окружком инструкторы Әхмеров иптәш унбиш сум акча бирде. Әйбәт кеше иде ул. Унҗиденче елны Сөембикә манарасына революция исеменнән ай куюда[1] күрсәткән зур фидакарьлеген дә бик ышандыргыч итеп сөйләргә ярата иде. «Мин» дигән егет, аңа чын дусларча баш иеп, ул биргән сәдака белән Төмән, Свердлов шәһәрен гизеп, Урал таулары арасындагы Карабаш комбинатына килеп чыкты...

## Тагын... һәм тагын

Әйе, тагын Урал кочагында мин.

Монда колчедан шахталары һәм шул руданы эретеп бакыр, көмеш, чуен, хәтта бик әз генә өлеш алтын да ала торган зур комбинат эшли. Якын-тирәдә бер башкорт авылы бар икән, Карабаш исеме шуннан алынган, имеш. Элек заманда болар барысы да Англия бае Уркварт кулында булган.

Карпинка шахтасына керешеп, аска төштем. Беренче тапкыр забой күрүем. Үзем шикелле «алаканат» буйдаклар тулган бер такта баракка урнашып, үз күленә чумган чуртандай булып киттем. Кулда бер төрле һөнәр дә юк. Авылдан кичәле-бүгенле дигәндәй килгән «кәрәк осталары» белән закладкада йөрибез. Колчеданы чыгарылып, буш калган забойларны балчык белән күмү дигән сүз. Акчасы да чыпчык төкерәге генә: күмәч белән чәйгә генә җитә. Астагы откаткага күчтем. Аргы забойлардан чыгарылган колчеданны вагонеткаларга төяп, клеть төбенә китерәбез. Ә мине иң кызыктырганы — бурильщик булу. Яңа дустым Гарәфи дә шуңа кызыга. Көн саен забойда Баян бабай белән очрашкач, янынннан китә алмый торабыз. Бәләкәйрәк кенә чандыр бу кеше күп еллар шушы шахтада эшләгән. Кече күңелле, әйбәт холыклы ул, утырып тәмәке тартканда үткәннәрне сөйләргә ярата торган гадәте дә бар. Күп ялына торгач, без аның ике кырыена өйрәнчекләр булып килеп бастык. Шактый авыр корыч перфораторны җилкә сөягенә терәп, өч электробур белән колчедан күкрәген тишә башлау — безгә бик күңелле булып китте. Зырлап әйләнгән бурлардан очкын чәчрәтеп чыккан күкертле руда тузанының авызларга, борын тишекләренә тулып, үпкәләргә утыруы, битләргә сылануы, күзләрне әчеттерүе дә берни түгел шикелле. Шахтадан чыккач, барактан якында гына булган урман читендәге күлгә барып чумабыз. Ул топ-тоныК сулы бик матур күл. Тирә-ягын урманлы биек таулар камап алган. Алардан ары тагын да өскә калкынып, түбәсендә яткан ак карны кояшта җемелдәтеп, Юрма таулары күренә. Кайчандыр ерак үткән заманнарда «пугаччылар» яткан, имеш, анда.

Бер ял көнне без шул күлне әйләнергә киттек. Яр буйлап тоташ аллея сузыла. Элек ул вак таш төеп ясалган тигез, шома юл булган, хәзер аны таудан төшә торган язгы сулар яргалап бетергән. Шул аллея

[1] Ай кую — хәрби шура, милли шура һәм тагын башкалар арасында «беренче булып ай кую өчен» барган «көрәш».

буенча әйләнеп, күлнең урамга тоташа торган аргы башына барып чыкканда бер таш багана күрдек. Аның башына аркылы чуен такта кагылган һәм анда...

Юк, үз күзләрем белән кат-кат укымасам, ышанмас идем. Бер кат уку белән генә болай да ышанмадым әле. Элек мондый язулар булганын гәзитләрдә күргәләсәм дә, арттыралардыр дип уйлый идем. Ә инде бу бағананы берничә тапкыр әйләнеп, төрле яктан карап, берничә кат укыгач, икеләнер урын калмады...

Әйе, ул чуен такта өстенә «Рабочимъ и собакамъ входъ воспрѣщенъ» дигән сүзләр бармак калынлыгы кара хәрефләр белән коелган иде! Без аңлап бетермәгәнне Баян бабай әйтеп бирде: патша түрәләре белән әгелчән түрәләренең күңел ача торган ябык бакчасы булган икән бу. Тауларында кыр кәҗәләре йөргән, поши яткан, күлдә балык аулаганнар, үрдәк атканнар, көймәдә йөргәннәр, сукмаклары әйләнеп ирек ачканнар, гыйшык тотканнар...

Гарәфинең бик ачуы килде ул чакта.

— Субалычлар! — дип куйды ул, күз акларына кан йөгертеп. Әле бер авыз сүз дә диярлек урысча белми торган авыл егете Гарәфи. Бик ачу белән әйтсә дә, көлкерәк килеп чыкты бу сүзе.— Давай йолкып атабыз! — дип шәпләнде ул аннары. Һәм барып бағананы кочаклады да төрле якка боргалап кымшатмакчы, суырып атмакчы булды. Ә багана төбенә дүрт почмаклап цемент коелган иде. Без көлештек кенә.

— Торсын,— диде кемдер.— Гыйбрәт бағанасы икән бу, акыл өйрәтә торган багана!..

Без бу күл буеннан ничектер талчыгып кайтып кердек тә урынга сузылдык. Гарәфи белән безнең тапчаннар янәшә. Юк-барга исе китми торган шат күңелле егет ул. Уен-көлке сүзне яраткан шикелле, тәмәкене дә «атып» тартырга ярата. Бирмәсәң, башын чайкый да, «ярар, бер елны бүдәнә симерсә, бер елны тартай симерә», дип куйган була. Ул да үги ана «рәхәтен» күргән малай икән. Ихтимал, шул да якынайткандыр безне. Гаҗәп бу дөнья, кая барма, үги ана да үги бала! Әллә дөньяның яртысын баскан тагы! Бигрәк тә миңа гел очрап кына тора алар.

Гарәфи үз күргәннәрен зарланып сөйләргә яратмый, күптән булып узган бер кызыклы әкият шикелле генә итеп исенә төшергәли. Атасы утынгамы, башка берәр җиргәме китсә, яшь анасы Гарәфине мунчага ябып куя булган, имеш.

— Әй утырам, малай, мунчада бер үзем, әй утырам,— дип башлый ул.— Җылы булса, бәк рәхәт кана, атна буе ягылмаган булса гына арка буйлап суык кыргаяк үрмәли, әттә ләүкәдә дә тешләр тешкә орына. Шулай бөрешеп утыра торгач, чыга бер мәлне ләүкә астыннан пәри малайлары бер көтү килеп. «Әйдә уйныйбыз да әйдә уйныйбыз!» имеш. Мин башта коелып төшкәнием, бактың исә, бер дә куркыр җирләре юк икән аларның. Гел минем тәслүк кыл муен, курай ботлы кырчын малайлар шунда. Түлке койрыклары бар да мөгезләре бар. Башта «Песи, песи, перс!»ле уйныйбыз, аннары «Читәнме-бүзме». «Перс!» дигәндә ачык авыз пәри малае кулын ала алмый кала, мин «шап!» итеп кул аркасына китереп сугам. «Бүз» дип җавап бирсә, «бер чеметкәнгә түз!» дип, беләген борып алам. «Читән» дисә, «бер чеметәм дә китәм» дип, тагын борып алам. Тегеләрнең беләкләре, кул аркалары гел шешеп бетә. Шуннан «күз томалашлы» уйнарга тотынабыз. Мине бер дә тота алмыйлар, ә мин, бер күз белән күреп, койрыкларыннан эләктереп кенә алам тегеләрне. Шулай бер көнне ду күчеп уйнап ятканда, бу малайларны бер кабуда йота торган ата гыйфрит җене килеп керде мунчага. Үзе бер карыш, сакалы биш карыш, авызы унбиш карыш! Капты-йотты, беттен-киттең, тидия! Ә күзләре чәй чокыры хәтле булып янып тора!.. «Фу-у, адәм исе бар монда!» дип кычкырды бу. Минем дуслар минут эчендә ләүкә астына сызып бетте-

ләр. Мнңа нишләргә хәзер? Эш харап бит, күп уйларга ара юк, тоттым да ләүкә өстеннән гыйфритнең башы аркылы сикереп идәнгә төштем, йөгереп килешкә мунча тәрәзәсен баш белән сөзеп ваттым да чыктым да чаптым ялан аяк кар өстеннән! Кайтып керсәм өйгә, ни күрим: өстәлдә табын, чәй токмачы, разный кәрчә-мәрчә. Бер кырыйда югары очның ат барышнигы Каһәфи. Утыра бу төрек патшасыныкы шикелле озын кара мыегын тырпайтып, симез күзләрен мимылдатып. Икенче кырыйда яшь катын. Шулай кара-каршы гына утырып, аулак чәй эчә икән болар. Пәс мин тизрәк кече якка, сандык артына!

Сизми дә калдым: чеби артыннан килгән песи шикелле, мамык тәпи белән генә яшь ана минем арттан чыкты да, сандык кырыенда яткан чүкеч белән маңгайга «шык!» иттереп китереп сукты да. Бер көлтә ут чәчрәде күзләрдән! «Башың бетәсе булмады, имгәк!» дигән зәһәр пышылдавын гына ишетеп калдым, аннары нәрсә булгандыр, белмим. Вәт, денсезне, малай, ә? Сөяркә аркасында бит инде бу...

Мин аның сүзләреннән кычкырып көләм. «Ну, сибәсең дә, малай, карга борчагын!» дим.

— Вәт дуракны,— ди бу.— Ник борчак булсын ул! Минә, ышанмасаң, тотып кара, шуннан бирле маңгай җәнчелеп калды...

— Мунчадагы пәри малайлары да чын инде, алайса?

— Чын! Ипекиләремдер, чын! — ди бу, күзен дә йоммыйча. Алай да ышандыра алмагач: — Бәй, әллә мин аларны шул мунчада ятканда төштә күргәнмендер дип елмая.

Аннары авыл мәзиненә унике яшьтән батрак булып керүен, хатыны бер дә моңа ит-май заты күрсәтмәгәч, базына төшеп, олы бер чүлмәк каймагын ярты ипи белән сыпырып куюын, шуның өчен куып чыгаруларын сөйләп көлдерә.

Рәхәт аның белән. Яшьлеген, шат күңелен җуймаган егет ул. Шушында үзен кыргычлап чын шахтер булырга, уку-язу ягын да эләктереп алырга, шуннан соң гына авылына кайтып, үзен күрсәтергә хыяллана Гарәфи.

Безнең баракта кызыл почмак бар, Сәрвәр исемле матур бер кыз газит-журналлар китерә. Гарәфи аның тирәсендә бөтерелеп йөри. «Давай әле, бетер минем надан башны!» дип инәлә. Безне кичәләр ясарга, спектакльләр куярга да котырта башлады ул кыз. Иң элек үзебезнең баракта бәләкәй генә концерт оештырдык, Гарәфи дә катнашты.

Губернабыз Уфимски,
Өязебез Бирски.
Безнең Бирски кызлары
Төскә матур, килешли...—

дигән җырына бик шәп кул чаптылар аның. Тора-бара күрше рудник «Беренче май» яшьләре дә катнашы белән драмтүгәрәк төзеп, берничә тапкыр театр «уйнап» алдык, клубта кичәләр ешаеп китте. Шул көннәрдә мин көлкегә кала яздым. Ник дигәндә, Сәрвәр тирәсендә Гарәфи генә бөтерелми, мин дә ул матурга гыйшык хаты язган идем. Ә ул усал кыз, әллә үзе, әллә сөйгән егете, минем хатны тоткан да «Шәпи агай» журналына салып җибәргән. Анда эшләүче Җамакай дустым, ярый әле, мине хур итәргә теләмәгән, хатны кире үземә җибәргән һәм әйткән: «Шәйхи дус! «Шәпи агай» синең гыйшык хатыңны бу юлга бастырып чыгара алмый. Итәк-җиңеңне җыебрак йөр, кызлар кызык итмәсен!..»

...Көннәр, эшләр шулай күңелле генә барганда салкын тидереп ютәлли башладым, тән кызулыгы да күтәрелде. Забойда колчедан катламы арасыннан суык тамчы тама аркага. Белмим, шуның шаукымы тидеме, җәйге эсседә коххы-коххы килеп, бизгәк тоткан кешедәй туңып йөрүчән булып киттем. Өстәвенә, ул чакта безнең бәләкәй рудникта

ашханә дә юк, баракта гаиләле кеше тормагач, үзең сатып алып аш пешертү дә мөмкин түгел иде. Шунлыктан, без, буйдаклар, бер ашаганда ярты күмәчне чәй белән «бөгәрләп», каптай кабарган корсак белән шахтага төшеп китәбез. Элекке шахтер: «Ат ите ашамыйча күмер чабып булмый», дип дөрес әйткән, күрәсең. Ипи дә чәй белән генә бурильщик булуы да кыен икән... Җитмәсә, ипие дә нәпач[1] калачы бит әле аның. Әче камыр белән кабарткан ыскырт тәмле, катысы чи каеш шикелле, теш белән тартып та өзеп булмый!..

Ничектер монда партия, комсомол ячейкаларының рольләре дә артык сизелми шикелле, шахта башлыгы да иске белгечләрдән куелган бер кеше иде. Бер җыелышта үзебезнең шушы хәлләр турында чыгыш ясарга туры килде, кызыбрак та кителде бугай, ахры, ләкин миңа җавап бирүче, ашханә һәм икмәк кибете булмауның сәбәпләрен әйтүче булмады. Ә инде бер унбиш көннән соң Рәхматулла Хәлиловтан хат килде. Уралобкомның татбаш бюросын җитәкләүче акыллы һәм зур белемле кеше иде ул. «Маннур туган, син анда Карабаш шахтерларын забастовка ясарга котыртасың, имеш. Үзеңне күреп белгәнгә күрә минем моңа ышанасым килми. Комсомолча ялкынлы булуың яхшы, ләкин ленинча дөрес юлдан барырга онытма. Вакытлы кыенлыклар узар, ашханә дә, бар да булыр...» дигәнрәк сүзләр бар иде анда.

Аптырадым да калдым. Хәер, озакка түгел. Өендә түл җыеп кына ята торган, эшчеләр аның фамилиясен дә белми торган бер организатор бар иде. Хәлиловка шул язып җибәргәнен аңлау кыен булмады...

Хәл һаман рәтләнми, ютәлләү, тирләү, тыңу һаман дәвам итә. Әни искә төшә: аның камзул киеп, йон шәлен иңенә салып, урын өстендә утырганы күз алдына килә. Ютәл нәселгә күчә, имеш, дигән сүз бар... төрлесен уйлыйм... Бер дә әни шикелле иртә китәсе килми бу дөньядан... Берни дә эшләмәгән бит әле мин...

Шахта медпунктында яшь кенә фельдшер ханым бар. Ул миңа климат үзгәртергә куша. Колчедан тузаны, завод газы бик зарарлы икәнен тукый, һич югы, берәр айга саф һавада булырга киңәш бирә. Ул Чиләбе кызы икән. Иң яхшы җир Аргаяш булачагын әйтә, башкорт кымызы белән кызыктыра, ә һавасы бушлай бирелә, ди. Кесәдә таракан туйдырырлык та рәт юклыгын белми ул. Хәер, больничный акчасы билеттан өч тәңкә артып та калды әле. Аргаяшка китеп бардым...

Карабашта узган көннәр, дуслар-иптәшләр турында шулай ук нидер язасым килеп, борлыгып йөрдем. Ләкин уйлар, күргән-кичергәннәр тиз гәүдәләнеп, тиз генә кәгазьгә ятмыйлар икән. Ихтимал, андый көч уянып та җитмәгәндер әле. Аннары ул елларда мин чәчмә сүз белән хикәя, повестьлар язуга читтәнрәк карый идем, бар табынганым шигырь алласы гына. Ә шигырь дигәнең, йөгән кимәгән дала тулпарыдай, миңа баш бирергә, атландырып чабарга бик теләми иде әле. Тик өч ел узгач язган «Колчеданлы таулар өстендә» поэмасында гына андагы тормыш, уй һәм хисләребезне әзме-күпме әйтеп бирергә тырыштым...

Аргаяшта беренче очраткан танышым Әсма Кафиева булды. Мин аны Свердлов каласы буенча беләм, педтехникумның соңгы курсларында укучы Чиләбе кызы иде ул. Бергә аралашып, кичәләрдә, спектакльләрдә катнашкалап йөрдек. Югарак озын зифа буйлы, сыек-зәңгәр күзле, мөлаем төс-битле, тыйнак кына холыклы, уйнап кына бер сүз әйтсәң дә оялудан битләренә кызыл йөгерә торган бу кыз, кыйгач салган башын югары күтәреп, ярым йомык күзләрен билгесез йолдызларга юнәлткән, бары тик үзе генә белгән хисләр эчендә бөтен дөньясын онытткан хәлдә, бик нәфис тибрәнү авазлары яңгыратып мандолина чиртергә ярата иде. Кайберәүләр юри шундый «сихри позалар» ясап

[1] Нәпач — ул чактагы нәпман, сәүдәгәр.

кылаңган була. Юк, Әсма үзенең шундый баш әйләндергеч матурлыкта утыруын үзе дә белми торган кыз иде. Мин аны шагыйрә булыр, яшертен шигырь яза торгандыр дип уйлый идем, ләкин андый «гөнаһсы» сизелмәде.

Менә шул Әсма мондагы татар мәктәбендә укыта, кияүгә чыккан, баласы да бар икән. Йөргән юлымда яманнар гына түгел, яхшы кешеләр дә һәр вакыт очрый торды миңа. Шул яхшыларның берсе булган Әсма Кафиева үзенең ире белән таныштырды. Кантон профсоюзларында эшләүче бу яхшы иптәш миңа хезмәт табып бирде. Ул елларда мондый бәләкәй җирләрдә эш табу бик кыен мәсьәлә иде. Авыл хуҗалыгы һәм урман эшчеләре профсоюзында секретарь булып хезмәт итә башладым. Бу комитетның сайланган рәисе, җәмәгать тәртибендә эш алып баручы Шәриф абый Зарипов, торыр урыным юклыгын белгәч, үз өенә алып китте. Аргаяшның иң аргы башында, тимер юл буенда бәләкәй генә, иске генә алачыктай ялгыз бер агач өй. Өйдә Шәриф абзыйның җәмәгате Шәргыя апа һәм кәрлә гәүдәле, җаенке тәпиле, алама ак йонлы бер эт. Шәриф абзый белән Шәргыя апа, сайлап куш-кандай, икесе дә бер-беренә охшаган әйбәт, тыныч холыклы, саф күңелле кешеләр булып чыкты. Хәтта өч көн саен җылы суда сабынлап юындыра торган этләре дә акыллы икән. Үзенең этлеген белдереп, ичмаса, бер тапкыр да өреп күрсәтмәде.

Элек гражданнар сугышында йөреп, хәзер авыл хуҗалыгы магазинында гади сатучы булып эшләгән Шәриф абзый белән бар гомерен кул эшендә уздырган Шәргыя апаның балалары булмый икән, шуңа күрә алар эт асрарга, балаларга дигән күз нурларын, күңел җылыларын шул эткә бирергә мәҗбүр икән. Телләреннән әйтелми торган бәхетсезлек моңы, бала сагышы, өлешсезлек җәбере бар иде бу әйбәт кешеләрдә.

Аласы утыз сум хезмәт хакымның егерме ике сумын Шәргыя апага бирәм, моның бәрабәренә ул мине үзләре белән бер табында тәрбия кылачак, урын-җир бирә һәм өс-башымны юачак. Калган акчаның алты тәңкәсенә кымыз эчәргә, ике сумын тәмәке төтененә кушып җилгә очырырга исәп бар...

Бакча эчендәге элекке бай йортына сәүдә конторы урнашкан, аның кызыл почмак хезмәтен дә үти торган бер зур бүлмәсендә берүзем утырам. Хәзергечә әйтсәк, местком секретаре буларак, членлык взнослары җыю, кәгазь тегү шикелле бик мөһим эшләр алып барам. Ярты айлап маташканнан соң гына буш вакыт та була башлады. Шигырь язам да шигырь язам. Кимендә биш-алты редакциягә Аргаяш дигән мәшһүр каладан мәшһүр шигырьләр агылып кына тора. Тик ул «мәшһүр»ләрнең уннан бере басыламы, юкмы, калганы «кәрҗин» машинасына төялеп, чүплек базына озатыла...

Безнең ишеләр өчен иң куркыныч урын — гәзитләрнең дүртенче битендәге «редакциядән җаваплар» бүлеге. «Фәлән фәләнскига: «Шигырь»ләрегезне капчыклап түгел, вагонлап җибәрсәгез, «Утильтресттан» премия биреләчәк»... «Кадир Карагайлыга: «Сөяклләрдән сарай салам» дигән «поэма»гызны укыганда тешләр сынып бетә язды...» дигән төслерәк җаваплар бөтен дөнья алдында башыңны хур итә. Бәхеткә каршы дип әйтимме, мин мондый ук үтергеч җавапларга дучар булмадым. «Каләмегез өметле сыман күренгән шикелле күк тоела, сирәкмирәк язгалап торсагыз да ярый...» дигәндәйрәк «канатландыргыч» сүзләр ишетә идем.

Шигырь белән җенләнүдән тыш мин әле, каяндыр уйлап чыгарып, профсоюз һәм башка темаларга мәкаләләр дә язам, хәтта басылгалыйлар да. Тик Уфадагы «Яңа авыл» гәзитенә генә ачу килде: унике әйбер җибәреп, бер җавап бирмәделәр. Казан матбугатының кургаш стенасын да тишеп кереп булмый хәзергә...

Эштән соң Шәргыя апаның үз анам пешергәндәй тәмле ашлары белән тамак туйдыргач, аннары идән астында чиреге белән күперел утырган кымызны чөмергәч, футбол уйнарга чыгып китәм. Әйе, әйе, футбол уйнарга! Мин әле Тоболда чакта ук «зәһәр футболчы» булып киткән идем. Хәтта «тешле» буцы белән үземне туп урынына тибеп, күкрәкне дә имгәтә язганнар иде. Җаен монда Мәскәү-Ленинград якларыннан кымызга килүчеләр байтак була икән. Шулар белән Аргаяш яшьләре бергәләп, тулы санлы бер команда төзеп, тимер юлның түбән ягындагы тигез урында мәйдан корып җибәрдек. Һәр көнне кичке якта яшел чирәм өстендә җан-фәрманга футбол куабыз, гол сугабыз, отабыз-отылабыз, куанычлар-көенечләр сөйләп бетергесез була... Мондагы врач та минем сул үпкәдән «шикле» урыннар табып, сөт белән эчәргә бик әче дарулар һәм нык саклану киңәшләре биргән иде. Барын да җиренә җиткереп булмады. Саф һавада һәр көнне хәлдән тайганчы чаба торгач, аннары әлсерәп кайтып кымызга ташлангач, Шәргыя апаның сихәт бирә торган ашлары белән туклана баргач, ютәл дә бетте, туңу-хәлсезлек тә юкка чыкты. Яшьлекнең ямавы — өстендә, дигәнрәк бер сүз бар бугай...

Сизелми дә көз килеп житте. Футбол мәйданындагы үләннәр ярым саргаеп, куырылып, картайдылар. Алар өстендә ажгырып чабучылар да юк хәзер, команда таралды. Ялгыз аптырап йөрим: ничек монда кыш чыгарсың?.. Озакламый бу авыл җирен тоташ кар басар, дөньяны тоташ җансызлык күмеп китәр, шул бәләкәй генә алачыктан кая чыгарга, кая борын төртергә белми ятарсың...

Шундый кысыр хәсрәт белән моңаеп йөргәндә, «Азад Себер» редакциясеннән хат килеп төште. Мин аны ике-өч кат укыганнан соң гына аңлый алдым, нигдидер ватык-җимерек хәрефләр белән язылган иде ул. Ләкин эчтәлеге бик матур иде аның: газит редакторы Сарим Фәхри иптәш мине эшкә чакырган. Сөенечтән баш күккә тиде. Шул ук вакытта шик-шөбһәләр дә баш калкытты: эшләп булырмы? Килешеп булырмы? Юк җирдән гаеп табып, сөреп чыгармасалармы? Мин инде авызы пешкән кияү бит. Дөнья гел яхшылардан гына тормавын үз сыртымда татып белә башладым. Шулай да якыннарым Шәриф абзый, Шәргыя апа белән саубуллашып, куанычлы тәвәккәллек белән тагын Себергә китеп бардым. Алдагы матур хыяллар, билгесез киләчәкләр җилкендерә иде мине...

## Сүнмәс факел

Редакциянең ике штаты бар икән: редактор, секретарь. Бу соңгы штатның бер өлеше авыл хуҗалыгы-агрономия материалларын штаттан тыш тәрҗемә итүче педагог һәм шагыйрь Кашшаф Рәшит иптәшкә түләнә. Калган житмеш биш сумы — миңа! Я алла, мондый хезмәт хакын минем әле өнемдә түгел, төшемдә дә алганым юк! Шуның егерме биш сумын фатир хуҗасы йолкый. Ләкин барыбер миңа бөя бәяргә житәрлек бу акча!

Сарим абзый Фәхри әйбәт кеше булып чыкты: эшкә жайлап өйрәтә, кирәк урыннарда көлдереп, чеметтереп тә алгалый. Бик хуп, чеметтерсен, түзәрбез, тик өйрәтсен генә! Бу бит минем хыял мәйданым. Бердән, өйрәнсәм, журналист булып китә алам. Икенчедән, иҗатымны үстерүгә дә юл ачык! Баштанаяк эшкә чумдым. Көндез редакциягә кергән хәбәрләрне әзерлим: тотыныр җире табылган һәр хаттан чыпчык борыныдай гына булса да бер хәбәр ясарга кирәк. Алдагы санга макет төзим, типографиягә чабам, корректура укыйм, газит версткасына катнашам. Ул көнне, «табадан төшкән беренче коймак»ны алып,

дурт битне дә яңабаштан укып чыкканчы төн урталары җитә. Башка кичләрдә подписка карточкаларын тәртипкә китереп, хәбәрчеләргә хатлар язып утырам. Юк, аларга гына түгел, Уралда, Тоболда, Себердә үзем белгән иптәшләрнең барына да хатлар җибәреп, «Азад Себер»дә язышырга һәм аны таратырга котырткан булам. Нәтиҗәсез калмады шикелле, ел башыннан гәзитнең тиражы ул чактагы традицион өч меңнән үсеп китте. Бу бәләкәй генә булса да алга сикереш иде. Айга бер тапкыр Себер яңалыкларын күрсәтә торган фото-сәхифә дә оештырып җибәрдек, айга бер тапкыр әдәби сәхифә чыгару мөмкинлеге дә туды. Себернең Кашшаф Рәшит, Хәлил Әмин, Х. Мөҗәй, С. Гафуров, Измайлов шикелле яшь шагыйрьләре һәм беренче башлап каләм тибрәтүчеләре катнашы белән чыгарылды ул. Сарим агай оста фельетончы булып чыкты. Мин язган шигырь, нәсер, хикәя шикелле әйберләр дә, аның таләпчән ярдәм иләге аркылы үзып, гәзит битләренә керә барды. Мондый югары киеренкелек белән яшәү төннәрне дә шигырь язып үткәрергә көч бирә иде...

Безнең гәзит кеше күзенә чалына башлады бугай.

Ерак Көнчыгыштагы Учан күмер учакларыннан, Бодайбодан, Алтай, Бийск, Зайсан, Семипалат, Тобол, Төмән якларыннан язучылар шактый күбәеп китте. Көннәрнең берендә Гариф Галиев дигән бер иптәшнең «Кирпечләр» исемле хикәясе килеп төште. Укып-укып карадык та «кертергә яраклы» таптык. Мин белми идем, ул күренеп килә торган бер язучы икән. Мәскәүдә инде күптән шаулый торган Мансур Крыймов та безгә бер шигырен җибәрде.

Монда эшләгән чагым мине күп нәрсәгә өйрәтте. Дөнья чикләре киңрәк ачылып, күбрәк әйберләр күренә, ишетелә, аңлашыла башлады. Әдәбиятның үткән тарихы, бүгенгесе, киләчәге бар, имеш. Аның теория-поэтика дигән нәмәрсәкәе дә бар икән әле. Шундый «бар»ларның миндә берсе дә юклыгын күргәч, үземнең берни дә белми торган шыр надан икәнемне тагын да яхшырак белә башладым. Әзме-күпме «калып»ка сыяр дәрәҗәдә шома язылган шигырьләр бастыру белән генә эш бетми икән әле, поэзиягә алып килерлек уй-фикерләрең, образларың булу, шуларны чумып алып чыгарлык күлең булу, халыкның тел байлыгын, иҗат хәзинәсен белү дә кирәк икән. Укырга кирәк миңа, укырга! Казанга китеп, берәр уку йортына чумарга кызыгам, бик кызыгам!

Кызыгам да бит, булмый шул әле. Борын төбендә армиягә китү мәсьәләсе тора. Егерме жиденче ел көзендә мин «набор»га керәсе егет. Хәрби хәзерлек үткәннән соң ял бирделәр. Анжеркага кайтып киттем. Үткән елны әти карт шахтадан пенсиягә чыккан да авылга күчкән, егерме чакрымдагы тайга эченә кереп утырганнар. Унбиш-егерме өйлек авыллары «Сухой» дип атала; инеш түгел, чүмечле чишмәләре дә юк, урман чокырындагы саз кизләвеннән су саркытып эчәләр. Каян тапканнар мондый черки оясын? Ник бу хәтле эчкәре кереп, урман әрчеп, төп каерып иңрәнүләр кирәк булган? Ә үзләренә бара торган юл өстендә ачык аланнар буйлап, уймакланып аккан Кәтат суы, Яе елгасы кала. Бер дә шуларны акыл күзе белән күрүче булмады микәнни соң?

Йорт-җирләре дә яңа күченүчеләрнекечә: ишек-тәрәзәсе булса, өйалды түбәсе ачык, капкасы булса, коймасы юк дигәндәйрәк. Картның хәзер яшь хатыннан алты баласы бар икән инде, шуларның берсе бишектә әле. Җиденчесе минем Шамил энекәш, үзләре икәү — барлыгы тугыз кеше бер бәләкәй генә өйдә мыжгып яталар. Ә кораблар корырдай зифа нарат урманы өсләренә аварга тора!

Картның ничектер сөйләгәне бар иде: энесе Галимулла абый белән Кытайда, Хэнган туннелендә эшләп, «баеп» кайткач, Пазый бабай алдына икесе дә йөзәр тәнкәлек микулайски акчаны чыгарып салганнар, имеш. Мин дә редакция «туннеленнән» шундый ният белән кайтып кер-

дем. Теге вакытта «таяк ашап» чыгып киткәннән соң дүрт ел гомер узган, иске үпкәләр юылган, күңелдә ата-ананы олылау хисе өстенлек алган. Кесәдә акча да бар. Шулай булгач, аларның Кытайдан кайтуына ничәмә еллар узганнан соң картның нәкъ үзен кабатлап, аны шаккатырмакчы булам, янәсе! Һәм әйтәсе бик матур сүзләрем дә бар: «Сиңа бик зур рәхмәт, әти, өс-башымны ялангач итмәдең, кече-кара яшемнән укытырга тырыштың, ачлы-туклы авыр елларда да мәктәптән аермыйча, миңа дөньяга чыгу өчен олы юл ачтың» һ. б. һ. б...

Самавар кайнап, сәке өстенә менеп утырды, табынга җыелдык, кала күчтәнәчләре куелды һәм, ниһаять, түш кесәдән советски йөзлекне кыландырып кына суырып чыгардым да әти алдына китереп салдым! Бик эффектлы килеп чыкса да, әти никтер бик ачылып китмәде. Шулай да бик озаклап дога кылды. «Рәхмәт, улым», диде. Күңелнең бик нечкәргән чагы булгач, әлеге теге тәмле сүзләрне каян башларга белми утыра идем, әни кеше үтә беркатлылык белән кинәт сорап куйды:

— Шамил синең җанда түгелме ул, Шәйхелсам?

Мин аңа карадым да аптырап калдым: һични аңламыйм. Ничек соң бу? Әтинең дә сүзсез генә тамак төбен кырып куюы хәтта сагайтып җибәрде. Чынлап та, кайда соң ул Шамил? Мин аны кайдадыр йорт арасындамы, урмандамы — эштәдер, шуңа күренмидер, кич кайтасыдыр, дип бер уйлап алган идем, бактың исә, аны миннән сорыйлар!

— Гел җәүнәй җөреп, дегет саткан акчаның да яртысын гына кайтарып, гел симерүе җитте, гел алып узды, шуңар чыгып качты инде ул! — дип өстәде әни кеше.

Аның баштагы соравында ниндидер борчылу сыман бер аваз ишетелгәндәй иде. Ә соңгы сүзләре белән ул инде әүвәлгечә үз ролендә икәнен күрсәтте.

Көтмәгәндә аның олы малае ундүрт яшьлек Лотфулла сүзгә катышты:

— Юк, без бит гел бергә йөрибез, бер тиен акча тотып калганыбыз юк! — дип кырт кисте ул.

— Син нәстә беләсең соң? Кысылмасана! — диде анасы, малайны читкә чөергәндәй итеп.

Сораштыра торгач, ниһаять, шул аңлашылды: каен тузы, нарат чаерысы хәзерләп, шуннан үзләре дегет кайнаталар икән. Шамил белән Лотфулла шул дегетне тирә-як авыллар буйлап, шахтага илтеп сатып йөриләр икән. Дегет белән ярты авыл шөгыльләнә, имеш. Шамил мин кайтудан ике генә көн элек бу өйдән качып киткән, буш куллай гына түгел, акча үзләштереп качкан була. Ләкин ул минем янга килмәде, кайда булуы мөмкин?

Табын яме бозылды, уйда болытлар куера башлады. Шушылар һәр вакыт берәр күңелсезлек тудырып кына торалар. Шырагайланып карт алдына йөз тәңкә чыгарып салу да көлке бер ахмаклык кына тоела хәзер. Кемнең исен китәрдем? Әллә кайчан киселгән кештәк кисәгенең кемгә кирәге бар соң монда?.. Шулай үзалдыма көеп, эчтә кайнаган ярсуны басып калыргамы, чыгарып түгәргәме белми утырганда, ишектән таза гына гәүдәле, хәлле генә өс-башлы, түгәрәк сакал-мыеклы бер кеше килеп керде, сәлам бирде, исәнлек сорашты, «у-у, кунак егете дә бар икән», дигән булып, миңа кул бирде, аннары егылып китәрлек хәбәр салды:

— Киленнең беренче баласына бәби ашы дигән нәмәрсәкәй маташтыра иде катын-кызлар, хәзрәт. Берәр сәгатьтән Шәмсебану абыстай белән бергәләп безгә рәхим итсәгез, яхшы булыр иде...

— Рәхмәт, Ибраһим,— диде түр башындагы «хәзрәт» әти,— ярар, карарбыз...

*Ахыры бар*

## Гамил Афзал

### Әлмәт яклары

Моңаеп озатам,
Сагынып каршылыйм
Җылы яктан кайткан кошларны.
Кайларга барсам да,
Сагынып кайтам мин
Әлмәттә яшәгән дусларны.

Ак тасма сузылган самолет юллары
Болытлар өстендә югары,
Болытлы көннәрдә зәңгәр моң ябынып
Чайкала Урсала урманы.

Гүя ки ярсыган сабан туй атлары,
Җиде ил,
Җиде юл чатлары,
Елховой, Миңлебай, Бөгелмә яклары
Яңарган, яшәргән чаклары.
Мөгезе дерт итеп
Мезазой сискәнде,
Сизенеп буровой көчкәнне,
Корычтай, алмазлы-атомлы замана
Теш белән таш кыя тишкәнне.

Болынны яңгыратып моторлар үкерде,
Торбалар зыңлавы колакта.
Байраклы бәйгеләр батырлар үстерде —
Даннары яңгырады еракка.
Дөньяны шаулатып
Девонны уяттык,
Фонтаннар атылды бу якта.
Күңелләр аклыгын,
Җиңүләр шатлыгын
Сөенеп яздык без китапка.

Урамнар аръягы яфракка төренгән,
Челтерәп чишмәләр йөгергән,
Кояшта карала карлыган, бөрлегән,
Алмалар аллана — бер дигән.

Тиеннәр сикерә нараттан наратка,
Азнакай юллары наратлык.

Аландай хуш исле көннәрне яраттык,
Күңелнең моңнарын тараттык.
Йөрәктә сакланыр Сарманы, Шөгере,
Талларга төренгән Зәй буе,
Тургайлы таңнарда суларга иелеп,
Таллары тирбәлә җәй буе.

Мин әле гомердә бик күп күрермен
Язларны, җәйләрне, кышларны.
Кайларга китсәм дә,
Сагынып йөрермен
Әлмәттә эшләгән дусларны.

## Буранда

Җир белән күк тоташ ак томан,
Ак томанда дөнья ят сыман.
Кайда гына әле юл башы,
Сакал очы инде ак сыман.
Ак томанда дөнья ят сыман.

Җир белән күк тоташ ак томан.
Бер карасаң, туган як сыман.
Ат дулатып буран эченнән
Чабып кына үтәр чак сыман.
Бер карасаң, туган як сыман.

Чабып кына үтәр чак сыман,
Ялын болгап чапкан ат сыман,
Утыр да кит ерак-еракка,
Яшьлегеңә урап кайт сыман,
Ялын болгап чапкан ат сыман.

## Язгы юаныч

Биек күкләр зәңгәрләнеп киткәч,
Җылы көннәр өмет арттыра.
Бу язны да күрәсе бар икән,
Яз артында яшел җәй тора.

Җәй соңында яткан мул уңышлар биреп,
Сары яфрак сибеп көз килер;
Пошмыйк әле яшьлек үтә диеп,
Туксан бише үтсә, йөз килер.

●

Кешене акларга тырышсаң,
Кешеләр катлаулы хосусән:
Берәүләр шәхесне кысучан,
Берәүләр ярыкка посучан,
Берәүләр тырпаеп торучан,
Берәүләр мал-мөлкәт җыючан,
Берәүләр туганын буучан,
Берәүләр карьера куучан.

Кешене аңларга тырышсаң,
Кешеләр катлаулы хосусәм:
Гөнаһлы кешеләр куркучан,
Тынгысыз кешеләр борчучан.

●

Алтыннар биреп алабыз,
Алкын суларга салабыз,
Мөлкәт кадерен каян белик,
Нужа күрмәгән бала без.

Далада утлар ягабыз,
Калада озак калабыз,
Ана хәтерен каян белик,
Дөнья күрмәгән бала без.

## Тамчылар

●

Тамчы-тамчы нәни шигырь яздым,
Тамчы-ядкәр итеп гомергә.
Тама-тама тамчы ташны тишә,
Ташны тишсен иде шигырь дә!

●

Таштан ташка басып тауга мендем,
Тамчы булып ташка таммадым.
Ташлар басып хур итәсен белдем,
Таш бәгырьле була алмадым.

●

Үлгәннәрнең үче минем җанда,
Килгәннәрнең көче минем җанда,
Былбыл булалмадым бөдрә талда,
Кайнап торган яшен минем канда.

●

Мин утырам күзгә күзне терәп,
Үз намусым белән кара-каршы.
Ялгышсаң да кайчак сирәк-мирәк,
Намус белән тату тору яхшы.

●

Алтын күргәч фәрештә дә азган —
Тар булса да йөргән урамым,
Бер йөк алтын бирсәләр дә азмам,
Кылыч йөзе кебек иманым.

●

Күкрәк киереп башладык җыр:
«Менә, без килдек, без килдек...»
Ата-баба күрмәгән чор.
Муллык, иркенлек! Иркенлек!

●

Уймак дулкыннарын чөеп-чөеп,
Урман буйлап ага бер инеш.
Табигатьнең иң саф моңы диеп,
Мин яратам аны шул килеш.

●

Төн тынлыгы ятып җирне коча,
Кара пәрдә ябып тауларга.
Төнне ярып самолетлар оча,
Кемнәр ашкынадыр, кайларга...

●

Шагыйрь дөньясы хыялдыр,
Кырыйсыз кара урмандыр,
Шигырь язмаган кешеләр
Ни кызык таба торгандыр,
Шагыйрь дөньясы — хыялдыр.

●

Шигырь — агу,
Шигырь — ширбәт,
Йолдызлы хыял кебек,
Эчеп тә туймам кебек.
Эчемдә ут,
Эчемдә нур,
Эчемдә буран кебек,
Буранда торам кебек.

●

Шагыйрь дөнья белән сөйләшә,
Каш җыерып заман тыңлап тора.
Акыллы сүзләрне, теләсә,
Мыек шәрифенә урап тора.

●

Сакалымны җилфердәтеп, дулкынлатып,
Күреп туймас илләрдә лә илләрдә
Йөрсәм иде бер шатланып, ил буйлатып,
Йөз яшь тулган көннәрдә дә көннәрдә,
Җем-җем итеп чаларган каш белән лә,
Патшалардан акыллы баш белән!

●

Данлыларның данына сырыштың,
Дансызларга карамадың.
Бик күпләргә ярарга тырыштың,
Беркемгә дә ярамадың.

●

Бу җирдә яшьлек бар, картлык бар,
Бу җирдә кайгы бар, шатлык бар,
Бу җирдә туу бар, үлем бар —
Барчасын кичергән күңел бар.

●

Тау битеннән сикереп аккан
Саф көмештәй чишмә бул син,
чишмә бул,
Ыбыр-чыбырваклыгыннан
Өстә бул һәм чиста бул син,
чиста бул.

●

Гаделлекне вакыт сизгер тойган,
Һәр асылны үз урынына куйган;
Дөньяларга сыймас тәкәбберләр
Тар кабергә сыйган.

●

Һәр яфракның битен сыйпап узам:
— Тырыш, яшә, сулма!
Бәрәңге булсаң да, гөл булсаң да,
Матурлана дөнья.

●

Үреләүреләүргә менәм,
Үрләрне күрермен дип,
Үрләрдә йөрермен дип.
Үрләрдә болытлар түбән,
Үртәлеп җилләр исә,
Үрләрне җилләр кисә.

●

Тау астында яткан чал арыслан
Чор пульсен капшап үлчи дә,
Исәнме, туган, дип сәлам бирә
Тау башында йөргән песигә.

●

Ялгыз карга чакырып яз китермәс,
Дигән халык кайчан-кайчандыр;
Ялгыз шагыйрь шигъри яз китергәч,
Тәрәзәсен киереп ачкандыр.

●

Бәби тапкан ана сыман
Басулар тып-тын ята,

Болыннар тып-тын ята.
Авыр сулый көзге урман,
Елмаеп таңнар ата,
Көрсенеп кояш бата.

●

Басулар иңендә зәңгәр моң.
Нигәдер ямансы бу айда,
Өзелгән кыл кебек күңел тын.
Җаныма урын юк бер кайда,
Нигәдер ямансы бу айда.

●

Күзләрең күгелҗем күк икән,
Сөйлисе сүзләрең күп икән,
Еласаң яшьләрең гөнаһсыз,
Көлүең таңнарга тиң икән,
Чәчәкләр иркәсе күбәләк —
Табигать баласы син икән.

●

Кулларың — аккошның канаты,
Гүлләрдәй күзләрең карашы,
Каендай буйларың, дускаем,
Җаныма көч бирә көн саен.

●

Ирештереп, сөзештереп юри,
Көнләштереп, үртәп, йөдәтеп,
«Мин-мин» дигән ата шайтан йөри
Кешеләргә этлек өйрәтеп.

●

Күңелсез күк дала, буш дала,
Суык җил сыкрата дөньяны,
Еракта җемелдәп ут яна;
Ни эзләп йөридер, кем җаны...

●

Арт якка карама, як-якка кара,
Вак якка карама, шат якка кара,
Ахмакка карама, әхлакка кара,
Ак якка кара син, саф якка кара!

●

Каты бул, дустым, усал бул,
Мәми авыз булма.
Каты бул, дустым, усал бул,
Әмма явыз булма!

●

Көрән болыт, сүрән болыт
Яварга уйламый да,
Күңеле тулган сабыйдай,
Көлми дә, еламый да.

Көрән болыт, түбән болыт,
Күңелсез иртә кебек,
Давылнымы, яшеннеме
Сагаеп көтә кебек.

●

Кызык түгел яшәү,
    Үрдән-үргә генә,
        Түрдән-түргә генә
            Үтүче булып.
Их, мин эшләр идем
    Урман буйларында,
        Яшел тугайларда,
            Көтүче булып!

●

Дәрәҗәң арту буламы,
Даннарга бату буламы,
Сиңа бүләк, сиңа хөрмәт,
    Аңламассың бу дөньяны.
Дәрәҗәң төшү буламы,
Авызың пешү буламы,
Кичәге дус сәлам бирми,
    Аңламассың бу дөньяны.

**Әдип Маликов**

# ЯШЬЛЕК УТРАВЫМ

ПОВЕСТЬ-ИСТӘЛЕК

I

## Көтелмәгән юл




Сәгыйдәне, ягъни егерме ел бергә тормыш кичкән иптәшемне, курортка озатырга җыенганда, ишектә звонок шалтырады: диң-диң.

— Телеграмма!

Кайгылы хәбәр китергәндә йөзебезгә күтәрелеп тә карамыйча, тиз генә чыгып таю ягын шәйләгән почта кызы бу юлы елмаеплар тора:

— Сөенче, абый!

Мин күзлегемне табып өлгергәнче, телеграмма Сәгыйдә кулында иде инде. Сөенечеңне бүлешергә аңа куш. Андый чакта ул җиңеләеп үк китә, хәтта биеп әйләнергә тотына. Сәгыйдә бу юлы нишләптер тынып калды, серле мәгънә белән алсу иреннәрен генә кыймылдата.

Телеграмма минем кулга күчте.

«Көньяк Сахалинны һәм Куриль атауларын япон империалистларыннан азат итүгә егерме биш ел тула. Сезне, хөрмәтле Әхнәф Галимович,— дигәннәр,— шул сугышларда катнашучы буларак, олы бәйрәм белән тәбрик итәбез, тормышыгызда иминлек һәм корычтай сәламәтлек телибез...»

Бу юлларны мин, әлбәттә, сөенеп, горурланып, тыныч кына укыдым. Ләкин телеграмманың ахырына җиткәч, түземем бетте, дулкынлануымны яшерә алмадым:

— Юбилейга чакырганнар ич!

Күпме гомер узганнан соң, ул чагындагы гади бер сержантны кем хәтеренә алыр да бәйрәм тантанасына чакыртыр икән?

Көне килеп терәлгән. Бүген булмаса, иртәгә юлга чыгарга кирәк. Әйтүе генә ансат. Мәскәү — Южно-Сахалинск самолетына эләгүләр, ай-һай! Билетлар аңа бер ай алдан сатылып бетә, диләр. Бәлки бармый калыргадыр, рәхмәт әйтеп, үзләрен дә юбилей көне белән котлап, җавап телеграммасы гына бирергәдер?

Адәм баласы дөньяга чыкмый, кузгалмый торса, казык итеп утырткан өянке ботагы шикелле, тамыр җибәрергә әзер. Аны тиз генә кымшатырмын димә. Миңа да Сахалинга бармый калырга йөз төрле сылтау бар.

Хатыным курортка җыена, яшелчә-җимеш бакчасы, өй, аквариумдагы балыклар ялгыз кала. Бу — бер. Икенчедән, яңа уку елы башланырга тора. Авылга, әбиләренә кунакка киткән улларыбыз сагынып кайтырлар безне. Аларны кем каршылар?

Сәгыйдә ягына карап алдым. Минем авыр кузгалу гадәтемне белә ул, карар чыгаруымны көтә...

— Бик озак уйлыйсың,— диде хатыным, түземен җуеп,— я, сүзеңне әйт!

Тел очына килгән беренче сүзне әйтттем:

— Барып булмас, ахры...

Юбилей күрмәгәнмени, янәсе.

Сәгыйдә мондый җавапка сөенгәндер дисезме? Киресенчә, мине үшәнлектә гаепләде.

— Обком тикле обком чакыра сине,— диде ул, кырысланып,— мондый хәл кеше гомерендә бәлки бер генә буладыр.

Сәяхәттән баш тартсаң, җүләр булырсың!

Чыннан да, телеграммага обком секретаре үзе кул куйган шул.

Сәгыйдә бераз йомшарып, хискә бирелеп, сүзен дәвам итте:

— Синең өчен бик истәлекле урыннар бит, Әхнәф. Өйдәге ыгы-зыгы бетмәс. Ике кулыңны селтә дә чык та кит.

...Менә мин юлда. Мәскәүгә килеп төшүгә, чакыру телеграммасын тотып, Оборона министрлыгына кердем. Билет, пропуск ягы тиз хәл ителде.

Ике салонлы һава корабле, әллә күпме язмышларны үз канаты астына җыеп, Ерак Көнчыгышка таба оча. Күңелемдә туган уйлар хәзер һич тынгылык бирмиләр. Егерме биш ел күрешми торган арада Утрау күп үзгәрешләр кичергәндер. Берәр полкташымны очрата алырмынмы? Хәтеремдә тирән уелып калган Харамитогэ сопкаларын тизрәк күрәсе килә.

* * *

Артта Европа һәм Азия торып калды. Ярты тәүлек эчендә ярты дөнья үтелгән. Әллә Җир шары кечерәя төшкәнме? Элек, без армиягә барган чакта, Ерак Көнчыгыш бик ерак булып тоелган иде. Кызыл вагоннардан төшеп, ике урында мунча керүебез хәтердә. Күпме солдат ипие ашалганын бер старшина гына белгәндер. Ә бу юлы чибәр стюардесса кыз кулыннан алган тәмле ашлар янына бер телем ак ипи дә житеп куйды. Бөтен юл азыгы шул, хәтта запас төенчегем дә юк.

Сопкаларда, тайга төпләрендә калган пилоткалы яшьлегем искә төшә. Ничә ел буе бер котелоктан ашап, ятсак — бергә, торсак — бергә гомер кичергән сугышчан дусларым бар иде. Берәүләр хезмәт срогын тутырып, туган якларына кайтты. Икенчеләре ятып калдылар, Сахалинны япон илбасарларыннан азат иткәндә, шул җиргә «мәңгелек прописка»га керделәр. Арабыздан китсәләр дә, окопташ дусларны күңелдән җуеп булмый. Каберләренә баш иярмен...

Шулай итеп, егерме биш яз узып та киткәнмени?

Пассажирлар, йомшак утыргычларын яртылаш аударган хәлдә, кайсы йокымсырап, кайсы китап укып бара. Минем күзләрем иллюминаторда. Аста төпсез тирәнлек. Диңгез белән атмосфера катламы бергә кушылып, куе зәңгәр төскә кергән. Әллә океан корабы, әллә катер йөзә шунда. Безгә ул ун мең метр биеклектән тагарак шикелле генә

булып күренә. Татар бугазы биредә шактый киң булырга тиеш. Аның диңгезгә әйләнгән урыны.

Стюардесса кыз салонга чыгып хәбәр итте:

— Самолет түбәнәя, кадерле юлчылар, алда — Сахалин!

Мин иллюминаторга ныграк иелдем. Яр сызыгы күренә. Ул зәңгәр томан белән өртелгән.

## «Южный...»

Сахалин — таулар утравы. Әйтерсең урын житмәгәнлектән сопкалар берсе өстенә берсе менеп утырганнар. Алар һаман үзгәрмәгәннәр: һаман монсу, мәгърур. Түбәләрендә алтын каурыйлы болытлар ял итә. Күккә нур сөңгеләре чәеп, Атау кояшы күтәрелә. Илнең беренче кояшы!

Мангаена «Южно-Сахалинск» дип язылган өч катлы аэровокзал. Капка зурлыгы пыяла ишекләр. Вестибюльдәге фигуралы ак чүлмәкләрдә күз явын алырдай матур чәчәкләр елмаеп утыра.

Аэровокзал тирәсендә арлы-бирле сугылганнан соң, беренче очраган автобус белән шәһәргә китәргә булдым. Самолет рейсын күрсәтеп, Мәскәүдән телеграмма биргән идем бируен. Хәер, бүген ял көне бит...

Шул вакыт вокзал түбәсендә көмеш репродуктордан бөтен тирәюньне яңгыратып, минем фамилиямне кычкырмасыннармы:

— Иптәш Мәүлитов, сезне уң як рәттә... нче номерлы «Волга» машинасы көтә!

«Волга»ны эзләп табуга, пөхтә генә киенгән, ак күлмәк өстеңнән зәңгәр галстук тагып жибәргән бер егет исәнләшеп, кулымны кысты. Машина ишеген ачты да:

— Рәхим итегез, кунак, Сезне Хәрби Совет гостиницасына илтергә куштылар,—диде. Юл буенча ул башка сүз дәшмәде. Шәһәр эченә керә башлагач:

— Газны киметә алмассызмы?— дидем мин.

Егет килеште, бераз жанланып та куйды:

— Мөмкин. Шәһәрне күрәсегез киләдер, мөгаен. Южно-Сахалинскины монда «Южный» дип кенә йөртәләр.

Мин үземне чыннан да көньяктагы шәһәрләрнең берсендә шикелле хис итә башладым. Йортларның беренче катлары пыяладан коелган. Пыяла заллар, пыяла ишекләр узучы-баручыны үзләренә дәшәләр. Эреле-ваклы кибетләрме, мастерскойлармы яки кафемы — эчтә кемнең нәрсә эшләгәне күренеп тора. Шәһәр яшеллеккә төренгән. Тротуар буендагы бөдрә каеннар, биек нарат һәм миләш агачлары, тайгадан рөхсәт сорап, зур бәйрәмгә килгән сыман, шундый да купшы киенгәннәр, шундый да шат күренәләр.

Зур урам чатына житкәч, светофорда яшел ут кабынганын көтеп, бераз тукталып тордык. Тротуар ташларына чек-чек басып, заманча мода белән киенгән кызлар уза. Алар үзләренең жир читендә, диңгез уртасында яшәүләрен тоялармы икән? Арада сумала шикелле ялтырап торган чем-кара чәчле, кысыграк күзле кореянкалар да күренә. Саф рус телендә, бераз тамак төбе беләнрәк сөйләшәләр, гөлдердәтеп көләләр.

Шәһәрне танымадым мин. Ул үзгәргән генә түгел, алмашынган, әрәңадан туган. 1945 елның августында безнең разведка взводы, удар батальон составында, Тойохарэга килеп кергәндә, аның исеме дә, жисеме дә башка иде. Япон шәһәре иде бу. Түбәләре толь яки дранча белән ябылган такта-фанер өйләрдән балык исе аңкып тора. Вак кына өлгеле озынча тәрәзәләр дөньяга ят күз белән карыйлар. Мондый йортлар турында: «Хужасы яшәгәндә тора, хужасы китсә, ишелеп

төшә»,— дигәннәре истә калган. Япониядә кышын да җылы булгач, иламы Микадо үзләрендә урнашкан гореф-гадәтне бозмаска — торак өйләрдә мич чыгармаска боерган, имеш. Әмма баерак түрәләр үз җайларын белгәннәр, менә дигән җылы, матур виллалар салдырып куйганнар. Алары хәзер дә исән. Түбәләре урталай бөгелгән, тәрәзәләре вакыт узу белән җиргә сеңгән хибаркалар да сирәк-мирәк очрап куя. Аларына әле «мәрхәмәтсез» бульдозерларның «кулы» җитмәгән, күрәсең.

«Волга»быз таулар ягына борылды, күләгәле тын тыкрыкларның берсенә кереп китте. Тыкрыкның исеме үк «Тихая» дип атала. Тармакланып үскән карагайлар, яктан-якка кулларын сузып, баш өстендә яшел түбә корганнар. Агачлар ышыгында ап-ак бина күзгә чалынды.

— Хәрби Совет гостиницасы...

Мондый гостиницаларда, белүемчә, командировкага килгән югары чиндагы хәрбиләр: полковник ишеләр, генераллар тукталучан була. Мин, армиядә каныма сеңеп калган гадәт буенча, үземне һаман рядовой яки сержант итеп хис итәм. Рядовой булып йөргән чакларым хәтердә ныграк саклана. Янымнан кызыл лампаслы генерал узганда әле хәзер дә йөрәгем уч төбенә күчәрдәй була. Минем өчен бик үк кулай гостиница булып чыкмас, ахры...

Өстенә ак халат кигән, иреннәреннән елмаю түгелергә торган гаҗәеп мөлаем бер ханым машина янына каршы алырга чыкты.

— Әйдәгез, рәхим итегез,— диде ул, бер үк сүзләргә басып ясап.— Әле генә обком дежурные да шалтыратып белешкән иде, тагын бер иптәш тә сорап килде сезне.

Күңелемнән яшен тизлеге белән сорау йөгереп узды: кем булыр икән? Яшел келәмнәргә йомшак кына басып, өске катка күтәрелдек.

— Иркенләп урнашыгыз,— дип, номерны күрсәтте хуҗа ханым,— әгәр ошамаса...

— Бик әйбәт, бик рәхмәт,— дидем мин, ихлас күңелдән сөенеп,— моннан да артыгы кирәкми.

Эш өстәле, аш өстәле, телефоны, ваннасы... Күз алдыма кинәт ике төрле Сахалин килеп басты: хәзергесе һәм элеккеге мин белгәне. Авыл мунчасы зурлыгы землянкада, ылыс түшәлгән тоташ сәкеләрдә егермешәр солдат бергә тезелешеп яткан чаклар бар иде бит. Арыган тән ястык сорамый, әгәр уятмасалар, шунда берәр тәүлек йокларга да риза була идек.

Юл кирәк-яракларын төрле тартмаларга бушаттым да кырынып алырга булдым. Үлә язып йокы килә. Күңелсез җыелышта утыргандагы шикелле иснәтә дә иснәтә. Хет бармакларыңны тешлә, иреңне чәйнә. Бәлки шифалы тайга һавасының тәэсиредер бу. Самолетта озак очу да исәнкерәткәндер. Исемә төште: Татарстанда бит хәзер төнге уникe, республикамның бик тәмләп йокыга киткән чагы. Тугыз сәгать вакыт аермасы. Яңа режимга күнеккәнче кыен булыр...

Тиз-тиз генә кырындым да, бераз ял итеп алу нияте белән, крахмаллап юган ак җәймә астына кереп чумдым. Озак та үтмәде, ишек шакыдылар. Җирән чәчләренә чал йөгергән, сипкелле йөзле берәү, үз алдына сөйләнә-сөйләнә, бүлмәгә килеп керде:

— Әхнәф Мәүлитов биредә тукталды, диделәр. Ул икәненә шикләнмим. Таныйсызмы? Танымас булсагыз, кул биреп тә тормыйм... Күз галып та маташмагыз...

Исеме җисеменә бик туры килгән шул:

— Рыжиков!— дидем мин, фамилиясен шунда ук хәтерләвемә сөенеп,— я ходай, ник танымаска?! Алексей Рыжиков!

— Иә, йә?

— Николаевич...

Ул йөзендәге бөтен җыерчыклары белән нурланып бер елмайды да урындык артына зур сары портфелен сөяде, аннары сәгатенә күз төшереп, миңа команда бирде:

— Сахалинга килеп, көпә-көндез йоклап ятмыйлар. Подъем! Җыенырга өч минут!

Рыжиков дусларча шелтәләп алганнан соң, тиз киенүемне күреп, сүзен дә кызганмады:

— Молодец, молодец! Запаста тотарга ярый. Хәзер офицермы?

— Запастагы капитан...

Картинага караган шикелле, күзләрен миннән алмыйча, ул бераз артка чигенде, аннары яныма килде:

— Мираж гына түгелсендер бит?! Я, саумы, полкташ!

Битемне каты сакалы чәнчеп алды, борыным тәмәке исен тойды. Без, бер-беребезнең аркаларын каты итеп дөмбәсли-дөмбәсли, ирләрчә кочаклашып күрештек. Шуннан гаепле кешеләр сыман икебез дә тынып калдык.

Мин Рыжиковны 1940 елдан башлап беләидем. Без аның белән беренче мәртәбә Александровск шәһәрендә, Сахалин дәүләт музеенда очраштык. Ул анда фәнни хезмәткәр булып эшли иде. Бөек Ватан сугышы башлангач, Алексейны Совет Армиясенә чакырдылар, дивизия газетасына хәбәрче итеп алдылар. Ул безнең полкка бик еш килгәләп йөрде. Килгән саен миннән солдат тормышы турында мәкалә яки зарисовка йолкып китә, язарга өлгермәсәм, землянкада кунып кала, барыбер җилкәдән төшми иде.

— Гафу ит, Әхнәф,— диде Алексей, шактый паузадан соң,— без сине үлгәннәр исемлегенә терки яздык. Фляга гаепле.

Мин берни аңлый алмыйча, аптырап, хәтта каушап калдым.

— Фляга? Нинди фляга?!

— Бер дә борчылма, хәзер күрсәтәм,— диде Рыжиков, сабыр гына кыймылдап,— кара син аны, ә? Тарихи хата китә язган бит...

Ул портфеленнән газетага чорналган бер төргәк алды да аны сүтә башлады. Төргәк эченнән корсагы яньчелеп эчкә баткан, бераз шадраланган иске фляга килеп чыкты. Су тутырып, билгә тагып йөри торган солдат флягасы. Бер ягында энә күзе зурлыгыдай төрткеләр белән бизәлгән «мемориаль» язу. Рыжиков:

— Менә укы, туйганчы кара,— дип, фляганы миңа сузды. Үзе сүзсез генә елмаеп, сигарет кабызды да форточканы барып ачты.

Укыйм:

«Әхнәф Мәүлитов.
Благовещенск, 1939—1940.
Сахалин, 1940...»

диелгән. Ин өстә әллә биш чатлы йолдыз, әллә йөрәк рәсеме. Анысы җуела төшкән. Ышанмас та идем, барысы да үз кулым белән язылган. Монысына шигем юк. Сорарга булдым:

— Каян килеп юлыкты бу сезгә, Алексей Николаевич? Берәр складта аунап ятмагандыр ич?

— Гафу ит, дустым, мин хәзер аэропортта булырга тиеш,— диде Рыжиков, күп мәгънәле итеп,— коньягыңны әзерләп куй!

Алексей сары портфеленнән ипләп, кадерләп кенә тагын бер әйбер тартып чыгарды. Монысы шактый калын, күләмле иде. Үзе китап сыман итеп тышланган.

Безнең иске подшивкалар, Сахалин дивизиясенең тарихы. Син карый тор... Кайткач сөйләшербез.

«За Советскую Родину!»— дип кычкырып җибәргәнемне сизми дә калганмын. Әйе, безнең газеталар. Поимагына «частьтан алып чыгарга ярамый» дип язылган. Ике битле ул газетаны җыйнаулашып укыган-

нан соң, тәмәкегә ертып тәрә идек... Битләре саргаеп беткән. Бирелә минем дә хәрби язмаларым, зарисовкаларым булырга тиеш. Алар берсе дә үземдә сакланмаган.

Рыжиков китүгә, мин комсызланып подшивканы актарырга тотындым. Тере тарих... Көнелдән җуелмас, йөрәк өзгеч тере тарих. Битләрен ачкан саен таныш исемнәр, таныш йөзләр калкып чыга. Һәр җөмлә артында бер гомер, олы язмышлар тора. Исән калганнар инде олыгайган, аларны сакал-мыек, дөнья мәшәкате баскандыр. Кызларын кияүгә биргәннәр, улларын армиягә озатканнардыр.

Ә үлгәннәр картаймый. Алар тарих хәтеренә, әүвәлгечә яшь-яшь килеш, мәңгелек солдат булып теркәлгәннәр.

Актара торгач, үзем язган очеркка юлыктым... «Ефрейтор Миңнулла». Уртада — фоторәсеме. Пилоткасын кыңгыр салып, туп-туры миңа карап тора. Күзләрендә тормыш яктысы. Миңнулла Миңнекәев... Походта бер йотым суны бүлешкән чаклар булды. Кызлардан килгән мәхәббәт хатларын бергә укыдык...

Баягы сөйкемле ханым каршы бүлмәдән, ачык ишектән, бу юлы үз итеп кенә миңа сүз кушты:

— Рыжиков шалтыратты, ямансуламаска кушты сезгә,— диде ул, кулындагы ак мендәрен кабарта-кабарта,— океан күгенең капкасын ябып өлгергәннәр. Петр Тимофеевич Сердюк белән Сабит Жумакаевич утырган самолет Хабаровскида тукталып калган икән.

Беренче фамилияне ишетүгә, калын таза гәүдәле, солдатлар белән «син» дип, җанына кереп, ягымлы итеп сөйләшә белгән, дивизиянең элекке политбүлек начальнигы подполковник Сердюк күз алдыма килеп басты. 1944 елның салкын кышында, тайгада хәрби өйрәнүләр барган арада, ул миңа партия билеты тапшырган иде. Кулымны кысып әйткән сүзләре әле дә хәтердә: «Син хәзер коммунист. Тормыш иярендә нык утыр, иптәш Мәүлитов...» Аның бу сүзләре гомергә онытылмаслык булып, күңелгә уелып калды.

Ә Сабит Жумакаевич... Минем элеккеге полк командирым подполковник Жумакаев булып чыга түгелме соң? Бу бүлмәне аның өчен әзерли микән әллә?

Хуҗа хатын, уйларымны сизгәндәй, болай диде:

— Полковник белән күршеләр булачаксыз. Ул хәзер отставкада. Бик әйбәт кеше. Уен-көлкеле, шаян. Сахалинга, мин белгәне, өченче тапкыр килүе. Гел шушы гостиницага туктала.

Ханым, үзе мине күрмичә генә, ачык ишекләр аша сөйләвен дәвам итте:

— Узган көз бер кәрзин алма төяп килгән. Берсе-берсе чәйник кадәр. Алма-Ата алмалары, үзем үстердем дип, һәммәсенә өләшеп йөрде.

Мине баштанаяк кызыксыну тойгысы биләп алды. Армия хезмәтендә көн белән төнне аермый торган, үз эшенә ахыргача бирелгән уттай командир иде ул. Полкның тезгенен кулында нык тотты. Таләпчәнлеге, гаделлеге өчен без аны ихтирам итә идек һәм аңардан курка да идек. Ул чагында Жумакаевка кырык-кырык биш яшьләр чамасы булгандыр. Хәзер, димәк, җитмеш тирәсе... Мине танымас, әлбәттә. Өч мең солдат арасыннан кемне генә хәтерләп бетерсен.

«Алма» дигәннән, минем Мәскәүдә алган лимоннарым бар бит әле. Сөйкемле ханыма тәкъдим итим булмаса...

— Юк, юк!— дип, артка чигенеп караса да, «үзебездә, Әлмәттә үсә» дигәч, ышанды, җиңелде. Ул сап-сары лимонны борын турысына китерде, тагын бер мәртәбә рәхмәт әйтте.

Көн кояшлы, матур. Ачык тәрәзәдән чәчәкләр исе бөркелеп керә. Подшивканың саргайган битләрен кыштырдатып, тайга җиле шаяра. Миңнулла рәсеме төшерелгән битне җил бер ача, бер яба. Әллә бөтен-

ләйгә шулай ябылып кына калсынмы? Безнең араларны бит хәзер мәңгелек аерып тора... Юк, булмый. Тарих хәтере бу. Аны күнелләрдән җуярга хакыбыз юк.

Кайчан башланды соң ул утлы сынаулар кичкән солдат дуслыгыбыз. Бергә узган авыр поход юлларын хыялымда бер урап чыкмыйча, күңелем тынычлана алмас, ахры.



II

## Исән булсак, бер кайтырбыз

1939 елның көзендә Башортстандагы Тәтешле военкоматыннан без бергә чыгып киткән идек. Кыңгыраулы атларга төялеп, тимер юл станциясенә кадәр җырлап баруыбыз хәтердә. Аның Мәйсәрәсе, күрәсең, чая кыз булган, «басу капкасын чыкканчы гына...» дип, Миңнулла янына сикереп менде дә шул килеш арбадан төшмәде. Аларны яңгырдан ышыклана торган чыпта белән баштанаяк бөркәп куйдылар. Яңа табышкан ике яшь йөрәк станциягә җиткәнче нинди вәгъдәләр бирешкәндер, беркем ишетмәде. Ишетерлек кенәмени, олау саен гармун үкерә, белгәне-белмәгәне җыр суза:

Сандугачлар да сайрамый,
Сандугачлар да сабыр.
Яшьли сөйгән ярларыбыз
Нужели ятка калыр?..

Һәркемнең үз-үзен онытасы, онытыласы килә, күңелен бушатасы. Өстән салкын яңгыр сибәләп торуын сизмәдек тә бугай.

Станциягә килеп җиткәч, безгә вокзал күрсәтеп тормадылар. Вагон әзер. Ишеге иңенә ачык. Вагон уртасында ташкүмер яга торган чуен мич. Ике якта икешәр катлы сәндерәләр. Алар өр-яңа такталардан. Нарат исе аңкып тора үзләреннән.

Военкоматтан безне озата килүче лейтенант шаяртып:

— Түшәк-ястыкларыгызны җәя торыгыз, мин озак тормам,— диде дә, арабыздан иң озын гәүдәле гармунчы егетне вагон старостасы итеп билгеләп, каядыр китеп югалды.

Ярый әле, менә озатып килүче юк монда, шуңа сөендем. Күңеле тулган әниемнең күз яшьләре военкомат янында коелып калды. Әти алай сынатмаска тырышты, тик читкә борылып, күзлеген генә сөрткәләп алды. Менә Миңнулланың хәле мөшкелрәк. Шундый чая булып күренгән Мәйсәрәсе безгә арты белән борылган да мышык-мышык «балавыз суга».

— Бар, юньсез, биленнән кочакла,— диләр иптәшләре, Миңнулланы дәртләндерергә тырышып. Арада үртәп торучылары да табылды:

— Ояла бит ул, башта, әнә, телефон баганасын кочаклап карасын...

Миңнулла бөтенләй каушап калды. Тал чыбыгыннан үреп ясаган кәрзинен әле кулына ала, әле җиргә куя. Алар сүзсез генә саубуллаштылар. Тик олау кузгалып киткән арада гына Мәйсәрәсе яшь аралаш елмаеп, соңгы сүзләрен әйтте.

— Хатыннан өзмә, яме, Миңнулла! Үзең кайткач, бергәләп укырбыз.

Паровоз бу вагонның кайсы ягына китереп тертер икән? Көнбатышка алып китәрме безнең башларны, әллә кояш чыккан якларгамы? Минем өчен кая булса да барыбер шикелле. Әлбәттә, Казан аша китсәк, шәбрәк булыр иде. Күрәсе иде шул «моңлы Казан, дәртле Казан»ны...

Көн кичкә авышып килә. Станция өйләрендә моңсу гына булып саргылт утлар кабынды. Алар безне җылытмыйлар. Биеп тә җылынып булмый. Өстәге киемнәр җеп бөртек чыланган. Кургаш кебек авыр болыт-

лар куерганнан-куералар. Яңгыр аралаш кар бөртекләре күренеп кала. Ноябрь үзенекен итә. Кемдер болын ягыннан бер кочак печән күтәреп килде. Без дә йөгердек. Чүмәләнең төбе генә торып калды. Без аунап барасы сәндерәләр туган як болынының хуш исе белән тулды. Мичкә ягып җибәрдек. Станция кибетенә «командировкага» киткән егетләр дә үз вакытында урап килде. Лейтенант кайтуга, тәнгә әтәч каны йөгергән, «түшәк-ястыклар» җәелгән иде. Ул кесә фонаре белән караңгылыкны телгәләп, безнең йөзләргә карап чыкты, кырыс кына елмайды.

— Молодцы, егетләр, болай булса югалмассыз!

— Баш исән булса, югалмабыз, иптәш лейтенант,— дип җавап кайтардык без аңа.

Исән булсак, бер кайтырбыз,
Көтегез, абзыкайлар...—

дип җырлап та алды берсе.

Фонарь яктысына шәм яктылыгы өстәлде. Һәркем үзенең чемоданына, капчыгына иелде. Күмәк табынга пешкән тавыклар чыга башлады. Янымда гына Миңнулла. Ул да тал чыбыгыннан үрелгән чемоданын алдына китереп куйды. Кадак шикелләрәк тимер кисәге белән аның кай җиренәдер төртүе булды, чемодан капкачы шылт итеп үзе ачылды. Эчендә пружинасы бар икән.

Без Миңнулла белән военкоматта каралып йөргән көннәрдә генә таныштык. Эчкерсез, гади һәм беркатлы булуы өчен аны үз итеп өлгердем. Егерме биш йорттан торган Җиремаз авылында, урман арасында көтү көтеп үскән ул. Кышын фермада, сыер савучы кызлар тирәсендә «чуалган», ат белән салам-печән ташыган. Үз гомерендә берәүне дә үпмәгән, киресенчә, кызлар аны егып, битен тешли торган булганнар. Чөнки алар күбәү, ә Миңнулла берүзе.

Җиремаз үзе кечкенә бер колхоз. Игеннәр өлгергәч, урман аралыкларына комбайн кертеп тормаганнар, кул белән генә урганнар. Комбайн, трактор руле тотардай егетләр күрше МТСка китеп беткән. Миңнулла иркә егеткә әйләнгән. Җәй көне сыер савучы кызлар латерьда куныл яшәгәндә аны урталарына алып та ята торган булганнар.

Җиремаз кешеләре кыш буе кап, чыпта сугалар, талдан кәрзин үрәләр. Миңнулла да бу һөнәрләрнең һәммәсен белеп үскән. Күрше авыл мәктәбенә йөреп, җиде классны тәмамларга да өлгергән.

Миңнулла чемодан капкачының эчке ягына Мәйсәрәнең фотосын кыстырып куйган. Кыз фотода чибәррәк күренә. Чәч толымнарын ике якка үреп төшергән, колакларына тамчы алка таккан. Ирен турысындагы кара миңе дә сизелеп тора.

— Яратасыңмы?

Миңнулла кинәт уңайсызланып куйды, маңгаена вак тир бәреп чыкты. Шәм яктысында аның йөзе балавыз шикелле сары булып күренә, күзе кысынкыланган. Көлемсерәп: «Әллә синең яраткан кызың бер дә юкмы?» — дип үземә сорау бирде. Мин дәшмәдем, ул да төпченеп, төбенә тоз коеп тормады.

Табыннар кинәеп киткәч кенә, һәммәбезне сискәндереп, вагон тарелкалары чыңлап-чылтырап куйды. Без утырган вагон караңгыда паровоз белән «чәкеште».

— Көнбатышка, егетләр, җылы якка!

Сөенергә иртә иде әле. Чуен тарелкалар чәкәшкәннән соң, безне бер сәгатькә якын урыннан-урынга тәгәрәтеп йөрттеләр. Ахыр чиктә, очыкырые күренмәгән эшелонның урта бер төшенә кыстырып куйдылар. Тимер юл составы, авыр гына кузгалып, көнчыгышка таба юл тотты. Күнелдәге нечкә кыллар чыңлап өзелгәндәй итте. Шул киту — китү булды...

Алдыр Урал буйлары,
Гөлдер Урал буйлары.
Ал булса да, гөл булса да,
Кала Урал буйлары...

Чал Урал тауларын кисеп, кара урманнар аша Себер кинлекләренә чыктык. Без утырган «колхозчы»лар вагоны янына шахта, завод егетләрен төягән вагоннар өстәлде. Йөгәнсез яшьлек туган илен сакларга китеп бара. Зур шәһәрләрдә тукталып тору да юк, ә картага төшмәгән разъездларда берәр тәүлек ятабыз.

Миңнулла вагоннан бик сирәк төшә, торып калудан курка, ахры. Шулай да ул бер көнне каяндыр табып, макароннан бушаган зур әрҗә күтәреп килде.— Вагоннарга!— дигән команданы ишеткәч, аяклары аның күзгә дә иярмәде. Башына әрҗә киеп, тыр-тыр йөгерүен бөтен вагон белән күзәтеп тордык.

— Сынык-санык ипекәйләрне шушы әрҗәгә салып барырбыз, егетләр,— диде хәлдән тайган Миңнулла якташларына,— күрше вагонда ипине буханкасы белән юлга ыргыталар, имансызлар. Азулары житкән...

Әрҗә икмәк сыныклары белән тулгач, сыерларына ашатырлар дип, без аны станция буенда сөт сатып утыручы апаларга бушатып китә торган булдык.

Челтәрле озын күперләр кала, бер урам булып сузылган Себер авыллары... Кулларын сузып, каршыбызга тайга наратлары йөгерә. Эшелон белән җыр бара. Миңнулла күбрәк вакытын йоклап үткәрә. Ферма кызлары тәки йокы бирмәгәннәр сиңа дип, үртәп тә карыйм үзен.

Миңнулла, әлбәттә, армиягә барасы көнен көтеп алган, үзен шуңа алдан хәзерләп торган. Нечкә талдан матур итеп кәрзин үргән, кызлар аңа кулъялык чигеп бүләк иткәннәр. Ә минем өчен бик кинәт, бер дә көтелмәгәнчә килеп чыкты бу китеп барулар. Пермь педагогия училищесын тәмамлаганнан соң, исәбем укуны дәвам итү — вузга керү иде. Я Уфага, я Казанга. Күңелгә кайсысы якынрак? Икесе дә бердәй газиз. Әти белән әни Уфада — берсе «Галия», икенчесе «Госмания» мәдрәсәсендә укыганда бер-берсен табышканнар. Әти хәзер мәктәптә башкорт теле укыта, татар әдәбиятыннан да керә. Галимҗан Ибраһимов, Сәйфи Кудаш, Мәҗит Гафуриларның үзләрен күреп белгән ул. Елына бер тапкыр Уфага барып, шунда калган яшьлек эзләре буенча хыялга бирелеп йөрмәсә, аның күңеле китек була. Еш кына үзе белән мине дә ияртә иде. Уфа минем җаныма әти-әни каны, ә Казан Тукай белән Такташ шигырьләре, Сәйдәш моңнары аша кереп урнашкан.

Мин Уфага да, Казанга да китә алмадым. Педучилищедан соң, закон кушканча, ике ел эшлә, энем, диделәр. Барда районы, Тол елгасы буендагы бер авылда укыта башладым. Буйга житкән кызлар, өрлектәй егетләр... Кызлар арткы партадан миңа карап, күзләрен кыландырып утыралар. Ай ярым гына эшләп калдым. Яңа Указ чыкты. Урта белемле булганнарны унсигез яшьтән Кызыл Армиягә ала башладылар. Теге кыланчык кызлардан котылуыма сөендем генә. Әле котылып бетмәгәнмен икән, иртәгә китәсе дигән көнне алар, кесәмә бөти-хат салып, мине аулак өйгә чакырдылар. Кич буе чикләвек ярдык, Такташ шигырьләрен укыдык, «күз бәйләш-сукыр тәкә» уйнадык. Яшем унсигез аша сикерсә дә, күңелем сабый булган әле... Каралу өчен мине туган ягыма — Тәтешле военкоматына кайтардылар...

Безнең район егетләрен соңгы елларда гел Ерак Көнчыгышка таба озаталар. Сугыш шуннан башланыр, аны япон самурайлары кабызып җибәрер дигән фикер күңелләргә нык сеңеп калган иде. Алгы өч тешен ыржайткан, кулына канлы пычак тоткан күзлекле самурайны аз күрдекмени без плакатларда. Халык йөрәген тетрәтеп узган Хасан күле, Халхин-Гол вакыйгалары зур кисәтү булды безгә...

— Вагоннарга!

Озын эшелон буйлап сузылган көчле команда дулкыны безне ерак, моңарчы күрелмәгән ят юлларга озата барды. Красноярскида кышка кердек, Иркутскида салкыннар кырык градуска җитте. Безгә җырлар буенча гына таныш Байкал күле тунарга өлгермәгән иде әле. Баш әйләнгеч борылмалы юллардан, түбәдә асылынып торган кыя асларыннан уздык. Дистәләгән туннельләрне кичтек. Байкал, Байкал... Моңсу зәңгәр киңлек. Нинди матур, мәһабәт күренешләр. Карталардан өйрәнгән туган ил географиясен үз күзләребез белән күреп, аңыбыз белән тоеп бардык без.

Армиягә китүнен үз романтикасы бар. Мин чик сакчысы булырга хыяллана идем. Кулыңа мылтык тотып, түшеңә бинокль асып, ике дөнья сызыгында керфек тә какмыйча сакта тору үзе нинди зур горурлык! Синең артыңда туган ил җәйрәп ята: бишектә сабыйлар йоклый, әниләр кием тегә, әтиләр корыч коя, җир сөрә... Син шуларның тынычлыгын саклыйсың. Бу хисләрне шигырьдә генә матур итеп әйтеп була. Бер киткәч, китәсе, диңгезләр кичәсе, күз күрмәгән, аяк басмаган зәңгәр утрауларга барып җитәсе иде. Диңгез суы тозлы, йөзә белмәгән кешене дә күтәрә, диләр. Чалкан ятып карыйсы иде диңгезгә!

## Чал Амур буенда

Поезд безне Ерак Көнчыгыш магистраленнән аерып, көньякка — Благовещенск шәһәренә таба алып китте. Киемнәргә ияргән туган як печәнен кагып төшерергә кызгана-кызгана, Амур туфрагына аяк бастык. Тозлы диңгез суларын татып караганчы, безгә җиде-сигез ай буена биредә үз тәнебездән тоз сыгарга туры килде.

Благовещенск Амур елгасы буйлап берничә чакрымнарга сузылган. Урамнары ком гына. Таш казармалар күп күренә. Без хезмәт итәсе полк шәһәр эчендә булып чыкты. Гарнизон капкасын ачуга — бер яклы урам, аннары текә яр. Шунда ук пограничниклар будкасы.

Гарнизон мунчасыннан безне солдат киеменә төреп чыгардылар. Бер-беребезне танымыйча аптырап беттек башта.

Кичләрен тирә-як караңгылык кочагына чума. Электр фонарьлары бик аз күренә. Казарма тәрәзәләренең капкачларын кояш баюга ябып куялар. Дәүләт чиге уза моннан. Амурның теге як ярында Маньчжурия җирләре. Анда японнар хуҗа. Хәйхә дигән шәһәрләре безгә күренеп кенә тора. Кичләрен анда да утлар сирәк кабына. Җилсез көннәрдә атлар пошкырганы, хәтта кешеләр сөйләшкәне ишетелеп куя. Караңгы төшү белән теге ярда япон, маньчжур этләре өрергә тотына. Бигрәк тә айлы төннәрдә сузып-сузып, шомлы итеп улыйлар. Хәйхәдә этләр фермасы бар дип сөйлиләр. Ферма этләрен, имеш, гранат астырып, танк астына керергә өйрәтәләр. Алар күн сумка киеп йөриләр икән. Амур өсте боз белән каплангач, сумкалы бер эт безнең якка чыккан, диделәр.

Безне бер ай чамасы «карантин»да тоттылар. Командирлар күп, кайсысы башрактыр, әле белеп бетергән юк. Әмма старшина Громов дигәненнән инде Миңнулланың коты алынырга да өлгерде. Хәлебезне белергә чал чәчле, башына йолдызлы папаха кигән, бик җитди кыяфәтле бер начальник килгән иде. Урам шикелле озын казарманы дер селкетеп команда яңгырады:

— Һир-р-а-а-а!!!

Старшина рапорт бирде. Полковник тавышын күтәрмичә, үз бәясен белеп кенә исәнләште. Хәрбиләрчә өздереп әйтә торган «Здраст!» урынына, карантин чуар һәм сикәлтәле авазлар белән җавап кайтарды. Җитмәсә, берсе тырышлык күрсәтеп, артыгын сузып та җибәрде:

— Здрастуйте!

Миннулла иде бу. Әкияттәге бичара куян хәлендә калган якташым үзен ничек кенә сиздермәскә тырышса да, старшина Громовның чая күзләреннән ычкына алмады. Полковник чыгып китәч, тегесе: «Бирермен мин сиңа «туй-те»...ләрне дип, Миннулланы куыра да башлады. «Теленне тешләсәң, яхшырак булмас идеме?!» Пәһлеван шикелле таза гәүдәле, киң күкрәкле старшина алдында якташым курчак кебек кенә булып күренә. Керфекләре түбән төбәлгән. Өйрәтелмәгән солдаттан ни сорыйсың инде. Громов үзе дә сизенде, ахры, соңыннан йомшара төште, елмайгандай итте. Без ул көнне тамаклар карлыкканчы, дөньябызны онытып, исәнләшергә өйрәндек. Миннулла гел старшина янында басып торды.

Громовның алдан ук әйтеп куйган сүзе булды: «Мин сезне инә күзеннән үткәрәчәкмен!»

Бу кадәр чуар халыкны, ай-һай, ничек бер төрле итеп бетерәсең.

Дневальный «подъем!» кычкырганда казармага сыеша алмыйбыз. Сәндерәләрнең югары катында йоклаучылар беренче каттагыларның җилкәләренә сикерә, кулларына баса. Итекләр, чолгаулар буталып бетә. Без Миннулла белән киемнәребезне күтәреп казарманың аргы башына йөгерәбез. Чөнки арада иң кыска буйлылар без, шуңа күрә урыныбыз сул флангта.

Шул арада старшина «карантин»ны тезеп, тигезләп өлгергән була.

— Һир-ра-а!

Сафка басканы да, басарга өлгермәгәне дә үрә катып, хәрәкәтсез кала. Кайсы сыңар итектән, кайсы чалбарның бер генә балагын кияргә өлгергән. Ә кайберәүләр итек, гимнастеркаларын кочаклап, ак штаннан гына «смирно» басып торалар.

— Менә күрдегезме бу типларны?! — ди старшина Громов, стройны шулар ягына каратып,— әгәр сугыш тревогасы була калса? Ил чигенә моннан ике минутлык юл. Самурайларның аяк баскан тавышлары да ишетелеп тора.

Кыяфәтләр житдиләнә. Бер дә уен-көлкесе юк. Без монда «пехота» гына түгел, чик сакчылары да икән бит...

Әниләр безне солдат тәртибенә тугач та өйрәтә башлаганнар. Аяклар төз булсын, куллар һавада буталмасын өчен кысып биләүгә биләгәннәр. Дөньяга туры карасын дип, башыбызны мендәргә җайлап, турылап салганнар. Биләүдән ычкынуга, без бу кагыйдәләрне оныткан-быз. Кызык бит, тәпи йөреп киткәннән бирле җиргә ничек басарга белмичә йөргәнбез. Физкультура укытучысына аз гына үпкәм дә калган. Бишенче-җиденче классларда безне физкультурадан өлкән яшьтәге тарихчы абый укытты. Борылa башласа, аягында көчкә басып кала иде ул. Аның башы әйләнә иде бугай. Ә «марш» атлавын күрсәң, гел дә көлке. Аякларын җирдән аермыйча, гәүдәсе белән генә чайкала. Без моны физкультура укытучысының итекләре зур булудан күрә идек. Бәлки ул итек эчендә генә марш атлый торган булгандыр... Лейтенантлар монда барысы да шәм шикелле төз гәүдәле, зифа буйлы. Артык хәрәкәт ясамаслар, артыгын сөйләшмәсләр. Адымнары төгәл, тантаналы. Итекләре шыгырт-шыгырт, куныччы балтырга сыланып тора.

Декабрь салкыны битне кыздыра. Салкыннар кырык биш-илле градуска житә. Юк, командирларның салкынга исләре дә китми. Шлем колакчыннары күтәрелгән, куллар ялангач. Шинель итәге бил каешына кыстырылган. Без шулай стройда йөрергә, җиргә басарга өйрәнәбез. Гәүдәңне җиңелчә генә этәреп, «һайт!» дигәндә бер адым алга күчәсең. Читтән күзәткәндә бик җиңел төсле тоелса да, утың кисканнән дә болай арыта. Тез астындагы сеңерләр җәя бавы сыман тартыла, маңгайдан кара тир ага. Табаннар уттай яна, аяк сөякләренең зыңгылдавы сыз-

лауга әйләнеп, җилекләргә төшә. Кар юк, җир туң, таш кебек каты. Нык басабыз. Безнең адымнарны «теге» яклар да ишетеп торсыннар.

Тәпи йөгереп киткәннән бирле, мин беренче тапкыр аяк табаны астында җир барын тоя башладым. Гади җир генә түгел, илленче параллельдә яткан ике дөнья сызыгы, җир шары үзе иде бу.

Казарма коридорында да, юынырга барганда да строевой адымнар белән генә йөрибез. Миңнуллага бу мәзәкләр ошап куйды, ахры, минем турымнан шык-шык басып, һәр вакыт честь биреп уза. Моңа хәтта старшина да игътибар иткән, бер көнне «молодец, Миннекәев», дип калды.

Миңнуллага карантинда чакта «молодец» сүзен старшина Громов авызыннан тагын бер мәртәбә ишетергә туры килде.

Мондый хәл иде. Гарнизон мунчасыннан хәрби форма киеп чыкканнан соң, чемоданнарга бирка тагып, аларны бер почмакка өяргә куштылар. Миңнулла биркага адресын язмыйча калдырган. Роталарга таралыр алдыннан Громов «карантин»ны җепкә тезде, тал чыбыгыннан үргән чемоданны саф каршысына китереп куйды.

— Хуҗасы бармы?

Беркем дә дәшми.

— Хуҗасы бармы дим?!

Миңнулла белән без һаман сул флангта. Уртада нинди тамаша барганын рәтләп ишетмибез дә. Громов, чемодан күтәреп, безнең якка атлый башлауга, якташым саф алдына атылып чыкты.

— Мин, Миңнулла...— дип мыгырданды ул, ни әйтергә белмичә, тотлыга торган кеше сыман, күкрәгенә сугып,— моя чамаданка!

— Ачып күрсәт!

Хуҗасы бераз «сихерләгәннән» соң, чемодан капкачы шылт итеп үзалдына ачылып китте. Старшина елмаерга мәҗбүр булды.

— Үзең үрдеңме?

— Мин, мин...

Громов Миннекәевнең кулына макароннан бушаган фанер тартма тоттырды һәм әйтте:

— Әйберләреңне шунда бушат!

Тал чыбыгыннан нечкәләп, матурлап үрелгән чемоданны старшина тагын бер мәртәбә күздән кичерде. «Моның берәр җөе бар микән» дигән сыман, астын да, өстен дә әйләндереп карады. Кабатлап сорады ул:

— Үзең үрдеңме?

Якташым бу юлы кыюланып киткәндәй булды. Ул, борынгы солдатларча, үкчәләрен бер-берсенә бәреп, көр тавыш белән җавап бирде:

— Так точно, иптәш старшина!

— Чемоданың миндә булыр,— диде Громов, Миңнуллага ягымлы итеп карап,— без аны хәрби учетка алабыз. Молодец, Миннекәев!

Шушы чемодан авторитетын күтәреп җибәрде дә инде Миңнулланың. Җиремазда үскән сыек тал чыбыклары сихри көчкә ия булып чыктылар. Бу турыда соңыннан. Ә хәзергә...

Сабан сөргән, сандал суккан, каләм тоткан куллар мылтыкка ябышты. Белгән һөнәреңне куеп тор, солдат законнары белән яшә. Карантин срогын тәмамлауга, безне батальоннарга тараттылар. Миңнулла да, мин дә разведка взводына, икебез бер отделениегә эләктек. Разведчик булу өчен кайсы ягыбыз килгәндер, анысын бездән сорап тормадылар. Тик Миңнулла гына үзенчә бер нәтиҗә ясап куйды:

— Күзлек кисәм, мин коеп куйган япон булам. Буебыз да кечкенә. моржадан кереп, юллыктан чыга алабыз...

Старшина Громов та разведчик икән бит. Хәзер ул бездә взвод командиры урынына. Ул инде берүзе ике японны капчыкка салып, аркасына асып кайта ала. Разведкада андыйлар да кирәктер.

Взвод егерме егеттән, ягъни өч отделениедән генә торса да, старшина команда биргәндә карантиндагы шәйгә җибәрә. Аның каршысына гүя биш йөз солдат баскан диярсең. Ул разведка взводын тезгәндә, бер казармада яшәгән пулеметчылар, минометчылар да, корт чаккан кебек, урыннарыннан сикерешеп торалар. Ахырдан, ялгышларын аңлагач, авыз эченнән генә сүгенә башлыйлар.

Минем отделение командирыма ничә яшь биреп тә булмый. Ул тумыштан ак чәчле. Маңгаенда өч җыерчыгы бар. Фамилиясе Батраков. Армиягә кадәр Кизель шәһәрендә милиционер булып эшләгән. Башта безне бер дә өркетергә теләмәде ул. Сабый бала урынына көйләде. Үз акчасына энә, җеп сатып алып, һәммәбезгә өләшеп чыкты. Аякка чолгау урарга да, гимнастеркага ак яка тегәргә дә өйрәтте. Койкасын җыештырса, коеп куйган шикелле була. Бер җыерчык күрмәссең. Салам матрас дип уйламассың да. Кабарып, түшен киереп ята. Мылтыкны ялт кына сүтеп ташлый, безнең күз алдында ялт кына җыя.

— Мылтык, хатын-кыз шикелле, җайлаганны, майлаганны ярата,— ди Батраков. Ә без, хатын белән яшәп карамагач, бик белеп тә бетермибез. Ләкин бу «көйләү»ләр озакка бармады. Хәзер гел аныңча булсын. Койкада бер җыерчык күрсә, урын-җирне туздырып, янадан җыйдыра. Алдына дөрес килеп басмасаң, кире куып җибәрә.

Минем иң теңкәмә тигәне честь бирү иде. Ул замандагы устав буенча, үкчәләр «чек» итеп бәрелүгә, уң кул «ялт» итеп козырек читеннән ычкынырга тиеш. Әле аның тагын кырык төрле вак детальләре бар. Менә шуларның берсе килмәсә, Батраков сине зырылдатып борып җибәрә. Ә мин «ялгышмасам ярар иде» дип, һәр хәрәкәтемне уйлап эшләргә тырышам. Аякларының күплеге турында уйласа, кыргаяк та йөрүен оныта, адымнарын саташтыра, имеш.

Батраков мине бер вакытны җиде мәртәбә рәттән борып җибәрде. Һәр куылу йөрәгемә ук булып кадала. «Син, якташ, нечкә күңелле булма, башыңны дураклыкка сал»,— дип әйтеп тә куйган иде Миңнулла. Юк бит, тотмадым аның киңәшен. Бик нервыма тигәч, сигезенчесендә кире әйләнеп килмәдем, үз хаҗәтем белән бүтән якка йөгердем. Артымнан ике кызылармеецны җибәргән. Берсе — армиягә кадәр тимерче булып эшләгән таза беләкле Себер егете Анохин, ә икенчесе — озын борынлы, камыт аяклы Белодедов.

— Командир сине конвой белән алып килергә кушты!— диләр.

— Конвойсыз да барам,— дидем. Инде суынырга өлгергән идем. Тагын шул ак чәчле Батраков каршысына килеп бастым. Маңгаендагы җыерчыклары арта төшкән. Күзләрендә нәфрәт чаткылары. Үгет-нәсихәт биреп тормады:

— Төнлә казарма идәнен юарсыз!— диде дә сүзен тәмамлады.

— Есть, казарма идәнен юарга!

Швабра белән идән юуны «танк йөртү» дип атыйлар икән. Башына төшсә, «танкист» та буласың дип көлешеп куйдылар.

Кичке аштан соң мин үз миссиямне көтеп уйга биреллем. Укытучы булган, имеш... Менә ничек бөгәләр үзеңне. Ярый ла, сыныш чыкмасаң. Төкерәләр синең белемеңә. Җитезлегең, җегәрең булсын...

Миңнулла минем моңаеп утыруымны күреп, ахры, яныма килде.

— Синең тай өйрәткәнең бармы, якташ?— диде ул тик торганда.

— Юк,— мин әйтәм,— хәтта өйрәткәннәрен дә күргәнем юк.

— Сөйлимме шул турыда?

— Сөйлә...

— Бер ятим колынны тәрбияләп үстерергә туры килде миңа,— дип башлады сүзен Миңнулла, караңгы стена буена чүгәләп.— Җәй буе сыерлар арасында көтүдә йөрттем. Сөеп кенә, сауган сөт эчереп кенә үстердем. Пошн бозавы сыман матур иде. Маңгаеннан сыйпасаң да, күзеннән үпсәң дә карышмый. Илла мәгәр аркасына кул салганны ярат-

мый. Кытыгына тия. Үсеп тай булды бу. Бик тә сылу, бик тә горур. Барыбер йөгән киярсең, мин әйтәм, тай булып кына йөрмәссең. Лутчы үзем өйрәтим. Ничек кирәк алай авызлыкладым да менеп атландым. Күз ачып йомганчы өй почмагына бәреп качты бит мине. Өч сәгать буена сыным катып, тынсыз яттым.

Ни булса шул дидем дә икенче көнне тагын тотып атландым. Авызыннан ак күбекләр чәчри, үрле-кырлы сикерә таем. Күзләре аларган, кыргыйланган. Әй очырып, җилдереп алып китте бу, җир дә бер, күк тә бер, малай. Я үләм, я калам. Бу хәлне эти дә күреп торган икән. Таем инде яр астына сикерә дигәндә, кинәт борылуы булды, мин очып төш тә кал. Ярдан тәгәри-тәгәри, чишмәгә су алырга килгән апаларның чиләкләрен бәреп ектым. Оятыннан җир тишегенә кер...

Без казарманың караңгы почмагында таш идәнгә чүгәләп утырганбыз. Үзенчә мине юату, тынычландыру өчен сөйли инде бу хәлләрне Миңнулла дип уйлыйм эчемнән. Әйдә, сөйли бирсен, әле «отбой»га кадәр вакыт бар...

Ул сүзен дәвам итте:

— Мине сангa сукмады таем, тәрбиямнең кадерен белмәде. Аны акылга эти өйрәтте. Юан арканнан буылмаслык кына итеп элмәк ясады да тайның муенына кидерде. Арканның икенче башын юан өянкегә бәйләп куйды. Хәзер кырыкмышның кытыгын качырабыз, улым, ди. Озын чыбыркы белән чаж да чож, кирәкме ярырга. Таем үрле-кырлы сикерә, яшьле күзләрен мөлдерәтеп миңа карап ала. Арканын өстерәп, һаман өянке тирәли чаба, гел урала бара. Ахыр чиктә, мескен атым, хәлдән тaеп, башын өянкегә салды. Әти дә шыбыр тиргә баткан.

— Менә шулай акылга утырасың ул,— диде әти, тайның куен тирәләреннән, аркасыннан сыйпап. Ә миңа:— Мә, җебеп торма, атлан атына. Тезгенне нык тот! — дип ачуланып та алды.

Бераз тире катканнан соң, таема атланып болынга чыктым. Кытыгы качкан, биеп кенә бара. Бер заман башын югары тотып, шундый да матур итеп кешнәп җибәрде бу. Әйтерсең дөньяга сөрән сала: «Менә күрегез, мин дә эшкә ярадым», янәсе.

Нигә дип сөйләде соң әле Миңнулла боларны?

Без, командирларыбызның каһәренә юлыккан берничә «җиз котелок»[1], төнге йокы исәбенә озын казарма идәне буйлап «танк» йөртәбез, үз тузаныбызны юабыз. Төрлебез төрле яктан. Беребез шахтер, икенчебез рәссам, өченчебез укытучы булган... Бөтен ил буеннан җыйганнар безне — авызлыкланмаган «кырыкмыш тайлар»ны. Арабызда һавалылар да, минем шикелле, тәртәгә тибүчеләр дә бардыр. Ләкин хәрби устав каршында без һәммәбез бертигез. Белмәсәң — өйрәтәләр, теләмәсәң — мәҗбүр итәләр.

Мин һаман бер нәрсә турында уйланам: буйсынырга теләмәгән яшь тайны Миңнулланың этисе өянкегә бәйләп ярган. Күрәсең, башкача мөмкинлеге булмаган. Шул көнгә калмас өчен, үз кытыгыңны үзең качыру яхшырак түгелме?

Армия өянкесе нык. Хәтәр давылларга, гарасатларга каршы торган, тамырларын гасырлар төбенә җибәргән өянке ул. Аны какшата алмыйсың...

Миңа карата гына усал түгел иде Батраков. Миңнулла да бер капты «капкын»га. Дөресрәге, бу юлы бергә эләктек. Якташым тәмәкесез тора алмый. Рус әйтмешли, колаклары күгәргәнче тарта. Төнлә дә торып берне төрә. Әллә Мәйсәрәсен өзелеп сагына инде.

---

[1] Җиз котелок — яшь солдатларны шулай дип йөртәләр.

Бер вакыт аның одеал астыннан гына пыскытып ятуын күргәч, мин дә компаниягә керергә булдым. Батраков моны сизенгән. Иртән уянуга хәтта тәмәке төпчегебезне дә табып алган. Сорау алу башланды:

— Төнлә кайсыгыз тәтәтеп ятты?

— Мин!— дип җавап бирде Миңнулла.

Мин дә аның сүзен үк кабатладым:

— Мин!

Отделение командиры:

— Әле сез группа беләнмени? Моның өчен закон катырак,— диде дә койкадагы ак җәймәне йолкып алды, аны дүрт почмагыннан дүрт кызылармеецка тоттырды. Тәмәке төпчеген җәймә уртасына салдык.

— Шагом марш!

Казармадан чыгып, конюшня янына юнәлдек. Без Миңнулла белән алдан барабыз. Кулыбызда сапер көрәкләре. Безнең арттан ак җәймәле «процессия» атлый. Узганы-күргәне көлеп озата. Туң җирне ярты метр тирәнлектә казып, саргайган тәмәке төпчеген «кабергә» төшердек...

Якташым шул көннән башлап, Батраковка үч итеп дигәндәй, бөтенләй тартмас булды. Ә мин тартуымны ташлый алмадым. Элек, армиягә кадәр, төннәр буе шигырь язып азапланган чакларда, авыздан папиросны бер дә өзми идем. Шул илһам китерә кебек, эзләгән рифмаларны табарга ярдәм итә. Тагын шигырь язасылар булмас дисеңмени? Әмма мин дә бирешмәдем. Отделение командирына үч итеп честь бирергә өйрәндем. Аңа үч итеп, занятиеләрдән соң, турник, брусья янына киләм, «ат» аша сикерәм, хәрби уставларга кадалып утырам.

Армиягә кадәр мин татар, башкорт шагыйрьләренең барлык шигырь китапларын укып чыктым. Бигрәк тә Такташ, Туфан поэзиясе белән җенләнеп йөрдем. Благовещенскига килгәч, әтидән Туфан шигырьләрен сорatып алдым.

Көндезге ял сәгатендә, башкалар мышнап, гырылдап йоклаганда, мин одеал астында гына «Урал эскизлары»н укып ятам. Бер көнне кәгазь кыштырдавын ишетепме, Батраков одеалымны тартып ачты да миңа тиз генә киенергә кушты. Без аның белән аяк очларына гына басып, «Ленин бүлмәсе»нә кердек. Каршысына утыртып, ул миңа үгет-нәсихәт укый башлады. «Син армиягә кадәр укытучы булган кеше, башкаларга үрнәк күрсәтергә тиеш»,— дигән сүзләре бигрәк тә йөрәгемә килеп кадалды. Батраковның белем, үзе әйтмешли, «дүрт класс һәм бер коридор». Ул ничектер шуның белән масая шикелле, һәр җирдә үзенең өстенлеген сиздерергә тырыша. Күрегез, янәсе, дүрт класслыларны.

Командир шигырь китабын кулына алып, теләр-теләмәс кенә актаргалады, аннары коры гына:

— Нәрсә турында?— дип сорады.

— Урал турында,— дидем мин аңа һәм:

Әй, машинист, каула паровозны,
Уралымны өзелеп сагындым! —

дигән юлларны рус теленә тәрҗемә итеп укыдым. Батраковның йөзе кинәт яктырып китте.

— Мин дә Уралдан бит, тагын укы әле,— дип, янымa күчеп утырды. Күрәсең, соңгы юллар аның иң нечкә кылына кагылган. Туган ягын ул да сагына икән...

Булган бар байлык ранец эченә тутырылган: бер көнлек азык запасы, кер кунмаган күлмәк-ыштан, бритва, мылтык чистарту әйберләре, плащ-палатка... «Урал эскизлары» да шунда кереп утырды. Солдат

«амбар»ын артык-портык нәрсәләрдән арындырганда, Батраков аны күрмәмешкә салыша торган булды. Ә башка бер вакытны Эрнест Хемингуэйнең «Сау бул, мылтыгым» дигән романын ул миңа тәки укырга бирмәде.

— Исеме әйбәт түгел, калдырып тор,— диде дә кулыма «Каравыл уставы»н тоттырып куйды

Амур буенда, без хезмәт иткән урында, кыш бер дә Урал кышына охшамаган. Кар ялындырып кына ява, аны да җил каядыр сыпырып алып китә. Мондагы җилләр хәтәр. Биттән сыйпап кына узмыйлар, чыбыркы очы сыман чирттереп-чирттереп алалар. Чалт аяз көнне һич көтмәгәндә ком бураны котыра башлый. Күк йөзе соры шинель төсенә керә. Кояш нурсыз шәүләгә әйләнә. Җил улый, аңа кушылып этләр улый. Амурның теге ягында ферма этләре улый...

1940 елның кышына аяк баскач, тревогалы төннәр ешаеп китте. Эт булып арып, татлы йокыга талганда гына шомлы команда тавышы ишетелә:

— В ружье!

Өч минут эчендә барына да өлгерәсең. Кулда мылтыгың, аркада ранец, иңдә противогаз, көрәк, билдә фляга... Әйе, Громов кулыннан алган фляга. Югалмасын өчен исememne язып куярга да өлгергән идем: «Әхнәф Мәүлитов. Благовещенск. 1939...»

Өстеңә сары тун кисәң, соры шинелең, камыт шикелле булып, ранец әйләнәсенә урала. Аяк астында рәтләп кар булмаса да, чаңгылар бездән калмый. Алар солдатның иңбашына менеп яталар.

Старшина шул арада складтан әллә ничә ящик патрон, яктырткыч ракеталар, гранаталар алырга өлгергән. Взводны ул тревога буенча җыйнала торган урынга туплап, приказ бирә:

— Тулы булмаган мәгълүматларга караганда, Благовещенск шәһәренең төньяк районына дошман десанты төшерелгән. Безнең бурыч — десантның кайсы юнәлештә хәрәкәт итүен, ничек коралланган булуын ачыклау.

«Мөгаен, чындыр» дигән шомлы уй йөгереп үтә күңелдән. Йөзе кара самурай Хасан күле янында, Халхин-Голда эшләгән этлекләрен тагын кабатлый алмас дисеңмени?!

Көнбатыш Европада фашизм котырына, мөстәкыйль дәүләтләрне аяк астына салып таптый. Самурайның да аппетиты аныкыннан бер дә ким түгел. Себер кинлекләренә, Уралга өмет суза ул.

Шунысы гаҗәп, бездә тревога булган төнне Хэйхэ гарнизоны да аякка баса. Ниндидер серле бәйләнеш бар. Элек, Маньчжурия җирләрен японнар басып алганчы, Благовещенск белән Хэйхэ бер шәһәр шикелле булып яшәгән. Ярдан-ярга кунакка йөрешкәннәр, кыз бирешкәннәр. Хәзер дә ике арада элемтә бар, диләр. Ләкин яшерен төстә: күгәрчен тәпиенә тагылган бөтиләр, элемтә этләре ярдәмендә, яктылык сигналлары аша. Шәһәр урамнарының кичтән караңгылыкка чумуы, тәрәзә капкачларының ябылып куюы тикмәгә генә түгелдер. Бездәге хәлләрне, димәк, теге ярга хәбәр итеп торучылар да бар.

Җиде төн уртасында, тревога белән кузгалып, гарнизонның запас капкасыннан билгесез юлга чыгулар беренче тапкыр гына түгел. Таш казармалар бушап кала. Полк таң нурын аяк өстендә каршылый. Ачык далада штык урманы чайкала.

Төп көчләрдән аерылып китү өчен безгә, разведчикларга, берәр сәгать чамасы йөгерергә туры килә. Индәге йөк төрле яктан гәүдәне түбән тарта. Тын кысыла, күз аллары караңгылана. Кием аша пар бөркелә, керфекләргә бәс куна. Менә-менә егылам дигәндә, ниндидер көч сине тагын алга этәреп җибәрә. Батальоннан шактый аерылгач, йөгерүдән

кызу адымга күчәбез. Мина барыбер юртакларга туры килә. Адымнар бәләкәй, старшина бер атлаганны мин ике атлыйм.

Әрәмәлек эченә килеп кергәч, кинәт кар барлыкка килде. Күн итекләрне салып, киез итекләрне кидек, чаңгыларга бастык. Үзе эссе, үзе салкын. Маңгайда — тир, ә бит очы, аз гына карамый торсаң, түгәрәкләнеп туңып та чыга. Белодедовның борыны агарган.

— Ышкы ятьрәк!— дип. Батраков аның янына килде, тукталып тормастан, егетнең бөркетнеке шикелле кәкрәеп төшкән озын борынын бияләе белән үзе үк уарга тотынды, кесәсеннән каз мае (посылка белән килгән) алып сөртте. Батраков ахырдан усал көлеп, кисәтеп куйды:

— Моннан соң борынына чехол элдереп йөре, алла бәндәсе!

Җылы чехол бар безнең. Ләкин аны борынга кидереп булмый...

Белодедов менә дигән чаңгычы булып чыкты «Выжт» итеп алга узып та китте. Аякларына күз дә иярми. Батраков аңа карата: «Җен!» дип кенә әйтергә өлгерде.

Чаңгыга баскач, хәрәкәт җиңеләйгәндәй булды. Аякларны җирдән өзеп атлыйсы урынга, таякларга авырлыкны саласың да чаңгыларны гына шудырасың. Үлә язып су эчәсе килә, иреннәр коп-кыры. Бил каешындагы фляганы селкетеп карыйм, чайкалган тавыш ишетелми. Суы туңган булырга тиеш. Бер арада тиз генә иелеп, кулыма кар алдым. Батраков моны күреп бармак янагач, кар ашау теләген җиңәргә туры килде. Шулай да бияләйгә эләгеп калганын яларга өлгердем. Авызга ком бөртекләре ияреп керде, телгә бияләй тәме йогып калды. Икенче ел хезмәт итүче «карт» солдатлар кесәләренә шикәр төреп салганнар. Ул арыган чакта хәл кертә икән. Бердәнбер юл — хәзерге хәлем турында уйламыйча, башка «дөнья» белән мавыгу. Студент чакларымны хәтергә төшереп карыйм. Такы-токы яшәсәк тә, оҗмах булган икән ул көннәр. Кадерен генә белмәгәнбез. Төннәр буе шахмат уйнап, китап укып утырсаң да, сиңа сүз әйтүче юк. Ял көннәрендә кинога я циркка чыгып чаба торган идек. Тулай торак күршесендәге конфет фабрикасына барып, мичкә тәгәрәтәбез, «акча сугабыз», туйганчы шоколад эремәсе эчәбез. Аңа аз гына спирт та кушалар, фабрикадан кайткач, кәеф шәп була. Икенче көнне маемлата, ашыйсы килми. Кинолык акча янга кала. Ә дәрестән соң, ашау-эчүне онытып, әдәби журнал чыгарулар, аның чираттагы номеры өчен ярыша-ярыша шигырь язулар...

Чаңгы кроссларыннан читләшергә тырыштым мин. «Илһам иясе» кеше спорт белән шөгыльләнә димени?! Әйдә, йөгерә, сикерә бирсеннәр. Ә син, янәсе, муза пегасына атланып чап.

Дөресен әйткәндә, педучилищеда укыганда спорт белән шөгыльләнмәдем диярлек. «Йөрәге ритмсыз тибә» дигән рентген кәгазен күрсәткәч, мине физкультурадан азат иттеләр.

Башкалар чаңгыда чыгып киткәндә, мин бер ялгызым аудиториядә калып, Чкаловларның, Гризодубоваларның батырлыклары, пограничниклар тормышы турында шигырьләр яза идем. Шигырь һәм чынбарлык... Поэзия һәм батырлык... Тормыш үзе, тик тормыш үзе генә поэзия чыганагы икәнен, кәгазь атка атланып, ерак китеп булмаячагын кем уйлаган ул чагында?

Дөнья барысы өчен дә уртак. Шагыйрь дә кулына балта, чүкеч, ә кирәк чагында мылтык тота белергә тиеш. Армия законнары берәүгә дә ташлама бирми. Табигать кочагында аунап, физик яктан чыныгып үскән егетләр биредә үзләрен хәтта өстенрәк тә сизәләр. Алардан калыштыңмы — бетте. Син көлкегә әйләнәсең. Үзеңә сиздермәсәләр дә, артыңда мыскыллап көләчәкләр: «ак сөяк...»

Кем чаңгыга баскан, кайсы берәүләрнең җилкәсенә, киресенчә, чаңгылар үзләре менеп кунаклаган. Әле миннән калышраклар да бар икән...

Сахрадагы дөя кәрваны шикелле, яктан якка чайкалып, озын колонна атлый. Мең кешедә — мең төрле уй...

Сашка Анохин белән Белодедов алдан юл ярып, взвод командирына төрле сигналлар биреп баралар. Анохин җилдереп кенә кире әйләнеп килә дә үзенең күзәтүләре турында старшина Громовка доклад ясый. Аннары ухылдап, тагын янибыздан чабып уза. Ул да арыган, ләкин сер бирми. Андый кеше бер егылса тора алмаслык булып егыла.

Анохинның аяклары озын шул, чаңгылары да үзләре шуып тора. Көнләшмәс җиреңнән көнләшерсең...

— Прива-а-л!

Ранецыңа башны терәп, аякларны югары куеп, изри-изри тәмәке төтәтүләр... Керфекләр авырая, күзне йокы баса. Шул арада әллә нинди төшләр күрергә өлгерәсең. Ун минут эчендә арыганлык бетми, киресенчә, аны бөтен буыннарың белән тоя башлыйсың.

Приваллар ясый-ясый, без ул көнне кырык чакрым җир үткәнбез. Полк ике калкулык арасындагы әрәмә буенда вакытлы лагерь корып җибәрде. Янибыздан гына, мылтык таганнарын аударып, кыр кәҗәләре чыгып чапты. Аларның үз дөньялары.

Бер-бер артлы солдат учаклары кабынды. Котелокларны чишеп алып, чәй кайната, ботка пешерә башладык. Батраков взвод өчен дүрт буханка кара ипи алып килде. Алар кирпеч сыман шакылдап торалар. Балта белән генә чапкаларлык.

— Сугыш вакытында сиңа мичтән генә чыккан җылы ипи биреп тормаслар,— ди Батраков,— учак өстенә куеп эретегез.

— Грузия шашлыгы ясыйбыз,— дип көлешәләр егетләр,— кызганыч, Кавказ кешеләре юк монда.

Чыннан да, арабызда җылы як «фрукты»ларыннан берәү дә күренми. Күбесе Башкортстан, Татарстан малайлары һәм Себернекеләр. Безнең турыда нарком «кырыс табигатькә бирешмәстәй чыдам халык» дип уйлый микән әллә? Ә сугыш дигәнең әкият түгел. Ул чынга әйләнде. Яман аты чыккан «Маннергейм линиясе» бөтен дөньяның игътибарын үзенә тартты. Ленинград тирәсендә канлы сугышлар бара. Фин чаңгычыларының тәвәккәллеге, житезлеге турында батальон комиссары бер дә киметмичә сөйләде. Ленинград тирәсе ут сулый. Шуның ялкыны безгә тия.

Кара пәрдәсен бөркәнеп, тау итәкләреннән, әрәмә буйларыннан төн шуыша.

Яктырак янадыр йолдыз
Төн кара булган саен...

Учаклар да шулай. Алар, шәһәр утлары сыман, балкып, җемелдәшеп торалар. Битне ялкын, арканы салкын куыра. Куллар чолгау киптерә, ә уйлар — еракта. Мең кешедә — мең төрле уй...

Урта буйлы, төп сыман нык, таза гәүдәле Башкортстан егеге Аркадий Петров күзләрен бер ноктага төбәп, тынып калган. Милләте буенча ул чуваш. Татарча да аз-маз сукалый. Ни турында уйлый икән? Тракторын сагына булыр. Петров күбрәк «ЧТЗ» турында сөйләргә ярата. Ана еш кына Белодедов та кушыла. Армиягә кадәр алар икесе дә механизатор булганнар. «Эх, танк училищесына эләгә алмадык бит».— дип уфтанып та куйгалыйлар. Белемнәре житми, алты класс кына. Ә мин, юләр, пехота училищесыннан баш тарттым. Ун класс тәмамлаганнарның һәммәсен диярлек карантиннан ук җыеп алдылар. Кайсысын Хабаровскига, кайберләрен Владивостокка хәрби мәктәпләргә укырга җибәрделәр. Ник юләр булыйм, минем укытучылык һөнәрем бар ич. Ике елымны тутырам да яраткан эшемә кайтам...

Миннулла белән икебезгә — бер котелок ботка. Икенчесендә — чәй. Минем бер кабасым да килми. Шикәрләп чәй генә эчтем. Тәнем дер-дер

калтырана. Битләрем, кызыша, уттай яна башладым. Тизрәк казармага кайтып, салам матраска авасы иде...

Хәлем торган саен начарлана барды. Тигез җирдә дә абына-сөртенә генә атлыйм. Отделение командиры Батраков мине култыклап алды да йөгертергә азаплана. Ахыр чиктә ул түзмәде, чаңгыларымны Анохинга, мылтыгымны Белодедовка бирергә кушты. Миннулла өлгеррәк булып чыкты: «Үзем!» — диде дә, миннән рөхсәт сорап тормыйча, чаңгы бавына ябышты. Якташым алдында үземне гаепле, башкалар каршында кимсетелгән итеп сизсәм дә, ләкин нишлим. Алар әле минем авыру икәнемне белмиләрдер дә. Әгәр бу турыда отделение командирына әйтсәң:

— Кар ашагансыңдыр!— дип, җикереп кенә куячак. Әйе, ашадым, түземем җитмәде. Бик сусагач, командирым күрмәгән арада бер уч кар әләктереп капкан идем.

Күк йөзе кара, йолдызлар кызыл төстә. Йолдызлар сикергәләшеп биешеп торалар. Мылтыгымны Белодедовка бирмәскә булдым. Солдатлар сугышта мылтыкларын кочаклап үләләр. Ә син поход барганда шул юеш борын алдында коралсызланып калырга тиешмени?

Казармада чакта отделение командиры әйткән сүзләр һаман колак төбендә: «Хуш, мылтыгым...» Исеме үк әйбәт түгел...» Менә хәзер шул сүзләр күңелемнән ут булып йөгерде.

— Мылтыгымны бирмим!— дидем, җан ачуы белән читкә тайпылып,— шунда ятып калам.

Батраков миңа:

— Чираттан тыш бер наряд! Кабатла приказны!— дип ысылдады.

— Есть, чираттан тыш бер наряд...

Мылтык үзем белән калды. Шул арада безнең янга Громов килеп житте. Ул эшнең нәрсәдә икәнен белеп, миңа артын куеп иелде дә әйтте:

— Кочакла муеннан!

Старшинаның тавышында зәһәр ирония сизелде. Шунда егылып кына үләсе иде бит. Взвод командирының җилкәсенә менеп атлап да бөтен полк алдына адәм хуры булып бар, имеш. Ярый, эш аңа барып житмәде. Громов отделение командирына санитар бричкасын көтеп алырга кушты. Без Батраков белән икәүдән-икәү генә юл читенә чыгып бастык.

Чайкалып, талгын гына басып, укчы роталар килә. Каска, котелоклар ай яктысында ялтырап-ялтырап куялар. Очсыз-кырыйсыз колонна агыла. Урман полосасы шикелле. Миңа да шул урман эченә кереп югаласы иде. Булдыксыз булып, игътибар үзәгендә калма икән. Полкташларың белән бергә, бер сафта атлау нинди зур бәхет...

Без көткән бричка килеп житүгә, Батраков мине санитар карамагына тапшырды да үзе, бөкресен чыгарып, колонналар читеннән алга таба йөгерде. Минем аркада ул хәзер ухылдап, хәлдән таячак. Ул да бит иңенә без күтәргән йөкне аскан. Походта иң кыены — куып житү.

Бричкага утырып озак бара алмадым, аякларым өйый, тәнем элеккедән дә ныграк калтырана башлады. Санитар миңа арба читенә тотынып тәпи-тәпи атларга кушты. Күпме атлаганмындыр, хәтерләмим. Юл буенча йокымсырап, әллә нинди төшләр күрә-күрә бардым. Янымда гына эти. Ул читкә борылып, күзлеген сөртә...

Педучилище залында музыкадан имтихан тотам икән. Бер вакытта да әрләүне белми торган музыка укытучысы, сорау билгесе сыман, бөкре гәүдәле, кылыч борынлы карт, рояль көенә җырларга куша миңа. Күпме генә тырышсам да, тавышым чыкмый. Тулай торак бүлмәсендә бергә яшәгән иптәшем, бакыр башлы Биктимер, кыюлык өчен дип миңа бер стакан вино салып бирә. Шуннан «Галиябану» көенә җырлый башлыйм...

*Ахыры бар.*

## Илдар Әхсәнов

# Бәсле гөлләр

I

Көтәсеңдер:
«Шуннан ары,
Оясыз бер кош кебек,
Йөрмәс, кайтыр...»
Юрауларың
Бетмәде шул юш килеп.
Үкенечләр белән калдың,—
Яшерен түгел, күз алды:
Ваклыклары бу дөньяның
Арабызга боз салды.
Йолкынмасын өмет, сүндер,
Җилләр каршы борылган...
Сулкылдатып үтте нидер
Нәкъ йөрәгем турыннан.
Оныттырыр, дидем, дала
һәм кыены эшләрнең.
Ерагайган саен ара
Түзә алмасым искәрдем.
Юк, сүнәргә түгел өмет,
Тиккә булмас юраулар:
Аера белгән юллар кебек,
Кавыштырган юллар бар!
Шулай булыр иде бәлки,
Җаным белән тартылып,
Кайтып килер идем тәки,
Башка төшкән кар кебек.
Син елмаер идең миңа
Шундый якын-якыннан;
Карадыммы күзләреңә,
Яз кояшын чакырмам.
Эсселәнер иреннәрең,
Тәндә ялкын кабыныр.
Кояш синең бу халәтең
Язга баглап калдырыр.
Сагынулар,
Юксынулар,
Күпме сабыр булмасын.
Берьюлы, әй, китереп кочар,
Ычкынган күк буасы.
Ничек үткән көннәр синсез,
Ничек синсез йөрелгән!

Гөл шикелле ихтыярсыз
Нур чәчелер йөзеңнән.
...Хыял гына болар бар да,
Тынгысыз юл сайладым:
Чакыруы тибә канда
Бер сынаган тайганың
Асыл ташны моннан эзлә,
Монда якты өметең...
Шаулый Себер, җырлар үзгә,—
Иягенең иңе киң!
Кәтмә монда, табалмассың,
Җиңел табыш, җиңел эш.
Бер каргасаң Себер кышын
Яратырсың мең өлеш!
Әйләнмәмен салкын ташка
Кырыс таулар холкыннан.
Йөз төбәсәң башка ярга,
Ул кадәрле йолкынмам;
Тик санама ялгыз итеп,
Сүзен егар көчсезгә;
Ташлама син артык рәнҗеп
Кәтәр сәгать чиксезгә.
Сулар койса өсләремнән,
Синерактан җылыттың.
Себер гизәм, итәгенә
Тотынып мин болытның.
Киң тайганың ак җәймәсе
Онытырды төсләрең;
Урал тавы әйләнәсе
Тулгый сагыну хисләрем...
Иңнән төшми майлы кием.
Кайчак уйлап торам да,
Җир карага манган, димен,
Югалмаска буранда.
Культбудкага кайтып кер дә
Шул киемнән ау, димәк...
Ә син миңа кибетләрдә
Эзлисеңдер ак күлмәк!
Шаулап тора урманнарың,
Безнең эштә ул шулай:
Забойларда бораулларның
Алмаз теше кыршыла.
Сулышлары белән башка
Бу дөньяга күз ачкан;
Кеше җаны, тормыш кушкач,
Чыдам икән алмаздан.
Юк, яктырмас иде күңелең,
Кайтып күреним ишектән.
Ак карыдай тау иленең
Пакь булуга ни җиткән!
Сайламадым бүтәнен:
Күңелемдә атап сиңа
Бәсле гөлләр йөртәмен.
Нинди сынаулары кабат
Килмәсеннәр ялганып,
Мин тирәннән кояш табам
Уятырга тайганы!

## II

Кар илендә тоташ мәрмәрдән
Шундый сарайлар мин төзедем.
Күрсәң икән килеп бер генә,
Явын алырлыктыр күзеңнең.
Җил хакимлек итә аларда.
Эшсез ятып түзә-түзә дә
Бер ташлана текә тауларга,
Бер ашкына ярсып үзәнгә.
Юкка эзләр сине...
Кар көртен
Ташлап тауның үзенә мираска,
Югала җил өзеп өметен.
Мин дә китәм бире кайтмаска.
Көннәр барам,
Айлар барам,
Ел барам,
Сызлатканчы тәмам җилекне.
Нурлы хәзинәгә юл ярам,
Серләр ятмасына җитеп мин.
Баш очымда — зәңгәр күк йөзе,
Чал кыялар иңе — иңемдә.
Урманнарның карлы керфеге
Ун сискәнә көнгә кимендә.
Йолдыз чагыла гүя чем-кара
Җир маен син учка алдыңмы;
Разведкага кабат чакыра
Вышкаларның корыч адымы.
Хөр яшәргә үзең рух биргән:
Күрешмәбез бәлки тиз ара;
Күз алдымнан китмәс гөлләрдәй
Иртәләрен кояш кызара.

## III

Аланлыкта,
Әкияттәге төсле,
Көрт иңенә будка сыенган.
Нур биешкән чишмәсенә тикле
Пошиларга изге тоелган.
Балавызлы чыршыларның иңен
Мамык шәлләр урап җылыткан;
Эзләгәндәй ак чәчәкле көнен
Түбән игән башын шомырткай.
Разведчиклар ярган сукмакларга
Өермәләр карлар ташыйлар.
Салкын тимер дөнья шаулатканга
Өне алынып кача пошилар.
Сагаялар әле шикләнүдән,
Без — зыянсыз халык, югыйсәк.
Ник тарсыныйк,
Әгәр бер чишмәдән
Сулыш кабынганчы су эчсәк.
Ышанычны җуймый үз күгенә,
Дәрәҗәне бер көн төшенеп,

Якынлаша поши песи генә
Яккан учагына кешенең.
Күзләрендә шәүлә уйнар аның...
Сөенеч, әй, булмый басынкы:
Җир куеныннан бөркеп кайнарлыгын,
Сәлам бирер утлы косынка!

## IV

Кышның әле монда үз нужасы,
Күк йөзендә чыңлап ай йөзә.
Йөрерсең дип кайчак сызасың,
Күпмегәчә шулай зилзилә?
Гамьсез үткән яшьлек көннәреңнең
Сүтелмичә булмас йомгагы:
Сабан туйларында йөрәгеңнең
Нинди дәртләр белән янганы...
Ярап тора иске тарихларың,
Сөйлә кушып чынын, ялганын.
Син тайгадан сора ир-атларның
Башын нигә кырын салганын.
Сүзсез калып шунда шашкан хистән,
Күмер өсти мичкә берәве.
Ул моңсу да, ул татлы да икән
Сагыну учагының көйрәве...
Талганчы бер күзәт таулар ягын
Сагышланып йөргән көнеңдә.
Күңелгә син яктылыклар салдың
Яз кояшы булып килдең дә.
Ышанычым белән канатлымын,
Кичерергә әзер барысын.
Кар аланын кочып капланамын
Синдәй сөенечем бар өчен.
Синең өчен, ерак кояшым ла,
Шундый киңлекләрем бар өчен.
Бәсле гөлләр яна баш очымда,
Язларыма төбәп барышым!

1972—73.

Әхсән Баянов

# ҺӘЙКӘЛ

ДРАМАТИК ПОВЕСТЬ

## ЕРАК АВЫЛ

Икмәк.
Икмәк — җирнең үзе төсле,
Түгәрәк.
Ераклардан килгән илбасарлар
Тырышканнар ашап бетерергә аны
Телгәләп.
Ирек өчен яуга күтәрелгән
Баһадирлар тоткан икмәкне
Тартып алып, ачлык туен, үлем туен
Бәйрәм итмәкче
Булган алар.
Сабый ирек кулындагы икмәк телемен
Тартып алып, биер-уларга
Теләгәннәр алар, теләгәннәр киләчәкне
Ачлык кулы белән буарга.
Теләгәннәр аяк кына баскан
Сабый өлешен шулай таларга.
Хәтәр юлга чыгып киткәнсең син, әткәм,
Ирек куймас өчен аларга —
Илнең гомерен, бәхетен дауларга.
Күрәм сине ерак шул елларда,
Талчыккансың үзең, аргансың.
Ерак авыл өе — кара төн.

Заһит. Син ул хәтле кайгырма әле, Арслан, баш кайгысы түгел ләбаса.

Арслан. Баш кайгысы бу, Заһит, баш кайгысы, командованиенең заданиесе үтәлми дигән сүз.

Заһит. Әй, без генәме дөньяда! Бер без үтәмәгәннән Армия җимерелмәс. Кызыл Армия бит ул!

Арслан. Без бу эшне харап итсәк, бүтәннәр корал китерә алмаса... Шуннан ни булыр? Колчак көчле! Көчле дошман!

Мәгъдәния. Көчле белән сүз көрәштермә, дигәндәй. Көчле икәнен белә торып ник сугышасыз, сугышмагыз.

Ахыры. Башы 10 санда.

А р с л а н. Менә сезнең кебек ахмаклар әдәм тесле яшәсен дип. Менә бу сукыр лампалар бетсен дип. Сугышабыз һәм җиңәчәкбез. Халыкның каралыгын, аңгыралыгын да җиңәчәкбез.

З а һ и т. Халыкны яманнарга ярамый, безнең халкыбыз бөек, әйбәт халык.

А р с л а н. Бөек, ләкин аның наданлык дигән әшәке дошманы бар. Уйлап карагыз: без кем өчен сугышабыз? Шушы халык өчен, бәхетле яшәсеннәр дип. Ә алар? Менә шушы авыл кешеләре? Юк, юк! Аңласалар, соңгы ризыкларын бирерләр иде алар безнең Кызыл гаскәр өчен. Бушка бирерләр иде. Ә без акчага, алтын акчага да бер йөк ашлык таптык. Бөтенесе бер йөк!

М ә г ъ д ә н и я. Төрле кеше бардыр инде.

З а һ и т. Бу тирәгә килмәскә кирәк булган безгә. Шундыйрак авыллар булып чыкты...

А р с л а н. Дөрес, бүтән чакта ярты көн арасында олау тула торган иде.

З а һ и т. Анысы дөрес. Бу тирәнең элек-электән даны киткән: саранлык, караклык белән.

А р с л а н. Чамадан тыш бай халык монда. Безгә каршы!

М ә г ъ д ә н и я. Иртәгә бүтән авылларга китәрбез. Мә, минем хөрмәткә *(аракы бирә).*

А р с л а н. Юк, аракысыз гына — давай, ял итәбез. Әйдә, Мәгъдәния! Иң шәп көеңне! Трам-та, трам-та та-та-таля, тралля-ля, ля, ля... Их! Яле!

М ә г ъ д ә н и я *(бии).* И-их!

Яратуымны да белдең,
Сизмәгәнгә салыштың шул,
Күрмәгәнгә салыштың.
Авыру төсле күчәр сиңа,
Тынгы бирмәс, бирмәс сиңа
Минем сагышым.
Сагышым.

З а һ и т. Әйбәтрәк, тагын да шәбрәк җырла. Син бит безнең шансонетка хәзер. Без буржуй түгел, без — революционерлар.

М ә г ъ д ә н и я *(ачу белән).* Күрерсең әле син минем нинди шансонетка икәнне.

А р с л а н. Дөрес, кимсеттермә үзеңне. Молодец! Трам-та-та! Трал-ля-ля-ля... Эх, Мәгъдәния!

М ә г ъ д ә н и я *(аны кочаклап).* Арсланым минем, җүләрем! Мә, минем стаканнан! Исерергә булгач, исерергә! Безгә барыбер!

З а һ и т. Исерергә булгач, исерергә!

А р с л а н. Эчегез, ләкин акылны түгел.

М ә г ъ д ә н и я. Бүген акыл кирәкми.

А р с л а н. Минем хөрмәткә.

М ә г ъ д ә н и я *(эчә).* Синең хакка *(җырлый).*

Китәм инде, син каласың,
Эзләсәң дә табылмам шул,
Үкенерсең — мин булмам.
Үргә табан агар сулар,
Юлын алыштырыр җилләр,
Ә мин борылмам.
Борылмам.

З а һ и т. Син дә бер генә күтәр инде Сылубикә хөрмәтенә.

А р с л а н. Мине исертеп сезгә ни бар?

М ә г ъ д ә н и я. Күңелдәге бөтен чүп-чарны юып китсен әле. Мә!

А р с л а н. Күңелгә чүп-чар тутырып йөрергә киңәш итмим мин сезгә.

Әхсән Баянов ◆ Ләкләк ◆

Мәгъдәния. Бернинди чуп-чар юк. Син ялгыш аңладың: вактөяк хәсрәтне димәкче идем мин *(җырлый).*

Ашыктырма соңгы кичне,
Болай да бик тиз үтә шул,
Аерылыр сәгать җитә.
Минутларга еллар сыйсын,
Бер гомерлек хисләр тулсын
Шушы бер кичкә,
Бер кичкә.

Арслан *(уйланып).* Ярый, сез кыланыгыз, миңа җитте.

Заһит. Арлы-бирле сугылып, үгетләп, янап, кычкырышып, ялынып, тәмам йончыдың син, Арслан.

Мәгъдәния. Әйе шул, син аргансың. Ял ит булмаса, бераз йоклап ал.

Арслан. Йоклар идем, бик йоклар идем.

Заһит. Мин сакка калам. Нәрсә, ышанмыйсыңмы?

Арслан. Сиңа ышанам да бит... Монда...

Заһит *(пышылдап).* Аны *(Мәгъдәнияне)* әйтәсеңме? Курыкма, ирек куймам.

Арслан. Курыкмыйм. Курыкмыйм. Сиңа мин ышанам. Но кара. Йоклыйсы булма.

Мәгъдәния *(якын килеп).* Күрше бүлмәдә урын җәелгән. Әйдә, үзем кертеп яткырам.

Арслан. Күрше бүлмәгә генә үзем дә чыга алам мин. *(Китә башлый да туктала.)* Заһит! Кара аны! Әгәр йокласаң, сине иртәгә аягыңнан күккә асам.

Заһит. Товарищ Арслан! Нинди шикләнү — иң якын дустыңнан.

Арслан. Син миңа андый ук дус түгел, конечно, сизеп торам. Син мине яратып бетермисең. Шулай да, начар булса да, туган тиеш кеше мин сиңа. Карт атайлар гына бертуган, канга хыянәт итә алмассың. Югыйсә, мин сине асам — аякларыңнан күккә асам!

Заһит. Арслан, дөрес әйтәсең, уртак канны пычрата алмам.

Арслан. Исермәскә ант итсәң, мин йокларга ятам.

Заһит. Менә инде!

Арслан *(җикереп).* Ант ит! Ата-бабалар хатирәсе белән.

Заһит. Ата-бабалар хатирәсе белән ант итәм, исермәм, йокламам.

Арслан. Ә хәзер бәйрәм итегез, тик артык шауламагыз — хуҗалар йоклый *(китә).*

Заһит. Сәер кеше.

Мәгъдәния. Акыллы кеше.

Заһит. Без аңардан да акыллырак.

Мәгъдәния *(кинаяле).* Син! Әлбәттә, акыллырак!

Заһит. Эшебезнең уңышлы чыгуы хөрмәтенә!

Мәгъдәния. Уңыш өчен.

Заһит. Безгә хәзер ашлык кирәкми. Киттек. *(Эчәләр.)* Тралитра трам-та траля-ля-ля... Әйдә, Арслан яраткан җырны, рәхәтләнеп йокласын.

*Мәгъдәния «Уел» көен көйли...*

Мәгъдәния. Җиттеме вакыт?

Заһит. Җитте бугай.

Мәгъдәния. Шуннан?

Заһит. Нишләргә соң?

Мәгъдәния. Капчык кайда?

З а һ и т. Арсланның мендәр астында.
М ә г ъ д ә н и я. Эчерә алмадык.
З а һ и т. Ничава, болай да эчкәннән хужерак ул.
М ә г ъ д ә н и я. Кереп хәлен бел, авырып китмәсен.
З а һ и т. Хәзер. *(Китә.)*
М ә г ъ д ә н и я *(җырлый).*

Сагынырсың мин булмам,
Мин булмам.

З а һ и т. Булды бит.
М ә г ъ д ә н и я. Хәзер үк?
З а һ и т. Әйтәм бит, эт булып алҗыган иде ул *(капчыкка суккалый, анда акча чылтырый).* Ничегрәк? Әт-тә-тә-тә!
М ә г ъ д ә н и я. Ат җигүлеме?
З а һ и т. Җигүле.
М ә г ъ д ә н и я. Хәерле!

Чыгып китәләр. Лампа, керосины бетеп, әкренләп сүнә. Дөньяны башта караңгылык баса, аннары кон яктыра.

А р с л а н *(бүлмәгә чыгып).* Заһит! *(Кычкырыбрак).* Заһит! Мәгъдәния! *(Каты кычкырып.)* Заһит, кайда син? *(Урамга чыгып йөгерә дә бераздан тагын керә һәм каты итеп кычкырып җибәрә.)* Заһит, мерзавец!

## БУШ КУЛ БЕЛӘН

*Сылубикә сүзсез генә «Уел» көенә моңаеп утыра, җеп эрли. Бераздан ишек кагалар да ул урыныннан сикереп тора.*

С ы л у б и к ә. Ходаем, ирсез өйгә төн белән кем килә инде. Әллә үзе кайттымы? Алай дисәң, әле биш кенә көн узды. Бүтән чакта унбишәр көн йөри иде. *(Ишекне катырак каккач.)* Кем бар анда?
Г о б ә й. Без бу, җиңгәчәй, ач әле.
С ы л у б и к ә. Нишләп йөрисез болай җиде төн уртасында. Улбу юктыр бит? *(Ача.)*

Юламан белән Гобәй керәләр.

Г о б ә й. Әллә ни юк. Кайтып җитмәделәрме икән дип, белмәкче генә булган идек.
С ы л у б и к ә. Үзең беләсең ләбаса, Гобәйдулла, тиз бит әле. Әллә берәр нәрсә ишеттегезме?
Г о б ә й. Ишетмәдек тә...
С ы л у б и к ә. Куркытмас өчен генә әйтми тормыйсыздыр бит?
Ю л а м а н. Берни дә юк, җиңгәчәй, курыкма. Без синең хәлне белергә генә кердек.
С ы л у б и к ә. Яшерәсез, күзләрегездән күреп торам.
Ю л а м а н. Дөньяда начар хәбәрләр. Шуны да әйтмәкче идек.
С ы л у б и к ә. Арслан исәндер бит?
Г о б ә й. Исән булырга тиеш.
С ы л у б и к ә. Әй, ходаем, әллә ничек сөйләшәсез. Нидер бар. Бар ла, әйтмисез генә. Әйтегез, әйт, нинди хәбәр?
Ю л а м а н. Хәбәр шул: безгә таба Колчак якынлаша. Бөгелмәне дә алган, Минзәләгә дә кергән.
Г о б ә й. Хәзер бу табатын килә ди.
С ы л у б и к ә. И ходаем, сезгә кагылмаслар микән?

Г о б э й. Безгә кагылмаслар да...
Ю л а м а н. Арсланны сакларга кирәк. Кайткач та тизрәк сыпыртсын.
С ы л у б и к э. Ай, ходаем, ай, ходаем...

Ишек кагалар.

Г о б э й. Кем анда?
А р с л а н. Мин.
С ы л у б и к э. Ай, Арсланым исән!

Чыраеннан язган А р с л а н керә. Аптырашып калалар.

С ы л у б и к э. Арслан, ни булды?
А р с л а н. Таладылар...
С ы л у б и к э. Ходаем...
Ю л а м а н. Аклармы?
Г о б э й. Бандитлар?
А р с л а н. Бандитлар боерыгы буенча, Заһит белән Мәгъдәния.
Ю л а м а н. Ашыкма, Арслан, алай ярамас.
Г о б э й. Гөнаһлы булуың бар. Үз туганыңнан шикләнмә.
А р с л а н. Барыбер әләгәчәк. Сез аңа әйтеп куегыз.
Ю л а м а н. Без аңа ничек әйтик, ул бит авылда юк.
А р с л а н. Булмаса, кайтыр, кайтмый булмас. Шул хәтле акчаны тотарга аның башы җитмәс.
Ю л а м а н. Син төгәлрәк сөйлә әле, Арслан агай, болай аңлашылып җитми. Сезгә кайтыр дип, нәрсә уйлап әйтәсең?
А р с л а н. Сез белгәнне уйлап.
Ю л а м а н. Мин берни белмим.
А р с л а н. Белмәсәң, бел: әнә Астрахань ягында дәүләткә ашлык илтүне тоткарлаган спекулянтларны атарга боерык биргәннәр. Бу җинаятьчеләрне дә шул ук хәл көтә, белеп торыгыз.
Ю л а м а н. Һмм...
Г о б э й. Авызың ни сөйләгәнне колагың ишетәме синең, Арслан агай?
Ю л а м а н. Гобәйдулла!
Г о б э й. Ул бит безнең күзгә карап әйтә.
А р с л а н. Монда балалар юк, Юламан, хәзергә сүз белән әйтергә ярамаса да, без үчебез дә аңлыйбыз сүзнең нәрсә хакында баруын.
Ю л а м а н. Сүзне гадәттә исбат итәргә туры килә.
А р с л а н. Анысын Чека раслар. Моңарчы раслап килделәр.
Г о б э й. Кайда соң синең Чекаң? Кайда? Бөгелмәдә Колчак, Алабугада Колчак, Минзәләдә Колчак. Син аяк баскан җир генә калды бит инде. Ә син безгә янап торган буласың. Аттырмакчы, имеш.
Ю л а м а н. Гобәйдулла... Ялгышасың. Ул безнең хакта сөйләми. Шулай бит, Арслан?
А р с л а н. Үз мәнфәгатьләрен генә кайгырткан булып, акка да, кызылга да кушылмаган булып, уңайлы форсат көтеп утыручы аждаһалар илдә шактый ул. Дөрес, алар бергә яшәмиләр, әмма бер явыз уй бөтен итә аларны — алар властька үз юллары белән омтылалар. Ил буенча җыйсаң, шактый зур банда булып укмаша алар. Шуларның кайбер очкыны безнең бу җиргә дә килеп төшкән булуы бик ихтимал.
Ю л а м а н. Кызык... шуннан...
Г о б э й. Ул әллә нинди җен телендә сөйли, миңа да тәрҗемә ит әле, Юламан.

Ю л а м а н. Шулай, ашыкмаска кирәк. Ашыкмаска.

Г о б ә й. Ни күтәргә тагын?

Ю л а м а н. Тәк-тәк. *(Ишекле-түрле йөренә.)*

А р с л а н *(түрдә кызыл байракны күреп).* Сылубикә, бу байрак нишләп монда?

С ы л у б и к ә. Китерделәр, аклар кулына эләкмәсен дип. Сәвит йортыннан.

Ю л а м а н. Әһем, әһ-ем.

А р с л а н. Эшләр хәтәр, чыннан да хәтәр.

С ы л у б и к ә. Әйттем мин сиңа, Юламан энең дә кисәтте, йөрмә үзеңә-үзең эш табып, ашлык ташып, диде. Менә күр инде көялегән.

А р с л а н. Кемдер эшләргә тиеш бит ул эшне дә. Гаскәр дә, шәһәр дә ачыкмаска тиеш.

С ы л у б и к ә. Синең биш-алты йөк арышың белән ил туя ди.

А р с л а н. Минем кебекләр бетмәгән.

С ы л у б и к ә. Менә ташысын иде шулар, син ят идең җылы өйнең түмен белеп кенә.

А р с л а н. Ялгыш сөйлисең, ялгыш.

С ы л у б и к ә. Әйдә, чишен инде. *(Арсланның аякларына иелә, чабатаны икәүләп чишәләр.)*

А р с л а н. Усал авылга эләктек. Алтын акчага да бирергә теләмиләр.

С ы л у б и к ә. Ашлыклары юктыр.

А р с л а н. Юктыр! Җыен карак, җыен ерткыч. Колчакны көтәләр. Күрсәтербез әле без аларга Колчакны!

*Сылубикә чабатаны алып күрше бүлмәгә кереп китә.*

Ю л а м а н. Шулай, Арслан агай, хәзер әйт инде: кайда безнең Заһит абыебыз?

А р с л а н. Акчаны эләктергәч кая китәргә кушылса, шунда киткәндер.

Ю л а м а н. Без әйтәбез сиңа: кайда Заһит?

А р с л а н. Белгән җирегездән эзләгез, минем кесәмнән түгел.

Г о б ә й. Кайда безнең Заһитыбыз, кадерле туганыбыз! Шул чаклы акча, шул чаклы алтын!

А р с л а н. Бүлешкәндә өч кешедән артмассыз дип уйлыйм.

Ю л а м а н. Шаяртма, Арслан, малайга чутлама безне. Без инде чирек гасыр яшәгән бу җирдә.

А р с л а н. Сезне шатландыра алам: шактый оста эшләде Мирзаһитыгыз. Мин йоклаган идем. Иртән уянып китсәм, җилләр искән. Кызык бит, ә?

Г о б ә й. Кызык.

Ю л а м а н. Туганнан туган абыебыз югалган, ә алар... кызык тапканнар.

А р с л а н. Сезгә туган булган кебек, Заһит минем дә туганым.

Г о б ә й. Сиңа бер ягы үги анып.

А р с л а н. Шуннан?

Г о б ә й. Синең күзләрең бик шикле карый, Арслан туган.

А р с л а н. Шулаймыни? Сез нәрсә, Заһитны ашап кайткан димәкчеме? Капчыкка Сылубикә бик тәмле ашамлыклар салган иде. Алар да бетмәде...

Г о б ә й. Бетәргә... Аларына чират җитмәгәндер.

А р с л а н. Шулай. Бер көнне Заһитны, икенче көнне Мәгъдәнияне, бүген сиңа чират. Яхшы чакта...

Ю л а м а н. Син кызма әле бик, без кызарга тиеш монда, син түгел, Арслан агай, без.

Арслан *(кычкырып)*. Сезгә ник кызарга? Бер нәрсәгез дә югалмаган. Сезгә нәрсә?

Гобәй. Ә Зәһит? Безнең яраткан абыебыз!

Арслан. Зәһитны сезнең ничек ятратканны мин беләм.

Юламан. Ә яратмасак?

Гобәй. Яратмаган бер кешене...

Арслан. Әйтеп бетер...

Юламан. Калып торсын.

Гобәй. Бүгенгә.

Арслан. Ә иртәгә?

Юламан. Иртәгә син аны эзләп табарсыңдыр бит.

Гобәй. Тапмый карасын.

Юламан. Менә шулай, үпкәләшмик. Син Зәһитны кайда калдырдың, шунда барып алып кайт инде, Арслан агай.

Арслан. Кайда? Каян?

Юламан. Без каян белик.

Арслан. Мин дә белмим.

Юламан. Ә син бел. Онытсаң, исеңә төшер.

Арслан. Чекага хәбәр итәрбез. Табарлар.

Юламан. Юк хәзер бернинди Чека.

Гобәй. Безнең абыебыз Чека белән китмәде. Без синнән сорыйбыз.

Юламан. Шулай итеп: кем табышыр, кем белен эзләрсең — безгә барыбер.

Арслан. Барыбер булса, хушыгыз.

Гобәй. Кунарга килмәдек, курыкма. Я безне дә югалтып куярсың.

Арслан. Югалсагыз...

Гобәй. Сөйләнеп кал.

Арслан. Тыныч йокы!

Юламан. Иртәгә! Кара аны! *(Китәләр.)*

Арслан. Туганнар!

## ТЕГЕРМӘН ЯНЫНДА

*Ерахта мылтык тавышлары ишетелә. Якында кемнәрдер кычкырып уза: «Аклар килә! Аклар! Безнекеләр чигенә! Аклар килә! Безнекеләр килә! Аклар!»*

Сылубикә *(урамга чыга)*. Я хода, ана улны, ата кызны белми дигәннәре шушыдыр инде. Кыямәт көне шушыдыр. Кызылларны да безнекеләр диләр, акларны да безнекеләр диләр.

*Гомәр күренә.*

Ак үрдәккә, күк үрдәккә
Җимнәр салдым дүмгәккә.
Эчем жана, тышым жана,
Әл дә капмый күлмәккә.

Сылубикә. Аклар керә ди бит авылга, нишләп йөрисең болай. Ник бармыйсың Арсланнар янына? Тәки китерәсезмени инде шуларны?

Гомәр. Мин башлаган сугыш түгел, чәнчелеп китсеннәр. И гомумән яратмыйм мин сугышны. Чәнчелеп китсен дөньясы.

Ак үрдәккә, күк үрдәккә...

Юламан белән Гобәй керә. Кулларында — ак флаг.

Гобәй. Гомәр, әйдә.

Гомәр. Кая?

Гобәй. Акларны каршыларга. Менә шушы флагны әләбез.
Гомәр. Ак минем үз өемдә дә бетмәгән.
Юламан. Флаг әләбез ди ул әйтә, флаг.
Гомәр. Миңа флагсыз да бик күңелле. Бигайбә, җәмәгать, мин андый эштән җәяүләп качам.
Гобәй. Арслан кызыллар ягында буталамы?
Сылубикә. Ир кеше өйдә ятмас.
Гобәй. Әен бөтенләй дә күрә алмас әле, болай булса.
Сылубикә. Үз туганыгызга шулай яламагыз, оятыгызга көч килмәсен.
Юламан. Дөресен генә әйтеп бир әле, җиңгәчәй, кайда үтерде ул Мирзаһитны — өйгә кайткачмы, юлдамы?
Сылубикә. Әстәгыйфирулла тәүбә, нинди сүз ул? Тузга язмаганны.
Гобәй. Әйт, без капчыкта ятмый, кайда мәете Мирзаһитның? Урмандамы, баздамы?
Сылубикә. Базда, базга күмдек, сөт-катык янына. Адәм актыклары — ни сөйлиләр бит, э?
Гобәй. Ишеттеңме, Юламан, базда ди бит?
Юламан. Ишеттеңме, Гомәр?
Гомәр. Минем колак сайлап кына ишетә, сезнең алама сүзләрне кертми ул минем чиста башыма.
Гобәй. Әйдә, Гомәр, Юламан, карап чыгыйк баздан.
Гомәр. Кәкәй кешеләр сез, әшәке кешеләр.

Гобәй белән Юламан өйгә кереп киткәч, алар артыннан Сылубикә дә кирә.

Сылубикә тавышы. Хакыгыз юк тентүгә керергә, законы юк.
Юламан. Нинди закон кирәк сиңа, кем син шул хәтле?
Гобәй тавышы. Кем законы кушмый, акларныкымы, кызылларныкымы?
Сылубикә тавышы. Икесенеке дә.
Юламан. Хәзер икесе дә юк. Хәзер безнең закон. Без хуҗа авылда.
Гомәр. Хуҗа диме? Кара, бер якка да кушылмыйча торды-торды да... Хәйләкәр! Тәки аклар беләнрәк, ахрысы, бу. Хәйләкәр!
Сылубикә тавышы. Ай, сөт өсте чүлмәгемне харап иттеләр. Ай, тәмуг кисәүләре. Баздан башыгыз чыкмагырлары! *(Урамга чыга.)* Гомәр, күрше булып ник карап торасың? Көпә-көндез тентүгә керделәр бит, таптыйлар, җимерәләр.
Гомәр. Әйттем мин аларга, сугыша алмыйм бит инде.
Сылубикә. Сугыш, сугышмыйча булмый ул.
Гомәр. Андыйлар белән кул пычратмыйм мин.
Сылубикә. Ә алар безне пычраталар, тентиләр, җимерәләр, таптыйлар. Ояты ни тора бит, Арслан өенә шушы юньсезләр тентү ясасын инде. Арслан ни әйтер.
Гомәр *(чыгып килүче Юламан белән Гобәйгә)*. Я, таптыгызмы?
Юламан. Авызыңны ерма, яме.
Сылубикә *(Юламан кулындагы кызыл флагны тартып алмакчы була)*. Тотынма әшәке кулың белән изге әйбергә.
Гомәр. Сиңа ник кызыл әләм, куеныңда агы бар бит инде.
Гобәй. Безгә аның икесе дә кирәк.
Сылубикә. Арслан флагы, хакыгыз юк. Бөтен авылныкы.
Гобәй. Авыл хәзер безнең кулда, без хуҗа. Әйдә, Юламан.
Сылубикә. Шунда берәр ядрә ярчыгы гына эләксен, башыгыз беткерләре.

**Гобәй.** Янәмә, төрләгән тавык, куркыта алмассың, синең кебекләрне күп күргән без.

**Юламан.** Хатын-кыз белән талашып үзеңне төшермә, Гобәйдулла, әйдә, киттек. *(Китәләр.)*

**Сылубикә.** Я ходаем, шушындый бәндәләрең дә йөри бит, нишләп җир йотмый аларны! Нишләп җир күтәрә... Ходаем! Ник кайтмый соң инде үзе. Әй, Арслан!

*Сәхнә артыннан тавышлар ишетелә. «Аклар килә! Аклар! Юламан белән Гобәй ак флаг элделәр. Аклар безгә тими, болай булгач! Аклар килә, аклар!»*

**Сылубикә.** Я ходаем, үзең сакла.

*Урамнан тагын тавышлар ишетелә: «Аклар авылга керми, аклар узып китә! Арслан абзыйны тоттылар! Арслан абзыйны үтерәләр!»*

**Сылубикә** *(ачыргаланып кычкыра).* Кайда, кайда?

**Тавышлар:** Тегермәндә! Үтерәләр!

**Сылубикә.** Арслан! *(Чыгып йөгерә).*

*Елга буе, тегермән буасы. Шунда Арслан ятып тора.*

**Сылубикә.** Арслан, нишләттеләр сине, Арсланым минем, нишләттеләр? *(Арсланның канлы башын тотып үкси.)*

**Арслан.** Елама, Сылубикә, ерткычлар алдында кимсетмә үзеңне.

**Сылубикә.** Арсланым, бәгърем, ни өчен? Нәрсә булды?

**Арслан** *(торып утыра).* Шул Заһит хакында... Үтергәнсең диләр.

**Юламан.** Үтермәгәч, кайда соң?

**Гобәй.** Кая куйдың безнең абыебызны? Әйтмәсәң тагын эләгә. *(Кендек белән кизәнә.)*

**Юламан.** Кая күмдең? Кая яшердең? *(Гомәргә.)* Күрәсеңме? Әйтәсе килми. Болай булгач, тагын кайсыбызны харап итмәс.

**Гобәй.** Кеше үтерүчегә — үлем!

**Сылубикә.** Гомәр дим, ни карыйсың, бер гөнаһсыз кешене харап итәләр бит! Кеше үтерергә нинди закон куша? Нинди суд? Аклар законымы, кызылларныкымы?

**Гобәй.** Аклар да юк монда, кызыллар да. Без — үзебез закон, без — үзебез судья!

**Сылубикә.** Кем куйды сине хөкемдар итеп? Хакыгыз юк! Якын килмәгез.

**Юламан.** Ә сезнең хакыгыз бар идеме безнең бертуган абыебызны үтерергә?

**Сылубикә.** Без үтермәдек! Минем Арсланым аңа тимәде, ышаныгыз! Ышаныгыз!

**Юламан.** Кем ышана?

**Гобәй** *(кендек белән кизәнеп).* Кем ышана? Синме, Гомәр?

**Гомәр.** Кем ышана дип... Нәрсәгә ышана?

**Юламан.** Арслан Заһитны үтермәде дип кем әйтә ала?

**Гомәр.** Мин әйтәм.

**Гобәй.** Син? *(Кендек күтәрә.)*

**Гомәр.** Син бик әтәчләнмә, калай әтәч. Кулың кыскарыр.

**Юламан.** Син күрдеңме үтермәгәнне?

**Гомәр.** Күрдем — ул үтермәде.

**Гобәй.** Кем үтерде?

**Г о м ә р.** Син.
**Г о б ә й.** Үз абыемнымы?
**Г о м ә р.** Арслан үз энесен нишләп үтерсен?
**Ю л а м а н.** Заһит Арсланга бертуган түгел, үги туган.
**С ы л у б и к ә.** Сез үзегез үтергәнсез! Үзегез!
**Г о б ә й.** Сүз көрәштерергә безнең вакыт юк. Әйдә, Юламан, син судья.
**Ю л а м а н.** Хәл ачык. Монда карар бер генә була: үтерүчегә — үлем.
**Г о б ә й.** Суд карары шундый.
**Г о м ә р.** Авылдашлар, акылдан язмагыз, авылдашлар!
**С ы л у б и к ә.** Кызганыгыз, намуслы кешене харап итмәгез!
**Г о б ә й.** Намусы-нисе белән — җәһәннәмгә! *(Арсланга таба килә. Арслан торып баса.)*
**Г о м ә р** *(аны туктатып)*. Кулыңны төшер, адәм актыгы!
**Ю л а м а н.** Исерекбаш.
**Г о м ә р.** Тамчы да капмадым.
**Г о б ә й.** Сыпырт яхшы чакта. *(Тагын кизәнә.)*

*Гомәр чигенергә мәҗбүр була һәм тына.*
*Сылубикә Арсланга таба килә. Гобәй аны йолкып ата да Арсланга үзе якынлаша.*

**А р с л а н** *(көч-хәл белән)*. Якын килмә, ерткыч!
**С ы л у б и к ә** *(Гобәйнең аяк астына егыла)*. Ерткычлар! Тамуг кисәүләре!
**Ю л а м а н.** Суд карары — бер. Халык сүзе! Җиренә җиткерергә!

Гобәй Арсланга табан атлый. Арслан тагын чигенә.

**С ы л у б и к ә.** Ат, ат, Арслан, ник атмыйсың?!

Арслан пистолетын күтәрмәкче була, күтәрә алмый — куллары имгәнгән. Пистолет җиргә төшә.

**С ы л у б и к ә.** Авылдашлар! Коткарыгыз! Алла хакына! Тамуглык гөнаһ алмагыз! Коткарыгыз!
**Г о б ә й.** Ата алмадыңмы? Булмыймы? Мә! *(Кендек белән селтәнә.)*
**А р с л а н.** Авылдашлар, безгә нинди кешеләр кул күтәргәнен күрмисезмени? Ялгышмагыз, кешеләр, белегез, талаучылар властен җимерсәк тә, тормышыгызда, гадәтләрдә калган гарипләкләр — менә болар. *(Юламан белән Гобәйгә күрсәтә)*, халык көчен, ил байлыгын урлап, кешеләрне талап яшәргә тырышучылар.

*Гобәй кендек белән бәреп, Арсланны суга төшерә.*

**С ы л у б и к ә.** Арслан! *(Йөгереп суга ташланмакчы була, аны тотып калалар.)* Арсланым!
**Г о м ә р.** Каешны ычкындырыгыз! Тегермәнне туктатыгыз! Туктатыгыз! *(Чыгып йөгерә.)*

Шактый вакыттан соң тегермән тавышы тына, ләкин Арслан гәүдәсен алырга өлгермәгәннәр.

**Г о м ә р.** Өлгерә алмадык. Төште дә юк булды! Су кан төсле ага...
**С ы л у б и к ә** *(җиргә тезләнеп, ачыргаланып кычкыра)*. Үтерүчеләр! Куркаклар! Ялганчылар! Сезне дөньяга тудырган аналарга ләгънәт. Иремнең каны, үземнең күз яшем тотсын! Үлгәндә дә кеше затыннан мәхрүм булып, кырмыска оясында үлгән еланнар төсле газапланып үлегез! Җылан-җаннарыгыз мәңге тамугта боргалансын, раббым. Раббым!

*Мин басма өстендә тезләнеп торган әниемә кул сузам. Тик кулларым җитми — арада еллар.*

*Күпме кешеләрне йоткан бу кое һәм тагын күпме йотар. Минем этиемне дә ул йоткан.*

*Кое төбендә су шаулый. Су шавы кеше тавышы төсле, Юламан тавышы төсле ишетелә.*

Кое тавышы. Синең әтиең генә түгел, бик күпләр монда — аларның саны-исәбе юк. Син дә шушында булачак. Шуның өчен килдең бит.

Мин. Әйе, шуның өчен. Син йоткан барлык төннәр, барлык көннәр һәм төннәр санынча каһәрләнгән упкын! Шуның өчен!

*Ярсынудан түзә алмыйча, кое авызына олы-олы ташлар ыргытам. Ә ул шыркылдап көлә.*

Кое тавышы. Тиле! Тиле! Тиле адәм! Ха-ха-ха-ха!

*Мин хәлдән таеп егылгач, кое тавышы да тына. Күрәм, янда гына кемдер басып тора.*

Мин. Син кем?
Ата. Мин — синең атаң. Гасыр яшьлеге.
Мин. Син миңа нәрсә әйтә аласың? Әтием?
Ата. Мин синең җирдәге эшләреңне хәтергә төшерергә килдем.
Мин. Нинди эш?
Ата. Алдыңа кара! *(Анда револьвер.)* Соңгы минутта ул кулымнан төште. Ул — сиңа мирас!
Мин. Мирас! Шул гынамы?

Ата.

Калдырдым мин сиңа зәңгәр күкне,
Караш җитмәс җирләр калдырдым.
Бар төсләрен җирнең, бар киңлеген
Күрер өчен күзләр калдырдым.
Яктылыклар җиргә өстәр өчен,
Җиңәр өчен акыл калдырдым.
Гаделлекне әкиятләрдән җиргә
Күчерер өчен закон калдырдым.
Әгәр булса күпме байлыгым,
Барысын сиңа, сиңа калдырдым.
Мин дөньяны сиңа калдырдым,
Синдә минем бөтен барлыгым.
Өметләрем аклый алдыңмы син,
Саклый алдыңмы?

Мин.

Сез калдырган дөнья яши, атам,
Бөтен килеш минем йөрәгемдә.

Ата.

Соңгы сүзем әнә җирдә ята —
Ал аны да.

Шул вакыт күз алдымда тагын ниндидер шәүлә барлыкка килде.

Шәүлә.

Әй, хөрмәтле ата,
Балаң эшли, яши минем белән,
Син әйтсә соңгы сүздән инде баш тарта.

А т а.

Син кем, хәерсез бәндә?

М и н.

Син кем?

Ш ә ү л ә.

Мин — Юламан, сезнең күләгәгез.

А т а.

Син исәнме һаман?

Ю л а м а н.

Мин мәңгелек буйлап, сезнең арттан барам.

А т а.

О, хәерсез, бәхетсез адәм!

Ю л а м а н.

Син мираслар санап киткән булдың,
Ләкин үзең карамадың татып,
Кан хакына алган заманаың
Минутында калдың ятып...
Ә мин син калдырган бөтен байлыклардан
Улың белән бергә файдаланам.
Әйт, кайсыбыз бәхетлерәк, акыллырак —
Синме, минме?

А т а.

Бу — Юламан.
Бик күп дошманнарны җиңдем, ләкин аны
Җиңалмадым.
Син җиңәргә тиеш.

Ю л а м а н.

Сез батырлар, ләкин сезнең йөрәктә дә була
Тик үзегез белгән курку, шикләрегез.
Мин — Юламан, сезнең шундый хисләрегез.
Мин — Юламан.
Көнләшүсез сөю, юк, булмаган,
Бәхет белән кайгы бергә йөри һаман.
Ә мин — сезнең юлдаш.
Мин яшимен сезнең күңелләрдә,
Мин яшимен дөнья йөрәгендә —
Чордан-чорга мирас.
Сез җиңәсез. Ләкин тиз үләсез, ә мин сезнең
Кыяфәтне алам.
Үлмәсәгез, тагын җаен табам —
Сезне мактап, сезне җырлап,

Түрегездә бергә урын алам.
Яшим, калам.
Мин — мәңгелек ялган.

А т а.

Ул хәзер ахыр чиккә җитеп азган —
Син җиңәргә тиеш аны, балам!

Ю л а м а н.

Көрәшүе кыен сезгә минем белән,
Мин бит хәзер сәнгать булып әверелдәм.
Әсәр булып килеп чыксам дөньягызга,
Бар син, аер: хаклык кайсы, ялган кайсы —
Сәнгать — сихер, шигъри ялган — аның чишмә башы
Әнә ул килә, баш иегез!

Сәхнәгә скульптор керә.

М и н.

Ленна!

Л е н и з а.

Әйе, мин бу.

М и н.

Әйт, син кем яклы?

Л е н и з а.

Мин матурлык яклы.

А т а.

Матурлыкның була төрлесе.

М и н.

Син — табигать яратучы. Әйтик, синең алда —
Каен гөмбәсе һәм чебен гөмбәсе.
Шуның кайсы матур синең өчен?

Л е н и з а.

Икесе дә.

М и н.

Агулысы да?

Л е н и з а.

Әйберләрнең миңа кирәк төсе, рәвеше,
Ә калганы сезнең эшегез, галимнәр эше.

Юламан.

Ишеттегезме? Бу — киләчәк сүзе,
Сез дә, мин дә барыбер аңа.

Лениза.

Художник — ул матурлыкка үлемсезлек китерүче.

Мин.

Юк, хаклыкны, дөреслекне терелтүче!

Нигә кирәк сәнгать, гаделлекне үтерүче?

Ата.

Күрәм, шактый көч куйган Юламан,
Гасыр уртасы аны белми.
Сиңа, улым, кала бер генә юл — җиңү.

Лениза.

Чын гүзәллек белми җиңелүне,
Ул — үлемсез.

Ата.

Дөрес, син җиңәргә тиеш!

Мин.

Атам, синең кулда корал иде теге чакта,
Ник атмадың?

Ата.

Анысы — минем хата.
Дошманнар күп иде, моннан явызлары,
Ә моның без кем икәнен, ни икәнен
Белми идек рәтләп ул чакларда.
Ә син кара, соңгы чиктә минем кулдан төшкән корал
Синең алда ята.

Юламан.

Ул аңардан хәзер баш тарта,
Заман инде башка, хәерсез ата.
Чөнки ул бик яхшы белә,
Миңа төзәп аткан пуля
Уза сезнең йөрәк аша.

Ата.

Ныклык кирәк мондый чакта.

Мин.

Мин нишләргә тиеш?

Ата.

Хәзер заман башка, үзең кара.

Мин.

Әйе, мин үземчә эшлим һәм сиченчә:
Мин барыбер атам,
Аңа һәм... йөрәгемә...

*Юламанның каршысына килеп атам... Шартлау... Һушыма килсәм, янымда беркем дә юк. Аптырап торам да торам. Коe туктаусыз үкерә. Аның үкерүен җиңеп, дәрья төбеннән сүзләр килә.*

Мин *(кабатлап).*

Калдырдым мин сиңа зәңгәр күкне,
Караш җитмәс җирләр калдырдым.
Бар төсләрен җирнең, бар киңлеген
Күрер өчен күзләр калдырдым.
Синдә минем бөтен батырлыгым,
Мин дөньяны сиңа калдырдым.

Әйе, мин синеңчә яшәргә тиеш. Һәм үземчә.

Кайтаваз *(ана тавышын китерә).* Арслан, сакла үзеңне, сакла, ат, кулыңда корал бит! Арслан! Авылдашлар! Коткарыгыз аны, алла хакына, коткарыгыз!

Мин. Анам тавышы!

Кайтаваз *(Юламан тавышын китерә).* Хәзер без хуҗа. Безнең сүз: үтерүчегә — үлем!

Мин. Юламан! Нинди сүзләр!

Кайтаваз. А-а-а-а!

*Авыртуга чыдый алмыйча, колакларымны каплыйм.*

## УТ

Мин. Шулай, әткәм, тарихны үзгәртеп булмый. Әгәр үзгәртеп булса, иң башта мин сине исән калдырган булыр идем. Юк, мин сине коткара алмыйм, димәк, тарихны да үзгәртә алмыйм. Аны бары тик бозарга гына мөмкин. Ә моңа беркемнең дә хакы юк. Аны мин дә бары тик булган хәленчә генә терелтергә тиеш. Бернинди куркыту, янауларга карамастан.

*...Дәфтәргә яңа юллар өстим.*
*...Купмедер утыргач, кемдер, арттан килеп, куллары белән күзләремне тотты.*

Мин. Һич әйтә алмыйм, кем сез?

Лениза *(кулларын ычкындырып).* Оныттыгыз дамы?

Мин. Лениза! Нишләп сез монда?

Лениза. Менә сиңа... кунакка үзе чакырды, үзе...

Мин. Мин чакырганга күрә түгелдер шул.

Лениза. Эш белән дә, билгеле.

Мин. Эскизлар алып килдегезме?

Лениза. Әйе.

Мин. Бик яхшы, тикшереп карагыз.

Лениза. Сез дә кайбер нәрсәләрне ачыклагансыздыр дип беләм.

Мин. Ачыклаган саен хәл кискенләшә. Бич тә сезнең файдага түгел.

Лениза. Әгәр киресенчә килеп чыкса? Мин сезнең хаксызлыкка ышанмасам?

Мин. Сезнең алда һәм Юламан агай алдында тезләнеп гафу үтенер идем. Ләкин шунысын әйтеп куйыйм, тарих шәфкатьсезлек дәрәҗәсендә туры сүзле. Ишетергә әзер торыгыз. Ул сезгә үзенең иң каты сүзләрен әйтәчәк.

Лениза. Нәрсә дип?

Мин. Сезгә менә нәрсә диячәк: Юламан Ардаширов утлы күмерләрне һәр вакыт бүтән кеше куллары белән тотып йөри. Аның янында һәр вакыт бер кеше палач ролен үти. Минем атамны ул үз юлыннан Гобәй дигән бер адәм аша алып ташлаган. Хәзер атамны ул икенче кабат үтермәкче, истәлеген юк итмәкче. Бу юлы Гобәй ролен ул миңа тапшырды — эшәке эшен художник куллары белән эшләтмәкче. Менә нинди коточкыч карьерист ул. Ә син...

Лениза. Фирудин, син вөҗдансыз!

Мин. Шулаймы? Туры сүз өчен рәхмәт.

Лениза. Сүзләрегезгә хисап бирә аласызмы сез? Әллә узган кошмар эченә кереп үк баттыгызмы? Сезне коткарырга кирәктер — караул кычкырыгыз.

Мин. Юк, үзем дә чыгып җитә яздым инде — күп калмады бугай.

Лениза. Мин, менә шушы кеше, художник — палач ролендә! Сезгә бу сүз өчен җавап бирергә туры киләчәк.

Мин. Ярый, мин әзер, исбат итегез хатамны.

Лениза. Минем сезнең белән сөйләшәсем дә килми *(китә башлый).*

Мин. Лениза, бер генә минутка.

Лениза. Тагын берәр матур сүз әзерләп куйдыгызмы?

Мин. Әйтмәкче идем шул... Үзегез яхшы күңелле булгач, сез дөньяда начар кеше юк дип уйлыйсыз...

Лениза. Гафу итегез, шундый хөрмәтле кешене сез сурәтләгән төстә күрә дә алмыйм мин, ышана да алмыйм...

Мин. Ярый, монда килүегез әйбәт булган. Белгән кешеләр белән сөйләшербез.

Лениза. Әлбәттә, сөйләшәчәкмен. Эшкә тотынырга рөхсәт итегез.

Мин. Алар белән яңадан сөйләшкәннән соң китапка яңа бүлекләр өстәлде. Теләсәгез укыгыз. *(Лениза дәфтәрне алгач.)* Укыгыз һәм күз алдыгызга китерегез.

*Узган көннәр безнең алга яңадан кайтты һәм кайчандыр яңгыраган тавышлар яңадан ишетелә башлады. «Аклар качты! Кызыллар кермәде! Безнекеләр китте! Аклар китте! Кызыллар килмәде. Безнекеләр килмәде».*

Сылубикә. Тамакларыгызга таш кергәннәр, акырмагыз, әнә кемдер Базы буеннан кычкыра, шуны тыңлыйк.

Ерактан тавыш. Пожар! Пожар! Җир янып кил(ә)! Җир яна!

Сылубикә. Җир яна! Дөньяның бетүе шушы икән. Адәмнәрнең бу хәтле азынуына ничек түзсен ул! Дөнья беткәндә җирнең бер каты янып килә дигәннәре хак икән! Хак икән!

*Тавышлар югары очка менеп китәләр: «Пожар! Пожар! Җир яна! Тегермән яна!»*

Сылубикә. Тагын ниләр күрәсебез бар икән. Нинди генә казалар китерер икән ходай! Ай алла! Пожар! *(тегермән янына ашыга.)*

Сылубикә. Әйттем мин сезгә, ходайдан әллә нинди афәтләр килер дип! Кеше каны тотмый калмый ул. Арслан каны, минем күз яшьләрем, каргышым бу! Бөтен авыл белән янабыз. Бер гаепсез кешеләр кыр өстендә калса, куллары канлы бәндәләрдән үч тә ала алмабыз без! Әшәке кешеләр тагын калыр, алар башкаларыбызның канын-яшен эчәрләр!

Гобәй. Шайтан бичәсе! Син чакырган афәт бу!

Юлаган. Су сибегез, су!

Гомәр. Торф яна!

Юламан. Коры торф өстенә кемдер зур учак яккан — пожарның башы шуннан.

Сылубикә. Кеше каны тота ул! Әлләниләр күрерсез әле. Күрми калмассыз!

Юламан. Авыл янса, синең өең берүзе утырып калыр дип беләсеңме?

Сылубикә. Минеке күптән янган инде. Аның эчендә җан калмаган, шуннан да куркынычрак хәл булмас! Безгә барыбер көн юк! Ятимнәр яше сезне дә озак җибәрмәс: алла җавабын кайтарыр. Менә күрерсез!

Гомәр. Контр! Контр! Контр! Карагыз, тегермән эте. Яна торган җирдә йөри. Контр! Монда кил! Мәһ, мәһ!

Юламан. Исемен дә тапканнар — Контр!

Гомәр. Арслан кушкан исем. Башта аларныкы иде ул.

Гобәй. Арсланда эт тә тормады.

Гомәр. Контр! Контр!

*Еракта эт күренә, ул, бу таба килгәндә, кинәт юк була.*

Гомәр. Харап булды, батты Контр!

Гобәй. Җир йотты. Тереләтә тәмуг!

Юламан. Контрның урыны шунда.

Сылубикә. Кансыз! Исеме генә шундый бит аның, ул сездән яхшырак иде! Мең кабат ягымлырак иде! Кешеләрне ярата иде! Эт булса да! Әйбәт эт иде ул, сезнең төсле түгел иде.

Гобәй. Убырлы карчык, үзеңне тотып салабыз бит шул утка.

Гомәр. Әй, җәмәгать! Кемдер килә, яна торган юлдан кайтып килә! Әй, мөсафир! Урап кил, сул яктан кил! Сул яктан! Карагыз әле, Заһит түгелме соң бу? Заһит! Заһит! Син бит бу!

Сылубикә. Заһит! Арслан үтергән Заһит!

Юламан. Булуы мөмкин түгел.

Гобәй. Бу Заһит түгел, бөтенләй чит юлаучы!

Алар алдына Заһит килеп баса.

Заһит. Нәрсә, энеләрем. Мине танымыйсызмыни инде? Оныттыгызмыни?

Юламан. Син Заһит түгел, алдама! Алдама!

Гобәй. Син чит кеше, юлбасар! Юри йөрисең безне харап итәргә.

Заһит. Мин бит бу, гөнаһ шомлыгына каршы, мин бу! Синең бертуган абыең — Заһит! Заһит мин! Шул арада оныттыгызмыни! Бер генә ай вакыт бит әле.

Юламан. Түгел, син безнең туган түгел. Каян килсәң, шунда олак!

Гобәй. Син безнең башыбызга гына исән калгансың. Арслан шунда үтереп бетермәгән!

З а һ и т. Арслан! Әй үтергән булса.

Г о б ә й. Ул сине тукмап кына ташлаган идеме? Син терелдеңме?

З а һ и т. Кыйнаган булса икән! Мин аның янына кайттым: бала кыйнаган кебек кыйнасын ул мине!

С ы л у б и к ә. Заһит — синме бу?

З а һ и т. Менә инде, кем булыйм, Заһит булмыйча?

С ы л у б и к ә. Җәмәгать, сез бу кешенең Заһит икәнлегенә ышанасызмы?

Г о м ә р. Инанабыз! Инанабыз! Заһит бу!

С ы л у б и к ә. Заһит, әйт, минем ирем Арслан сине үтердеме?

З а һ и т. Үтерсә әйбәтрәк була иде!

Ю л а м а н. Ул сине үтерер дәрәҗәдә кыйнаган, алайса!

Г о б ә й. Шулай диген, әйт, ялганлама!

З а һ и т. Кыйнаса икән! Хәзер кыйнасын ул мине.

Г о б ә й. Ахмак!

Ю л а м а н. Ул акылсыз булып калган, кыйналудан.

Г о м ә р. Арслан сине нишләтте?

З а һ и т. Арслан миңа тырнагы белән дә чиертмәде! Авылдашларым! Иптәшләрем! Туганнарым! Мин сезнең хөкемегезгә кайттым: теләсәгез нишләтегез!

С ы л у б и к ә. Сез, сез... Мәгъдәния белән...

З а һ и т. Теләсәгез нишләтегез: без ялгыштык, шайтан котыртуына түзә алмадык!

Г о м ә р. Нишләдегез?

З а һ и т. Без... Мәгъдәния белән...

Ю л а м а н. Заһит! Акылыңа кил!

Г о б ә й. Акылга килерлек булса, монда кайтамыни ул! Афәт. Син алып кайттың бу афәтне! Бу җир син кайтканга күрә яна!

С ы л у б и к ә. Гомәр, әйтеп бетерсен Заһит!

Г о м ә р. Шуннан, Заһит, Мәгъдәния белән сез... Шуннан нәрсә булды?

З а һ и т. Без... Арслан йоклагач... *(Юламан белән Гобәйгә күрсәтеп.)* Менә болар сүзен тыңлап харап булдым мин...

Ю л а м а н. Әшәке! Үз туганыңа үзең яла ягасың. Пычрак җан!

З а һ и т. Сезнең сүзне тыңлап харап булдым мин! Туган! Ходай биргән туганнарны миңа!

С ы л у б и к ә. Заһит, алла хакы өчен әйтеп бетер — син югалган аркасында Арсланны үтерделәр бит!

З а һ и т. Үтерделәр? Кемнәр? Кемнәр аңа кул күтәрә алды?

С ы л у б и к ә. Менә алар — синең туганнарың — Юламан белән Гобәй!

Ю л а м а н. Мин аңа кул тидердемме? Күрдегезме, җәмәгать?!

С ы л у б и к ә. Син үз кулың белән түгел, Гобәй кулы белән...

Ю л а м а н. Гобәй үзе балигъ... Үзе өчен үзе җаваплы.

Г о б ә й. Син ни сөйлисең, Юламан!

Ю л а м а н. Мин аңа тырнак белән дә чиертмәдем!

З а һ и т. Арслан! Нинди кешене харап иткәннәр!

Г о м ә р. Ә үзең? Шул кешене ташлап качкансың — каракларча...

З а һ и т. Ташлапмы соң! Без Мәгъдәния белән...

Г о б ә й. Кайда куйдыгыз алтыннарны?

З а һ и т. Мәгъдәния белән урлап качтык без ул акчаларны.

С ы л у б и к ә. Халык акчасын!

Г о б ә й. Арсланның һәлак булуына — аның алтыннарын, акчаларын урлаган кешеләр гаепле... Без ялгыштык! Без ялгыштык!

Ю л а м а н. Минем бер кемгә тырнак белән дә чиерткәнем юк, каты сүз дә әйткәнем юк.

С ы л у б и к ә. Юламан түгел син, елан!

Ю л а м а н. Ирецнең яраткан туганына шундый каты сүз әйтә аласың!

С ы л у б и к ә. Туган!

Ю л а м а н. Әйтәм бит... Мин түгел, Гобәй!

Г о м ә р. Заһит, әйтеп бетер, кайда ул сез урлаган алтыннар?

З а һ и т. Аларны миннән Мәгъдәния урлап качты!

Г о м ә р. Кая качты?

З а һ и т. Кая булсын: аклар ягына, Колчак ягына. Уфага таба... Мин үтә алмадым.

Г о б ә й. Заһит, син җинаятең өчен җавап бирергә тиеш.

З а һ и т. Курыкмыйм, җавап бирәчәкмен. Мин шуны белеп кайттым... Минем белән син дә...

Г о б ә й. Мин урламадым...

З а һ и т. Мин үтермәдем...

Г о б ә й. Ялганлама, син... Арслан сине үтермәкче булган. *(Кендек чыгара.)*

З а һ и т. Җәмәгать, коткарыгыз!

Г о м ә р. Заһит, кач!

З а һ и т. Коткарыгыз!

Заһит юл буйлап йөгерә, аны Гобәй куа.

С ы л у б и к ә. Бетәләр, янган юл буйлап киттеләр! Бетәләр! Коткарыгыз!

Г о м ә р. Заһит! Заһит! Әй!

*Заһит уңга чыгыйм дигәндә яртылаш җиргә бата.*

З а һ и т т а в ы ш ы. Коткарыгыз, а, янам! Ай!

*Аңа сугарга барган Гобәй дә бата.*

Г о б ә й. Синең аркада... Ай, коткарыгыз! Ай-ай-ай.

С ы л у б и к ә. Коткарыгыз! Коткарыгыз, харап булалар!

Ю л а м а н. Сылубикә, алар синең ирецне кызганмадылар! Бетсеннәр!

Г о м ә р. Эт баткан җирдә үк! Өчәүләп! Баттылар, югалдылар!

Ю л а м а н. Этләрчә! Аларга шул кирәк!

С ы л у б и к ә. Арслан каны! Минем әрнешләрем! Кайта, афәт булып кайта!

М и н *(хәзерге заманнан)*. Юламан Ардаширов! Ул миңа да тырнагы белән чиертмәде? Ардаширов!

## МИН ДӨНЬЯНЫ ЯРАТАМ

Л е н и з а. Монда язганнар хак булса, Юламан абый минем күзләремә ничек карар икән?

М и н. Юламан абыйны? Карар, туп-туры карар. Безне оялтырга тырышыр әле.

Л е н и з а. Ә монда минем эскизлар...

М и н. Күрсәтегез халыкка.

Л е н и з а. Нәрсә әйтер икән халык?

М и н. Ни әйтсә дә хак әйтер, ышанырга туры килер.

Л е н и з а. Ни уйларга да белмим хәзер.

М и н. Ни булса да халыкка, гаделлеккә хыянәт итмәскә киңәш итәм мин сезгә. Мин беләм, хыянәт гафу ителми — гомергә һәм мәңге. Бу — минем анам сүзләре, сөт белән тәнемә кереп урнашкан.

Л е н и з а. Ана сүзләре. Ул аларны кемгә әйткән?

М и н. Беләсегез килсә, укып бетерегез.

Лениза укырга керешә: җәйге басу, Сылубикә арыш ура.

Сылубикә. Үземә иптәшкә я малай, я кыз алып кайтам инде. Кайсын бирер ходай: малаймы, кызмы. Ир бала булса, әтисе кушармын дип йөргән бер исем бар иде. Шуны кушарбыз — Фирудин дип. Әтисенең шундый бер бик якын дусты булган — Себердә үлеп калган, сөргендә чакта. Мәхмүдә! И, мин сине янда дип сөйләнгән булам тагы... Кара, бу таба, безнең янга кемдер килә. Ярый, килә бирсен. Җәй көне басуда кеше өзелеп тормас инде ул. *(Бераз тынып торгач.)* Сөер кыяфәтле — безнең авылныкы түгел. Әллә нинди бер карачкы, кап-карадан киенгән. Җәйге челләдә кара киенгән кеше — кайгылы кеше булыр. Берәр кемен үтергәннәрдер... Әллә инде, ходаем...

*Җәһәт кенә көлтәләренә ислә һәм килучегә таба карамаска тырыша.*

*Мөсафирә якын ук килеп, сүзсез басып тора. Сылубикә аңа күз дә ташламый.*

Мәгъдәния. Сылубикә апа, син бит бу? *(Сылубикәгә якын ук килә, тегесе һаман кутәрелми.)*

Сылубикә *(күтәрелеп)*. Шуннан?

Мәгъдәния. Сылубикә апа!

Сылубикә. Әйе. *(Горурлык хисе белән.)* Мин — Сылубикә.

Мәгъдәния. Мин — Мәгъдәния.

Сылубикә. Бу исемне әйтүдән чирканмаган кеше дә калган икән әле. Ул бердәнбер булырга тиеш.

Мәгъдәния. Мин үзем Мәгъдәния. Үзем. Танымыйсыңмыни? Бер елда онытгыңмы?

Сылубикә. Юк, танымыйм, хәтерләмим.

Мәгъдәния. Без бергә тордык синең белән, бер түбә астында... Мин шул Мәгъдәния.

Сылубикә. Ул Мәгъдәния үлде.

Мәгъдәния. Юк, үлмәде. Мин исән.

Сылубикә. Ул үзе эшләгән барлык әшәкелекләрдән хурланып, үзен-үзе кумалмас дәрәҗәгә килде. Аннан үзенә-үзе кул салды. Аның урынында мин дә шулай эшләр идем.

Мәгъдәния. Ә мин алай эшли алмадым. Мин — шундый кеше.

Сылубикә. Син үз кыяфәтеңне күралмыйсың. Артык хәерче булганга, көзге алырга хәлең җитмидер синең. Тышкы кыяфәтеңне түгел, эчке кыяфәтеңне күрсәтә торган көзге. Юк шул андый көзге дөньяда, юк. Шундый көзге булып, синең чын йөзең күренсә иде, сиңа дөньяда беркем дә карый алмас иде, чирканып читкә борылыр иде. Син хәтта үз битеңә үзең төкерер идең. *(Уйланып торгач.)* Юк, ялгышам, төкерә алмас идең, «бу — мин» диярга батырлыгың җитмәс иде синең. *(Урагын тоткан хәлдә Мәгъдәниягә таба килә.)* Мәгъдәния булсаң, син шундый кеше. Әйт, Мәгъдәнияме син? Әйт!

Мәгъдәния *(куркып бөрешә)*. Түгел, түгел!

Сылубикә. Син Мәгъдәния түгел!

Мәгъдәния. Әйе, Мәгъдәния түгел мин...

Сылубикә. Әшәке! Әгәр сораучы булса, куркаклыктан үз исеменнән дә баш тарткан әшәке җаннар була дисәм, ышанмаслар иде. Ә андый кеше бар. Әгәр ул син булсаң, хәзер мин синең күзләреңне чокып чыгарырга тиеш булыр идем. Хыянәтчел йөрәгеңне, пычрак йөрәгеңне йолкып ташларга тиеш булыр идем. Бәхеткә каршы, син Мәгъдәния түгел. Бар, юлыңда бул, хәерсез мөсафирә, минем сине күргәнем юк, күрергә теләмим. Бу басу — игеп кыры. Син баскан җирдә бодай үсмәс, ызан буйлап уз, иген корымасын.

Мәгъдәния китә башлый да кире борыла.

Мәгъдәния *(үксеп).* Мин! Мин — Мәгъдәния! Мә, када! *(Тезләнә, күкрәкләрен ача.)* Мә! Чәнче, када, үтер! Чокып чыгар күзләремне — дөнья миңа хәрам булсын. Йолкып ташла йөрәгемне — дөнья рәхәте хәрам булсын. Мин — Мәгъдәния.

Сылубикә. Кызганыч, кулымда корал юк.

Мәгъдәния. Урагың белән! Ул шундый үткен, ялтырап тора. Урак белән! *(Ләкин Сылубикә килә башлагач, үзе куркып кычкыра.)* Сылубикә!

Сылубикә *(урагына карый).* Урак белән? Арыш исе, шушы изге туфрак исе сеңгән урак беләнме? Булачак балам күңеле кебек, ирем намусы кебек шушы якты, чиста урак беләнме? Синең өчен артык зур хөрмәт күрсәтү булыр иде бу! Бар, тизрәк, җиребезгә синең арттан афәт килә күрмәсен. Кешеләребезгә күренеп йөрмә, бәхетләре кимемәсен.

Мәгъдәния. Мин китәм. Соңгы сүземне, актык теләгемне үтә.

Сылубикә. Әйт теләгеңне.

Мәгъдәния. Арсланга тапшыр соңгы сүземне.

Сылубикә. Әйт сүзеңне.

Мәгъдәния. Мин аны эзләп авылга кергән идем. Өегез бикле...

Сылубикә. Кешесенә карата бикле дә була шул.

Мәгъдәния. Урамда бер олы кеше дә күренмәде.

Сылубикә. Урак өстендә кем өйдә ятсын.

Мәгъдәния. Балалардан сорадым: алар Арсланны үлде диделәр.

Сылубикә. Зинһар, ул хакта...

Мәгъдәния. Ул үлмәгәндер бит? Дөрес түгелдер бит бу сүз? Зинһар, мине куркытмагыз, ул исәндер бит?..

Сылубикә. Аның үлүеннән сез куркасыз!.. Ә үзегез...

Мәгъдәния. Ул исәндер бит? Мин зиратка бардым: анда аның каберен таба алмагач, тынычлангандай булдым: ул исәндер бит?!

Сылубикә. Арслан кебек кешеләр үлми. Ул исән.

Мәгъдәния *(җиңел сулап).* Аллага шөкер. Мин аны харап итә яздым... Әгәр үлгән булса, бу үлемдә мин дә катнашкан булыр идем. Аның акчаларын, җыелган алтыннарын без Заһит белән бергә урладык бит... Минем башыма килә торган нәрсә түгел иде бу. Юламан белән аның абыйсы Гобәй кушуы буенча... Минем сезгә ачуым да купкан чак иде: өйдән куып җибәргән көнегез иде: мин риза булдым...

Сылубикә. Алар — Юламан, Гобәй!

Мәгъдәния. Заһит ул акчаны Юламаннарга алып кайтырга тиеш иде: анысына риза булмадым. Шуңа күрә Заһитны үзем белән алып киттем.

Сылубикә. Ә соңыннан? Син ул акчаларны кая куйдың? Заһиттан син урлагансың бит.

Мәгъдәния. Мин ул акчалар белән шәһәргә кайтып кешечә яши башламакчы идем.

Сылубикә. Кешечә яшәр өчен кеше булырга кирәк. *(Мәгъдәния җавап бирми.)* Кайда ул байлык?

Мәгъдәния. Уфага кереп барганда мине Кызыл гаскәр кешеләре тотып алдылар да акчаларны кире бирмәделәр.

Сылубикә. Аллага шөкер!

Мәгъдәния. Арслан нәрсә әйтте минем хакта?!

Сылубикә. Әйтмә ул исемне пычрак телең белән.

Мәгъдәния. Сылубикә! Минем беләсем килә. Ул ни әйтте?

Сылубикә. Намуслы кешеләр үлгәч тә күрәшәләр, үлгәч тә җиңәләр. Үлгәннәр тарафыннан тере килеш җиңелүдән дә хурлыклы җиңелү юк, диде Арслан. Бу сүзләрне мин улларымның улларына тапшырсын өчен туачак улыма әйтеп калдырачакмын.

Мәгъдәния. Сез әллә ничек сөйлисез... Томанлы итеп. Арслан әллә чынлап та исән түгелме?

Сылубикә. Арслан исән. Әйт, аңа нәрсә тапшырырга? Югыйсә, сез аның белән үлгәч тә очрашмаячаксыз. Шайтан нәселен аның янына үткәрмәсләр. Әйтеп кал сүзеңне.

Мәгъдәния. Мин аңа үзем әйтермен дип кайткан идем.

Сылубикә. Чак кына иртәрәк кайткансың.

Мәгъдәния. Ул кая китте?

Сылубикә. Әйтеп бетер сүзеңне.

Мәгъдәния. Сүзем шул: ул мине, мин җуләрне гафу итсен.

Сылубикә. Хыянәт гафу ителми. Гомергә һәм мәңге.

Мәгъдәния. Ул гафу итәр... бәлки. *(Китә башлый.)* Хуш, Сылубикә, хуш!

Сылубикә. Юлың кая таба?

Мәгъдәния. Аяклар кая таба китәр, шул таба.

Сылубикә. Кайда да бер кояш.

Мәгъдәния. Кайда үлсәң дә барыбер. Хушыгыз! *(Китә.)*

Сылубикә хәлсезләнеп чүмәлә төбенә утыра. Озак та үтми, басу буйлап яшь бала тавышы яңгырый. Еракта, яр буенда, Мәгъдәния силуэты күренә һәм югала. Җәйге күренеш сакланган хәлдә заман алмашына.

Лениза *(дәфтәрне миңа суза)*. Рәхмәт.

Мин. Я, ничек?

Лениза. Ашыктырмагыз мине, мин үзем... Үземнең төшенәсем килә *(тау ягына карап)*. Анда кемдер килә бугай.

Мин. Тукта. Әнием! *(Каршысына барып, җитәкләп китерәм.)* Ник килдең, әнием. Нәрсә бар?

Ана. Кайтканнар... теге зобанилар монда киләләр.

Мин. Әйбәтләп, әни, каушама, кемнәр кайткан?

Ана. Шул инде... Юламан. Ачуланыштык дигән идең. Берәр нәрсә уйлап кайтмасын тагын. Атаң төсле итеп куймасын. Бар, балам, кит син моннан.

Мин. Юк, әни, мин китмим.

Ана. Килеп җиттеләр, балакаем!

Юламан *(керә)*. Исәнмесез. *(Эндәшүче булмагач.)* Лениза, сезнең кәефегез киткән димме? Фирудин безнең проектка каршыдыр инде. Шуның өченме?

Лениза. Юк, әле без карамадык.

Юламан. Әйдә соң, карыйк, күрсәтик. *(Сәхнәгә керүче Гомәрне күреп.)* О, кемне күрәм мин! Гомәр! *(Кочакла632амакчы була, тегесе читкә тартыла.)* Таныйм, таныйм. Молодец, артык бирешмәгәнсең дияр идем мин.

Гомәр. Мактама, Юламан, бирешелде инде, бик каты бирешелде. Шулай да азау тешләрем исән әле.

Юламан. Ярый, ярый. Бик әйбәт дияр идем.

Лениза. Юламан абый, эскизлар белән... Әллә бераз сабыр итикме?

Юламан. Юк, мондый эшне сузу ярамас. Халыкның үткәненә һәйкәл салабыз бит. Аның өчен тырышабыз. Шулай. Менә шушында булыр дибез инде. Авылыбызның иң биек төшендә. Сез ничек карыйсыз, иптәш скульптор?

Лениза. Авылның киләчәген, үсәчәген исәпләгәндә, урыны әйбәт, анысы...

Г о м ә р. Бик хуп, җәмәгать. Алга карап яшисез икән.

Ю л а м а н. Дөрес! Авыл көннән-көн зурая безнең. Үсә!

Г о м ә р. Урыны шулай. Ә теге... ни дисез соң әле... сурәте...

Л е н и з а. Һәйкәл.

Г о м ә р. Ә һәйкәл дигәнегез нindirәк була?

Ю л а м а н. Сезнең белән киңәшергә кайттык менә. Хәл итик бергәләп — сезнең заказ бит. Художник гипска күчергәнче үк киңәшергә теләде. Халык белән.

*Бер зур кәгазь щит күтәреп бастыралар.*

*Сурәттә кеше басып тора: аяк астында — кара кошлы флаг, патша флагы. Герой шул кошның койрыгына баскан. Ике кулы белән тагын нидер күтәреп тора.*

Л е н и з а. Макет эшләнеп бетмәгән. Бу ике кулураклы-чүкечле флаг күтәреп торырга тиеш.

Г о м ә р. Кем куллары?

Л е н и з а. Герой куллары.

Г о м ә р *(алга узып)*. Туктагыз әле, балалар, ныклабрак карыйк әле. Герой куллары дидегезме? Бу адәм героймы инде?

Л е н и з а. Герой булырга тиеш иде.

Г о м ә р. Ниткән герой булсын, Юламан бит бу! Нәкъ үзе инде, суйган да каплаган — Юламан! Шул бу, шул. Егетләр, бәхәссездер. Конешно, шул!

Л е н и з а. Мин Юламан Ардашировны прототип итеп алмакчы булган идем шул.

Г о м ә р. Ничек дидегез? Прутип дидегезме?

Л е н и з а. Прототип.

Г о м ә р. Юламан үзе бик дөрес эшли, прутип булып. Без дә прутип. Бу сурәт безгә кирәкми.

Ю л а м а н. Ничек кирәкми? Заказны җибәргәнсез бит.

Г о м ә р. Безгә чын герой кирәк... Арсланны ясагыз. Авыл Советыбызның беренче председателен! Менә ул герой иде! Ә болар... ягъни Юламаннар... пучтәк алар.

Ю л а м а н. Иптәшләр! Мин скульпторның консультанты буларак, сезгә килгән рәсми вәкил буларак...

Г о м ә р. Менә нәрсә, Юламан туган, инде унтугызынчы ел түгел. Нотыгыңны туктат инде син, матур гына иттереп.

Ю л а м а н. Нәрсә, сүз дә бирмисезме? Бездә сүз ирегeн кысарга ярамый — бу минем хокукым...

Г о м ә р. Син ул хокуктан дөрес файдалана белмәдең инде, иске авылдаш. Син моннан тай инде, яхшы чакта.

Ю л а м а н. Ә таймасам? Иптәшләр, бу нинди тәрбиясезлек? Нинди әдәпсезлек? Егерменче гасырда! Егерменче гасыр уртасында!

Г о м ә р. Без үзебезчә инде — гаеп итмә. Әмма дә ләкин тай диюебез хак, югыйсә, сизми дә калырсың.

Ю л а м а н. Хөрмәтле авылдашлар, кадерле якташлар... Мин Арсланны хәтерлим... Яхшы кеше иде ул... Тик герой түгел иде, авантюрист иде, бунтарь иде.., үлеме дә... шуның аркасында килеп чыкты.

А н а. Авылдашлар, үлгән кешене мыскыл иттермәгез, Арсланның рухын рәнҗетмәгез.

Г о м ә р. Юламан, син һаман да шул кәкәй килеш калгансың икән. Дөнья тәки үзгәртмәгән сине. Кайда яшәдең син? Мәгарәдәме? Адәм хурлыгы. Мәрхүм белән көрәшә бит.

М и н. Ул аның белән бөтен гомере буе көрәште.

А н а. Ирек куймагыз, авылдашлар... Аңа ирек куйсаң...

Г о м ә р. Соңгы сүзем шул сиңа, Юламан. Ходай миңа озын гомер бирде. Шулай да бәхетле булмадым — гомерем буе пычрак вөҗдан белән яшәдем. Синең аркада пычраттым мин аны: синең Арсланга сузылган кулыңны бәреп сындырырга батырлыгым җитмәгән. Хәзер инде үләр алдыннан синең гөнаһыңны гүргә иярттерә хәлем юк. Сүземне әйтәм мин сиңа хәзер — синең үзеңә дә, залим җаныңа — рухыңа да урын юк безнең авылда. Тиз генә сыпырт син моннан. Я! *(Таяк күтәрә.)*

М и н. Ярамый, бабай. *(Кулын тотам.)*

Г о м ә р. Кешесенә күрә ярый ул. Я!

Ю л а м а н. Сезнең бу тәртибегез өчен...

Г о м ә р. Янама, без беләбез хәзер. Куркудан узган инде хәзер без. Һм... Әләм күтәреп тора, имеш. Кайсы әләм? Менә монымы? *(Куеныннан кызыл флаг чыгара.)* Таныйсыңмы син моны?

Ю л а м а н *(сискәнеп)*. Күргәнем юк.

Г о м ә р. Күргәнең булмагач, һәйкәлдә нишләп аны син тотып торырга тиеш?

Ю л а м а н. Ә... хәтерлим... хәтерлим бугай.

Г о м ә р. Хәтерлә, хәтерлә — авылыбызның беренче кызыл әләме, син Арсланнар өеннән талап чыккан байрак бит ул.

Ю л а м а н. Ялган!

С ы л у б и к ә *(байракны алып)*. Әйе, шул, әйе, мин дә таныйм — Арсланым байрагы. *(Кулына ала, битләрен каплый.)*

Г о м ә р *(Юламанга)*. Син аны кызыллар килә башлагач әлдең, конишно. Хәлбуки, синең куеңда ак елан, ак әләм дә бар иде. Арслан һәлак ителгәч, истәлеге булсын дип, сез әлеп куйган җирдән алган идем.

Л е н и з а. Герой! Менә сиңа герой!

Ю л а м а н. Ышанасыңмы син шуларга, Лениза?

Л е н и з а. Юламан абый, һәйкәл булып каласыгыз килгәч, сез ник бүтән төрле яшәмәдегез соң?

Ю л а м а н. Лениза!

Л е н и з а. Хәйлә белән алдырмакчы булдыгызмыни?

Ю л а м а н. Мин сезне аңламыйм, Лениза.

Л е н и з а. Ә мин сезне аңладым бугай. Бер генә нәрсә башка сыймый: шундый зур гөнаһны нишләп күңелегездә йөртә алдыгыз — авылыгыз каршына басып, нишләп гафу сорамый түзә алдыгыз?

Ю л а м а н. Нинди гөнаһ?

Л е н и з а *(аптырап)*. Эх, Юламан абый!

М и н. Җитәр, Лениза, күп сөйләштек инде без — ул үзенең сафлыгына тәмам ышанган.

Г о м ә р. Судан ак, сөттән пакь. Бәйләнә башласаң, сәбәп тә юк — искитмәле.

Л е н и з а. Ул чактагысы — ялгышлык ди. Ә хәзергесе? Бу да гаеп түгелме?

Ю л а м а н. Болай дәвам итү мөмкин түгел. Безнең сүз бетте — хушыгыз. *(Китә, аның белән беркем дә саубуллашмый.)*

Г о м ә р. Арслан басып торган урынны дәгъваларга кайткан, оятсыз. Дәгъваламый тор әле *(таяк белән макетны төртеп аудара.)*

Л е н и з а. Сез... нишлисез? Ә! Дөрес! Чүп була димәсәгез, калсын шушында — миңа кирәкми.

Г о м ә р. Калмасын әле. *(Сурәтне суга ата.)* Агып китте.

А н а. Яңадан кайтмасын инде.

Г о м ә р. Һәйкәлне үзең карап ясат, Фирудин энем — Арсланнар рәнҗерлек булмасын — арабызга чын герой кайтсын.

А н а.

Арсланнар рухы? Ул — безнең арада,
Киткәне юк аның бер кая да.
Күзгә күренмичә яшәде ул, яши һаман
Безнең белән. Менә бит ул! *(Байракны җәеп күрсәтә дә миңа бирә.)*

М и н *(байракны алып).*

Аталардан калган ядкяр...

А н а.

Изге васыять һәм аманәт — сезнең кулда.
Ышанычым, өметем дә минем шунда:
Хәзер инде сез яшәгез алар кебек —
Җитәкчегез Хаклык булсын һәм Гаделлек.

М и н.

Тыныч бул син, анам, ышан һәм борчылма —
Сезнең өмет — безнең канда,
Йөрәк тибеше күк
Ишетелә әнә аның тавышы да...

А н а.

Мин ишетәм аны, балам — өткәң тавышы кебек.

Г о м ә р.

Ишетәм мин дә.

Л е н и з а.

Мин дә.

А т а т а в ы ш ы.

Элек мин дә сезнең кебек идем,
Бу дөньяны сезнең төсле сөя идем.
Күккә карап елмая һәм көлә идем,
Җиргә сезнең кебек басып йөри идем.
Кеше идем, тере идем.
Йөрәгемдә чын кан иде, кызыл иде.
Тәнемдәге, җанымдагы җәрәхәтләр
Сезнекечә,
Сез тойганча сызлый иде,
Сызлый иде...
Ләкин түздем, җиңелмәдем,
Ләкин үлдем, үлдем чынлап.
Калды чыңлап,
Колагымда җиңү тавышы калды чыңлап.
Шул җиңүне сезгә калдырдым мин.

М и н *(кабатлап).*

Колагымда җиңү тавышы калды чыңлап.
Шул җиңүне сезгә калдырдым мин.

Ата тавышы.

Кеше идем, мин дә тере идем,
Хәзер җил мин — шаулап исәмен,
Хәзер су мин — шаулап агамын.
Шушы урман, шушы иген, шушы һавамын.

Мин.

Мин җилләрне сөям.
Алар мине
Әнкәм кулы,
Әткәм кулы төсле сөяләр.
Гаебем булса, өшетә, үртәләләр,
Кайгым булса — елый.
Шатлыкларым булса, сөенәләр.
Чал дулкыннар,
Хисләремә җавап итеп,
Шундый йомшак сыйпый, кочалар.
Бишек җырын яңгырата кошлар.
Зурайгач та һаман дус алар.
Адашмадым буран һәм төннәрдә.
Күпме йөреп,
Урман, яланның,—
Сөюемнең,
Җирне сөюемнең чикләренә
Чыга алмадым.
Шул сөюне миңа бүләк иткән
Анам һәм атам!
Икмәгемне.
Тормышымны хөрмәт иткән кебек,
Сезне яратам.
Сезне сөйгән кебек,
Күздән яшь килерлек итеп,
Җирне,
Күкне,
Суны яратам!

Гомәр.

Әйе, сезнең бу заман да
Үзегез белән, яңа Арсланнар белән бергә
Тарих булып калыр.
Заман — сез төзегән якты сарай булса,
Башкаларга әзерләнгән таш нигезгә
Һәйкәл булып басмак булып тырышулар
Кирәк булмас сезгә.
Үрнәк алып безнең үрнәкләрдән,
Гыйбрәт алып безнең гыйбрәтләрдән,
Шуны белеп яшәгез сез.

Мин.

Аталар эшен, исемен яманларга,
Кагылырга безнең горурлыкка һәм вөҗданга,
Ирек куймабыз без беркемгә дә, һич кайчан да.

Лениза.

Ана шаһит сүзебезгә!

Мин.

Байрагыбыз — вәгъдәбезгә
Төшмәс кер дә, тузан бөртеге дә.
Бүгенгене сезнең күзләр белән күреп...

Лениза.

Чын батырлык-гүзәллекне һәйкәлләргә күчереп,
Геройлар...

Мин.

Без яшәрбез сезнең кебек.

Ана.

Күзләремнең яктылыгын арттырдыгыз,
Балкыттыгыз җир-күк ямен, сөенечен.
Бар аналар исеменнән сезгә рәхмәт,
Сезгә рәхмәт Арсланнар исеменнән.

Лениза.

Терелләр байрак күтәрә
Үлгәннәр өчен!

Мин.

Батырларга һәйкәл — шушы дөнья,
Рәссамнар күк бизәп, төзеп үзебезчә,
Саклап аны бөтен көенчә,
Тапшырырбыз яңа чорга!

Ана.

Ак юл сезгә!

1967—1970.

## Василий Горяинов

### Моң

Күрү белән яраттым бу якны,
Яраткандай туган ягымны.
Камышлы Ык белән ак Минзәлә,
Нигә соң сез шулай ягымлы?!

Үзәкләрне өзә сандугачлар,
Бу, ахрысы, сөю тавышыдыр.
Төнбоеклар үрелгәннәр таңга —
Табигатьнең назы шушыдыр.

Таң җиленә кушылып и сыздыра,
И сыздыра татар гармуны...
Ык суына сеңгән микән әллә
Туган җирнең, илнең бар моңы.

## Михаил Яременко

### Социалистик Хезмәт Герое Г. Латыйпов белән сөйләшү

«Тукай-Җәлил иленде»
дигән шигырьләр циклыннан

Килеп төште дә ул кулны кысты,
Председатель Госман Латыйпов.
— Тын алыймчы бераз, юл арытты,
Урак өсте, туган, вакыт юк...
— Украинадан, дала егете мин,
Михаил,— дим,— минем исемем.
...Көнләшәдер хәтта эшчән кояш
Эшен күреп мондый кешенең.
Күкрәгендә балкый Алтын Йолдыз,
Хыяллары мине уйлатты.
Якты юлга, нурлы якты чорга
Әйди Госман, әйди «Гигант»ны.
Одессаның «Аврора»[1]сын Госман
Туган кырларына чәчәр дә
«Бер басуның игеннәре кебек
Язсын,— дияр,— бергә яшәргә!..»
Мин сүз кушам:
— Безнең олы дуслык
Мәңгелек,— дим,— иген шикелле.
— Мулрак уңыш алыйк,— дип елмая
Һәм кочакка кыса ул мине.

АСФАН БУРАНОВ тәрҗемәләре.

---

[1] «Аврора» — Одесса өлкәсендәге «Пограничник» колхозының югары уңыш бирә торган көзге бодай сорты. «Гигант» колхозы әнә шул колхоз белән дус.

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**СЕНТЯБРЬ-ОКТЯБРЬ, 1972 ел.**

«Волжская коммуна» газетасының 1 һәм 2 сентябрь саннарында «Тольятти — Чаллы» дип исемләнгән гомуми баш астында чыккан мәкаләләрдә Куйбышев һәм КамАЗ төзүчеләренең хезмәттәге уңышлары сурәтләнә.

«Советская Башкирия» газетасы (2 сентябрь) «Тугандаш Татарстан җирендә» дигән рубрика белән яшь язучы Айдар Хәлимнең «КамАЗ утлары» исемле язмаларын бастырып чыгарган. Автор Кама автомобиль заводы төзелешенең барлык совет халыкларының игътибар үзәгендә булуын яза.

«Известия» газетасы каршында чыга торган «Автоэкспедиция недели» журналы үзенең 38 нче номерын Кама елгасы буендагы гигант төзелешкә багышлаган.

«Главмособлстрой материалы» берләшмәсе предприятиеләре Чаллы шәһәренә 20 мең квадрат метр мәйданда торак йортлар төзү өчен детальләр һәм конструкцияләр озаттылар. Ел ахырына кадәр Чаллыга тагын 50 мең квадрат метр торак йортлар өчен төзү материаллары җибәреләчәк. Бу турыда ТАСС хәбәрчесе яза.

Социалистик индустрия» газетасының 16 сентябрьдә чыккан санында «Бүген КамАЗда» дигән рубрика астында бөтен Союз удар комсомол төзелешләрендә эшләүчеләрнең социалистик ярыш йомгаклары бирелгән. СССР Монтаж һәм махсус төзү эшләре министрлыгының һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының Күчмә Кызыл Байрагы 1972 елның беренче ярты еллыктагы уңышлары өчен Кама автомобиль заводын төзүче яшьләр коллективларына бирелгән.

«Строительная газета» (17 сентябрь) Красноярскида төзелә торган прицеплар заводындагы эшләрнең барышын сурәтли. Бу завод продукциясе КамАЗ эшләп чыгарачак машиналар өчен файдаланылачак.

«Чаллыда яңа шәһәр, заводлар комплексы әле яңа төсмерләнеп кенә килә, ә аларның даны инде Татарстан республикасы чикләреннән ашып бөтен илгә таралды, Көнбатыш Европага, хәтта Кушма Штатларга барып җитте»,— дип яза «Известия» газетасы хәбәрчесе Хохлов (19 сентябрь).

«Книжное обозрение» журналы (№ 43) Казан педагогия институты доценты художник В. Игнатьевның бүгенге Чаллы күренешләрен, автогигант төзүчеләрнең хезмәтен, тормышын сурәтләгән рәсемнәре, репортажлары альбомын укучыларга тәкъдим итә.

«Бавлинский рабочий» газетасы 3 октябрьда КПССның Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре Р. Беляевның мәкаләсен бастырып чыгарган. «Чаллыдагы төзелеш,— дип яза автор,— хезмәттә осталыкка ирешү мәктәбе. Тугандаш республикалардан килгән меңнәрчә егетләр һәм кызлар туган якларына менә дигән белгечләр булып кайтачаклар».

«Северная правда», «Вечерний Минск», «Молодой ленинец» газеталары КамАЗ турында АПН хәбәрчесенең «Татарстанның яңа һөнәре» исемле мәкаләсен чыгарганнар.

ТАСС хәбәр итә: КПССның XXII съезды исемендәге Витебск станоклар заводы КамАЗга 20 станок җибәрде. Удар төзелеш заказы вакытыннан алда үтәлде. Витебскидагы Коминтерн исемендәге завод та КамАЗ өчен станокларны вакытыннан элек җитештерде. Витебск машина төзүчеләре ясаган станоклар югары сыйфатлы. Шундый агрегатларның берсе Болгариядә үткәрелгән Халыкара күргәзмәдә алтын медаль белән бүләкләнде.

КамАЗ заказын Гомель шәһәрендәге Киров исемендәге завод та вакытыннан бер айга элек үтәде.

«Кама автомобиль заводы — илебездәге төзелеш эшләренең баш лабораториясе. КамАЗда бик күп яңа конструкцияләр, хезмәттә рациональ алымнар һәм ысуллар имтихан уза»,— дип яза «Строительная газета» 4 октябрьда чыккан санында.

«Социалистическая индустрия» газетасында (7 октябрь) Кама автомобиль заводының генераль директоры Л. Васильевның «КамАЗ — иң мөһим төзелеш» дигән мәкаләсе басылып чыккан. Шул ук санда «Социалистик индустрия Кама автомобиль заводы төзелешендә» дигән атналык газета чыга башлавы әйтелә. Яңа газета мөһим объектларны кору эшләрен, төзелеш графикларының үтәлешен, КамАЗ төзү буенча партия һәм хөкүмәт программаларын тормышка ашыруны үз контроле һәм җәмәгатьчелек контроле астына алачак.

ТАСС хәбәр итә: Днепропетровск шәһәрендәге күтәрү-транспорт җайланмалары заводы узган ел КамАЗ өчен скважиналар бораулау җайланмалары ясауны үзләштерде. Алар бораулап-төеп тутырыла торган субайлар әзерләүдә кулланыла. Май аеннан башлап завод җайланманың камилләштерелгән моделенә күчте. Аларның да беренче партияләре инде КамАЗга җибәрелде.

«Вечерний Ростов» газетасының икенче бите (12 октябрь) тулысы белән Кама буендагы удар төзелешкә багышланган. Газетаның махсус хәбәрчесе, КамАЗда булып, төзелешнең киң масштабын, автозавод төзелешендә эшләүче якташларының хезмәтен, төзелештә эшләүче төрле милләт вәкилләренең үзара дуслыгын сурәтли.

«Кеше тормышка аяк баса. Аңа дөрес юл сайлауда, күңелендә ятышлы һөнәр үзләштерүдә ярдәм күрсәтү өлкән иптәшләренең бурычы», — дип яза «Советская Россия» газетасында (19 октябрь) КПССның Чаллы шәһәр комитеты секретаре иптәш Столяров. Мәкалә яшь буынны тәрбияләү проблемасына багышланган.

«Вечерняя Москва» газетасының 24 октябрьдә чыккан санында Документаль фильмнарның Үзәк студиясе әзерләгән «КамАЗ причаллары» фильмына рецензия басылган. Рецензия авторы фильмга уңай бәя бирә.

ТАСС хәбәр итә: «КамАЗның ремонт-инструменталь заводы өчен Горький механика заводы камилләштерелгән җылылык агрегатлары әзерли. Ел ахырына кадәр 36, ә барлык промышленность комплексы өчен 260 шундый агрегат җитештереләчәк.

## Малик Хәмитов

# КАБАТ КАЙТТЫ ЯШЬЛЕК



Зыятдин кыска төнле җәй көннәрендә дә йокыдан кояш белән бергә уяна. Торгач та беренче эше — балкондагы чәчәкләргә, гөлләргә су сибү. КамГЭС поселогындагы зур торак йортның дүртенче катындагы 229 номерлы аның квартирасын урамнан ук белергә мөмкин: балконы һәм кояшка караган тәрәзәләре төрле төстәге чәчәкләргә, үрмә гөлләргә төренгән булыр. Кыш көне аларның күбесе өйгә күчә, март аенда ук чәчәк ата башлый, ә инде кырау төшми башлагач ук, балконга, тәрәзәләрнең тышкы ягына чыгып урнаша. Беренче карашка шактый кырыс чырайлы, үткен зәңгәр күзле, саргылт чәчләренә инде яртылаш бәс кунган бу илле яшьләрендәге кеше чәчәкләр ярата, гомумән, табигатьне ярата. Язгы таңнарда, вакыты булганда, сандугачлар сайравын, күке кычкыруын сәгатьләр буена тыңларга әзер ул. Ә эштән кайткач, нинди генә һава булмасын, Кама елгасы буена чыга. Кулларын аркасына куя да, күзләрен елга киңлекләренә төбәгән килеш, һәйкәл кебек тынып кала. Йомшак чәчләре Камадан искән җил уңаена сибелә, диңгез суы кебек зәңгәр һәм тирән нурлы күзләре дымлана.

Нәрсә уйлый икән соң ул мондый чакларда?..

Бала чактан нечкә күңелле һәм шул ук вакытта бик шук, житез Зыятдинга унике яшьтән үк тормыш дилбегәсен үз кулына алырга туры килмәсә, ул ата-ана тәрбиясен күреп үссә, мөгаен, я шагыйрь я бер сәнгать кешесе булыр иде. Юк шул, бик яшьли атасын-анасын югалтты ул. Әлбәттә, меңнән артык хуҗалыгы булган Кечү Чынлы авылында аңа сыеныр урын табылган булыр иде, әмма малайның горур йөрәге ят кешеләрдә күз көеге булып калырга теләмә де. Аннан шунысы да бар иде: үз авылыннан тыш та дөньяның ик сез-чиксез икәнлеген белгән нинди генә малайның чит җирләрне күрергә теләге булмасын! Зыятдин Уралга, Чиләбе шәһәренә ничек барасын сорашып белде: башта Ульянга (Ульяновск шәһәрен ала авылында шулай кыскартып йөртәләр), шуннан поездга утырып Чиләбе шәһәренә барып җитәргә була. Ә Чиләбедә аның туганнар туган абыйлары тора иде.

...Бөек Ватан сугышы башланганда Зыятдинга унҗиде яшь т тулмаган иде әле. Шулай да ФЗӨ мәктәбен бетереп һөнәр алган Урал заводларының берсендә үзен ударник һәм уңган активист ите күрсәтергә өлгергән комсомолец иде инде ул. Яше җиткәнче үк фронтка да үзе теләп китте...

...Вахта автобусы. Унсигез-егерме яшьлек егетләр-кызлар — автозавод һәм аның йөрәге булачак ТЭЦны төзүче төрле һөнәр ияләре — шау-гөр килеп көлешәләр, бер-берсенә мәзәк сүзләр әйтеп шаярышалар. Алар арасында өстенә брезент комбинезон, башына кепка, аякларына резина итекләр кигән олырак яшьтәге бер кеше дә бар. Ул читтән караганда, йөзенә күз салмасаң, юлдашларыннан тәбәнәгрәк буйлы булуы белән генә аерылып тора кебек. Тагын шунысы да бар икән: ул яшь-җилкенчәкләрнең шау-шулы мәзәкләренә кушылмый, иреннәренең бер кырые белән генә елмайган килеш, трасса читендәге зур төзелеш панорамасын күзәтеп бара.

Өч ел эчендә бу төзелеш Зыятдин өчен җанга иң якын урын булып әверелде. «Олы башыңны кече итеп, җыен яшь-җилкенчәк арасында эшләп йөрмә»,— дип тынычрак урын һәм эш тәкъдим итсәләр, һич тә риза булмас иде ул. «Тыныч эш эзләп кайтмадым мин туган якларыма, Уралда да мин шундый эштә идем бит»,— дияр иде.



Әйе, 1945 елда Эльба елгасы буенда автоматын старшинага тапшырып, сугышка кадәр эшләгән җиренә — Уралга, Карпинск машина төзү заводына кайтты һәм кулына икенче төрле утлы корал — утлы булса да тыныч хезмәт коралы — сварка аппараты алды. Озак еллар дәвамында тимерне газ һәм электр уты белән эретеп ябыштыручы булып эшләде. Тора-бара, сугышта алган яралар һәм контузияләр үзләрен нык сиздерә башлагач, тынычрак эшкә — Нязепетровск ит комбинатына күчте. Газеталардан Татарстанда, Кама буенда автогигант корыла дигән хәбәрне укыгач, күңеле туган якларга кайтырга өйдәде. Биш куллап каршы алдылар Зыятдинны төзелештә. Хәтта, Бөек Ватан сугышы герое һәм төзелешкә бик кирәкле белгеч икәнлеген искә алып, чираттан элек бер бүлмәле генә булса да квартира да бирделәр. Хәер, ялгыз кешегә бер бүлмәсе дә бик җиткән, кызлары Уралда ук үсеп буйга җиттеләр, башлы-күзле булдылар. Ә хатыны күптәннән инде гүр иясе.

Зыятдин ике елга якын ТЭЦ төзелешендә, Украина егете Маринец җитәкчелегендәге комсомол-яшьләр бригадасында эшләде. ТЭЦ нигезенең 550 тонналы арматурасы, ике йөз илле метр биеклектәге морҗа каркаслары аның катнашында монтажланды.

Автогигант төзелешендә иң мөһим тармаклардан булган икенче автохуҗалыкның автомастерскоена тәҗрибәле белгеч кирәк булгач, Зыятдинны газ һәм электр белән эретеп ябыштыру остасы итеп бирергә күчерделәр...

Икенче автохуҗалык — ТЭЦ тукталышы белән рәттән генә. ТЭЦ калкурак урында булганга, моннан төзелешнең күп өлеше ачык күренә. Әнә кою заводы, әнә җыю заводы каркаслары, ә арырактагы төзелешләр иргәнге зәңгәр томанга төренгән. Ә күктә, әлек бирәзо җәелеп үскән иген басуларын сагынып бугай, тургайлар сайрый. Сугыш кырында да тургайлар сайрый иде, туп, мылтык-пулемет

тавышлары тынган арада сандугачлар сайраган вакытларда да ун сигез яшьлек Зыятдинның йөрәге үрле-кырлы сикергәне бар... Хәер андый ашкынулар сандугач сайраганда гына түгел, һөҗүм алдын нан да була торган иде...

Волхов фронты. 1943 елның 11 январь көне. 12 сенә каршы төн дә ачлыктан интеккән Ленин шәһәре кешеләрен блокададан коткар өчен хәлиткеч һөҗүмгә күчү турындагы приказ барлык сугышчы ларга җиткерелде. Ә иртә белән Волхов фронтының барлык тәр туп лары артиллерия әзерлеген башлады. Дошман оборонасының берен че, аннан икенче сызыкларына меңләгән туплардан меңләгән тонна корыч яуды, «катюша» миналары яман сызгырып, артларыннан утлы сызыклар калдырып бер-бер артлы дошман оборонасы ягына очты. Җир дерелди, ату тавышларыннан кысылган һава колакка каты бәрә, ә сугышчыларның йөрәге ашкынулы иде. Ниһаять, һө җүм. Беренче артиллерия әзерлеге 140 минут дәвам итте. Дошман оборонасының алгы сызыгында уналты километр озынлыгындагы фронтта җәһәннәм уты уллады. Шул ук вакытта Ленинград фронты ның 67 нче армиясендәге бер мең дә җиде йөз орудие телгә килде..

Генерал Минзакир Әпсәләмов дивизиясе составындагы 414 нче полк сугышчылары, алты көн дәвам иткән каты сугышлардан соң, немецларның Синявин калкулыклары итәгендәге ныгытмала рына барып җиттеләр.

Моңа кадәр күбрәк оборонада булсалар да, сугышлы разведка ларда катнашкалаган Зыятдин Арсланов һөҗүм вакытында тирә юнендә очкан пуляларның, снаряд һәм мина ярчыкларының үзенә тию мөмкинлеге турында уйлап та карамады. Әллә балалык чыгып бетмәгәнгәме, сугыш аның өчен уен кебек иде. Үлемнән курыкмады ул: үлемне күп күргән иде инде. Аннары елап калучы ата-анасы, бала-чагалары юк. Сугышның һәр минуты никадәр кешеләрнең ба шына җитә — гадәти күренеш. Әмма шунысы: гомерне бушка бир мәскә! Әнә күрше взвод командиры Яков Богданның артиллерия әзерлеге вакытында исән калган доттан унике иптәшен кырып салган дошман пулеметына каршы берүзе китүен барысы да күреп торды лар. Дотка килеп җитәрәк яраланды, пуля корсагына тиде бугай, әмма ул соңгы көчен җыеп кинәт сикереп торды да амбразурага таш ланды. Доттагы пулемет тончыгып тынып калды. Гимнастеркасының сул як кесәсендә саклана торган комсомол билетын тугыз пуля ти шеп узган иде Яковның. Чын батырларча һәлак булды ул һәм алга ашкынган ротага юл ачты.

Сержант Миңлебаев, инде яраланган булуына карамастан, һө җүмгә ташланган взвод белән командалык итүне үз кулына алды. Дошман траншеялары алдында чәнечкеле тимер чыбык киртәләр взводның юлын бүлде. Миңлебаев озак уйлап тормады, аркасы белән чәнечкеле тимер челтәр өстенә ятты да:

— Минем гәүдә аша алга! — дип команда бирде. Тере күпер аша атылып чыгып, немец траншеясына бәреп кергән сугышчылар үз үзләрен белми сугыштылар. Автомат, мылтык түтәләре дә, сапер көрәкләре дә, хәтта йодрыклар да ходка китте. Исән калган дошман солдатлары чигенде.

Синявин калкулыгы итәгенә урнашкан 5 нче номерлы эшчеләр поселогы берничә мәртәбә кулдан-кулга күчте. Анда дошманның бу участокта бик көчле ныгытылган терәк пункты урнашкан иде. Ни һаять, 414 нче полк сугышчылары поселокны һәм ныгытмаларны штурм белән алдылар. Дөрес, күп кенә солдатлар бу ныгытмалар янында мәңгелеккә ятып калды. Ләкин алар гомерләрен бушка бир мәделәр. Ленинград блокадасы өзелде: 1943 елның 18 гыйнварында Волхов фронтының Икенче удар армиясе составындагы 18 нче укчы

дивизия сугышчылары Ленинград фронтының 136 нчы укчы дивизиясе солдатлары белән очраштылар...

Ниһаять, тарихи көн килде. Уналты ай буе дәвам иткән блокада өзелде, Ленинградка капка ачылды. Ладога күленә кысрыкланып, камалуда калган немец гаскәрләре көньякка таба бәҗраны кисәргә маташып карадылар, ләкин үзләре тәмам тар-мар ителделәр. Ленин шәһәрен Ватан белән тоташтыручы коридор барлыкка килде. Дөрес, коридор зур түгел, бары сигез-унике километр киңлектә иде. Әмма бу сугышлар Бөек Ватан сугышы тарихына әһәмиятле операция булып кереп калды. Утыз километрлап озынлыктагы коридор буйлап шул ук көнне азык-төлек, медикаментлар һәм башка кирәк-яраклар төягән машиналар колоннасы Ленин шәһәренә таба юл алды...

1943 ел дәвамында фашист гаскәрләре, бу коридорны ябып Ленинград шәһәрен кабат блокадада калдыру нияте белән, күп мәртәбәләр куәтле һөҗүмнәр оештырып карадылар, сугышка, кырылып беткәннәре урынына, яңадан-яңа частьлар керттеләр. Күп көнә торак пунктлары, хәрби әһәмияткә ия булган калкулыклар әллә ничә тапкыр кулдан-кулга күчте. Әмма совет солдатлары Ленин шәһәре белән Ватанны бәйли торган бу гаять мөһим юлны нык сакладылар. Ә өч ай әзерлек күргәннән соң, 1944 елның башында Волхов һәм Ленинград фронты гаскәрләре Новгород һәм Мга юнәлешендә үзләре хәлиткеч һөҗүмгә күчтеләр.

18 нче, Кызыл Байраклы, Суворов орденлы Мга дивизиясенең элеккеге командиры отставкадагы генерал-майор Минзакир Әпсәләмов үзенең истәлекләрендә бу сугышлар турында болай дигән иде:

«Дошманны тар-мар итеп, аның куәтле ныгытмаларын, каршылык күрсәтү төеннәрен җимерә-җимерә, күп санлы контратакаларын кире кага-кага, 18 нче укчы дивизия Мга, Тосно, Плюсса, Струги Красные, Карамышево шәһәрләрен һәм бик күп авылларны азат итте. Бу операциядәге уңышлы сугышчан хәрәкәтләре, Мга шәһәрен азат итүе өчен дивизиягә Мга исеме бирелде. Тосно шәһәрен азат итүе өчен Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнде. Ватаныбыз башкаласы Мәскәү ике тапкыр, ә аннары блокададан котылган Ленинград җиңүчеләр хөрмәтенә, шулар исәбеннән 18 нче, Кызыл Байраклы Мга дивизиясе хөрмәтенә салют бирде...

Бу юл бик авыр һәм катлаулы булды, ул физик һәм мораль киеренкелек таләп итте. Бу юлны без җиңү шатлыклары, сугышчан дусларны югалту кайгылары белән үттек. Солдатларның да, командирларның да шәхси һәм массовый батырлыклары исәпсез булды. Башлыча юлсыз, сазлыклы, баткак урыннар аша, тылдагы частьлар ярдәменнән тыш (алар мондый урыннарда безнең арттан өлгерә алмыйлар иде), туйганчы ашамый, эчми, тиешенче сугыш кирәк-яраклары белән тәэмин ителмәгән килеш, һөҗүмгә барырга туры килде. Безнең сугышчылар бирешмәделәр, барысына да түзделәр. Җиңү шатлыгы алга рухландырды, ерткычларча җәзалап үтерелгән совет кешеләре һәм партизаннарның мәетләре, фашист илбасарларының ерткычлыклары турында исән калганнарның сөйләгәннәре дошманнардан рәхимсез үч алырга чакырды...»

Шул дивизиядәге рядовой солдат Зыятдин Арслановның бу сугышларда кичерешләре, ул күрсәткән батырлык үрнәкләре генерал әйткәннәргә менә дигән мисал булып тора. Мга шәһәре өчен сугышларда Зыятдиннар полкы иң җаваплы участокта — дивизиянең авангардында иде. Алар ротасы, шәһәргә бәреп кергәндә көчле пулемет уты астына эләгеп, ятарга мәҗбүр булды. Вак чыршы куаклары арасына ышыкланып артиллерия снарядларыннан ышыккә ышыкланып калган доттан фашист пулеметчысы өзлексез ата, йөгергән исәпкә

кайда туры килсә, шунда яткан сугышчылар өстеннән сызгырышып пулялар сибелә, кайберләре чуер ташлы җир өстенә бәреләләр дә зыңгылдап, читкә очалар. Ротада инде әллә ничә кеше һәлак булды, яраланучылар да шактый иде. Ә доттан рота яткан ачык ялан уч төбендәге кебек күренә булса кирәк. Зыятдин ачудан тешләрен кысты, никадәр сугышчан дусларын һәлак иткән ул фашистны ничек кенә булса да үтерәсе килде аның.

— Эх, полковой пушка булсын иде!.. Туры наводка белән...

Зыятдин тавыш килгән якка әйләнеп карады. Моны әйтүче взвод командиры кече лейтенант Кречетов иде. Зыятдин җавап бирергә сүз тапмады. Хәер, командир өчен аның сүзе кирәкми дә иде. Зыятдин күзләрен кабат алга текәде. Юк, турыдан дотка хәтта шуышып та бару мөмкин түгел. Флангка чыгып булмыйммы икән! Ул ун метрлап читкәрәк шуышты. Тагы да егерме-утыз метрлап читтәрәк снаряд чокыры каралып күренде. Аннан чыршылыкка таба сай гына ерганак сузылган иде. Зыятдин шуышып Кречетов янына кабат килде.

— Иптәш кече лейтенант, дотның артына чыгарга рөхсәт итегез,— диде, сулышын еш-еш алып.— Дөмектерәсе иде фашистны граната бәйләме белән.

Командир, күзләрен туктаусыз ут сибеп торган дотка текәп, беравык дәшми торды,— үзен Зыятдин урынына куеп, шуышып тылга чыгу мөмкинлеген күңеленнән кичерде булса кирәк. Бераздан кыска гына итеп әйтеп куйды:

— Тырышып кара.

— Була ул, иптәш кече лейтенант.

— Ике бәйләм гранаталар ал. Әмма сак бул!

Фашист пулеметчысы лента алыштыргандырмы — бик аз вакытка гына пулеметтан ату тынып торды. Зыятдинга шул гына кирәк иде, ул аяк өстенә сикереп торды да бар көченә әлеге снаряд чокырына йөгерде. Чокырга килеп егылуы булды, өстеннән, коелган шөпшәләр өере кебек, пулялар сызгырышып узды. Зыятдин кычкырып көлеп җибәрде.

— Әһә, кабахәт, өлгерә алмадыңмы!..— Аның тавышы ярсулы иде.

Ерганак эчендә кар шактый тирән иде. Уң як кырына карга шапылдашып туктаусыз пулялар чума, ә ул һаман алга шуыша. Әллә Зыятдинны немецларның шәһәр читендәге позицияләреннән дә күрделәрме — тирә-юньдә миналар төшеп ярыла башлады. Мина шартлавы, мина ярчыкларының зырылдап очуы пулялар сызгыруына кушылды.

Кече лейтенант Кречетов инде күпне күргән солдат, ул минаның яки снарядның кеше өстенә туры килеп төшүенә бик очраклы була торган хәл дип карый. Ә читкә төшеп ярылган мина ярчыклары, дот пулеметы уты кебек үк, Арслановка зыян китермәячәк, чөнки ул ерганак төбеннән шуыша. Шулай да командир Зыятдинга якынрак мина төшеп, металл, төтен катыш кар баганасы күтәрелгән саен, сискәнеп китә — сугышта төрле хәлнең булуы мөмкин бит. Төтен таралып, ерганак төбендә тирән карны ерып шуышучы Зыятдинны кабат күргәч кенә ул җиңел сулап куя.

Менә Зыятдин шулай шуыша-шуыша чыршылыкка кереп югалды. Командир өчен минутлар сәгатьләр кебек озын тоелды. Ә доттан пулемет һаман тыкылдый. Бөтен ротаның бу минутлардагы язмышы Зыятдинның җитезлегенә бәйле иде... Ниһаять, көчле шартлау тавышы тирә-якка яңгырады. Фашист доты булган урын өстеннән

ютен тарадырга да өлгермәде, Зыятдиннар ротасы атакага күтәрелде.

— Ватан өчен!..

Роталар, батальоннар «ура!» кычкырып шәһәр читендәге дошман оборонасына ташландылар. Фашистлар штык сугышына каршы тора алмады, дошман беренче траншеядан, аннан икенчесеннән, өченчесеннән алып ташланды.

Зыятдин Мга шәһәренә беренчеләр сафында бәреп керде. Яраланды, контузия алды, әмма сафтан китмәде... Ә 27 январь көнне 114 нче полк командиры аның күкрәгенә «Батырлык өчен» медален тагады.

Зыятдин Арслановның беренче хөкүмәт бүләге иде бу...

...Мастерскойда әле беркем дә юк иде. Зыятдин киң итеп ишекне ачып куйды. Эш коралларын барлады, рубильник тоткычын күтәреп тикшереп карады: ток киләме?

Эштә дә сугыштагы гадәте Зыятдинның. Беркайчан да начальникның эш күрсәтүен көтеп тормый, башкаларга да салынмый. Һәр шоферның сүзен тыныч кына тыңлый. Аннары шундук эшкә ябыша: машинаның экскаватор чүмече эләгеп яньчелгән яки ярылган кузовын ябыштыра, сынган яисә чатнаган детальләрне «әһ» дигәнче төзәтеп бирә.

Зур төзелештә машиналар еш имгәнә. Автохуҗалыктагы КраЗ, ЯАЗ, МАЗ, ГАЗ һ. б. заводларда эшләнгән зур йөк күтәрә торган машиналардан башка ике кулсыз калыр иде төзелеш. Сугышта яраланган, имгәнгән солдатларга беренче ярдәмне санинструкторлар күрсәтә иде. Ә биредә машиналарга беренче ярдәмне Зыятдин һәм аның ике иптәше — Виктор Зиновьев белән Андрей Степанов күрсәтә. Икесенә бергә кушып санаганда да Зыятдин яше юк әле аларда. Ә начальниклары — Янимов, Николай Федорович — анысына да тыз да тулмаган. Шулай да алар яшендә мин фәлән-төгән идем дип, сүз-үзенә ташлама ясамый Зыятдин. Һәр көнне диярлек эшкә ул иң беренче килә. Чөнки ул яхшы белә: һәр машина төзелешкә төзек чыгарга тиеш. Ә моның өчен Зыятдиннар җаваплы бит. Фронттан калган гадәт буенчадыр инде, ул һәр эштә дә үзен зур җаваплы итеп тоярга өйрәнгән. Башкача булдыра алмый.

Машиналары төзек булмаган шоферлар да эш сәгате башланганчы ук килеп җитә. Әнә капкада Анатолий Глазов күренде. Уң кулын күтәреп, Зыятдинга сәлам бирде дә тиз генә машинасы янына йөгерде. Күп тә үтмәде, мастерской янына иң беренче булып аның машинасы килеп туктады. Анатолий копоттагы ярыкларны ямап куюны һәм кузовның як-ягындагы очлы кырыйларын түгәрәкләп кисеп ташлауны үтенде. Зыятдин, сүзсез генә ым кагып, ризалык белдерде һәм машинаны җир белән тоташтыру өчен кузов артына кечкенә тимер труба сөяп куйды. Аннары, башына битлеген элеп, эшкә дә керешә. Копоттагы ярыкларны ямау кыен булмады, әмма кузовның калын тимер як-якларын түгәрәк итеп тигезләү нык кына иләндерде, һәр миллиметрын кисү өчен көчле электр дугасы карышында шактый тир түгәргә туры килде. Дөрес, аның вазифасы түгел иде заводтан шул килеш чыккан машина кузовына үзгәреш кертү. Әмма егете тырыш, иртән торып иң беренче булып килеп җиткән, экскаватор чүмече эләгеп кала да теңкәгә тия, ди. Үзе хуҗалыкта елдынгы шоферларның берсе. Андыйларга ничек ярдәм итмисең инде. Әлегә чират көтеп торучы машиналар да юк...

Озын буйлы, киң җилкәле, гәүдәсен бераз иебрәк йөрергә гадәтләнгән Виктор Зиновьев та килде. Зур борыны астында калын прен-

нәре очлаеп тора. Беренче карашка астыртын кебек күренсә да, би күндәм һәм мөлаем егет ул. Виктор да вакланып, монысы миңа ка рый, тегесе сиңа дип, эш бүлешеп тормый. Килеп туктатмасаң, көн буе бирүзе баш күтәрми эшләргә мөмкин. Ярдәмчел, кешелекле егет Баш иеп, сүзсез генә исәнләште дә яңа килеп туктаган машинаны «дәваларга» кереште...

Мастерской алдында ике урында утлы очкыннар чәчрәвен Нико лай Федорович Янимов ерактан ук күрде, очкыннар аңа гүя нин дидер могҗизалы көчкә ия булган кара тимер маскалы ике җан иясе авызыннан сибелә кебек тоелды...

Нечкә күңелле кешеләрдә генә була торган моңсу карашлы тыйнак һәм кыюсызрак хәрәкәтле, ябык чырайлы начальник ин элек сварщиклар янына килде.

— С-с-степанов нишләп күренми!— диде, гадәтенчә бераз тотлы гып, аннары исәнләшергә онытуыннан уңайсызланып, ашыгып өс тәде:

— И-и-исәнмесез...

Сварщиклар аппаратларын беразга сүндереп тордылар.

— Хәерле иртә, Николай Федорович,— моны сул кулы белән битлеген югары күтәргән шапкә Зыятдин әйтте.— Ә Андрей төшкә кадәр сорап китте. Ашыгыч эше килеп чыккан икән...

— Алай булса ярый. Т-т-тик машиналар т-т-тоткарланмасын. Армый эшләгез.

— Дөресен әйтергә кирәк иде, Зыятдин Миңлебаевич,— диде Виктор, Янимов күздән югалгач,— Андрей кичә үк сәрхуш иде бит. Рәтләп эше дә булмады.

— Өлгерербез, Витя. Дүшәмбе көнне үзе белән рәтләп сөйләшер без. Эшлисе килмәсә — китәр. Ә хәзергә Николайны борчырга иртә рәк... Кулы алтын ул егетнең. Андыйлар КамАЗда бик кирәк.

Виктор дәшми генә риза булды. Алар икәүләп тә өлгерәләр, хәзер кыш көне яки язгы, көзге пычрак вакытлар түгел: машина лар күп имгәнми. Шулай да чиратлашып эшләү җиңелрәк инде... Машиналар эшкә китеп бетте. Парк тынып калды. Хәзер инде, кай бер машиналар юлда андый-мондый ватылып «дәваланырга» дип килгәнче, ял итеп алырга да була.

Әмма тәмәкеләрен кабызырга гына өлгергәннәр иде, Николай Фе дорович тагын килеп җитте. Һәм Зыятдинга мөрәҗәгать итеп сүз башлады.

— Син ТЭЦ монтажникларын беләсең икән, Зыятдин Миңлебае вич,— диде үтенечле тавыш белән.

— Әйе, беләм, Николай Федорович. Мин элек шунда эшләгән идем бит.

Николай Федорович аклангандай итеп, сүзен дәвам итте:

— Баш инженер да шулай диде. Бер баллон да газ калмады бит безнең. Дүшәмбе көнне генә китерергә вәгъдә бирәләр. Сорап тормас сыңмы икән дусларыңнан.

— Була ул, Николай Федорович. Әлегә машиналар да юк. Кил сәләр Виктор карап җибәрер. Хәзер барып киләм.

Зыятдин папиросын тирән итеп суырды да дусларча елмаеп на чальнигының җилкәсенә кулын салды.

— Үзеңә генә уңайсыздыр, Николай,— диде якын итеп.— Семь яңны кайчан алып киләсең инде.

— Т-т-тулай торакта уңайсыз бит. Яшь бала белән. К-квартира биргәннәрен көтәм инде?

— Әйдә, бүген кичкә миңа кил,— Зыятдин Зиновьевка карап күзен кысты.— Виктор да килә. Өч буйдак күңелле итеп үткәрик әле ялны.

— Рәхмәт, Зыятдин Миңлебаевич. Рәхәтләнеп киләм...

* * *

Кунакларга табынны мена диган итеп азерладе Зыятдин. Өй дә матурлап җыештырылган, идәннәр юылган иде. Бирегә буйдак кеше тора дип һич уйламассың. Менә звонок шалтырады.

Болай да интеллигент кыяфәтле Янимов, яңа костюм кигәч, ак күлмәгә якасына модалы галстук тагып җибәргәч, бигрәк спайлашып киткән. Урамда очрап кыйнап китсә дә танымассың.

Ә Виктор өстенә нинди кием кисә дә, шул ук Виктор булып кала инде: таракка буйсынмас каты сары чәчләре маңгаена төшкән, зәңгәр күзләре көлеп тора. Өстендә — диңгезчеләр киеме.

— Хәерле, кич, герой! — диде ул, кирә керешкә, һәм кесәсеннән өстәлгә коньяк шешәсе чыгарып куйды. Николай Федорович гаҗәпләнеп Викторга карады.

— К-к-кем герой?

Виктор биредә үз кеше — ул Зыятдин белән ТЭЦта ук бергә эшләгән иде — зур-зур атлап түргә узды, сервант тартмасын ачты һәм аннан бер-берсенә тоташтырып беркетелгән орденнар — зур-зур бронза, көмеш һәм алтын йолдызлар алып, Викторның әрсез гадәтләрен килештермичә карап торган Николай Федорович алдына салды. Янимовның күзләре шар булды.

— Оһо,— диде ул,— полный кавалер.

— Николай Федорович КамАЗда яңа кеше бит әле,— диде Зыятдин, елмаеп.— Белмәве бик табигый.

Янимов орденнарны кулына алды, түшенә такты һәм балаларча кукраеп, күкрәген киереп көзге алдына килеп басты.

— К-килешә бит, ә?

— Их, син, горе герой, колодкалы орденнарны уң якка тагалармыни?— Виктор Янимов түшеннән орденнарны алды да дөрес итеп үзенең бушлатына беркетте.

— Охшаганмы мин геройга, Зыятдин Миңлебаевич?

Орденнарны тагып кына карау да аларның икесендә дә үзенә күрә бер мактану, горурлану хисе уятты.

— Бу орденнарның т-т-тарихын сөйләсәгез иде,— дип, Янимов, үтенечле карашын Зыятдинга төбәде.

— Анысы качмас, егетләр. Әйдә утырышыйк!..

Алар таң атканчы сөйләшеп утырдылар. Зыятдинга моннан утыз ел элек булып үткән вакыйгаларны кабат сөйләп бирергә туры килде.

...Совет гаскәрләре Үзәк һәм Көньяк фронтларда гитлерчыларны көнбатышка таба көннән-көн зуррак тизлек белән куалар, илебез җирен фашист баскыннарыннан азат итү торган саен киңрәк колач ала бара иде. Ленинград һәм Волхов фронтларында да һөҗүм сугышлары көчәйде. Полклар тәүлеккә биш-ун километр көнбатышка таба күчә иде. Азат ителгән торак пунктлары көннән-көн күбәйде. Гаскәрләр Балтик диңгезеннән Ильмень күленә кадәр өч йөз километрдан артык арада көчле һөҗүм сугышлары алып бардылар. Бер ай сугышлардан соң фронт сызыгы Ленинградтан йөз илле-ике йөз километрга күчте. Дошман армияләренең «Төньяк» группасы бөтенләе белән диярлек тар-мар ителде, аның калдыклары Балтик буена чигенде. «Чигенгәндә фашистлар юлларны эштән чыгара, күперләрне җимерә, елгаларны кичү өчен яраклы барлык нәрсәне юк итә, элемтә линияләрен боза иде. Безнең гаскәрләргә һөҗүмне юлсыз, сазлыклар, куллар, күп санлы елгалар аша дәвам итәргә туры килде. Мондый урыннар дошманга оборона тотар өчен уңайлы, ә безгә һөҗүм итү өчен бик җайсыз иде.

Мегроозеро, Аккош, Мандроозеро күлләре районын дошман әруча ныгыткан иде: озакка чыдамлы ут нокталарына броня калпаклар кидерелгән, танкларга каршы тимер баганалар утыртылган, чәнечкеле тимер чыбык киртәләр корылган, миналанган. Барысы да бик нык маскировкаланган — килеп төртелмичә һич белерлек түгел...

Дошманны бу ныгытмалардан һөҗүм итеп килгән шәпкә бәреп чыгару мөмкин түгел иде. Авангардтагы 414 нче полкны дошман көчле пулемет уты белән каршы алды»,— дип язды соңыннан дивизия командиры Минзакир Әпсәләмов.

...Таң беленеп кенә килә иде. Нарат урманы иртәнге җилдән салмак кына шаулый. Пехота тавышсыз-тынсыз гына алга бара. Менә пехотаны танклар, авыр туплар таккан тягачлар, снарядлар, миналар төягән автомашиналар куып җитте. Дошман ныгытмаларына җитәргә шактый бар әле. Привал. Кинәт җир тетрәгәндәй булды. Ялга туктаган пехота, танклар һәм артиллерия өстенә снарядлар, миналар ява башлады. Күктә самолетлар күренде. Дошман самолетлары төркем-төркем киләләр дә, яман үкереп, нәкъ полк урнашкан урын турысына танаулары белән кадалып төшәләр, төшкән уңайга эре калибрлы пулеметлардан, пушкалардан аталар, бомбаларын коялар. Бомба туры тиюдән бер машина шартлап күккә очты. Җир актарыла, дәү-дәү наратлар тамырлары белән каерылып авалар, снарядлар, миналар әледән-әле агач кәүсәләренә тиеп шартлыйлар да тирә-юньгә бик күп металл ярчыклар сибәләр. Яралылар кычкыра, ыңгыраша, елый...

Юан бер нарат төбенә поскан Зыятдинның күзләре уң якта агачлардан биек булып өскә күтәрелгән очлы кыяга төште. Киртләч кыя ышыгыннан чыгып килгән кояш нурында нәрсәдер ялтырап киткән кебек булды.

— Корректировщик!— Арсланов автоматын күкрәгенә кысып тотты да алга атылды.

— Петя, командирны күрсәң әйтерсең: мин кыяга оялаган фашист каргасын бәреп төшерәм,— диде ул юлда очраган солдатка.

Солдат сүзнең ни турыда барганын төшенмәде бугай, нәрсәдер әйтергә теләп, шактый китеп өлгергән Зыятдинны үз янына чакырды. Зыятдин әйләнеп тә карамады. Озакламый аның кечкенә, ябык, әмма җитез гәүдәсе таштан ташка сикерә, текә кыя буенча өскә үрмәли иде инде. Ул хәзер снаряд, бомба шартлауларын да ишетми иде. Хәтта безнең зенитка снаряды тиеп, каядыр урман эченә төшеп шартлаган дошман самолетына да игътибар итмәде. Бөтен дикъкате әлеге киртләч кыяда иде. Очлы гранит ташка киселеп каналган бармакларының авыртуын да сизмәде ул.

— Менә кая оялаган икән ул кабахәт.— Зыятдин ярсып тешләрен кысты.— Никадәр кешенең башына җитте явыз...

— Һенде һох!

Рация микрофонына нәрсәдер әйтеп маташкан немец корректировщигы сискәнеп китте, уң кулы автоматка үрелде. Ләкин үзенә төбәлгән автомат тоткан совет солдатын күргәч, сул кулын өскә күтәрде.

— Ташла автоматыңны, югыйсә, пух-пух итәм.

Немец аңламады. Зыятдин автоматының чакмасына басты, фашист баш очыннан бер өер пулялар сызгырышып узды һәм ул куркып таш өстенә ауды.

— Ташла коралыңны!— Зыятдин немец кулындагы автоматка төртеп күрсәтте.

Ниһаять, Зыятдинның әйткәне немецның башына барып җитте, ул, йөзтүбән яткан килеш, автоматын бер читкә этәрде, ә Зыятдин аны иелеп алды да сул як җилкәсенә элде.

— Тор аяк өстеңә, фриц! Встать... Менә шулай... Ә куллар... һенд... һенд... Менә... менә... Юк, юк... Менә моны җилкәңә күтәр — Зыятдин рациягә, аннан немецның җилкәсенә ымлады.

— Хәзер инде ком, форварте,— дип боерды аннары ул, немец рацияне җилкәсенә күтәргәч...

Ике көннән соң, немецлар әлеге көчле ныгытмаларыннан алып ташлангач, полкташлары Зыятдин Арслановны Дан орденының өченче дәрәҗәсе белән котладылар...

Ә Дан орденының икенче дәрәҗәсе белән Зыятдин Висла елгасын кичкәндәге батырлыклары өчен бүләкләнде.

Польша шәһәре Гданскидан ерак түгел, Тчев шәһәре турысындарак, елга аръягына чыгып, полкка плацдарм яулап алу лейтенант Кречетов взводына йөкләнде. Взвод елганы югалтуларсыз кичте, бу вакытта дошманның алгы оборона сызыгын полк артиллериясе көчле ут астында тотты. Хәвеф-хәтәрсез сул як ярга чыгып җиткү турында хәбәр килү белән, артиллерия тынып калды. Взвод шундук «ура!» кычкырып немец траншеяларына ташланды. Кул сугышы башланды. Дошман ничек кенә булса да совет солдатларын биек ярдан елгага тәгәрәтергә тырышты. Әлбәттә, көчләр тигез түгел иде. Шактый кеше сафтан чыкты. Әмма ул арада дошман траншеяларында сугыш алып барган Кречетов взводына ышыкланып, тагын ике взвод елганы кичәргә өлгерде. Беренче траншея, аннан икенчесе немецлардан чистартылды. Немецлар әле генә үзләренең алгы оборона сызыгы булган траншеяларына гранаталар, Ленинград һәм Волхов фронты сугышчылары арасында «дурило» дигән аты чыккан алты көпшәле реактив минометларыннан мина яудырырга керештеләр. Әмма траншеяларга ныгып урнашкан совет сугышчыларын чигенергә мәҗбүр итү җиңел түгел иде инде. Күбрәк психикасы сәламәт булмаганнарга тәэсир итәргә сәләтле, ачы чинап очып төшеп бик каты шартлый торган, безнең «катюша»лардан аермасы җир белән күк арасы хәтле булган «дурило» миналары безнең сугышчыларга әллә ни зыян китерә алмады. Шулай да сугыш кызганнан-кыза барды. Мина ярчыгы лейтенант Кречетовны яралады. Яман авыртудан тешен кысып, ул яралы кулын бәйләтте дә командалык итүен дәвам итте. Немец солдатлары безнең плацдарм тоткан сугышчылар өстенә сукыр чебеннәр кебек ябырылдылар. Гранаталар, пулеметлар, автоматлар утыннан бик күбесе җиргә тәгәрәде, калганнары чигенергә мәҗбүр булды. Алда танклар, аларга ышыклanып аягүрә һөҗүм итеп килүче немец солдатлары һәм офицерлары күренде. Иң алдан килгән танк тубының беренче снаряды ук безнең станоклы пулеметны, расчеты белән бергә, сафтан чыгарды. Танкка каршы мылтык расчеты урнашкан оядан да тавыш-тын ишетелми иде. Зыятдин траншея буйлап шунда йөгерде. Киң җилкәле, зур гәүдәле Викулов, мылтыкның түтәсен иңбашына терәгән дә, башын сул якка салып, тынып калган. Күзләре нурсыз. Ярдәмчесе, куллары як-якка җәеп, йөзтүбән ауган. Зыятдин һәлак булган дусларының гәүдәләрен бер читкәрәк урнаштырды да мылтык янына үзе ятты.

Танк һаман якынлаша. Ул туп-туры Зыятдинга карап килә кебек. Зыятдин мылтыгын бик җентекләп төзәде дә атып җибәрде. Әмма танкка берни булмады. Хәтта ул тизлеген арттыра да төште бугай әле. Ничек онытты соң әле Зыятдин — бу бит «тигр», аның алдагы бронясын хәтта 76 *мм*лы снаряд та ала алмый... Ничек тә аны ян белән борылырга мәҗбүр итәргә кирәк! Моның өчен... Зыятдин мылтыкны танкның гусеницасына төбәде. Атып җибәрде дә, нәтиҗәне дә карап тормастан, тиз-тиз генә мылтыкны кабат корды. Гусеницасы өзелеп яны белән борылган танк бортына бер-бер артлы

тагын ике тапкыр броня тишә торган эре калибрлы пуля җибәрде. Ниһаять, «тигр» өстендә кара төтен пәрдәсе күтәрелде.

Траншеяга якын ук килеп өлгергән икенче танкны Зыятдинның сугышчан дусты Петр Жданов гранаталар бәйләме ташлап яндырды. Сугыш кырында дүрт танкысын, дистәләрчә үле солдат һәм офицерларын калдырып, дошман бу юлы да чигенде.

Гитлерчылар биш тапкыр атакага күтәрелде ул көнне, каты сугышлар иртә таңнан караңгы төшкәнче туктамады.

Ә икенче көнне иртән Висланы кичеп өлгергән безнең гаскәрләр, куәтле артиллерия әзерлегеннән соң, киң фронт буйлап фашист илбасарларын Польша җиреннән тәмам куу өчен зур һөҗүм башладылар...

Гданск шәһәрен алу өчен безнең гаскәрләргә иң башлап, Быдгош — Тчев — Гдыня тимер юлы буенча сузылган дошман ныгытмаларын җимереп, фронтны өзәргә кирәк иде. Һөҗүм, шушы ныгытмаларга терәлеп, тукталып калды. Тимер юл буйлап дошманның бронепоездлары йөреп торды, безнең сугышчыларга, танкларга снарядлар, пулялар яудырды. Фашистлар, соңгы көчләрен туплап, совет гаскәрләренең һөҗүмен бу сызыкта туктатырга теләделәр. Тимер юл тирәсе танкларга каршы корыч баганалар, миналар, тирән итеп казылган чокырлар белән тулы иде. Шулай да совет солдатлары адымлап-адымлап булса да алга баруларын туктатмадылар, көннән-көн дошман оборонасына эчкәрәк юл сала бардылар.

Лейтенант Кречетовның автоматчылар взводында соңгы каты сугышлардан соң бары сигез солдат калган иде. Шулай да әле ул хәрби берәмлек, взвод. Хәрби приказда аңа отделение түгел, взвод хәл итәргә тиешле бурыч куелган: сугышлы разведка ясарга — тимер юлның көнбатыш ягына үтеп чыгып, дошманның көчен белергә, ут нокталарын, инженерлык корылмаларын ачыкларга һәм разведка нәтиҗәсен радио аша дивизиянең команда пунктына хәбәр итәргә!

Лейтенант Василий Кречетов «взвод»ны дүрт төркемгә бүлде. Һәр төркемдә... икешәр автоматчы.

Рядовой Арсланов белән рядовой Петр Жданов иң беренче булып тимер юл калкулыгының көнбатыш ягына үтәргә, җайлы урын табып яшеренергә һәм күргәннәрен радио аша команда пунктына хәбәр итәргә, ә калган өч төркем, төрле урыннан ут ачып, дошманның игътибарын Зыятдиннардан читләштерергә тиеш иде.

Зыятдин, взвод командирыннан бинокль алып, нейтраль зонадан тимер юл калкулыгының һәр метрын күзәтергә кереште. Күзләре талгач, бинокльне Ждановка бирде. Алмашлап алар дошман ягын көне буе күздән кичерделәр.

Тимер юлга таба тигез дала буйлап сай гына ерганак сыман уйсулык сузылган иде. Димәк, калкулык аша су агу өчен ачыклык калдырылган булырга тиеш. Чыннан да, бинокль аша күренеп тора, бу ерганак калкулыкка килеп терәлгән урында тирәкләрдерме, әллә узган елдан калган үсемлек кураларыдырмы, куерак булып үскән...

Егетләр тәвәккәлләделәр. Арка капчыкларына күп итеп дисканы тутырдылар, бил каешына «лимонка»лар элделәр һәм ярты төн җиткәч, автоматларын алдылар да бик зур саклык белән алга шуыштылар. Ниһаять, калкулык. Әлеге ерганак терәлгән урынны эзләп сулгарак шуыштылар. Кинәт якты йолдыз булып ракета атылды һәм иң югары ноктасына менеп җитте дә, бөтен тирә-якка яктылык сибеп, эленеп калды. Җир өстендә энә ятса да күренерлек иде. Икесе дә сулыш алырга да шикләнеп тынып калды. Пулеметтан аткан тавышлар ишетелде. Артларыннан утлы җеп кебек сызык калдырып, безнең алгы сызыкка таба яктырткыч пулялар очты. Димәк гитлерчылар Зыятдиннарны абайламадылар. Гитлерчыларга каршы

әч төркемгә бүленгән алты солдат, автоматлардан һәм пулеметлар җавап уты ачтылар. Дошман позицияләре хәрәкәткә килде. Фашистлар автомат һәм пулеметлар гына түгел, минометларын, алты көпшәле «дурило»ларын да эшкә җиктеләр.

Егетләр, шау-шудан файдаланып, кызурак алга омтылдылар. Менә якында гына әлеге куаклык шәүләсе төсмерләнде.

— Труба!— дип пышылдады алданрак шуышып барган Петр.

— Кеше сыярлыкмы?

— Бер генә түгел, ике кеше сыярлык. Тик яртылаш су тулган.

— Анысы пустяк!

— Син гәүдәгә дә җиңел, житезрәк тә. Алдан кер әйдә!..

Зыятдин алга чыкты. Автоматын сул кулына күчерде, бил каешындагы гранаталарны аркасынарак шудырды, капчык ләмкәләрен җайлабрак беркетте дә пычрак су ерып трубага кереп китте. Бераздан Жданов та кузгалды.

Немецлар пычрак су тулы труба аша үз позицияләренә чыгу мөмкинлеген башларына китермәгәннәр — аргы якта да бернинди дә сак юк иде. Якында гына немецча сөйләшкән тавышлар ишетелде.

Егетләр, труба аша дошман ягына чыккач, беравык тын да чыгармыйча хәл җыйдылар, аннан шул ук ерганакның дәвамы буйлап тагы да сулгарак тайпылдылар. Шуыша торгач, немецларның тылына таба сузылган бер траншеяга тап булдылар. Зыятдин юлны шушы траншея буйлап дәвам итәргә ниятләде, Петр да моңа каршы килмәде, чөнки немецлар калкулыкның бу ягында үзләрен һәртөрле куркынычтан азат дип сизәләр, траншея буйлап түгел, тигез җирдән аяк өсте йөргәндә дә пуля тиюдән шикләнмиләр... Шулай бара торгач, траншеядан шактый читтә зур-зур кара өемнәр шәйләделәр. Шул яктан әкрен генә җил исеп куйды. Җил бензин һәм янган резина исе алып килде — димәк, безнең снаряд яки мина тиеп җимерелгән машина булырга тиеш. Анда немецлар да юктыр, әлбәттә, җимерек машинаны нигә саклап торсыннар, ди. Чыннан да, шулай булып чыкты, бер генә түгел, дүртәүләп. Тәзгерәк кабиналысын сайлап, эченә кереп утырдылар. Бик вакытлы булып чыкты бу — сибәләп яңгыр яварга керешге. Трубадан чыкканда юешләнгән, пычранган маскхалатларны салып куйдылар да рацияне җайладылар.

— Килеп җиттек, әйбәт кенә урнаштык. Таң атуын көтәбез,— дип командованиегә хәбәр иттеләр, чамалап үзләре урнашкан квадратны да белдерделәр.

Озакламый алгы сызыкта атышлар тынды. Таң беленде. Ә яңгыр һаман ява иде. Ясын әйдә, күзәткәндә бинокль пыяласыннан кояш нурлары чагылмаячак, аннары немецлар да яңгыр астында ул хәтле арлы-бирле тузгымаячак...

Тимер юл буе тоташ озакка чыдамлы ут нокталары белән ныгытылган. Икенче эшелонда дотлар шахмат тәртибендә — һәр дотны бүтәннәре уты контроль астында тотарлык итеп урнаштырылган. Пехота белән һөҗүм итеп кара син аларга! Танклар әле шактый артта, аларны Висла елгасын кичү һәм күлләр, сазлыклар токтарлады. Авыр артиллерия дә шулай ук. Дивизия белән полк батареялары гына хәрәкәт итә. Җитмәсә тагын, взводларда гына түгел, батальоннарда да сугышчылар нык сирәгәйде. Бу шартларда һөҗүмне гаять сак оештыру мәҗбүри — моны һәрбер солдат белә иде. Ә приказны барыбер үтәргә кирәк!

Зыятдин белән Петр башта дошманның ут нокталарын картага төшерделәр, аннан алар урнашкан квадратларны командованиегә хәбәр иттеләр. Бу эшне бетергәннәр генә иде, Петр үзләре килгән траншеяга таба төртеп күрсәтте. Баштанаяк коралланган ике немец

солдаты ят телдә нәрсәдер сөйләшә-сөйләшә траншея буйлап каядыр баралар иде. Менә алар җимерек машиналар турысына килеп җитте, берсе, нәкъ шул урында туктап, машиналарга таба борылды. Икенчесе дә тукталды. Егетләр, сулыш алырга да шикләнеп, тынып калдылар. Кабинаның бу ягына утырган Зыятдин җиңел сулап куйды: үз йомышларын үтәр өчен генә тукталганнар икән... Солдатлар бардылар-бардылар да кинәт юкка чыктылар. Озак та үтмәде, алар югалган урынга тагын ике солдат пәйда булды. Аларның траншея буйлап әйләнгеч юлдан йөриселәре килмәде, ахрысы, турыдан гына элдерттеләр.

— Димәк, даими сак астында тотарлык бик мөһим нәрсә бар анда,— диде Жданов һәм картага шул урынны билгеләп сорау билгесе куйды...

— Караңгы төшкәч белербез, сакчыларны да дөмектерербез,— диде Зыятдин. Жданов, ризалыгын белдереп, башын какты.

Кичкә таба 15 сәгать 30 минутта безнең дивизиянең полк батареялары — 76 *мм* лы туплар телгә килде. Алар кая җитте — шунда түгел, алдан билгеләнгән прицел белән тиешле урынга төзәп аттылар. Дошман оборонасының беренче һәм икенче эшелоны өстендә стена булып кара төтен күтәрелде. Бер дотка берьюлы берничә снаряд төшеп шартлады. Ут нокталарының күбесе сафтан чыкканны Зыятдин белән Петр күзәтеп тордылар, алар ныгытылган ут ноктасына төз тигән снаряд шартлаган саен үз-үзләрен «ура!» кычкырудан чак кына тыеп калалар иде. Артиллерия үз эшен әйбәт башкарды — күп кенә дотлар җимерелде. Әмма Зыятдиннарның дошман тылындагы эшләре бетмәгән иде әле — аларның тагы артиллерия налетының нәтиҗәсе, җимерелмичә калган дотлар турында командованиегә хәбәр итәсе калды. Алдан корылган план буенча, взводның нейтраль зонада калган өч төркеме, таң алдыннан тимер юл калкулыгы янына Зыятдиннар юлыннан килеп, төрле урынга ныгып урнашырга һәм дошманнар өстенә автоматлардан, пулеметлардан ут ачарга тиеш иде. Зыятдин белән Петр алдында җавап уты ачкан ут нокталарын билгеләү һәм алар турында безнекеләргә хәбәр итү бурычы тора иде.

Ике егет калган вакытны бушка уздырмады. Төн урталары җиткәч, яшеренгән кабиналарыннан чыктылар, оеган тәннәрен яза-яза, инде шактый кибеп өлгергән маскхалатларын киделәр һәм зур саклык белән әлеге ике солдат кереп югалган урынга таба үрмәләделәр. Колхозларда яшелчә яки бәрәңге саклый торган базларны хәтерләткән озын гына землянка булып чыкты бу. Әлеге траншея шул землянкага төшә торган баскычка килеп төртелә. Сакчыны дөмектерергә дип кузгалырга гына торганда, арттан аяк тавышлары ишетелде. Егетләр тиз генә читкәрәк шуыштылар. Димәк, сакчылар алмашыр вакыт җиткән. Ярый әле, алданрак килеп, эшне бозып өлгермәделәр. Язмыш аларга бу юлы да рәхимле булды.

Ничә елдан бирле инде бу ике егет — Зыятдин Арсланов белән Петр Жданов — берсенең шинелен аска җәеп, бер шинельне ябынып бергә йоклап, бер котелоктан аш бүлешеп, бергә оборонада тордылар, бергә сугыштылар, ничәмә-ничә атакаларга бергә бардылар, бергәләп ничәмә-ничә үлемнең күзенә карадылар. Шулай да шөкер әлегә, икесе дә исән, хәтта икесендә дә бер үк хөкүмәт бүләкләре... Сугыш һәм тормыш тәҗрибәсе, үз-үзеңә нык ышану, тәвәккәллек һәм кыюлык — ә солдат өчен бик кирәкле бу сыйфатлар яшь булсалар да аларның икесендә дә җитәрлек — моңа тикле уттан да, судан да сау-сәламәт чыгуларының, мең үлемнән исән калуларының сәбәбе шулардыр, мөгаен. Ә бу юлы аларны очраклылык коткарды.

Әйе, бәхетле йолдыз астында туганнар икән! Хәер, сугышта очраклылык, үлем кебек үк, адым саен бит ул...

Сак алышынып ярты сәгатьләп үткәч, ниятләрен гамәлгә ашырырга дип, яткан урыннарыннан кузгалдылар. Сакчыларның берсе тышкы ишек төбендә сигаретын суыра-суыра йөренә иде. Йөрәгенә хәнҗәр кадап, тавышсыз-тынсыз гына эшне бетерделәр. Икенчесен дөмектерү тагы да җиңелрәк булды. Тышкы ишекне аз гына ачып күз салганнар иде, карбид лампасы яктысында ап-ачык күренде: сакчы буш әрҗә өстенә автоматын тезләре арасына кыстырып утырган да, башын бер якка салып, йоклап киткән. Чигәсенә автомат түтәсе белән тондырдылар — «эһ» тә итмәде, авып төште.

Корал складыы булып чыкты бу — эченнән бетон белән ныгытылган землянка. Өр-яңа автоматлар, пулеметлар, гранаталар, миналар, дискалар, корылган пулемет ленталары...

Хәзер ни эшләргә икәнен сүзсез дә төшенделәр: землянка тирәсенә дүрт урынга дүрт пулемет алып чыгып, дошманга төзәп куйдылар. Тагын өчесен як-якка читкәрәк уңайлы урын сайлап урнаштырдылар. Һәрберсе корылды, яннарына күп итеп дискалар һәм ленталар запасы, гранаталар ташыдылар. Дошман тылына чыгуларына бер тәүлек тулды дигәндә немецларның чигенү юлында дуга рәвешендәге көчле оборона әзер иде. Яктыра башлау белән, икесенә дә эш җитәрлек булачак...

Туган ил ягыннан сызылып таң беленде. Һөҗүм башлануын ике дус түземсезлек белән дулкынланып көтте. Көн яктырыр-яктырмас, тимер юл калкулыгы аша Зыятдиннар юлыннан чыккан взводның калган алты сугышчысы төрле урыннан дошман позицияләренә ут ачты. Дошман траншеялары да хәрәкәткә килде. Немецлар үзләренә каршы аз санлы совет сугышчыларының һөҗүм итүен аңладылар, батальонга якын солдатлар һәм офицерлар атакага күтәрелде.

— Вакыт! — диде Зыятдин һәм ике баш бармагы белән пулемет гашеткасына басты. Бер егерме метрлап читтәнрәк Жданов пулеметы да телгә килде. Зыятдин лентадагы патроннарны тулысы белән дошман өстенә сибеп бетерде дә икенче пулемет янына йөгерде. Ике яктан ут эчендә калган фашист солдатлары арасында паника купты. Немецларның иң курыкканы чолганышта калу иде — алар атакага баруларын оныттылар, өсләренә тылдан да пулялар сибелүен белгәч, арлы-бирле йөгерергә керештеләр. Уңайлы позициягә урнашкан Зыятдин белән Петр да, взводның бүтән сугышчылары да аларны чебен урынына кырдылар. Сугыш күп булса ярты сәгатькә барды, немецларның исән калганнары, коралларын ташлап, кулларын күтәрде.

Бу рейдның нәтиҗәсе шул булды: йөзләрчә немец солдаты һәм офицеры үтерелде, 38 е әсир ителде, меңнәрчә өр-яңа пулемет һәм автомат, ун меңнәрчә снарядлар, миналар, патроннар һәм гранаталар кулга төште. Иң мөһиме — безнең яктан берничә югалтусыз диярлек, берничә километр арада дошман оборонасы өзелде, дивизиягә Гданск шәһәренә һөҗүм итү өчен юл ачылды. Дивизия командованиесе сугышчыларның бу батырлыкларына зур бәя бирде, аларның һәрберсе хөкүмәт бүләкләренә тәкъдим ителде. Ике дус — Зыятдин Арсланов белән Петр Жданов — иң югары солдат бүләгенә — Дан орденының Беренче дәрәҗәсенә лаек булды.

1945 елның 18 апрелендә СССР Верховный Советы Президиумы исеменнән Армия командующие Зыятдин күкрәгенә 356 нчы номерлы, Петр Жданов күкрәгенә 357 нче номерлы зур алтын йолдыз такты.

Ә җиңү көнен алар икесе дә Эльба елгасының уң як ярында каршы алдылар...

* * *

...Егетләр тын да алмый тыңладылар. Бигрәк тә Николай Федоровнч. Ул кисәк кенә утырган урыныннан сикереп тора да бүлмә буйлап кызу-кызу йөрергә керешә. Аннан тагын килеп утыра һәм күзләрен бер ноктага текәп, тынып кала. Беравык шулай уйланып торганнан соң, Зыятдиннан сөйләгәнен тагын кабатлавын сорый. Ә Виктор беркатлы дорфалык белән, тик кенә тыңлап утыруны талап итеп, Янимовның күлмәк җиңеннән тарта, әмма бүтән вакытта башын иеп, кашларын җыерып, астыртын итеп — мондый карап әлегә кадәр үзләрен бик батыр дип йөргән адәмнәрнең дә тез буыннарын йомшарта иде — текәлеп карау файда бирми: начальнигының хыялы — хәзерге чынбарлыкта түгел, ул Зыятдин булып фашистлар белән сугыша, атакага бара...

Июнь төне бик кыска бит ул. Тәрәзәләрдән бүлмәгә яңа көн — ял көне нурлары кереп тулды. Виктор торып электр утын сүндерде дә сигарет пачкасына үрелде. Пачка буш иде. Аннары Зыятдин гына тарта торган «Беломор» пачкасын капшап карады. Анда да тәмәке юк иде. Шуннан тәмәке көле савытыннан төпчек эзләргә керешә. Тапкач, җиңел сулап куйды. Һәм телгә килде:

— Герой, Петр Жданов исәнме хәзер? — дип сорады, төпчеген кабыза-кабыза. Ә җавапны ишеттеме икән, чөнки шырпысы сигарет төпчегенә түгел, э иренәнә тиде һәм ул, тәмәкене уйлап тапкан бәндәне каргый-каргый, ванна бүлмәсенә салкын су астына йөгерде. Ә Зыятдин болай дип җавап бирде:

— Запастагы старшина Петр Тимофеевич Жданов хәзер Липецк өлкәсендә. Колхозчы...

— Ә К-к-кречетов кем? — моны Николай Федорович сорады.

— Василий Сергеевич Себердән иде. Элек укытучы булган. Хәзерге язмышын белмим, хат алышкан юк...

Ул арада бүлмәгә болай да калын, әмма шырпы утыннан пешеп, тагы да күперган аскы иренәнә ниндидер крем сөртә-сөртә кергән Виктор сүзгә кушылды:

— Син ничек уйлыйсың, Янимов? Әгәр АТХ капкасына: «Бездә Бөек Ватан сугышы ветераны, Дан орденнарының тулы кавалеры Зыятдин Миңлебаевич Арсланов эшли»,— дигән язу кадаклап куйсак, ничек булыр?

— Идея. Б-б-баш эшли синең, Виктор. Арслановның кем икәнен әле бездә күпләр белми. Ә аның эше һәм ул үзе һәркем өчен горурлык булачак. Ә коллективның үз кешеләре белән горурлануы ул — патриотизм...

Янимов беравык тынып торды, ул да Виктор кебек үк сигарет һәм «Беломор» капларын капшады, аннары, карашын Зыятдинга төбәп, сүзен дәвам итте:

— Зыятдин Миңлебаевич, сезнең кебек мин дә чәчәкләрне яратам, табигатьне, гүзәллекне яратам. Мин дә авылда туып-үстем. Ләкин безнең якта — Курганда — җир уңдырышлы түгел. Сезнең Терентий Мальцевны ишеткәнегез бардыр. Ул үзе колхозчы һәм... академик. Ул мине күптән белә, мин дә аны малай чактан бирле беләм. Бергә эшләдек. Мин сигезне бетергәч тә тракторчы булдым. Ул ничек сөрергә, ничек чәчәргә өйрәтә иде. Аның киңәше белән техникумга кердем. Бетердем. Мастер булып «Сельхозтехника»да эшләдем. Мальцев кебек, уңдырышсыз җирне уңдырышлы итүче кешеләрне бик ихтирам итсәм дә, кечкенәдән үк машина җене кагылганга, менә монда килдем. Монда туфрак бездәге кебек түгел, уңдырышлы булган икән. Уңдырышлы туфрак катламын кырып алып бик дөрес эшлиләр бирсдә. Әрәм итмиләр. Андый катламны булдыру

өчен дистәләрчә еллар кирәк бит. Ә без төзи торган заводның уңыш бирү сәләте — тагы да зуррак,— Николай Федорович боларны дәртләнеп, бер дә тотлыкмыйча сөйләде.

— Син дә озын итеп сөйли беләсең икән, Николай Федорович,— диде Виктор һәм урыныннан торып киерелде.— Конторадагы белдерүне укыгансыздыр. Бүген безнең коллектив Кама аръягында ял итә. Миндә тәкъдим бар: без хәзер үк кузгалыйк!

— Ә катерлар йөрми бит әле.

— Транспорт өчен кайгырмагыз. Көймә, ишкәкләрен салындырып, сезне көтә.

— Ә б-б-батырмассыңмы соң безне?

Виктор бу сүзләрне үзеннән көлү, мыскыллау дип аңлады.

— Кем дип беләсең син мине,— дип сөйләп китте ул, кызып.— Казаннан поезд белән чыккач та, Мәскәү юлында Обсерватория дигән поселокны беләсеңме син? Нәкъ Идел дигән зур елга буенда ул. Бәлки география дәресләрен дә хәтерлисеңдер,— Виктор мыскыллы елмайды.— Кама дигән елга да шунда коя. Менә шул поселокта туып үстем мин. Бездә бала-чага, тәпи йөри башлаганчы ук, йөзәргә өйрәнә. Сезнең Кургандагы кебек өстәл астында үрмәләп йөрми... Полундра! Җыену өчен сезгә ун минут.

— Ә азык-төлек, т-т-тәмәке?

— Парад белән мин командалык итәм, барысы да әзер. Кичәдән үк. Бүтәннәр җыенып катер белән килеп җиткәнче, балык та тотарга өлгерербез әле, әйеме, герой.

— Молодец, Виктор,— диде Зыятдин,— синең белән дошман тылына разведкага барырга була.

— Ишеттеңме?— диде Виктор, Янимовка карап.— Күпме күргән карт солдат әйтә моны.— Һәм ул кукраеп, күкрәгән киерде дә «смирно» басты.

— КамАЗ төзелешенә хезмәт итәм, иптәш полный кавалер!

— Солдатың солдат, әмма карт түгел,— дип каршы төште Викторга Янимов.— Бездән дә яшь әле ул, күңеле белән генә түгел...

Әйе, дөрес әйтте Николай Федорович: һич тә карт итеп сизми Зыятдин үзен. Аңарда һаман әле — моннан утыз ел элек булган ашкыну, йөрәге һаман да яшьләрчә җилкенә, яшьләр арасында үзен ят итеп түгел, иш итеп тоя, рухы гел яшьләрчә күтәренке.

Юк, моннан утыз еллар элек сугыш кырларында бөтенләйгә калмады аның яшьлеге, биредә, бөек төзелештә — КамАЗда кабат кайтты ул!

**Рәмзи Максудов**

# БҮГЕНГЕ АВЫЛ КЕШЕЛӘРЕ

## Тәнзилә



әнзилә. Бу исемдә көмеш кыңгырау тавышы бар. Бу исемдә таң җиле җиңеллеге бар. Тәнзилә Рәхимҗанова исеменең җисемен аклый. Фермадамы, җәйләүдәме — дус кызлары аның көмеш кыңгыраудай чыңгырдатып көлгәнен ишетәләр. Кыен чакта да Тәнзилә иң алдан фермада,— курмы китермәгәннәр яки автопоилка эштән чыккан,— сеңлебез кул кушырып, мөдир кушканны, осталары килгәнне көтеп утырмый, телефон трубкасын ала да председатель иптәшнең туп-туры өенә шалтырата.

Ахирәт дусты Хәнифә ничәмә-ничә тапкыр әйтте инде аңа, телеңне тыеп тор, өстеңә бәла алма, сиңа гына бик күп кирәкмени соң, диде; юк, холкың шундый тынгысыз, үзең шундый тиктормас булгач, берни дә эшләр хәлең юк, эшең эш, көлүең көлү булсын!

Күптән түгел шундый бер хәл булды.

Буадан башлыклар килеп төште. Өйрәнгән гадәт буенча аларны колхозның иң яхшы савымчысы Тәнзилә янына алып килделәр. Башлыклар сораша, хәлләр ничек, эшләр көйлеме, рәнҗетмиләрме, янәсе.

Сеңлебез әйтте дә салды.

— Рәнҗетмәгән кая ул! Елның елында радиоалгыч бүләк итәләр. Өй тулды радиоалгыч белән. Быел мин яңа йорт салдым, тик менә... өй туе үткәрергә кыенсынып торам. Председатель телевизор бирмәсме дип көтәм. Бирә-нитә калса, түр башына ук менгереп куяр идем дип уйлыйм, ә ул, рәхмәт яугыры, мине шатландырырга ашыкмый.

Идарәдә быел кыйммәтле бүләкләр бирмәскә дигән карар чыгарганын да белеп тора Тәнзилә, колхозчыларның телевизор ише әйбер алырлык акчалары барлыгын да белеп тора, ә менә теле тик тормады, район җитәкчеләре алдында әйтте дә салды. Председатель бер кайчан югалып калмый торган кеше бит инде, ул булып ул кып-кызыл булып кызарды, парторг Симунов хәтта бер читкә үк кител барды.

Район җитәкчеләре җитди халык, председательгә әйттеләр, идарәдә хәл итегез, диделәр. Бер мәртәбә хәл иткәнне тагы нигә хә

итеп торырга, карар чыккан, аңлаешлы итеп әйтелгән, тагын ни кирәк. Көнеле түзмәде Тәнзиләнең, житәкчеләрне ферма капкасы төбендә куып житте дә бая әйткәннәренә аңлатма бирә башлады:

— Сез ялгыш уйлый күрмәгез. Өй туен үткәрү көне билгеле инде, минем үземнең ун телевизор алырлык рәтем бар. Ә бүләкнең кадере зуррак, аны кешеләргә күрсәтеп була, ул бит ихтирам дигән сүз... Әйтсеннәр генә, Тәнзилә сеңелкәем, радиоалгычыңны кибеткә илтеп бир, ул бит әле өр-яңа, өстәмәсен түлә дә алып кайт телевизор дисеннәр, үз акчама алам, колхоздан бирелгән бүләк булып исәпләнсен.

Житәкчеләр көлеп жибәрделәр. Хак сүз әйтә Рәхимжанова, алдынгы савымчыны ихтирам итәргә, телевизорына көмеш калай беркетеп, бүләк дип язарга кирәк.

Тәнзиләне савымчы дуслары бик ярата. Андый кешене яратмый буламыни?! Үзе өчен тырышмый бит, барысы өчен тырыша, матур булсын, күңелле булсын, эш авыр йөккә түгел, бәйрәмгә әйләнсен дип тырыша. Аның тирәсендә мәктәп эскәмиясеннән генә килгән кызлар бөтерелә. Тизрәк эшкә өйрәнәселәре, Тәнзилә төсле матур итеп яшисeләре килә. Эшкә өйрәнү дигәннән... хәзер бит сугыштан соңгы заман түгел, бер урынга ике-өч өйрәнчек килә, эшли белсәң эшлә, эшли белмәсәң, урыныңны башкаларга бир. Тиздән буш урынга конкурс игълан итә башлыйсылар, имеш. Хезмәт хакы аз түгел, механизаторлардан ким алмыйлар.

Ярдәм сорап килгән яшьләрне вакытым юк дип борып жибәрми Рәхимжанова. Беренче мәртәбә бозаулаган тананы саварга өйрәтә, савар алдыннан сыер имиенә массаж ясауны да күрсәтеп бирер, хайванның холкына төшенергә дә өйрәтер. Бер карасаң, болар барысы гади бер нәрсә, үзеннән-үзе белеп була торган эшләр кебек, ныклабрак уйлап карасаң, борын-борыннан килгән, ана кызын үсмер бала чагыннан сыер саварга, мал-туарны яратырга, үз итәргә өйрәтеп килгән.

Тормыш булгач, бар да ал да гөл булып кына тормый. Дәгъвалашып киткән чаклары да була. Савымчыларыңны әледән-әле алыштырып торалар икән, инде өйрәтеп кенә житкерим дигән бер үсмер урынына, кулыннан эш килми, «көн узсын, чабата тузсынга» йөри торган әлләзи боламыгын бирәләр икән, туганың булса да турысын әйтеп бирергә туры килә.

Фермага яки жәйләүгә Гарифә апа килгән чаклар бәйрәм була. Атказанган колхозчы, тәжрибәле савымчы, хәзер көннәрен пенсиядә үткәрүче, үтә дә ягымлы, кече күңелле бу апага Тәнзилә матур итеп жыру жырлый. Гарифә апа жырны тыңлый белә. Кызлар жырлап бетергәч, ул бераз моңаеп утыра да үзе эшләгән заманнарны искә ала. Фермада егерме биш ел эшләгән ул — искә алыр эшләре бар. Жанын биреп эшләгән — дәрәжәле исемне юкка гына бирәләр дисеңме!

— Минем сыерларым көтүнең башында йөри торганнар иде. Сабан туенда беренче килгән юртаклар кебек. Тик замана башка иде. Хәзер генә ул, ресторанда меню төзегән кебек, рацион төзелә. Хайван, жан кисәгем, бер үк, хәзер ничек булса, элек тә шул иде: ашатсаң бирә сөтне, ашатмасаң — юк. Бер кочак артык печән саласыңмы, башакка онны өстәбрәк жибәрәсеңме, савымчылар ташлана сиңа, алардан да бигрәк башлыклар көн күрсәтми. Якты көнең караңгыланып китә, дөньяда торасың килми башлый, билләһидер газим. Ә бит гел ферманыкын гына биреп тә тормыйсың. Ничә еллар жәйләүгә урак тотып йөрдем. Бер кочак үлән урып кайттыңмы — үз сыерларың гына түгел, бөтеннәрнеке дә үләнгә үрелә. Нишләргә дә аптыраган. Савымчылар үпкәли, сыерны саварга кирәк, ә сыерлары минем янга китеп баралар. Ул гына да түгел, өстәп азык бирмәсәң,

сөтне яшереп калдыра сыерлары. Тора-бара башка савымчылар да өстәмә азык бирергә күнегеп киттеләр.

Гарифә апа сүзен очлагач, тагын беркавым уйга калып утыра. Урыныннан тора башлый, биле катып киткән, яза алмый азаплана, кызлар, көлешә-көлешә, ике яктан култыклап торгызалар аны. Тәҗрибәле сыер савучыны тыңлау гыйбрәтле. Үткәннәрне искә төшерә, хәзергесе белән чагыштырып карап була. Хәзер бит әнә азык сыерларга җитәрлек булсын дип тырышалар. Бирми кара азыкны! Җәйләүгә яшел печәнне атлар ташый. Узган ел әнә корылык иде, сугарып үстерә торган болыннан ташыдылар.

Тәнзилә фермага килгән чакта алай кыен түгел иде инде, шулай да Гарифә апаның сөйләгәннәре аның да күңелен кузгата. Моңсуландыра. Ләкин моңаеп йөрү аның холкында юк, ул урыныннан сикереп тора, юлындагы беренче кызны кочаклап ала да көмеш кыңгыраудай чыңгырдатып көлә, рәхәтләнеп бер җырлап җибәрә, тигез, бердәм тавышлар аның җырын күтәреп алалар, куәт өстиләр, әйе, куәт өстиләр. Тәнзиләнең тавышы, көтүне башлап йөргән сыерлар төсле, юртак атлар төсле, көмеш кыңгырауларын чыңлатып, алдан бара...

## Нурулла

Ат заводы дип әйтсәм зуррак булыр, колхозның чабыш атлар үстерә торган фермасы бар. Эшне башлап җибәргән чакта ул тирәдә байтак кына бәхәсләштеләр, әле дә бәхәснең беткәне юк. Язын, юллар өзелгән чакта, машиналар гына түгел, чылбырлы тракторлар да үтеп чыга алмаган чакта, яки сабан туйлары җитеп, эшлияләчуклы атлар бәйрәмгә кузгалган чакта, әлбәттә, бәхәс тынып тора. Юллар кипкәч, бәйрәмнәр үткәч, бәхәс тагын өскә калка, тагын шыңшып йөрүчеләр табыла: нигә, имеш, безгә ат фермасы, нигә, имеш, сыер-сарыкларга ашатасы азыкны атларга әрәм итәргә? Мәсьәлә идарә утырышына тикле килеп җитә. Үн ел инде шул мәсьәлә тирәсендә баш ваталар.

Парторг Симунов кем яклыдыр, ул кадәресен белмим, шулай да ул мине атлар аранына алып килеп, ат фермасын оештырган кеше Нурулла Гафуров белән таныштырды. «Гигант» колхозындагы байтак кешеләргә хас булганча, Нурулла юмор хисеннән мәхрүм түгел икән.

— Син, Леонид Васильевич, монда кунак алып килердән элек, атларга солы җибәртергә әмер бирер идең, юкса бит, бодай саламына гына калып бара эшләр,— диде ул елмаеп.

Симунов, ләм-мим сүз дәшмәстән, борылып үз юлына китеп барды. Ат караучы Нурулла мине ат араннары буйлап йөрткән чакта, мин сырт өсләре, савырлары икегә ярылып торган, йоннары елык-елык килгән таза-көр рысакларны күреп аптырабрак калдым:

— Мондый көр атлар бодай саламы белән генә тукланамыни? — дип сорамыйча булдыра алмадым.

— Карабодай саламы да, кукуруз да, солы да бар безнең. Андый затлы азык күбрәк кырыкмышларга китә. Безнең эш шундый: башлыклардан вакытында каерып алмасаң, авызыңны күтәреп калырга туры килә. Алар уенда ат түгел, сыер. Йа хода, сыер дигәндә алар тиреләреннән чыгарга әзер! Сыер бер курмыны ашамый икән, алар аңа шундук икенчесен төртәләр. Ә бит чынлап торып уйласаң, сыер талымсыз мал бит ул. Суның ул теләсә ниндиен эчә, чишмә суы, саз суы дип талымлап тормый.

Китте сыерларны тетеп, китте, мин сиңа әйтим! Мин хәтта аның сөт эчүенә, сыер ите ашавына да шикләнә башладым.

Ат турында сөйли башлауга, йөзләре үк ягымлыланып, күзләре үк нурланып китте. Менә ул Җирән кашканың муенын сыпыра башлады, тегесе идән сайгакларына тоякларын бәреп, усалланып пошкырып җибәрде.

— Ир канаты — ат, ил канаты — егет, — дип сөйләнә-сөйләнә, ул ат аранын ябып, бу якка чыкты. Әле генә ягымлы, йомшак чырае кинәт җитдиләнде, миңа карап сүзен дәвам иттерде: — Аттан да чистарак нинди хайван бар дөньяда? Аттан да нәзберегрәк нинни хайван бар? Юк, туганкаем, саз суын эчмәс ат, ул синә сыер түгел, юк-бар хайваннан калган курмыны ашамас ат, аның үзенә бир, яңаны бир, ихтирам итеп бир. Атны яманлаган, атның көне бетте дигән бушбугазларны күралмыйм мин. Машина да булсын, трактор-комбайны да булсын, алар үз урынында, ат үз урынында!

Бәйгеләрдәге ат! Җиргә тоягы гына тиеп китә, лачын булып оча бит ул. Атланып чаба белмисеңме — ат өстеннән җил очырып төшерә. Ялына ят, һәр күзәнәгенең, һәр мускулының тетрәнеп торганын тоярсың, ат үзе генә түгел, бәйгене икәүләп аласыз — син уйлап кына бетердең, ат шундук син уйлаганны үти дә куя — аттан да акыллырак хайванны табып кара син бар, бөтен дөньясында таба алырсың микән?

Нурулла миңа таба иелә төште, йөгән сабагын тарткандай, бармакларын кыймылдаткалап, серлерәк тавыш белән сөйләргә кереште:

— Атның холкын белергә кирәк. Ульяновск ипподромында бер рысак һәлак булды. «Срок» исемле иде. Ничек һәлак булды диген? «Срок»ны ипподромга машина белән китерделәр. Усков үзе,— атның хуҗасын әйтәм,— стартта икән. «Срок»ны кузовтан төшерергә тиешле кеше, бәйге карап, авызын ачып калган, машинада рысак барын оныткан. Ахмак халыкка ат ышанып тапшырырга ярыймы соң? Гонг — атлар чабышка атылган. «Срок»та алар белән китмәкче! Кузовтан җиргә сикергән дә йөрәге ярылып үлгән. — Нурулла сулыш алган арада туктап торды, аннары тагын сөйләп китте: — Атны караган врачлар әйтте, йөрәге ярылып үлгән дип. Атның холкын белергә кирәк, аның белән исәпләшергә кирәк, туганкаем. Тукта, нигә әле мин синең алда атны яклап лекция сөйләргә тотындым? Килгәнсең бит монда, димәк, атны яратасың, яратмасаң, килмәгән булыр идең... Әйдә, мин сиңа рысакларны күрсәтим, юкса, хәзер минем алмашчым, энем Әнәс килеп җитәр. Без аның белән ун ел инде бергә эшлибез монда. Ярата атны. Мин аны дипломлы наездник итәргә телим, шуңа өйрәтәм. Өйрәнергә аны Ульяновск ипподромына җибәрергә кирәк, моннан ерак та түгел ул, һаман шул, әлеге дә баягы — кешеләргә аңлатып гомер үтә: кирәк эшме соң ул дип шикләнәләр...

Ат арәннары буйлап киттек. «Кипучий» дип табличка эленгән буш аран янына туктадык.

— Монда минем иң яраткан атым торадырые, шуңа күрә хәзер буш тотам, аны алыштырырдай ат булганны көтәм.

Бераз баргач, тагын табличка: «Авангард. Ике яшь ярым».

Нурулла Гафуров ат аранына кулын тыгып, ак кашкалы кара туры кырыкмышның башын сыпыра башлады:

— Менә шушыараннан башланды безнең рысаклар фермасы. Хәтеремдә, көз иде, беренче рысакны, нәселле чаптарны алып кайттык. Исеме «Мечта» иде. Кычкырганны, дорфа кыланганны бер дә яратмый иде. Бәйгедә кирәк түгелгә бер тарттыңмы, яки бүтән бер хәрәкәт ясадыңмы — шундук көйсезләнә, я дистанциядән чыга, я

сине иң азаккы итеп алып килә. Без аның белән дус яшәдек, үз сабан туебызда да, районда да беренче бүләкләрне алып килдек. Менә шушында торадырые ул. Хәзер аның нәселе, яшь атлар чабышка йөри. Менә бу да аның токымы. Малай холкы бетмәгән әле, я иркәләнә, я тибеп җибәрергә чамалап тора. Күрдең, күрдең — колакларны ничек шомарта, ничава, җилбәзәклеге бетүгә акыллы ат чыгачак аннан. Шәп ат чыгачак. Кышын җиңел чанага җигеп өйрәтсәк, язын сабан туена алып чыгарбыз.

Нурулла Гафуров мине бер араннан бер аранга йөртеп, атларның яше, холкы, нинди бәйгеләрдә катнашуы турында сөйли, республика һәм ил күләмендәге бәйгеләрдә катнашырлык атлар һәм наездниклар әзерләү хыялларын сөйли.

Саубуллашкан чакта авыр гына көрсенеп куйды:

— Атны аранда түгел, бәйгедә карарга кирәк. Менә анда аның барлык сыйфатлары, холкы-фигыле, булдыклылыгы билгеле була. Кеше кебек. Әйтик, бераү и матур сөйли, и матур сөйли, теле-телгә йокмый, эш эшли башласа, бер тиенгә торырлык адәм булып чыкмый. Икенче бераүнең авызыннан сүзне аркан белән дә тартып ала алмассың, эш эшли башласа, кулыннан гөлләр коя, карап торулары ук җан рәхәте! Тагын нәрсә әйтим, сабан туена килегез, сюрпризларым бар, күреп китәрсез, кем белә, бәлкем файдасы да тиеп куяр...

## Проворовлар

Җәйләүдә мин мотоциклга атланып чапкан көтүче күрдем. Сыерлар читкә, еракка ук китә башладымы, мотоциклын кабызып ала да борып алып килә. Миңа бу кызык тоелды. Эт белән көтү көткәннәрен күргәнем бар минем, мотоцикл белән көтү көткәннәрен күргәнем юк иде. Шуңа күрә мин икенче көнне дә парторг Симуновтан мине мотоциклны көтүче янына алып баруын үтендем, новатор белән якыннанрак танышасым килде. Ләкин без көтүченең үзен очрата алмадык, аның алмашчысы кашларын җыерып:

— Мотоцикл өчен председательдән эләкте инде безгә. Сыерлар сөтне киметте, күземә күрсәтмәгез ул тырылдавыгызны, ди. Тынычлык кешегә генә түгел, мал-туарга да кирәк, ди, ә сез пытыр да пытыр — дөнья бетереп чабасыз, ди. Алып килмәдек мотоциклны,— дип үзен кенә әйтеп бирде яшь көтүче.

Кайткан чакта парторг миңа төрттеребрәк куйды:

— Да, туганкай, сенсация барып чыкмады. Ярый, борыныңны салма, мин сиңа шундый бер могҗиза күрсәтермен, аһ итәрсең!

Һәм ул миңа кунакханә каршындагы почмак йортны күрсәтте. Әзер өй түгел, бура иде әле ул. Дөресрәге, аның инде шифер белән түбәсе дә ябылган, тик тәрәзә-ишекләре куелмаган. Әлеге йорт шундый да дәү, аның янәшәсендәге алты почмаклы йорт бәләкәй бер сарай кебек кенә күренә иде. Мин аны берничә мәртәбә күргән идем инде, тик әһәмият бирмәгән идем: авылларда бит хәзер андый каралтылар күп салына, я аптекадыр, я мастерской-мазардыр дип фикер йөрткән идем.

Симунов минем әлеге йортка бик әллә ни исем китмәгәнне күргәч, үпкәләгән сыманрак әйтеп куйды:

— Әгәр бик беләсең килсә, бу йортны безнең иң яхшы комбайнчыбыз Александр Иванович Проворов өлкән улына сала. Ә син аларның семьясы нинди икәнне беләсеңме? Барлык балалары механиза-

торлар. Хәтта кызын да комбайнчыга кияүгә бирде. Хәзер алар урак өстендә өч комбайн белән иген урдыралар.

Без Проворовларга килгән чакта, хуҗа үзе, алтмыш яшьтән инде узган булса да, әле һаман төз гәүдәле, тап-таза ир, фуганок белән такта шомартып тора иде. Верстак, аннан-моннан гына каккалап куйган бер нәмәрсә түгел, нык кул белән, озакка җитәрлек итеп ясалган верстак, булачак веранданың тышкы ягында иде. Проворов үз эшенә шундый бирелгән иде, безнең сәламгә дә тиз генә җавап бирмәде. Фуганогын тактаның буеннан-буена алып чыккач кына ул безгә карап исәнләште һәм чәчен машинка белән алдырган ун яшь чамасындагы малайны, онытып булса кирәк, иске өйдән эскәмия алып килергә җибәрде.

Төзелә торган йорттан озын буйлы, кояшта унган сары чәчле, утыз яшьләрендәге бер кеше чыкты. Симуновның миңа сөйләвенә караганда, бу Проворовның өлкән улы Петр булырга тиеш. Комбайнда ун ел эшли. Урак өстендә иген ура, калган вакытын шофер булып машина йөртә икән. Аның артыннан ук ишектән башын тыгып шундый ук озын буйлы, ирен өстенә бала йоны гына үскән бер егет карап алды. Монысы Николай, комбайнда Петрның ярдәмчесе. Менә хәзер өй салганда да ул Петрга булыша икән. Без килгән чакта алар олы якта идән җәяләр иде, аларның эшен карап чыккач, эш кешесенә комачауламас өчен без өлкән Проворов белән верстак янына чыгып, малай алып килгән эскәмиягә утырдык.

— Урак урганны сөйлә дисеңме? — дип, өлкән Проворов парторгка карап алды.— Аның нәрсәсен сөйлисең? Күпмегә генә җитә ул урак өсте? Кайчан чыктык әле уракка?

— Уналтынчы июльдә, — диде парторг.

— Та-аак, уналтынчы июльдә чыктык, егерме сигезенче июльдә точка куйдык. Менә шул. Бар булганы унике көн. Ә борчакны дисәң, аның без өч көндә эшен бетердек.

Монда да әллә ни материал табылмаганны күреп, Симунов мине юатырга булды:

— Беренче көнне сводка алу белән, (анда Проворовлар беренче булып баралар диелгән иде), киттем мин боларга. Өчесе бер участоктан уралар. Һәр комбайнныкын, бүтәннәр кебек, аерым-аерым үлчәтмиләр, өлкән Проворов барысын бергә, бөтен семьяга язддырырга кушкан.

Безнең янга Петр да чыгып утырды. Сүзнең ни турында барганын шундук аңлап, көлемсери төшеп тыңлый башлады.

— Ә бит беренче урынга вымпел бирәү генә, премия пакеты да бирәү. Кемгә бирергә? Ярый әле, Петр коткарды, ул беренче комбайнда бара иде. Әйдәгез, ди, вымпелны да, премияне дә эти комбайнына бирик. Монарчы ничек булса, шулай булсын.

Петр елмаеп куйды.

— Ә нәрсә,— диде ул, сүзгә кушылып.— Тузан эченнән вымпелнең кайсы комбайнда икәнен дә аера алмыйсың. Премия акчасы да этидә булса ышанычлырак, арыган чакта аз-маз сыйлап та куя. Әгәр, әйтик, премия синең үзеңдә генә булса, күмәк казанга — өйгә бирер идең дә койрыгын да күрә алмас идең.

Этиләре дә җанланып китте:

— Син, корреспондент иптәш, ни өчен без, Проворовлар гел беренчелекне алып киләбез дип кызыксынасың инде, әйеме? Юкса, парторг сине безгә алып килеп тормас иде. Менә миңа кара, Петрга кара, Колькага кара дә әйт: минем белән балалар арасында аерма күрәсеңме? Минем белем ике класс та бер коридор дигәндәй, ә аларның сигезьеллык та унъеллык. Өстәвенә, әле кыш көннәрендә, озын төннәрдә китап тотып утыралар. Аларның барысы бит бер казанга җыела. Аш казанына түгел, баш казанына.

— Ләкин бит һаман да беренче булып барыр өчен башкалардан үзгәрәк эшләргә, тизлекне дә регулировать итәргә кирәктер? Бүтән төрле сәбәпләре дә бардыр?

— Менә-менә. Бүтән төрле сәбәпләре. Элек кенә ул комбайнда чаптар атта чапкан төсле чабалар иде. Хәзер рәтен белеп кенә, җайлап кына эшләргә туры килә. Саламында бөртек калмасын, камыл биек киселмәсен...

— Юк, Александр Иванович, тизлекне дә чуттан чыгарып ташлама әле син,— диде парторг.— Хәзерге заманда тизлек тә бәләкәй нәрсә түгел. Өстәвенә, сез бит җәяү йөрмисез, агрегатлар янына сезгә әбәтне дә китерәләр...

— Без нәкъ менә җәяү йөрибез,— дип эләктереп алды өлкән Проворов һәм хәйләкәр генә көлемсерәде.— Сүз дә юк, поварыбыз Бибинур бик тә уңган, ашны ул җиренә җиткереп пешерә, ләкин бит үз өең дә бар, үз карчыгың да бар, аларны да онытып бетерергә ярамый. Өйгә гуртом кайтып ашадың, карчыкның түбәсе күккә тия, үзең дә шуннан сөенеп китәсең, кәефең күтәрелә... Ә бит, туганкайлар, уракны аны комбайн белән генә урмыйсың, кәеф белән дә урасың. Семьяда татулык — бөек нәрсә ул. Башта бер семьяда татулык, ягъни кечкенә семьядагы татулыкны әйтмәкче булам, аннары икенче семьяда, зуррак семьяда, бөтен колхоз семьясында татулык. Барың бер булып, булсынга эшләсәңме... Һи, җүләр, гөрләп-гөрләп китәсе эшләр. Бер карасаң, бик тә гади, бик тә күптәнге хакыйкать, ә менә шул хакыйкатьне барлык урында, барлык колхоз-совхозларда урнаштырып, дөресрәге, элекке хәленә кайтарып кара: хәзерге техникага татулыкны китереп кушсаңмы, таулар җимерергә була, таулар.

Беренче булып өлкән Проворов урыныннан күтәрелде. Аннары Петр кузгалды. Озакламый аларның Николай белән идән сайгаклары арасына чөй суккан тавышлары тонык кына ишетелә башлады.

Ул арада Проворовларның иң яше, төпчекләре Владимир кайтып, кибеткә кадак кайтып җитмәвен хәбәр итте. Өлкән Проворов һич тә нервыланмады, кибеттә кадак булмауга да кәефе китмәде, тыныч тавыш белән төпчегенә әйтте:

— Яшикта тактадан суырган кадаклар бар. Шуларны турайтып кагарбыз. Син, улым Володя, булмаса, шул эшне эшли тор әле.

Владимир веранданың аргы почмагындагы калын чуен плитаны үзенә табарак тартып, кадак төзәтергә утырды. Бер-ике мәртәбә суккач, «ай!» дип бармагын авызына капты. Күрәсең, ялгышып бармагына суккан, чит кеше карап торганда гел шулай була ул. Кәефе китеп, кәкре кадакны веранда артына атып бәрде.

Өлкән Проворов тактаны фуганок белән буеннан-буена йөреп чыкты да, әйләнеп килешли, Владимир янына туктап:

— Анда, улым, веранда артына бер кадак төшеп китте. Алып керсәң икән шуны. Яңа әле ул, эшкә ярый әле ул,— диде.

Буа районы,
«Гигант» колхозы.

**Редакциядән:** Журнал наборда вакытта Тәнзилә Рәхимҗанованың Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнүе турында куанычлы хәбәр килде.

# Г. КУТУЙНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

**Самсон Закладный,**
отставкадагы гвардия полковнигы.

## СОЛДАТ КУТУЙ

Гадел Кутуйның туууына 70 ел тулу көннәре якынлашканда мин аның «Тапшырылмаган хатлар»ын тагын бер мәртәбә укып чыгарга булдым. Шул ният белән КПСС-ның Воронеж өлкә комитеты мәгариф йорты китапханәсенә мөрәҗәгать иттем.

— Ул китап бездә бар,— диде китапханә мөдире. З. Худякова,— ләкин, беренчедән, ул хәзер кулда, икенчедән, аның битләре шул тикле теткәләнеп беткән, сез аны рәхәтләнеп укый да алмас идегез. Воронеж университеты китапханәсеннән сорап карагыз сез аны. Анда белешмәләр өчен саклана торган махсус данәсе булырга тиеш.

Университет китапханәсендә «Тапшырылмаган хатлар», чыннан да, бар иде. Әмма анысы да бик нык таушалган булып чыкты. Тик мин моңа куандым гына. Яхшы китап гел шулай таушалган була бит ул. Шулай да бу очракта бер нәрсәне искәртеп үтмичә булдыра алмыйм: «Тапшырылмаган хатлар»ны рус телендә ешрак һәм зуррак тираж белән бастырасы иде. Миллионлаган китап сөючеләр тарафыннан яратып укыла торган әсәр ич ул.

Кутуйның әйбәт язучы булганлыгы һәм аның әсәрләрен укучылар яратып укыганлыгы — мәгълүм факт. Шуңа күрә бу мәкаләмдә мин язучы Кутуй турында гүгел, бәлки Бөек Ватан сугышында фашистларга каршы көрәшеп йөргән сугышчы Кутуй турында сүз алып барырга булдым.

Гадел Кутуй белән мин беренче тапкыр кырык икенче елның декабрендә танышттым. Чатнама суык көннәрнең берсе иде. Безнең әле яңа гына оешкан авыр гвардия минометы бригадасы Мәскәү товар станцияләренең берсендә эшелоннарга төяләп, Сталинград ягына юл тотты. Дон фронты гаскәрләре дошманның фельдмаршал Паулюс командалыгындагы группировкасын чолганышта тоткан көннәр иде бу. Димәк, дошманның ул группировкасын тәмам туздырып ташлар өчен безнең ярдәм дә кирәк булган, дип уйладык без.

Юлда барышлый бригаданың политбүлеге сугышчылар арасында политик аңлату эшен тагын да киңәйтеп җибәрде. Партия, комсомол җыелышлары, политик темаларга әңгәмәләр үткәрелде, яңа техниканы өйрәнүгә зур әһәмият бирелде. Беркөнне шулай бригада командиры белән бергәләп сугышчылар утырып бара торган вагоннарны тикшереп йөргәндә мин бер вагондагы тәртипнең гаҗәеп әйбәт булуына игътибар иттем. Бу вагондагы барлык солдатларның да сакал-мыегы кырылган, киемнәре чиста һәм пөхтә иде. Утыз биш яшьләр чамасындагы чибәр генә бер кызылармеец вагондагылар белән политик әңгәмә үткәреп тора. Үзе болай форма буенча киенгән булса да, аның кадровый солдат түгел икәнлеге чамаларга була иде. Ләкин мәсьәләне бик белеп сөйли. Сугышчылар аны зур игътибар белән тыңлап утыралар иде.

— Сезнең батареяда әңгәмә алып баручы кеше кем ул? — дидем мин безне озата чыккан капитан Кожельниковтан.

— Рядовой Кутуев ул,— диде дивизион командирының политик урынбасары.— Зур белемле, культуралы иптәш. Мин аны агитатор итеп билгеләдем. ВКП(б) членлыгына кандидат. Көнбатыш фронтта сугышкан чакта үзен кыю һәм тәвәккәл итеп күрсәтте. Солдатлар арасында да авторитеты зур.

Мин шундук Кутуевның фамилиясен блокнотыма язып алдым һәм аның үзе белән сөйләшергә кирәк булыр дип күңелемә салып куйдым. Тиздән сөйләшергә җае да чыкты. Икенче көнне бригаданың агитаторлары киңәшмәсе булды. Анда Кутуев та катнашып, үзенең эш тәҗрибәсе белән уртаклашты. Шул чыгышыннан соң ул миңа тагын да күбрәк ошап китте һәм мин аның үзен генә алып калып, тормышы хакында сораштыра башладым.



Г. Кутуй фронтовик.

— Фамилияне сез инде беләсез,— диде ул, бик ягымлы елмаеп.— Исемем — Гадел. Милләтем буенча татармын. Укый-яза беләм. Сугышка кадәр төрле эшләрдә эшләдем. Сугыш башлангач үзем теләп фронтка киттем.

— Укый-яза алуыгызны мин болай да яхшы беләм, иптәш Кутуев,— дидем мин аңа.— Татарлар арасында укый-яза белмәүчеләр гомумән юк хәзер. Әйдәгез, шаярмыйча гына сөйләшик әле.

— Әйе шул,— диде ул кинәт җитдиләнеп,— безнең халыкны артка калган дип әйтеп булмый. Бездә хәзер кеше язганны укып кына калмыйлар, үзләре дә язалар.

— Бәлки сез үзегез дә язучыдыр. Әллә булмаса артистмы сез? Шулайрак сизелә. Тик төгәен генә әйтә алмыйм. Ә беләсе килә.

Шул чакта безнең эшелон тиешле станциясенә килеп җиткән иде, сүзебезне артык дәвам итә алмадык.

Эшелоннан төшкәч, бригада, машиналарга төялеп, югары командование тарафыннан күрсәтелгән туплану урынына килде.

Сталинград далаларында ачы җил уйный, тәкерек төшмәслек каты салкын. Яңа елга каршы көн иде ул. Бригада сугышчыларының күңелләрен күтәреп җибәрү өчен нидер эшләргә кирәк иде. Шул мәсьәләне хәл итү өчен без командирларны штабка чакырттык.

— Иң элек солдатларны суыктан сакларга кирәк,— диде бригада командиры.— Аннары яхшылап ашатырга һәм кайнар чәй эчертергә кирәк. Ә калган ягын солдатлар үзләре чамаларлар. Барыгыз, үзегезнең частьләрегезгә кайтыгыз да землянкалар казуны оештырыгыз!

Землянкалар әзер булганда сәгать кичке уннар җиткән иде инде. Ул землянкаларның өсләрен палаткалар белән каплап, эчләренә салам җәйгәнче тагын шактый вакыт үтте. Солдатлар сакал-мыекларын кырынган арада, поход казаннарында итле кәбестә ашы һәм карабодай боткасы да пешеп өлгерде. Котелоклар, кашыклар эшкә кереште. Яңа ел тууын белдереп, Кремль курантлары суккан тавышны радиодан тыңлагач, без бригада командиры белән икәүләп, землянкаларга кереп, сугышчыларны Яңа ел белән котлап йөрдек. Гвардиячеләрнең кәефләре яхшы иде. Землянка саен диярлек күңел ачалар: кайсында җырлыйлар, кайсында шигырь укыйлар янсә мәзәк сөйләшеп, көлешеп утыралар иде. Гадел Кутуйны да без шигырь укып торган чагында туры китердек. Русча укый иде ул. Шигыре бик әйбәт иде. Тик, кызганычка каршы, мин аның ул шигыренең исемен язып алмаганмын.

— Монда да Кутуев активлык күрсәтә икән бит! Яхшы оештыручы булырга тиеш ул,— дидем мин бригада командирына, землянкадан чыккач.

— Шулай булуы гаҗәп тә түгел,— диде командир.— Язучы икән бит ул!

— Шулаймыни? — дидем мин мәгънәле иттереп.— Кызык... Әйдәгез, без аны политбүлеккә алыйк та бригада тарихын язып баруны тапшырыйк.

— Мәслихәт булыр,— диде бригада командиры, минем тәкъдим белән килешеп. Шул хакта боерык бирергә вәгъдә итте.

Икенче көнне ук Гадел Кутуй иңенә күн сумка асып минем янга килеп җитте.

— Иптәш подполковник,— диде ул, ягымлы тавыш белән,— бригада командирының боерыгы буенча рядовой Кутуев сезнең карамакка килде!

— Килүегез бик яхшы булган, иптәш Кутуев,— дидем мин аңа.— Хәзер сез политбүлектә эшли башлаячаксыз. Сезнең язучы икәнлегегез миңа инде билгеле. Бездә сезгә дә эш җитәрлек булыр. Тик башта миңа шуны әйтегез әле: политбүлек карамагына җибәрелүегезгә үзегез ризамы соң? Минемчә, канәгать булырга тиешсез. Бу бит хезмәт буенча күтәрелү!

— Мин бик үк риза түгел, иптәш подполковник,— диде ул, миңа туры карамыйча гына.

— Ә нигә риза түгел икәнен әйтә алмыйсызмы?

— Дивизиондә моңарчы мин гел солдатлар белән бергә була идем. Ә монда, белмим, ни эшләрмен икән. Аннары минем сезгә язучы икәнлегемне расларлык бер нәрсәм дә юк бит әле янымда. Шулай булгач, нинди язучы булыйм инде мин.

— Анысын соңыннан сөйләшербез. Ә хәзер бригада командованиесе сезгә бригада тарихына караган материалларны җыйнап һәм кәгазьгә теркәп баруны йөкли. Солдатлардан аерылам дип курыкмагыз. Сугышның алгы сызыгында булырга да, атакага барган танкларны күзәтергә дә, «Катюша»лар залпын күрергә дә туры киләчәк әле сезгә. Һөҗүмгә ничек әзерләнгәнне дә, һөҗүм вакытында кемнәр аеруча батырлык күрсәткәнне дә, әлбәттә, белеп торырсыз. Шунсыз бригаданың тарихын язу мөмкин дә түгел бит.

— Алай булса мин каршы түгел!— диде Кутуй, шундук җанланып китеп. Кесәсеннән блокнотын чыгарды да:— Минем монда кайбер нәрсәләр язылган иде, тыңлап карагыз әле, иптәш подполковник,— дип кычкырып укый ук башлады: «Югары командование ставкасының боерыгы нигезендә, өченче авыр гвардия миномет бригадасы 1942 елның 20 декабрендә төзелде. Бригаданың командиры итеп гвардия подполковнигы А. В. Михайлов, политбүлек начальнигы итеп гвардия подполковнигы С. А. Закладный билгеләнде. А. В. Михайлов урта буйлы, нык, таза кеше. Политбүлек начальнигы да шулай ук нык күренә, тик ул буйга бераз озынрак. Бригада бик тиз арада төзелде. Михайлов белән Закладный иптәшләр 1942 елның 19 декабрендә Оборона Халык Комиссариатына чакыртылып, бригада төзергә боерык алып кайттылар, ә икенче көнне сәгать унда алар инде төзелгән бригадалары белән бергә эшелоннарга төялеп, фронтка киттеләр».

— Менә бик шәп, бу эшне сез инде башлаган да булгансыз икән!— дидем мин, куанып.— Инде бу эшкә ныклап торып тотынырга һәм бригададагы хәлләрне көн саен язып барырга кирәк булыр. Ә хәзер политбүлеккә барыгыз да андагы иптәшләр белән танышыгыз, урнашыгыз!

— Кулдан килгәнчә тырышырбыз, иптәш подполковник,— диде Кутуй. Чөсть бирде дә, тиз-тиз атлап, заманында немецлар тарафыннан төзелгән, ә хәзер безнең политбүлек урнашкан блиндажга таба китте.

Дон фронты командующие боерыгы нигезендә безнең бригада генерал Батов командалыгындагы 65 нче Армия карамагына тапшырылды һәм үз тарихында беренче мәртәбә булачак һөҗүмгә әзерләнү эшләренә керешә. Алда торган һөҗүмнә уңышлы башкарып чыгу өчен политбүлек бригаданың сугышчылары арасында агитация-масса эшләрен тагын да киңәйтә төште. Политбүлек хезмәткәрләре, шул исәптән Гадел Кутуй да, частьләргә, дивизионнарга барып, сугышчылар алдында торган бурычларны аңлаттылар. Гвардиячеләр ул көннәрдә ару-талуны белмичә тырышып эшләделәр: туң җирне казып, минометларны куярга мәйданнар ясадылар, иңнәренә күтәреп, авыр снарядларны тиешле урыннарына ташыдылар. Сугышчыларга аеруча кыенга туры килгән чакларда Кутуй да шулар янына тукталып, тирләп-пешеп ярдәм

итешә. Бишәр потлы снарядларны берәр сугышчы белән икәүләп күтәреп барган чакларында: «Менә бу «күчтәнәчләр» тиздән фашистлар өстенә очачак. Исән калучылары булса, «Иван Грозный» дип атала торган бу коралның нәрсә икәнен гомерләре буена хәтерләрендә тотарлар!» — дип сөйләнгәләп тә куя торган иде.

Һөҗүм кырык өченче елның гыйнварена билгеләнде. Һөҗүм башланасы көнне таң сызылу белән бригада командиры, штаб начальнигы һәм мин, Кутуйны да үзебез белән ияртеп, алгы сызыктагы күзәтү пунктына киттек. Тымызлык һәм тын иртә иде бу.

— Давыл алдыннан була торган тынлык менә шушыдыр инде ул! — дип куйды шунда Кутуй.

Шул истәлекле иртәдә булган хәлләрне Кутуй үзенең блокнотына соңыннан менә ничек итеп теркәп куйган иде: «8.05 — менә ул күптән көтелгән минутлар. Еракка ата торган туплар барысы да берьюлы атарга тотынды, һавада «Катюша»ларның ялкынлы койрыклары биешә һәм җырлаша башлады. Ә 8.55 тә безнең «Андрюша»лар эшкә кереште. Фашистлар өстенә шундый ут өермәсе сибелде — туп тавышларыннан хәтта бөтен җир гуләп һәм тетрәп торды.

Безнең гвардиячеләрнең залпыннан соң, бер секундка да кичекмичә, танклар һәм пехотачылар күтәрелеп, алдагы Шәрә тауга һөҗүмгә киттеләр. Меңләгән авыр миналар, йөзләрчә тонна снарядлар тиешле урыннарына барып тиеп, дошманның бик күп ут нокталарын юк итте. Миномет һәм артиллерия утының куәтеннән рухланган пехотачылар тизрәк хәрәкәтләнә башладылар. 27 нче гвардия укчы дивизиясе частьләре беренчеләргә югалтусыз диярлек дошманның бик яхшылап ныгытылган оборона ныгытмасын өзеп, Сталинградка таба китте. Шәрә тау мина һәм снаряд чокырлары белән теткәләнеп бетте. Дошман оборонасының алгы сызыгындагы барлык тере җан иясенең көле күккә очырылган иде...»

Шулай итеп, бригада үзенең алдына куелган беренче бурычны уңышлы үтәп чыкты һәм Дон фронты гаскәрләре составындагы әле бер армиягә, әле икенче армиягә күчерелеп, һөҗүмен дәвам итте. Чолганыш боҗрасы һаман кысылды, дошманның югалтулары көннән-көн арта барды.

Әнә шул көннәрдә, коммунистлар партиясенә алуны үтенеп, политбүлеккә алдынгы сугышчылардан йөздән артык гариза керде. Шул гаризаларның берсе Гадел Кутуйныкы иде. «ВКП(б)га член итеп алуыгызны үтенәм. Ленин эшенә, партия эшенә һәр вакыт турылыклы булырга сүз бирәм. Дошманны җиңү өчен көчемне дә, тормышымны да кызганмам»,— дип язган иде ул гаризасында. Партия комиссиясенең кырык өченче елның январь ае ахырында үткәрелгән утырышында Кутуй бертавыштан коммунистлар партиясе сафына член итеп кабул ителде. Утырыш тәмамланганнан соң Кутуй минем янга килде дә:

— Партия сафына кабул итүегез өчен рәхмәт, иптәш подполковник. Киләчәктә тагын да тырышыбрак эшләрмен. Иң җаваплы участокларга җибәрүегезне үтенәм,— диде.

Мин аны, сез болай да бригаданың иң киеренке сугышлар барган урыннарында булдыгыз бит бу араларда. Барыгыз, хәзер яхшылап ял итегез, дип землянкаларына кайтарып җибәрдем.

Берничә көннән соң партиягә яңа алынган иптәшләргә билетлар тапшыру тантанасы булды. Анда да Гадел Кутуй бик дулкынланып чыгыш ясап, партия принципларына турылыклы булачагын әйтте. Кутуйга партия билеты тапшырган чакта төшерелгән фоторәсем миндә әле дә саклана. Менә ул рәсем: карагыз, Гадел Кутуй әнә ничек чын күңеленнән куанып, сул кулына партия билетын тотып тора. Аңа билет тапшырган бригада командиры иптәш Михайловның йөзе шулай ук шат. Ул бик теләп аталарча бер җылылык белән Кутуйның кулын кыскан. Ә уртада утыручы кеше — бу юлларның авторы. Аның йөзендә дә канәгатьлек, дустанәлек чагылып тора.

Сугыш корбансыз гына булмый, әлбәттә. Узган һөҗүм көннәрендә безнең бригадада да югалтулар булды. Политбүлек сугыш корбаннарын тиешенчә хөрмәт белән күмүгә дә зур әһәмият бирде. Үлгән иптәшләрнең истәлегенә багышланган митингларда Гадел Кутуй да катнашты һәм дулкынландыргыч сүзләр сөйләде. Батарея командиры өлкән лейтенант Д. Н. Молянев белән рядовой И. М. Багинны күмгән чагында үткәрелгән соңгы тапкыр хушлашу митингында аның сөйләгән сүзләре хәзер дә

хәтеремдә саклана: «Чуваш егете Молянев, рус егете Багин. Бүген без сезне соңгы юлга озатабыз. Сез ил азатлыгы өчен көрәштә корбан булдыгыз. Совет халкы сезне беркайчан да онытмас. Дошманны җиңеп чыкканнан соң без тагын сезнең каберләрегезгә килербез, хөрмәт белән сугышчан байракларыбызны иярбез. Ә хәзер без сезнең өчен дә дошманнан үч алырга, аны тизрәк тар-мар итәргә тиешбез. Немец илбасарларына үлем! Безнең сугышчан антыбыз менә шул. Бу антыбызны дала җиле бик еракларга илтеп җиткерсен!» — диган иде ул.

Дошманны урап алган боҗра шул тикле кечерәйгән, безнең минометлар аткан миналар хәтта аның аргы ягына ук барып төшә ала иде инде. Дошманга борылырга да урын юк иде. Шулай булуга да карамастан, аларның командованиесе һаман әле



Г. Кутуйга партия билеты тапшыру.

бирелергә теләми. Тик үзләре теләп безнең якка чыгучы немец солдатлары көннәнкөн күбәя бара. Алар белән политбүлек хезмәткәрләре әңгәмә алып барган чакта Кутуй да һәр вакыт шунда була торган иде. Аның бригада тарихы өчен язып барган көндәлек язмаларында әсир немецларның әңгәмә вакытында сөйләгән сүзләре дә китерелгән: «Мин элек аллага ышанмый идем,— диде унтер-офицер Франц Шибер.— Ләкин кичә сезнең авыр минометлар безнең өскә ут яудыра башлагач һәм траншеяларыбызга рус танклары һәм солдатлары ябырылгач, тезләнеп алладан мине исән калдыруны сорап ялварырга туры килде. Тик ул мине коткармады. Мине әсир иттеләр.

— Юк өчен борчылма. Андыйлар бер син генә түгел. Әнә, кара,— диделәр Шиберга, безнең якка үз теләкләре белән чыгып килүче немецларны күрсәтеп,— йөзләрчә, меңнәрчә фашистларны әсирлеккә бирелергә мәҗбүр итәбез без хәзер! Исән калганыңа шөкер ит син!»

1943 елның 27 январь кичендә 64 нче Армия командиры генерал Шумилов безнең бригада командирына телефоннан боерык бирде:

— Сезнең бригада,— диелгән иде ул боерыкта.— Сталинградның фельдмаршал Паулюс армиясе штабы урнашкан районга залп бирергә тиеш. Ул залп безнең армиянең җиңүен дошманга хәбәр итүче набат булып яңгырасын. Ут позициясенә кайда урнашырга һәм кайчанга әзер булырга икенлеген тиздән штабтан хәбәр итәрләр.

Бу боерыкны алуга безнең командир бригаданы тревога буенча аякка бастырды. Политбүлек хезмәткәрләре, шул исәптән Кутуй да, булачак җиңү залпы турындагы әлеге боерыкны сугышчыларга яхшырак аңлату өчен окопларга киттеләр. Шул ук төндә, армия штабы боерыгы нигезендә бригада марш ясап, икенче ут позициясенә күченде. Марштан соң Кутуй белән очрашкач, ул миңа:

— Табигать тә безнең һөҗүмнең уңышлы булуын тели кебек, иптәш подполковник. Карагыз әле күктә йолдызлар ничек матур һәм якты булып җемелдәшә! Солдатларның да кәефләре яхшы, дошман өстенә ут өерергә ашкынып торалар,— диде.

— Үзең дә яхшылап әзерлән, Кутуй,— дидем мин аңа.— Сиңа да язар нәрсәләр күп булыр дип уйлыйм.

— Борчылмагыз, иптәш подполковник,— диде ул, гадәтенчә ягымлы елмаеп.— Миннән эш калмас!

Һәм, чыннан да, соңыннан ул бу һөҗүм турында бик белеп, дөрес итеп язган иде. Мисал өчен берничә генә җөмләсен китереп үтәм: «Бөтен бригада сугышчылары ашкынып, зур түземсезлек белән көткән залп 11 сәг. 50 минутта башланды. Менә бу залп дисәң дә залп иде, ичмаса! Хәтта җансыз миналар да, дошман группировкасының иң явыз калдыклары өстенә баруларын сизенгәндәй, гадәттәгедән ныграк, ачулырак сызгырышып очалар иде. Бригада үзенең куәтле минометлары белән дошманның уннарча дзотларын җимерде, күп кенә ут ноктларын, автомашиналарын һәм сугышчыларын юк итте. Фельдмаршал Паулюс та, ниһаять, котылып кала алмаячагын аңлады булса кирәк, үзенең генераллары белән әсирлеккә бирелде. Менә шулай итеп Сталинград янындагы тарихи сугыш 1943 елның 2 февралендә тулысынча безнең җиңү белән тәмамланды...»

Шул тарихи җиңүдә катнашкан сугышчыларга хөкүмәтебезнең орденнары һәм медальләре бирелде. Гадел Кутуйга «Батырлык өчен» медале тапшырылды. Ә бераз соңрак ул «Сталинградны саклау өчен» медале белән дә бүләкләнде.

«Без — сталинградчылар» исемле атаклы нәсерен Кутуй нәкъ әнә шул Сталинград сугышларыннан соң язды да инде. «Хуш, сау бул, Сталинград! Безне яңа сугышлар көтә... Ләкин без һәр вакыт һәм һәр җирдә сине истә тотарбыз. Әгәр бездән:

— Сез кемнәр?— дип сорасалар:

— Без — сталинградчылар! — дип горур җавап бирербез.»

Сталинград өчен көрәшкән сугышчыларның ул чордагы халәте искиткеч дөрес чагылдырылган бу юлларда!

Сталинград операциясеннән соң безнең бригада Мәскәүгә кайтарылды һәм шунда алдагы һөҗүмнәргә хәзерлек эшләренә керешге. Ләкин озак та үтмәде, бригадага яңа урынга күчәргә боерык бирелде. Шунда барышлый безгә Ясная Поляна аша үтәргә туры килде. Үтеп барышлый автомашинабыздан төшеп, бригада командиры иптәш Михайлов, Кутуй һәм мин Лев Николаевич Толстой кабере янына тукталып, баш киемнәребезне салып тордык. Аннары Кутуй, бездән рөхсәт сорап, Ясная Полянада әдипнең музеен да карап чыгарга дип калды.

Кутуй безнең колоннаны шул ук көнне кичке якта куып җитте һәм Толстойның тормышына бәйләнешле байтак кына нәрсәләрне күреп-белеп килгәнлеген әйтте. Шул ук вакытта фашистларның хәтта әдипнең музеена да бик зур зыян китереп, аны эштән чыгара язганнарына ачынып та кайткан иде ул.

Безнең бригадага ул чакта Брянск тирәсендәге урманнарга тукталырга һәм урнашырга боерык бирелгән иде. Шунда килеп урнашкач, мин Кутуйның тагын бер гадәтен белдем: урманга гашыйк кеше икән ул. Аз гына буш вакыты булдымы, хәзер урманга кереп китә иде дә, берәр алан буена сузылып ятып, блокнотын поход сумкасына куеп, яза да яза торган иде. Аннары кинәт кенә урыныннан кубып, арлыбирле йөренеп ала. Туктап агач кәүсәләрен сыйпаштыргалап куя торган иде. Минемчә, урманда ул аеруча илһамлана иде. Чөнки ул чорларда Кутуй бик күп язды. Кәефе дә әйбәт, тәнгә дә тазарып киткән иде шул чакта. Миндә аның әнә шул Брянск урманнарында бер төркем солдат һәм офицерлар белән бергәләп төшкән рәсеме бар. Ул рәсемдә дә Кутуйның һәм рухи, һәм физик яктан халәте бик яхшы булганлыгы аермачык күренеп тора. Бу мәкаләм белән бергә мин ул рәсемне дә

«Казан утлары» редакциясенә җибәрәм. Ләкин журналда бастыра алуларына бик үк ышанып бетмим. Чөнки кадрлары кечерәк [1].

Брянск фронтында безнең гвардия бригадасы җәйне Болхов, Карачев, Брянск шәһәрләрен азат итүдә катнашты һәм һәркайда үл алдына куелган сугышчан бурычларны тулысы белән башкарып чыкты. Дон фронтындагы шикелле үк, политбүлек хезмәткәрләре белән бергәләп, Кутуй да сугышчылар арасында ару-талуны белмичә көндәлек политик эшләрне алып барды. Ул инде тәҗрибәле политик хезмәткәр булып җитлеккән иде һәм мин аның үзенә тапшырылган партия эшенә авырсынып караганын белмим.

Шунысын да искәртеп үтәсем килә: сугышларда язмыш Кутуйга рәхимле булды. Нинди генә кыен һәм хәвефле хәлләрдә калырга туры килсә дә, Кутуй аларның барысыннан да исән-сау котылып килде. Беркөн шулай бик күп дошман самолетлары көтмәгәндә бригаданы бомбага тотты һәм безне зур югалтуларга дучар итте. Җитмәсә, бу хәл төн уртасында булды. Политбүлек хезмәткәрләре йоклап яткан автомашинага да бомба кыйпылчыклары тиеп, машинаның әрҗәсен иләккә әйләндереп тишкәләп бетергән иде. Машинадагыларның да берничәсе үлгән, кайсылары каты яраланган, ә Кутуйга берни дә булмаган. Мондый очраклар Кутуй тормышында бүтән чакларда да еш булды, әмма ул гел исән-имин кала килде.

Безнең бригаданы бер фронттан икенче фронтка (гадәттә, аеруча зур һөҗүм булырга тиешле юнәлешләргә) бик еш күчереп йөртәләр, шунлыктан безнең тормыш күбесенчә юлда, автомашиналарда үтә иде. Кырык өченче елның көзендә безне тагын яңа урынга — Балтик буе фронтына күчерделәр. Бер генә йорты да исән калмаган Великие Луки һәм бик нык җимертелгән Невель шәһәрләрен үтеп тукталдык та Витебскины азат итү өчен әзерлек алып бара башларга боерык алдык. Ләкин ул көз бик яңгырлы килеп, пычрак булганлыктан, аны азат итү шактый озакка тартылды. Киеренке сугышлар алып бару җирләр туңып, карлар төшкәннән соң гына мөмкин булды. Тик барыбер, күп кенә районнары азат ителсә дә, Витебск кырык дүртенче елның кышында да дошманнан арындырылмаган иде әле. Аны азат иткәнне көтмәделәр, безнең бригада тагын бүтән фронтка күчәргә боерык алды. Эшелоннарга төялеп, без Мәскәү ягына юл тоттык. Мәскәүгә якынлашып килгәндә бер тукталышта мин Кутуй утырып бара торган вагонга барып кердем. Кутуй ниг... нигәдер күңелсез һәм моңсу кыяфәттә утыра иде.

— Ни булды сиңа, Гадел, авырмыйсыңдыр бит? — дидем мин хәвефләнеп.

— Авырмыйм, иптәш подполковник,— диде ул, тырышса да моңсулыгын яшерә алмыйча.— Ләкин кәефне шәптән дип әйтә алмыйм. Семьямны, туганнарымны һәм гомумән Казанны искә алып, шуларны сагынып килә идем әле. Аннары бу араларда нигәдер хатлар да килгәне юк.

— Туганнарны сагынмаган кеше юктыр инде ул монда, Гадел. Мин үзем дә менә хатынымны һәм балаларымны өзелеп сагынам. Әгәр мөмкинлек булып, хәзер өйгә кайтып китәргә туры килсә, атлап түгел, очып кайтып китәр идем шикелле. Түзик инде, Гадел. Күбенә түздек, азына ничек тә чыдыйк. Сугыш бетәргә күп калмый бит инде.

Үзем Кутуйга шушы сүзләрне әйттем, ә күңелемнән: «Бу егетне кыска вакытлы ялга кайтарып булмас микән соң? — дип уйладым.— Кайчаннан бирле тырышып хезмәт итеп йөри, бер тапкыр кисәтү дә алганы юк. Аннары Казан белән Мәскәү арасы, бердән, әллә ни ерак түгел, икенчедән, Казан олы тимер юл үзәге: теләсә кайчан утырып кайтырга да, китеп барырга да мөмкин. Шулай булгач, форсаттан файдаланып, нигә туган иленә кайтарып китермәскә икән кешене?»

Чираттагы тукталышта ук мин бу фикеремне бригада командирына әйттем. Иптәш Михайлов минем тәкъдимгә берсүзсез риза булды. Шундук командирның тыл буенча ярдәмчесенә Кутуйны ялга яңа киемнәр һәм ял көннәренә азык-төлек белән тәэмин итәргә боерык та бирелде. Хәтта фронтовикларга сугыш вакытында бирелә торган аракы порциясен дә биреп җибәрергә әйтелгән иде ул боерыкта. Сүз җаенда

---

[1] Иптәш Закладный хаклы булган: ул җибәргән рәсемдә Кутуй ачык чыккан булса да, кадрлары кечкенә булу сәбәпле аны журналда бирергә мөмкин булмады.— **Редакция**.

шунысын да ачыклап утим: Кутуй бер вакытта да эчү белән мавыкмады. Фронтовикларга тиешле булган йөз граммын, дөрес, эчә иде. Әмма шуннан артыгына нәфесен сузган чагын мин әйтә алмыйм. Ә менә чәйне ярата иде ул. Чәй янында сөйләшеп утырырга да бик һәвәс иде. Сугышлар тынып торган арада учакта кайнатып чәй эчкәндә кәефе аеруча күтәренке була торган иде...

Үзенә ял бирелүен белгәч, Кутуй шул тикле куанды, беркавым хәтта ни эшләргә дә белмичә аптырап торды. Аннары рәхмәт әйтеп, тиз генә җыенды да Мәскәүдәге безнең эшелон килеп туктаган Ленинград вокзалыннан Казан вокзалына китте. Ә эшелон үз маршруты буенча кузгалып китте.

Кутуй ялдан әйләнеп килеп җиткәндә безнең бригада Ленинград тирәсенә, Выборг юнәлешенә урнашып, «Маннергейм» сызыгын штурмларга хәзерлек алып бара башлаган иде инде. Кутуй да килеп төшү белән ныклап торып эшкә кереште. Бригада тарихына материаллар туплавын дәвам итү белән бергә сугышчылар арасында политик әңгәмәләр үткәрде, «Молния»лар чыгаруда катнашты, үзган сугышларда аеруча зур батырлыклар күрсәткән солдатларны популярлаштыруга булышлык итте. Алгы сызыктагы сугышчыларга ризыкның вакытында илтелүен тикшереп тору да аңа йөкләнгән иде.

Ленинград фронты гаскәрләренең һөҗүме бу юлы бик уңышлы булды. 1940 елда «Маннергейм» сызыгын алу өчен өч ай вакыт сарыф ителгән булса, быел шул ук ныгытма нибары ун көн эчендә безнең гаскәрләр кулына төште. Финляндия капитуляция ясады һәм фашистлар блогыннан чыкты.

Әнә шул кырык дүртенче елның җәендә бер көнне Гадел Кутуй минем янга килде дә:

— Иптәш полковник[1], мин сезгә армия газетасы редакциясенә эшкә күчәргә җыенуымны әйтмәкче идем,— диде.

— Ни сөйлисез сез, Гадел? — дидем мин, бу хәлгә сәерсенеп.— Бездә нәрсәсе ошамый?

— Ошамаудан түгел,— ди бу иплəп кенә.— Барысы да бик әйбәт иде миңа бу бригадада. Ләкин тиешле урынымда түгел шикелле тоела миңа. Әле шушы араларда гына мин үзебезнең якташ журналистларны очратып сөйләштем. Алар да шулай диләр һәм үзләре янына армия газетасына эшкә килергә чакыралар. Анда эшләсәм мин илгә күбрәк файда китерермен дип уйлыйм, иптәш полковник. Озакламый мине шунда күчерү турында боерык килергә тиеш.

Нишлисең, мәсьәлә инде хәл ителгән булгач, Кутуйның бездән китүе кызганыч булса да, ризалашудан башка чара калмады. Берничә көннән аны газета эшенә күчерү турында югарыдан боерык та бирелде. Киткәндә Гадел минем белән бик җылы саубуллашып, истәлеккә фоторәсемен дә калдырып китте. Бу мәкаләнең башында урнаштырылган рәсем — әнә шул чакта бүләк иткән рәсеме инде Кутуйның.

Кутуйдан соң нибары берничә көн үтүгә минем үземне дә хезмәтем буенча югарырак урынга күтәреп, икенче урынга күчерделәр. Шулай итеп, бригада белән дә, Гадел Кутуй белән дә бәйләнеш өзелде. Тик сугыш беткәч биш-алты елдан соң Совет Армиясе Үзәк йорты гостиницасында гвардия полковнигы А. В. Михайлов белән очрашып сөйләшкәннән әры гына Кутуйның вафат булганлыгын ишеттем.

— Язмыш аңа синнән соң да рәхимле булды — Кутуй сугыш тәмамланганчы исәнсау йөрде,— диде миңа полковник Михайлов.— Ә менә авыру дигән яман нәрсә снаряд һәм пулялардан явызрак булып чыкты — Гадел Кутуйны безнең арабыздан алып китте.

Ләкин һәр вакыт ачык йөзле, киң күңелле, теләсә кем белән бик тиз аралашып, уртак тел табып эшли ала торган Гадел Кутуйны мин үлгән итеп һич тә күз алдына китерә алмадым. Әле хәзер дә гел тере булып күз алдымда тора ул минем. Мөгаен, Кутуйны белгән бүтән фронтташлары да аны шулай хәтерләрендә саклыйлардыр.

---

[1] Ул чакта миңа полковник дәрәҗәсе бирелгән иде инде.— С. З.

Фатих Урманчиев

# «НИК АКМАДЫМ ДӘРЬЯГА БОЗ БУЛЫП...»

## БӘЕТЛӘРДӘ ХАТЫН-КЫЗ ЯЗМЫШЫ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Бәетләр — татар халык иҗатындагы төп һәм үзенчәлекле жанрларның берсе. Жанрның борынгы болгар чорыннан безнең көннәргәчә сузылган күп гасырлык үсеш юлы бар. Бәетләрнең эчтәлеге һәм образлар системасы үзенең байлыгы һәм күп төрлелеге белән аерылып тора. Жанрның иң зур тематик төркемнәреннән берсен хатын-кызлар турындагы бәетләр тәшкил итә. Билгеле булганча, күпчелек бәетләрнең эчтәлеге өчен фаҗигалелек хас. Феодализм һәм капитализм дәверләрендә туган бәетләрдә хатын-кызларның ифрат авыр һәм кимсетүле хәле шактый тулы яктыртылыш тапкан. Моңа, күрәсең, бәетләрнең авторлары еш кына хатын-кызлар үзләре булуы да тәэсир иткәндер.

Бәетләрнең авторлыгын билгеләгәндә, алардагы бер сәнгать үзенчәлегенә — вакыйгаларның күпчелек очракларда беренче зат исеменнән сөйләтелүенә игътибар итәргә кирәк. Бу алым хәтта һәлак булган кешеләр турындагы бәетләрдә дә саклана. Вакыйганы үлгән кеше исеменнән сөйләтү, безнеңчә, бәетне чыгаручы шул үлгән кешенең әнисе яки якын кыз туганы булганда психологик яктан күбрәк аклана. Хәзерге вакытта да өлкән яшьтәге хатын-кызлар арасында бәет чыгаручылар һәм аларны оста итеп башкаручылар очрап тора. Кыскасы, бәетләрнең туында һәм таралуында хатын-кыз авторлар әһәмиятле роль уйнаган. Алдарак күрсәтеп үткәнебезчә, нәкъ менә шушы хәл бәетләрдә хатын-кыз язмышының киң яктыртылуына мөһим бер сәбәп булып тора. Жанрның иң борынгы үрнәкләреннән күренгәнчә, мондый традиция инде шактый күптәнге заманнардан бирле килә. Мисалга «Ханәкә-солтан бәете»н алыйк.

Башта әсәрнең исеме турында берничә сүз. һ. Атласов һәм Г. Рәхим белән Г. Газиз бу бәетне «Илаһи йыру» дигән исем астында бастырып чыгаралар[1]. «Илаһи» сүзе охшашы-тиңдәше булмаган, изге дигән мәгънәне аңлата. Ә «йыру» (дөресрәге, «җыру») дип элекке заманнарда эпик характердагы тезмә әсәрләрне яки борынгы озын җырларны атап йөрткәннәр. «Җыру» атамасы бәетләргә карата соңгырак заманнарда да кулланылган.

һ. Атласов бу әсәрнең нинди жанрга каравын билгеләми. Г. Рәхим һәм Г. Газиз, эчтәлегеннән чыгып, аны бәетләр рәтенә кертәләр һәм, шартлы рәвештә, тарихи әсәр итеп карыйлар. Дөрес, анда конкрет тарихи вакыйга сурәтләнми, тарихи шәхесләр дә телгә алынмый. Бәетне, шартлы рәвештә булса да, тарихи әсәр итеп санаганда, Г. Рәхим һәм Г. Газиз аның теле һәм эчтәлеге шактый борынгы заманга караган булуын истә тоталар. Чыннан да, бу бәетне бастырганда һ. Атласов аның 1732—1733 елларда язылган иске кулъязмадан алынуын күрсәтте. Димәк, бәетнең

[1] һади Атласов. Казан ханлыгы. Казан. 1914 ел. 64 бит; Г. Рәхим, Г. Газиз. Татар әдәбияты тарихы. 1923 ел. 144—145 битләр.

чыгарылуы XVIII гасырның беренче чирегеннән дә соң була алмый. Әсәрнең бәрынгылыгын андагы төп геройның Ханәкә-солтан исемле кыз булуы да раслап тора. XVIII—XIX гасырларда кеше исеменә «солтан» сүзе өстәп әйтү ирләргә карата гына кулланыла, һәм ул «иң яхшы егет» дигәнне аңлата (егет солтаны). Элеккерәк заманнарда исә хатын-кыз исемнәренә дә «солтан» сүзе өстәп әйтелү очраклары билгеле. Казан ханы Хәлилнең хатыны Нур-солтан исемле булган [1]. Адик-солтан (соңрак Касыйм-хан) хатынын Солтан-Нигәр-ханым дип атаганнар [2]. Касыйм патшасы Сәет-Борһанның (XVII гасыр) енисе Фатыйма-солтан-бикәм исемен йөрткән [3].

Идарәче даирәдәге хатын-кызларның исемнәренә төрле дәрәҗә атамалары (солтан, хан, ага) кушу, гомумән, бөтен Көнчыгыш дөньясында киң кулланылган. «Гүр-углы» дастанын тикшерүгә багышланган хезмәтендә бу моментка фольклорчы Б. А. Каррыев та игътибар итә. «...Кер-оглы»ның төркмән һәм үзбәк версияләрендә,— дип яза ул,— батырның хатыны Ага-Юныс дип атала. Ономастика (тел белеменең ялгызлык исемнәрне өйрәнү бүлеге — Ф. У.) күзлегеннән караганда, бу беркадәр сәер тәэсир калдыра. Ләкин китерелгән тарихи факт электә ирләр исемнәренә генә түгел, бәлки хатын-кыз исемнәренә дә «ага» сүзе кушылуы традициясе турында сөйли. Бу — төркмәннәрдә бүгенге көндә дә кулланыла» [4]. Өстәп шуны әйтәсе килә, «Гүр-углы» дастанының татар версиясендә батырның кәләше Нигәр-ханым исемле [5]. Татар халкының «Кол патша» әкиятендә Гүзәл-хан исемле кыз бар.

Бу әйтелгәннәр барысы да һ. Атласовның «Ханәкә-солтан» бәете герое танылган нәселдән булган дигән фикерен куәтлиләр. Әсәрнең эчтәлеге дә шуны раслый. Бәет әсирлеккә төшкән кыз исеменнән сөйләнелә. Аның сүзләреннән аңлашылганча, моңа кадәр ул гаҗәп рәхәт тормышта яшәгән, ни теләсә шуны кигән, ни теләсә шуны ашаган. Шушы бәхетле вакытларны искә төшерергә теләгәндәй, әсәр гүзәл табигать күренешләрен тасвирлау белән башлана:

Агач башы бөрләнер,
Язга чыкса төрләнер,
Кояшлар чыкса нурланыр,
Яуга төшкән хурланыр.

Бу строфаның соңгы юлы кызның тормышында булган кискен үзгәреш, аның башына килгән зур бәхетсезлек турында хәбәр итә. Дошманнар аны туган җирләреннән аерып читкә алып китәләр.

Госман бер Хафиз кызы идем,
Ханәкә-солтан атлы идем;
Сахтиян кимәс наз идем,
Чабата тапмый барамын.

Соңрак иҗат ителгән бәетләрдәге кебек үк, бу әсәрдә дә герой үзенең фаҗигале язмышыннан зарлана, туганнары һәм якыннары белән бәхилләшә. Әсәрдә хикәяләү югары эмоциональ киеренкелек ала. Хәтта табигать тә күңелсез, ямансу күренешләре белән генә сурәтләнә:

Агач башы кук томан,
Мин бу җирдә күп тормам,
Ут китәрмен, су бирмән,
Кирәк тә чакта мин булмам.

«Ханәкә-солтан» әсәре бәет жанрының безгә мәгълүм булган борынгы үрнәкләре арасында үзенең югары сәнгатьлелеге, жанр үзенчәлекләрен аеруча тулы чагылдыруы белән аерылып тора.

---

[1] һ. Атласов. Казан ханлыгы. 62 бит.
[2] В. В. Вельяминов-Зернов. Исследование о касимовских царях и царевичах. Рус телендә. Санкт-Петербург. 1863 ел. 2 кисәк. 193 бит.
[3] Шунда ук, 3 кисәк. 191—192 һәм 461—502 битләр.
[4] Б. А. Каррыев. Эпические сказания о Кер-оглы у тюрко-язычных народов. Рус телендә. Мәскәү. 1968 ел. 14 бит.
[5] В. В. Радлов. Образцы народной литературы тюркских племен. 4 кисәк. Санкт-Петербург. 1872 ел. 258—261 битләр.

Әсәр турында сүзне тәмамлап, тагын шуны әйтергә кирәк, Ханәкә-солтан образының тарихи прототибы юк кебек. Ул төрки халыклар фольклорында киң таралган эпик традицияләр нигезендә тудырылган җыелма образ булырга охшый. Академик В. Жирмунский күрсәтеп үткәнчә, Каныкей (татарча әйтелеше — Ханәкә) исеме төрки халыклар эпосында шактый еш очрый. Кыргыз халкының эпик герое Манасның хатыны Каныкей исемле була. Туктамыш ханның Идегәйгә әсирлеккә төшкән кызларының берсе Каныкей, икенчесе Таныкей исемле. Алар соңыннан Идегәйнең хатыннары булалар. «Чура-батыр» җырында Каныкей һәм Таныкей — калмык ханы Караманның сеңелләре. Караманы җиңгәч, Чура Каныкейга, аның дусы Исембай Таныкейга өйләнәләр. «Кобланды-батыр» җырында калмык ханы Алшагирның кызлары Каныкей һәм Таныкей батыр Кобландыга әсир булып эләгәләр...[1]

Күренә ки, Ханәкә-солтанның исеме дә, язмышы да төрки халыкларның бик күп дастаннарында һәм эпик җырларында сурәтләнгән хатын-кыз образларын хәтерләтә. Монда шунсы бик мөһим: ясалган чагыштырулар күрсәткәнчә, татар фольклорының үзенчәлекле лиро-эпик жанры булган бәетләр үз үсешләренең башлангыч чорында төрки халыклар фольклорларының эпик традицияләрен киң файдаланганнар. Һәм жанрның иң борынгы үрнәкләреннән берсендә төп урынны хатын-кыз образы алып торуы да игътибарга лаеклы.

Тикшерелгән мисал күрсәткәнчә, хатын-кызлар турындагы бәетләрнең иң борынгы үрнәкләрен конкрет тарихи вакыйгалар белән бәйләү кыен. Лəкин соңга табарак бу хәл үзгәрә. Бер яктан, соңгырак заманнарда туган бәетләрнең тарихи чыганаклары турында безгә инде күбрәк беләбез. Икенче яктан, жанрның сәнгать принциплары үсеш һәм үзгәреш кичерә. Нәтиҗәдә, бәет жанры, борынгы эпос традицияләреннән ераклашып, конкрет тарихи чынбарлыкка таянырак үтеп керә. Моның шулай булуын, мәсәлән, «Мәгърифә кыз бәете»ндә күрергә мөмкин.

Бу бәетнең туу вакытын Әминә Халит, шактый ышандыргыч дәлилләр нигезендә, XVIII гасырның азагы белән билгели[2]. Бәетнең исеменә һәм эчтәлегенә карaганда, ул янгын вакытында Мөһди исемле бер алпавытның кызы һәлак булу уңае белән чыгарылган. Бәеттә яшь һәм матур кызның шулай фаҗигале төстә һәлак булуына кызгану һәм әрнү белдерелә:

Ут эченә төшеп янган
Зифа буйлы Мәгъри;
Тилмереп янганнан корган
Әнкәсенең бәгыре.

Шушы фаҗигале вакыйганы поэтик тасвирлау белән генә чикләнгән очракта да бәетне жанрның уңышлы үрнәкләреннән санап булыр иде. Аны чыгаручы кеше, шушы фактка игътибарны юнәлтеп, кызга һәм аның әти-әнисенә карата кызгану-теләктәшлек тудырырга омтылса да, ул, чынбарлыкны дөрес һәм тулырак чагылдыру өчен, башка фактларга да мөрәҗәгать итмичә булдыра алмаган. Бәеттә алпавытның утта янган байлыклары санап чыгыла, утны, бай алпавыттан үч алу өчен, «беглый»лар төрткән булуы әйтелә. Шулай итеп, бәетнең объектив эчтәлеге һәм идея юнәлеше автор теләгеннән киңрәк һәм тирәнрәк булып чыккан.

Хатын-кызлар турындагы бәетләр арасында «Хан кызы» бәете үзенчәлекле урын тота. Бу әсәрнең туу вакыты, геройлары, идея юнәлеше турында капма-каршы фикерләр әйтелеп килә. Берәүләр анда чыннан да хан кызы турында сүз бара дип саныйлар һәм шул нигездә бәетне борынгы әсәрләр рәтенә кертәләр. Икенчеләр мәсьәләгә башка күзлектән чыгып карыйлар[3]. Безнеңчә, бәхәсне хәл итү өчен

---

[1] В. Жирмунский. Народный героический эпос. Рус телендә. М.—Л. 1962. 306 бит.

[2] Әминә Халит. Бәетләр тикшерү тәҗрибәсеннән. «Совет әдәбияты». 1934 ел. 6 сан. 56—59 битләр.

[3] Кара: Х. Ярми. Татар халкының поэтик иҗаты. Казан. 1967 ел. 127 бит; М. Мәһдиев. Халык иҗатына бер караш. «Казан утлары». 1968 ел. 11 сан.

әсәрнең үзенә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Башта шуны искәртеп үтик, бәетнең герое әсәрнең барлык вариантларында да «хан кызы» дип йөртелми. Мәсәлән, Х. Ярми чыгарган «Бәетләр» җыентыгының «Аңлатмалар» бүлегендә урнаштырылган вариантта егет кызга «туташ» дип эндәшә. Билгеле булганча, «туташ» сүзе кызларга хөрмәт, илтифат күрсәтүне аңлата. Ә «хан кызы» сүзләре безнең телебездә еш кына «иркә, назлы кыз» мәгънәсендә дә кулланылалар.

Әсәрнең эчтәлеге бик гади. Ул кыз һәм егетнең капма-каршы сөйләшүе (җырлашуы) формасында төзелгән. Егет кызның ишек төбенә килгән һәм аңардан ишекне ачуын, йөзен күрсәтүен үтенә:

— Аччы, туташ, ишегеңне, мин керием,
Йөзләреңнең ниндилеген бер күрием.

Кыз, назланып-чытлыкланып, егетнең теләгенә каршы төшә. Ченки аның йөзен күрү өчен ишекне ачу мәҗбүри түгел ләбаса:

— Йөзләремнең ниндилеген белмисеңме,
Аяз төнне тулган айны күрмисеңме?

Егет яңадан үзенең үтенечен кабатлый, кызның күзләрен күрәсе килүен әйтә. Кыз бу юлы да баштагы җавабын кабатлый:

— Күзләремнең ниндилеген белмисеңме,
Ай янында рушан йолдыз күрмисеңме?

Диалог дәвам итә. Егет кыздан аның кашларын, керфекләрен, иреннәрен, чәчләрен карарга рөхсәт итүен үтенә. Кыз исә аңа яңа тулган айга, җәядә киерелгән укка, җир җиләгенә, кара ефәккә карарга киңәш итә... Татар халык иҗатындагы мондый традицион чагыштырулардан киң файдалану әсәрдәге сурәт һәм тасвирларга искиткеч нәфислек, матурлык һәм камиллек бирә.

Шулай итеп, егет никадәр генә ялынмасын, кыз аңа ишекне ачмый:

— Аччы, туташ, ишегеңне, мин керием,
Мине сөйсәң, мине дисәң, бер үбием.

— Сине генә сөйгәнемне белмисеңме,
Сөям диеп алдап кына йөрмисеңме?

Соңгы җавабында кыз инде ишекне ни өчен ачмавына бернинди дә сылтау китерми. Әмма бәетнең икенче вариантында ул ишекне ачса әти-әнисе һәм туганнары күрүдән куркуын әйтә. Билгеле булганча, элек татарларда егет белән кызга туйга кадәр очрашу рөхсәт ителмәгән. Монда да шул гадәт чагылмыймы, дигән сорау туарга да мөмкин. Ләкин бәеттә консерватив гадәтләрне гаепләп бер сүз дә әйтелми. Күрәсең, кызның үз-үзен тотышын аның назлануы, ялындыруы белән генә аңлатырга туры килә. Әлбәттә, шундый шартларда егетнең кызга «хан кызы» дип эндәшүе бик табигый. Бу — әсәрнең рухына, аның эмоциональ яңгырашына ятышып тора. Әсәрнең эстетик табигатендәге шушы үзенчәлекне истән чыгару аның эчтәлеген бозып аңлатуга китерергә мөмкин. Биредә һич төрле фаҗига яки драма да, социаль тигезсезлек тә күренми. Әсәрдә хан сарайларындагы тормышны тасвирлый торган бернинди детальләр дә очрамый.

Үзенең эчтәлеге белән дә, формасы ягыннан да бу әсәр бәет жанрының башка үрнәкләреннән аерылып тора. Аның сәнгатьчә эшләнешенең соклангыч камиллеге халык эстетикасының гаҗәп югары дәрәҗәгә күтәрелүе турында сөйли. Һәм бәет, һичшиксез, борынгы заманга түгел, ә яңа чор фольклорына, XVIII яки хәтта XIX гасырларга карый.

* * *

Татар хатын-кызларының язмышын чагылдырган бәетләр безгә XIX гасырга кадәрге чордан аз санда, аерым үрнәкләр рәвешендә генә килеп җиткән. Аларда хатын-кыз тормышының кайбер яклары гына тасвирлана. XIX гасыр фольклоры исә

бу темага кагылышлы бай материал бирә. Бу чор өчен бәет жанрының тормышка тагын да тирәнрәк үтеп керүе, чынбарлыкны киңрәк һәм күп кырлырак итеп яктыртуы хас.

Татар кызларының революциягә кадәрге тормышы турында сөйли торган борынгы бәетләрдән халык арасында әеруча киң таралганы — «Җиде кыз бәете». Ул XIX йөз башларында туган булырга тиеш. Г. Толымбай җыентыгында бу бәетнең бер варианты түбәндәге строфа белән башланып китә:

Тарих мең дә сигез йөздә
Кырыгынчы ел эчендә,
Мондый хикмәт һич булмады
Безнең гомер эчендә [1].

Г. Толымбай, бу бәет чыннан да XIX йөзнең 40 нчы елларында чыккан булырга тиеш, дип саный. Казан дәүләт университетының фәнни китапханәсендә сакланган бер кульъязмага таянып, Х. Ярми дә якынча шушы ук датаны яклый. 1825 елда җиде байның кызы, ирләр киеменә киенеп, Каргалы (Оренбург) мәдрәсәсенә киләләр һәм, кем икәнлекләрен белдермичә, анда 17 (?!) ел укыйлар [2]. Димәк, кызларның фаш ителүе һәм бәет чыгарылу XIX йөзнең башына туры килә.

Бәет бу кызларның тормышын шактый тәфсилләп тасвирлый. Мәдрәсәдә укыганда аларның кызлар икәнлеген озак вакытлар беркем дә белми. Әмма барыбер соңыннан сер ачыла. Шәригать кануннарын бозган өчен, кызларны мәчеткә ябып бикләп куялар. Бәеттә әйтелгәнчә, халык арасыннан аларга теләктәшлек белдерүчеләр дә була:

Арада аңлы халык бар,
Безне азрак яклыйлар.

Әлбәттә, ул вакыттагы тәртипләр таләп иткәнчә, кызларны мәдрәсәдән куалар. Тик аларның берсенә мулла үзенең улын өйләндерә. Бу факт вакыйганы тагын да кызганычрак итә. Бәеттә мулла өендә калган кызга күп кенә көенечле юллар багышланган:

Карчыга йонын коядыр
Канатларын кагынып.
Бәдриҗамал саргаядыр
Үз әнкәсен сагынып.

Үзенең идея эчтәлеге белән бәет шәригать кануннарына каршы юнәлтелгән. Бәеттә сөйләнгәнчә, кызлар, ислам дине богауларын өзеп, иҗтимагый тормыш аренасына чыгарга омтылалар. Ул заманнар өчен бу артык кыю адым була, һәм кызларның омтылышы уңышсызлыкка очрый. Ихтимал, хатын-кызларның семья рамкаларыннан чыгып, иҗтимагый тормышта катнашырга омтылу фактлары чынбарлыкта ешрак та булгандыр. Чөнки гаилә тормышы хатын-кызлар өчен ифрат авыр, тынчу була, анда рәхимсез патриархаль тәртипләр хөкем сөрә. Иҗтимагый строй, социаль-экономик һәм мораль шартлар, ислам дине хатын-кызны иң кечкенә хокук һәм иректән дә мәхрүм иткән.

XIX йөздәге бәетләрнең күбесендә яшь кызларның тагын да авыррак һәм кызганычрак хәле сурәтләнә. Семьядагы коточкыч ярлылыкка түзә алмыйча, алар байларга һәм муллаларга асраулыкка барырга мәҗбүр булалар. Менә «Асрау кыз бәете». Анда яшь кенә кызның әнисе үлеп китүе, әтисенең хәер сорашуы турында сөйләнелә. Аптырагач, әтисе кызны шәһәргә илтергә һәм берәр бай семьяга асраулыкка урнаштырырга карар бирә:

Яхшырак җиргә бирсәм,
Төзәлер өстең-башың;
Фәкыйрьлек тә онытылыр,
Күзеңнән түккән яшең.

[1] Г. Толымбай. Бәетләр. Казан. 1935 ел. 147 бит.
[2] Х. Ярми. Бәетләр. Казан. 1960 ел. 345 бит.

Шәһәргә баргач, кыз белән әтисе бик озак асраулык урыны эзләп йөриләр. Ниһаять, бер бай кызны алырга риза була. Баштарак бай һәм аның хатыны кызга яхшы гына карыйлар, киендерәләр, ашаталар. Әтисе шәһәргә килгәч, кызның акыллы һәм пехтә дип мактыйлар. Ләкин кыз 15 яшьләргә җиткәч, аның тормышы бөтенләй үзгәреп китә. Байның үсмер кызга күзе төшә, ул аңа бүләкләр алып кайта башлый, карт хатынын аерып, кызга өйләнергә вәгъдә бирә. Иренең асраугa мөнәсәбәтен бай хатыны да сизә һәм кызны төрлечә мәсхәрәләргә, авыр эшләр кушарга тырыша:

Абыстай карый ямьсез,
Телләре ачы, тәмсез;
Хезмәтне куша авыр,
Сөйли бигрәк яман сүз.

Кызны алдап үз теләгенә ирешкәч, бай да асраугa кырын карый башлый, үзенең баштагы вәгъдәләрен оныта. Хуҗа хатынның җәбер һәм мәсхәрәләренә түзә алмыйча, бай тарафыннан алданган яшь кыз үз авылына кайтырга һәм бер карт кешегә кияүгә чыгарга мәҗбүр була.

Бу бәетнең композициясе төзек, андагы хикәяләү өчен эзлеклелек, детальләрнең тулылыгы, драматик киеренкелек хас.

Мондый вакыйгалар ул вакытлар өчен типик бер күренеш булып, бәетләрдә аларның әрнүчә фаҗигаләре генә чагылган. Мисал өчен тагын «Мәгъсүмә бәете»н китереп үтәргә мөмкин. Анда асрау кызның мулладан йөккә узуы һәм, сернe фаш итмәс өчен, мулла белән абыстайның Мәгъсүмәне үтерүләре турында сөйләнелә. Бәет мулланың әхлаксызлыгын, бозыклыгын фаш итә. Әсәр кискен драматизм һәм көчле сатира белән сугарылган.

Күргәнебезчә, бәетләрдә яшь кызларның коточкыч авыр һәм фаҗигале тормышлары шактый тулы яктыртыла. Революциягә кадәрге тормыш картиналары арасында кыз сату кебек күренешләр дә очрап торган. Соңгы чик хәерчелеккә төшкән крестьяннар, семьяларын туендыру өчен, үз кызларын сатарга мәҗбүр булганнар. Бәетләрдә әнә шундый фаҗигаләр дә чагылыш тапкан. Мәсәлән, «Кыз сату бәете».

Хикәяләү 16 яшьлек кыз исеменнән алып барыла. Ниндидер бер кансыз кеше, ата-аналардан яшь кызларын сатып алып, аларны башка якларга сатып җибәрү белән шөгыльләнә. Бу кызны да ул әтисеннән 115 тәңкәгә сатып ала.

Унҗиде кыз чыгып киттек,
Урын юктыр ятарга;
Без мескенне алдылар
Базарларда сатарга.

Бәеттә әйтелгәнчә, бу җан тетрәткеч вакыйгага иген уңмаган каты ачлык елны була. Бер якта — үз баласын сату кебек иң соңгы чиккә җиткерелгән ата-ана, икенче якта — чит кешегә сатылып, кол, товар хәленә төшкән кыз бала. Аның әти-әнисенә үпкәләп, рәнҗеп әйткән сүзләре әсәрдәге драматик киеренкелекнең иң югары ноктасы булып тора:

Әй, әткәем, әнкәем,
Бәне утка аттыгыз,
Бала дип тә белмәдегез,
Мисле хайван саттыгыз.

Татар кызының язмышын сурәтләгән традицион бәетләр арасында сирәк очрый торган, гадәттән тыш вакыйгаларга нигезләнгән әсәрләр дә бар. Шундыйлардан берсе — халыкта киң таралган «Зөлхәбирә бәете». Мостафа исемле бер мулла, исправник белән карта уйнап, бар мал-мөлкәтен оттырып бетерә. Ахырда ул картага үзенең кызы Зөлхәбирәне куя һәм аны да оттыра. Дин әһелләренең шушындый кансызлыгы һәм әхлаксызлыгы халыкта тирән ризасызлык һәм ачу тудыра:

Мостафа мулла, йөзе кара,
Кәртле уйнап кызын оттырган.

Исправник, сотскийлар җибәреп, Зөлхәбирәне үзенә алып китә, Зөлхәбирәнең «Туган авылымнан чыгып киттем, шунда булды дөнья тәмугы» кебек сүзләре аның нинди хурлыклы һәм авыр хәлгә төшүен бик ачык аңлаталар. Кызның үзен-үзе үтерүе шул чордагы иҗтимагый стройга һәм җинаятьче түрә-башлыкларга протест һәм ләгънәт булып яңгырый.

Иҗтимагый стройдан ризасызлык «Хәерниса бәете»ндә тагын да көчлерәк һәм ачыграк чагыла. Бәетнең вакыйгасы түбәндәгечә. Бер татар егете Маруся исемле рус кызын ярата һәм аңа өйләнә. Әсәр яшьләрнең мәхәббәтен тасвирлаган шатлыклы юллар белән башланып китә:

Татар егете, рус кызы
Бер-берсен сөештеләр;
Аламын дип, барамын дип,
Вәгъдәләр бирештеләр.

...Маруся исемен җуеп,
Хәерниса куштылар.

Ләкин ул замандагы тәртипләр, һәм мәчет, һәм чиркәү динне болай мәсхәрәләүгә түзеп тора алмыйлар. Хәернисаны эзәрлекләү, сорау алулар башлана. Тик ул түрәләр алдында каушап төшми:

Курыкмыйча җавап бирә
Хәерниса — батыр кыз:
«Үзем сөйдем, үзем бардым,
Сезгә чукмаем мин тез».

Алга таба вакыйгалар тагын да киеренкерәк төс ала. Хәерниса авылдагы дин башлыкларына буйсынмагач, становой үзе килә. Хәернисаны Бөгелмәгә алып китәләр, төрлечә мәсхәрәлиләр: ялангач көе урам буйлап йөртәләр, камчы белән кыйныйлар.

Ләкин Хәерниса барлык җәзаларга түзә, үзенең мәхәббәтеннән баш тартмый. Шуннан соң аны төрмәгә ябалар һәм ахырдан атып үтерәләр.

Татарга чыккач Маруся,
Поп, түрә җыелдылар;
Хәерниса гүзәл кызның
Газиз башын җуйдылар.

Егеткә дә үз авылында яшәргә ирек бирмиләр. Бигрәк тә дин әһелләре котырына. Егет һәм аның әти-әнисе мондый эзәрлекләүгә түзә алмыйча, авылдан качып китәргә мәҗбүр булалар. Шул рәвешчә, ике яшьнең саф һәм кайнар мәхәббәте фаҗигале төстә өзелә. Бәеттә бу уңай белән тирән кызгану һәм протест белдерелә:

Рус татарны сөйгән,
Татар русны сөйгән.
Тора бирсеннәр шатланып,
Кемгә соң алар тигән?

Бәет авторлары, мондый бәхетсезлекнең килеп чыгуына кемнәр сәбәпче икәнен күрсәтеп, аларны кискен рәвештә гаеплиләр:

Поп һәм мулла, становой
Урамнардан үттеләр,
Ил өстенә кара кайгы
Алар салып киттеләр.

Кыз баланың кияүгә чыгуы аның тормышында инде бик борынгы заманнардан (матриархат патриархат белән алмашынуы чорыннан) бирле үзенә күрә бер драма, бәхетсез вакыйга булып килә. (Сүз, әлбәттә, яшьләрнең сөешеп кавышу очраклары турында бармый.) Сыйнфый изелү һәм дини фанатизм шартларында

туйга кагылышлы фаҗигале яклар тагын да күбәя һәм көчәя төшә. (Кызның яратмаган кешесенә көчләп бирелүе, яшь хатынлыкка баруы һ. б.)

«Туй бәете», «Тегү тектем, чигү чиктем» кебек бәетләр карт кешегә кияүгә бирелүче кыз язмышы турында сөйлиләр. Гадәттәгечә, хикәяләү кызның үз исеменнән алып барыла. «Туй бәете»нең герое, картның байлыгына кызыкканнары өчен, әти-әнисенә шелтә катыш рәнҗү белән мондый сүзләр әйтә:

Бармыйм, әткәй, бармыйм, бәгърем,
Бармыймын мин бабайга;
Аңа барганчы барырмын
Соранып йөргән малайга.

Билгеле булганча, кияүгә чыгу, өйләнү процессында кыз һәм хәтта егет тә бик пассив роль уйнаганнар. XIX гасырда инде тәмам урнашып җиткән туй йолалары күрсәткәнчә, татарларда һәм бөтен көнчыгыш мөселманнарында кияүгә бирү, өйләндерү мәсьәләләрен тулысынча ата-ана хәл иткән. «Туй бәете»ндә нәкъ әнә шундый очрак турында сүз бара. Әсәр күңелдә авыр тәэсир калдыра:

Карлыгачлар очкан чакта,
Сандугачлар калдылар;
Фәрештәдәй яшь йөрәкләр
Кайгы-хәсрәт алдылар.

Мондый бәетләрнең тарихи нигезләре турында беркадәр сүз булды инде. Өстәп шуны әйтергә кирәк, гомер буе башлары хәерчелектән чыкмаган хезмәт ияләре яхшы тормышны материаль җитешлектән башка күз алдына китерә алмаганнар. Шуңа күрә кызларын бай кешегә биреп алар үзләренчә яхшылык эшлибез дип ышанганнар. Чынлыкта исә яшь кыз бай йортында бик авыр хәлгә дучар ителгән. Еш кына ул монда икенче, өченче, хәтта дүртенче хатынлыкка килгән. Шуңа күрә дә кызларны кияүгә бирүне тасвирлаган бәетләрдән моң, сагыш, хәсрәт бөркелеп тора. Киленнең чит семьядагы авыр тормышын күрсәткән әсәрләргә мисал итеп «Бәхетсез килен бәете»н һәм «Киленнәр бәете»н күрсәтергә мөмкин. Күп санлы туй һәм кыз елату җырларындагы кебек, бу әсәрләрнең эчтәлеген кызның әти-әнисе йортындагы һәм килен булып төшкәч ире йортындагы тормышларын капма-каршы куеп чагыштыру тәшкил итә. Ата-ана янындагы тормыш иң якты буяуларда тасвирлана. Ир йортындагы тормыш — ямьсез, авыр һәм караңгы. «Киленнәр бәете»ндә әнә шул икенче тормышның гомумиләштерелгән картиналары бирелә:

Бисмиллаһи вә биллаһи
Бу бәетнең башлары,
Калган салма, суык чәй
Киленнәрнең ашлары.

Килен кеше бичара,
Япма буа биленә;
Юк гаебен бар итеп,
Әләкләләр иренә.

Бу төркем бәетләр турында сөйләнгәннәрдән бер нәтиҗә килеп чыга: алар барсы да диярлек революциягә кадәр яшәгән татар хатынының яшь чагыннан алып соңгы көннәренәчә булган тормышын авыр һәм кайгылы итеп күрсәтәләр. Әлбәттә, башкача булуы да мөмкин түгел. Ул чагында жанрның чынбарлыкны реалистик чагылдыру принциплары бозылган булыр иде.

Шулай да «Хан кызы» шикелле юмористик, я булмаса героик-трагик пландагы бәетләрдә хәл башкачарак тора. Соңгы төргә мисал итеп «Кыз солдат бәете»н күрсәтергә мөмкин [1]. Шәмсекамәр исемле кыз, ирләр киеменә киенеп, үзенең энесе

[1] «Азат хатын» журналы. 1966 ел. 7 сан. 17 бит. Ф. Ахметова публикациясе.

урынына армиягә китә һәм фронтка эләгә. Бу хакта ул зур горурлык белән хәбәр итә:

Өч мең солдат арасында
Кыз солдаты мин генә.

Бәеттә әйтелгәнчә, Шәмсекамәр гади солдат кына түгел, ә башкаларны өйрәтүче, күрәсең, командир була:

Шәмсекамәр зирәк бала,
Өч мең солдат өйрәтә.

Моңа кадәр бәеттәге хикәяләү гадәттән тыш фактлар һәм вакыйгалар турында барды. Алга таба әсәргә әйтерсең стихияле рәвештә, сугыш турындагы традицион бәетләр рухындагы бер строфа килеп керә:

Кара-каршы өегез,
Солдат булды кызыгыз.
Без сугышка кергән чакта
Хәер-дога кылыгыз.

Ләкин, тулаем алганда, бәетнең эчтәлеге башка сугыш бәетләренекеннән аерылып тора. Шуңа күрә хикәяләү яңадан үзенең элекке рухына әйләнеп кайта. Шуның белән бергә анда борынгы героик-эпик традицияләр белән бәйләнеш сизелеп китәли. Әйтик, халык эпослары өчен хас булган «12» саны файдаланыла:

Унике ел мин сугыштым,
Белмәделәр кыз диеп...

Димәк, әле генә китерелгән бәет күрсәткәнчә, татар хатын-кызларының революциягә кадәрге язмышын чагылдырган әсәрләрдә трагизм, фаҗигалелек бердәнбер линия булмаган. Аерым очракларда юмористик яки героик-эпик рухтагы әсәрләр дә туа торган («Хан кызы», «Кыз солдат бәете»).

* * *

Традицион бәетләрдә һәртөрле хокуклардан мәхрүм булган, реакцион шәригать законнарына буйсынып яшәргә мәҗбүр ителгән, төрлечә кимсетелгән һәм җәберләнгән бәхетсез хатын-кыз образы тудырылган. Халык лирикасы хатын-кызларның язмышын аларның үз авызыннан ук әйттерелгән түбәндәге юлларда гаҗәп төгәл һәм тәэсирле итеп билгели:

Нигә тудым дөньяга кыз булып,
Ник акмадым дәрьяга боз булып!

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң безнең илдә хатын-кызларның хәле тамырдан үзгәрде. Шуңа күрә дә совет чоры бәетләрендәге хатын-кыз образлары революциягә кадәрге әсәрләрдә тудырылган хатын-кыз образларына бөтенләй капма-каршылар. Алар — революция тарафыннан тулы хокук алган, яңа тормыш өчен актив көрәшкә күтәрелгән кешеләр. «Тәзкия матур бәете»ндә совет укытучысы Тәзкиянең авылдагы җәмәгать эшчәнлеге җентекләп тасвирлана. Балалар һәм авыл кешеләре аны яраталар, хөрмәт итәләр. Тәзкия халык алдында муллаларны һәм кулакларны фаш итә, аларның чын йөзләрен ачып бирә. Укытучы кыз совет дошманнары кулыннан һәлак була. Ләкин бәеттә төп игътибар геройның үлеменә түгел, ә аның көрәшенә юнәлтелгән. Бу көрәшнең тулы җиңү белән бетәчәгенә тирән ышаныч белдерелгән.

«Тәзкия матур бәете»нә бик аваздаш тагын бер әсәр — «Гаптиева бәете». Гаптиева да, Тәзкия кебек, кулакларга каршы көрәштә корбан була. Бәетнең төп идея эчтәлеге бу фаҗигане тасвирлауга түгел, ә кулакларның ерткычлыкларын ачу, нәфрәт хисе тәрбияләүгә, дошманнардан үч алырга чакыруга хезмәт итә. Бәетнең

соңгы строфасында әйтелгәнчә, көрәш, үч символы булып Гаптиева кабере өстендә кызыл флаг җилферди.

Бу мисаллар күрсәткәнчә, революциядән соң иҗат ителгән бәетләрдә алгы планга актив герой образы куела, образны индивидуальләштерү һәм типиклаштыру процессы көчәя. Бер яктан, бу — жанрның эстетик мөмкинлекләре киңәю, икенче яктан, бәетләрнең халык лирикасы һәм профессиональ поэзия белән элемтәсе көчәю нәтиҗәсе булып тора. Мондый процесс Бөек Ватан сугышы чорында һәм сугыштан соң хатын-кызларга багышлап чыгарылган бәетләрдә тагын да тирәнәя төшкән. Моның бик мәһим нәтиҗәләреннән берсе итеп лирик бәетләр барлыкка килүне санарга кирәк.

Лирик агым революциягә кадәрге бәетләрдә дә (бигрәк тә хатын-кызларга багышланган әсәрләрдә) шактый ачык сизелә иде. Ләкин жанр тарихында саф лирик бәетләр булганы юк иде.

Традицион бәетләрдәге эмоциональлек башлыча вакыйгаларны җентекләп тасвирлаудан, фаҗигале картина тудырудан килә иде. Геройның эчке кичерешләре һәм хисләре вакыйгалар аша ачыла иде. Бөек Ватан сугышы чорында туган лирик бәетләрдә төп игътибар вакыйгаларга, фактларга түгел, ә геройның хис-кичерешләр динамикасына юнәлтелә. Мондый фикерне «Салих улым» исемле бәет ярдәмендә расларга мөмкин. Бу әсәрдәге ана образы тирән лиризм белән сугарылган. Бәет ананың үз улын фронтка нинди җылы, әчкерсез сүзләр әйтеп озатып калуы турында сөйли. Башта ана улыннан хатлар алып тора һәм шулардан юаныч таба. Бер вакыт хатлар килми башлый. Ана йөрәге ниндидер бәхетсезлек булганын сизенә, тик моңа ышанырга теләми, ул әле көтә... Хикәяләү ана исеменнән алып барыла һәм бу да әсәрнең тәэсир көчен арттыра. Ананың кичерешләре риторик сораулар ярдәмендә белдерелә:

Әллә дошман җирләрендә
Тоткын булып ятамсың,
Әллә яуны тар-мар кыйлгач,
Илебезгә кайтамсың?..

Улының язмышы турында сорап ана җилләргә, кошларга мөрәҗәгать итә. Ләкин җавап юк. Беразга гына кабынып киткән өмет нуры инде бөтенләйгә сүнә. Тик ана үз улының изге юлда, ил азатлыгы, халык бәхете өчен һәлак булуын яхшы аңлый. Шушы хакта уйлау аңа авыр кайгысын кичерүдә терәк-юаныч булып тора.

Сугыш елларында совет хатын-кызлары кичергән авыр язмыш турында сөйләүче бәетләр байтак. Без биредә аларның иң характерлыларыннан берсенә генә тукталып үттек.

* * *

Бер тематик төркемгә кергән бәетләрне генә тикшереп чыгу да жанрның үсеш тарихы буенча әһәмиятле нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Беренчедән, эчтәлек буенча. Хатын-кызларның иҗтимагый хәле һәм шәхси язмышлары урта гасырлардан алып безнең көннәргә кадәр бәетләрдә киң яктыртылыш табып киләләр.

Икенчедән, карап үтелгән мисаллар гасырлар дәвамында жанрның эстетик табигате ничек үзгәрә килүе турында ачык төшенчә бирәләр. Аның иң беренче үрнәкләрендә борынгы татар һәм гомумән төрки эпосы традицияләренең шактый көчле йогынтысы сизелә. XVIII—XIX гасырларда социаль-тарихи һәм социаль-көнкүреш вакыйгаларының асылына төшенү алгы планга чыга, бу хикәяләү ысулының эмоциональлегенә һәм киеренкелегенә китерә.

XX гасырда бәетләрнең халык лирикасы һәм профессиональ поэзия белән бәйләнеше нык көчәя. Шуның нәтиҗәсе буларак, бәетләрдә образларны индивидуальләштерү һәм аларның рухи кичерешләрен сурәтләү зур әһәмият казана.

Талия Корбангалиева

# СОВЕТ ВЛАСТЕНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЕЛЛАРЫНДА ТАТАРСТАНДА КИТАП БАСУ

Милли телләрдә китап басу эшен юлга салу Бөек Октябрь революциясе нәтиҗәсендә ирешелгән зур казанышларның берсе дияргә була.

Революциянең беренче көннәреннән үк басма сүз яңа тормыш төзү эшенә җигелә. Большевиклар партиясе һәм совет хөкүмәте марксистик-ленинчыл матбугатны үстерүгә ифрат зур игътибар бирәләр. Китап, басма сүз халыкка революциянең төп максатларын аңлатып бирергә, хезмәт ияләрен яңа тормыш төзү эшенә тупларга, эшче һәм крестьяннарның дуслыгын ныгытырга, халыкның гомуми культурасын үстерергә, хезмәт иясе массаларында дөньяга марксистик караш тәрбияләргә, кыскасы, халыкка, революция эшенә хезмәт итәргә тиеш була.

Патша Россиясендә китап басу эше түбән дәрәҗәдә торган. Милли телләрдә китаплар аз басылган. Күп кенә халыкларның полиграфия базалары үк булмаган. Совет хөкүмәте эшне нәкъ әнә шуннан — милли нәшриятлар оештырудан, милли полиграфия базалары булдырудан башлый. Революция җиңүгә, Милләтләр эше буенча Халык Комиссариатының барлык бүлекләре милли телләрдә газеталар, китаплар, төрле брошюралар һәм плакатлар чыгарырга керешә. Культура ягыннан арттa калган милләтләрнең ихтыяҗын истә тотып, Милләтләр эше буенча Халык Комиссариаты каршында ике махсус нәшрият — Көнчыгыш һәм Көнбатыш нәшриятлары төзелә. Бер үк вакытта милли республикаларның үзләрендә нәшриятлар оештыру эше башлана.

Казан шәһәре элек-электән Идел буенда яшәүче халыклар өчен үзенә күрә бер культура үзәге саналып килгән. Совет властеның беренче елларында күп кенә шәрык халыкларының, шулай ук Идел буендагы башка тугандаш халыкларның милли матбугатын үстерүдә ул әһәмиятле роль уйный. Мәсәлән, үз автономияләре оешканчы, Мари, Удмурт һәм Чуваш нәшриятлары безнең шәһәрдә эшләп килә. Шулай да Казанның китап басу эшен юлга салуда тоткан төп урыны татар халкы, Татарстан белән бәйләнгән.

В. И. Ленин милли окраиналарда, аерым алганда Татарстанда, китап басу эшенең торышын игътибар белән күзәтеп барган. Мәсәлән, 1918 елның 28 июлендә ул Милләтләр эше буенча Халык Комиссариатыннан татар телендә күпме әсәр басылганлыгын хәбәр итүне үтенә. Партиянең X съезды барган көннәрдә Казан журналисты В. Бахметьев юлбашчы белән очрашып сөйләшә. Әңгәмә вакытында В. И. Ленин аңардан Татарстанда матбугат эшенең торышы, республиканың полиграфия базасы, аның мөмкинлекләре турында да сораша[1]. Татарстан АССРны төзү өчен хәзерлек барган көннәрдә Шәрык халыклары коммунистик оешмаларының үзәк бюросы хезмәткәрләре В. И. Ленин янына безнең крайда китап басу эшенең торышы турында махсус доклад белән керәләр.

В. И. Ленинның Кремльдәге китапханәсендә егерменче еллар башында Казанда басылган ике дистәләп китап саклана[2]. Бу факт үзе генә дә аның Татарстандагы матбугат эше, аерым алганда, Казанда

---

[1] «Дружба народов» журналы. 1957 ел. 11 сан. 29 бит.
[2] В. Аристов. Прочитано Ильичем. Рус телендә. Казан. 1970 ел.

чыккан иҗтимагый-политик басмалар белән якыннан кызыксынып баруы турында сөйли.

Татарстанда китап басу эшенең бик бай, шактый гыйбрәтле һәм кызыклы үсеш тарихы бар. Беренче чорда бездә газета-журналлар һәм китап басу, аларны тарату белән күп төрле оешмалар шөгыльләнә. Менә кайберләре: партиянең Казан губерна комитеты һәм аның милли секцияләре; Казан губерна башкарма комитетының матбугат бүлеге һәм аның милли бүлекчәләре; РСФСР Наркомнацының Үзәк мөселман, чуваш, мари, керәшен бүлекләре; РКП(б) Үзәк Комитеты каршындагы Шәрык коммунистик оешмаларының үзәк бюросы; Көнчыгыш фронтының Икенче һәм Бишенче армияләренең политбүлекләре; РСФСР Наркомнацы каршындагы Үзәк мөселман хәрби коллегиясе...[1] Болардан тыш, егермеләп хосусый нәшрият рус һәм татар телләрендә китаплар, газета-журналлар чыгарып килгән.

Мондый хәл китап басу эшендә зур кыенлыклар тудыра. Бердәм үзәкнең булмавы, барыннан да бигрәк, китап, журналларның сыйфатына начар тәэсир ясый. Көн тәртибенә нәшрият эшен ныклы юлга салу, үзәкләштерү мәсьәләсе килеп баса. 1918 елның сентябрь аенда Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты «Россия телеграф агентлыгы турында» карар чыгара. Бу карар нигезендә Халык Комиссарлары Советы каршындагы матбугат бюросы һәм Петроград телеграф агентлыгы, шулай ук урыннардагы барлык информация учреждениеләре бердәм үзәк информация агентлыгына берләштереләләр (кыскартылган исеме — «РОСТА»). Урыннарда информация агентлыгының җирле бүлекләре оештырыла. Губерна шәһәрләрендәге бүлекләр — «ГубРОСТА», а өяз шәһәрләрендәгеләре «УездРОСТА» дип йөртелә башлый.

1919 елның 21 ноябрендә партиянең Казан губерна комитеты губернада «РОСТА»ның җирле органнарын төзү турындагы мәсьәләне карый. Шунда ук Казан «ГубРОСТА» составында татар бүлеге оештырыла. Бераз соңрак барлык өязләрдә «РОСТА»ның өяз бүлекләре төзелә. «ГубРОСТА» барлык җирле информацияне туплаучы үзәккә әйләнә, ул җирле матбугатны һәм үзәк матбугатны губерна тормышы турындагы хәбәрләр белән тәэмин итеп тора.

Партиянең Казан губкомы матбугат таратучы органнарны ныгыту һәм камилләштерү буенча да зур эш башкара. Совет властеның беренче айларында һәр нәшрият каршында аерым экспедицияләр эшләп килгән була. Хезмәт ияләрен газета-журналлар һәм китаплар белән тәэмин итү эшен тагын да яхшырту максатыннан чыгып, 1918 елның икенче яртысында, совет дәүләтенең махсус карары белән, башкалада һәм урыннарда матбугат тарату буенча үзәкләшкән органнар оеша башлый. ВЦИКның матбугат тарату буенча Центропечать агентлыклары барлыкка килә.

1918 елның октябрь аенда шундый ук оешма Казан губерна башкарма комитеты каршында да төзелә. Матбугат тарату эше белән шөгыльләнгән бөтен учреждениеләр: аерым газеталар каршындагы экспедицияләр, конторалар, газета-китап киосклары Центропечатьның губерна агентлыгы карамагына тапшырыла.

1919 елның февраль башларында партиянең Казан губкомы карары белән Центропечатьның губерна агентлыгы базасында өч бүлекчәдән торган (гомуми бүлекчә; әдәбият-нәшрият бүлекчәсе; экспедиция бүлекчәсе) матбугат бүлеге төзелә. Шул ук елның май аенда әлеге матбугат бүлеге каршында нәшрият коллегиясе оештырыла. Казанның бөтен нәшриятлары шушы коллегиягә буйсындырыла, аңа шулай ук матбугатта чыккан барлык әйберләрне күзәтеп бару эше дә йөкләнә[1].

Матбугат бүлеге турыдан-туры нәшрият эше белән дә шөгыльләнергә, плакатлар, өндәмәләр, халык алдында уку өчен төрле җыентыклар, декламацияләр бастырып чыгарырга тиеш була. Бүлеккә шулай ук матбугат эшчеләре хәзерләү, журналистларның белемнәрен күтәрү, төрле күргәзмәләр, «сатира тәрәзәләре» оештыру бурычы да тапшырыла[2]. Бүлекнең эшчәнлеге бөтен кантоннарга җәелдерелә. Казан губерна башкарма комитетының карарында күрсәтелгәнчә, нәшриятлар матбугат бүлегенең рөхсәтеннән башка бер нәрсә дә баса алмаганнар. Типографияләр аннан узып заказ кабул итмәгәннәр. Шундый чаралар ярдәмендә матбугат бүлеге китап басу эшен билгеле бер тәртипкә салуга ирешкән.

---

[1] ТАССРның Үзәк дәүләт архивы (ҮДА). 273 фонд. 1 тасвирлама. 18 саклану берәмлеге. 11 бит.

[1] КПСС өлкә комитетының партия архивы 868 фонд. 1 тасвирлама. 4 эш. 33 бит.
[2] Шунда ук. 155 бит.

1919 елның 21 маенда Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты «Дәүләт нәшрияты турында»гы законны раслый. Әлеге закон нигезендә барлык совет, партия, кооператив нәшриятлар бердәм дәүләт нәшриятына берләштереләләр. Галимнәрнең, әдәби берләшмә һәм оешмаларның, шулай ук башка оешмаларның нәшрият эшчәнлеге Дәүләт нәшрияты контрольлегенә алына...[1]

Әлеге закон нигезендә, Казан губерна башкарма комитеты каршындагы матбугат бүлеге Дәүләт нәшриятының Казан бүлегенә әйләндерелә. Аның мөдире итеп Татарстан Халык Мәгариф Комиссариатының коллегия члены Кочергин билгеләнә.

Дәүләт нәшриятының Казан бүлеге 1919 елның 22 июлендә оеша һәм 1920 елның июнь аена кадәр шул исем астында эшләп килә. Татарстан Автономияле Совет Социалистик республикасы төзелгәч, ул Татарстан дәүләт нәшрияты дип йөртелә башлый. Үзенең берьеллык эшчәнлеге дәверендә Госиздатның Казан бүлеге төрле тармакларга караган йөзләрчә китап чыгара. Ул китаплар белән якыннанрак танышу киң катлау укучылар өчен дә кызыксыз булмас дип уйлыйм.

Культура революциясе ихтыяҗлары беренче планга киң массага адресланган китаплар чыгару мәсьәләсен куя. Совет властеның беренче елларында шундый әдәбият чыгару белән барлык совет нәшриятлары шөгыльләнә. Шулай да мондый төр әдәбият чыгаруның төп урыны РСФСР Госиздаты һәм аның урыннардагы бүлекләре була. Казан бүлегенең пропаганда-агитация бүлекчәсе 1920 елның бер аенда гына да 16 исемдә төрле брошюралар, листовкалар һәм плакатлар бастырып чыгара. Аларның гомуми тиражы 120 мең данәдән артып китә, шуның 33 меңе татар телендә басылган әдәбият[2]. Казан нәшрияты чыгарган беренче басмалар арасында шулай ук «Коммунистлар партиясе манифесты» бар. Ул 50 000 данә тираж белән басыла.

Нәшрият даими төстә сорау һәм җаваплар рәвешендә язылган лекция-әңгәмәләр чыгарып бара. 1920 елда, мәсәлән, 3000 данә тираж белән «Коммунистның беренче уку китабы», 2000 данә тираж белән Таняевның «Безнең партия» исемле брошюрасы басыла. Массаларга революцион тәгълиматны аңлатканда татар пропагандистлары һәм агитаторлары бу кулланмалардан киң файдаланалар.

Билгеле булганча, революциядән соң РКП(б) Үзәк Комитеты И. Ходоровскийны Казанга җитәкчелек эшенә җибәрә. Биредә ул марксизм-ленинизм тәгълиматын популярлаштыруга багышланган күп кенә хезмәтләр яза: «В. И. Ленин — пролетариат революциясенең бөек юлбашчысы», «Партияләләр һәм партиясезләр», «Өченче коммунистик Интернационал һәм аның барлыкка килүе», «Съездлар һәм аларның әһәмияте» һ. б. Ул хезмәтләрнең һәркайсы Казанда зур тиражлар белән басыла. И. Ходоровский хезмәтләренең төп әһәмияте шунда, аларда һәркемгә аңлашылырлык гади тел белән Ленин тәгълиматының төп положениеләре, сыйнфый көрәш тарихына караган катлаулы мәсьәләләр бәян ителә.

Нәшрият шулай ук гражданнар сугышы вакыйгаларын яктыртуга зур игътибар бирә, хезмәт иясе массаларына социалистик ватанны саклауның никадәр әһәмиятле булуын аңлата, аларда туган илгә, хезмәт халкына мәхәббәт тәрбияли. Эспеның «Колчак патшалыгында бер ел» дигән брошюрасы шул максатларны күздә тотып чыгарыла. Нәшрият чыгарган политик басмалар арасында «Революция һәм профессиональ союзларның III Бөтенроссия съезды карарлары», «Хезмәт турында законнар кодексы» кебек рәсми документлар мөһим урын тота.

Бөтен ил буенча В. И. Ленин әсәрләрен чыгару көчәя. В. И. Ленин әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итү эше революциягә кадәр үк башланган иде. Бездә бу эшне оештыручылар һәм башлап җибәрүчеләр беренче профессиональ татар революционеры Хөсәен Ямашев һәм күренекле татар язучысы Гафур Коләхметовлар була. Октябрь революциясеннән соң В. И. Ленин әсәрләрен тәрҗемә итү һәм бастырып чыгару эше ныклы системага салына, киң колач ала. Архив документларына карaганда, В. И. Ленинның революциядән соң татар телендә, беренче булып, түбәндәге әсәрләре басыла: «Тынычлык солыхын ратификацияләү турында доклад», «Солых турында декрет», «Җир турында декрет» һәм РСДРП(б)ның VIII съездында, шулай ук Советларның гадәттән тыш IV съездында сөйләгән докладлары. Болардан күренгәнчә, татар матбугаты, беренче чиратта,

[1] Собрание узаконений и распоряжений рабочего и крестьянского правительства. Рус телендә. 1919 ел. 265 бит.

[2] КПСС өлкә комитетының партия архивы. 15 фонд. 1 тасвирлама. 23 эш. 8 бит.

юлбашчының совет властеның төп бурычларына, илдә иминлек урнаштыруга һәм контрреволюция белән көрәш мәсьәләләренә караган хезмәтләренә игътибар биргән.

Иҗтимагый-политик әдәбиятны, бигрәк тә В. И. Ленин әсәрләрен чыгарганда, нәшрият объектив характердагы күп кенә кыенлыклар алдында кала. Квалификацияле тәрҗемәчеләр һәм редакторлар җитешми, татар телендә политик терминологиянең эшләнмәгән булуы кыенлыклар тудыра. Госиздатның Казан бүлегенә бу кыенлыкларны җиңүдә РКП(б) Үзәк Комитетының культпромы зур ярдәм күрсәтә. Тагын шуны да әйтеп китәргә кирәк, В. И. Ленин әсәрләрен, төрле сәяси хезмәтләрне һәм рәсми документларны өйрәнүне җиңеләйтүдә редакция исеменнән бирелә торган зур булмаган керешләр яки йомгаклау сүзләре әһәмиятле роль уйный. Аларда гади тел белән партиянең һәм дәүләтнең политик мәсьәләләргә карашы аңлатыла. Татар укучыларына В. И. Ленин әсәрләрен үзләштерүне җиңеләйтү максатыннан чыгып, китап ахырында аерым сүзләргә һәм терминнарга аңлатмалар бирелә.

Совет властеның беренче елларында ук Татарстан тарихын өйрәнү буенча киң күләмдә башланып киткән фәнни эш тарихи әдәбият чыгаруны юлга салырга булыша. Халык Комиссарлар Советы Октябрь революциясен һәм РКП(б) тарихын өйрәнү буенча Үзәк комиссия төзү турында махсус карар кабул итә. Бу карар нигезендә Дәүләт нәшриятының Казан бүлеге каршында «Испарт»ның Казан подкомиссиясе оештырыла һәм ул партия тарихына, Казан губернасындагы революцион хәрәкәт тарихына караган материаллар җыю һәм аларны бастырып чыгару мәсьәләләре белән шөгыльләнә башлый. Губернадагы җирле халыклар тарихын, аларның этнографиясен өйрәнү эше киң колач ала. Мисал төсендә, Никольскийның «Идел буе халыкларының тарихы буенча конспект», «Чуваш этнографиясе буенча кыскача конспект» дигән брошюраларын күрсәтергә мөмкин.

Агитация-пропаганда һәм иҗтимагый-политик әдәбияттан тыш, нәшрият фәнни-популяр әдәбият һәм үзлегеннән укучылар өчен төрле кулланмалар чыгару эшенә дә җитди игътибар бирә. Зур тиражлар белән төрле кулланмалар, сүзлекләр, белешмәлекләр басыла. Үзлекләреннән укырга-язарга өйрәнүчеләргә ярдәм йөзеннән «Наданлык бетсен», «Җиңеләйтелгән матур язу белешмәсе», «Гаиләдә һәм мәктәптә», «Кешеләр арасында һәм әкиятләр патшалыгында», «Уку өчен беренче китап», «Уку өчен икенче китап» кебек кулланмалар чыгарыла.

Крестьяннарны политик яктан тәрбияләүгә партия һәр вакыт зур игътибар бирел килә. РКП(б) Үзәк Комитетында крестьяннар белән эшләү буенча махсус бүлек булдырыла. Крестьяннар арасында пропаганда эшен җәелдерү авылга реаль ярдәм күрсәтү белән бәйләп алып барыла. 1920 елдан крестьяннар арасында ифрат зур оештыру һәм агитация эшләре башланып китә. Массаларга коллектив хуҗалыкларның өстенлекләрен аңлату мәсьәләсе көн тәртибенә килеп баса. Бу бурычларны уңышлы хәл итүдә басма сүзгә, китапка зур урын бирелә. Әлеге чараларны тормышка ашыру йөзеннән, татар телендә «Авыл нинди налоглар түли?», «Крестьяннарга саклык кассасы нигә кирәк?» кебек брошюралар чыга. Арада аеруча зур популярлык казанганы «Авыл коммунасы» дигән брошюра була. 1920 елдан башлап нәшрият авыл хуҗалыгының аерым тармаклары буенча (үсемлекчелек, терлекчелек һ. б.) махсус кулланмалар чыгара башлый. Шул ук елдан Госиздатның Казан бүлеге «Советлар Россиясенең авыл хуҗалыгы китапханәсе» дигән серия чыгарырга керешә. «Уртак игенчелек», «Совхозлар турында минем белгәннәрем», «Яшелчәләрне кышын саклау» кебек популяр брошюралар нәкъ шул сериягә керә. 1920 елның январь аеннан, «Знамя революции» газетасының кушымтасы төсендә, «Деревенские думы» дигән газета чыга башлый, шул ук елда «Халык хуҗалыгы» дигән журналның да беренче саны дөнья күрә.

Нәшрият планнарында хатын-кызларга багышланган әдәбият, шулай ук атеистик пропаганда буенча китаплар чыгару да елдан-ел киңрәк урын ала бара. Дөрес, дингә каршы әдәбият бастыру эше шома гына бармый. Совет властеның беренче елларында бу төр әдәбият системасыз төстә һәм бик аз санда басыла. Без, мәсәлән, Гудкованың «Алла турында кайбер нәрсәләр» дигән бер брошюрасыннан башка, телгә алып сөйләрлек нәрсә тапмадык. Дингә каршы татарча китаплар чыгару эше тагын да сүлпәнрәк бара. Билгеле, бу бер Казан нәшрияты өчен генә

хас күренеш түгел. Башка милли нәшриятларда да хәл шул чамадарак була.

Йомгак рәвешендә шуны әйтергә кирәк, Госиздатның Казан бүлеге үзенең киң халык массаларына адресланган китапларында шул чор өчен хас бөтен иҗтимагый мәсьәләләрне күтәреп килә. Бу, үз чиратында, большевиклар партиясенә һәм эшче-крестьян дәүләтенә хезмәт иләрен политик яктан тәрбияләү эшен нык җиңеләйтә. Бу җәһәттән карагандa, агитацион әдәбият «үз эшен коралның башка төрләренә — пушка, пулемет, винтовкаларга карагандa һич кем башкармый, ул хезмәт иләренең бөтен фронтларда җиңүен тәэмин итә»[1]. Шул кадәресен дә билгеләп үтәргә кирәк, совет властеның беренче елларында массовый әдәбиятны укучыга карап дифференциацияләү практикасы булмый. Ул, барыннан да бигрәк, гомумән киң массаларга адресланган агитация-пропаганда әдәбияты була. Актуальлек, партиялелек, һәркем аңларлык гади телдә язылган булу — аның төп сыйфатлары. Массовый әдәбият чыгарып, Госиздатның Казан бүлеге үз өстенә төшкән төп бурычларны үтәргә омтыла. Сүз массаларга политик тәрбия бирү, гомум хуҗалык мәсьәләләрен конкретлаштыру һәм аңлатып бирү, социалистик җәмгыять төзү тәҗрибәсен өйрәнү, хезмәт иләренә атеистик тәрбия бирү турында бара.

Халык мәгарифен чын фәнни нигезләрдә үстерү эше дә Бөек Октябрь революциясеннән соң гына башлана. 1917 елның декабрендә башлангыч һәм урта мәктәпләрне, шулай ук югары уку йортларын, дини учреждениеләр карамагыннан алып, Халык Мәгариф Комиссариаты карамагына бирү турында декрет кабул ителә. Тагын бер елдан чиркәүне дәүләттән һәм мәктәпне чиркәүдән аеру турында закон чыга. Ә 1918 елның 18 февралендә Мәгариф эше буенча дәүләт комиссиясе «Совет мәктәбе турында»гы карарны халыкка җиткерә. Бу карар нигезендә, мәктәпләрдә дин укыту, дини йолалар башкару катгый тәстә тыела. Һәм, ниһаять, «Бердәм хезмәт мәктәбе турындагы декларация»дә совет халык мәгариф системасының төп принциплары формалаштырыла. Революциягә кадәрге төрле типтагы күп төрле мәктәпләр урынына ике баскычтан торган бердәм хезмәт мәктәбе төзелә. Укучыларның социаль составы нык үзгәрә, мәктәпләргә эшче һәм крестьян балалары килә. Уку-укыту эшенең максатлары, бурычлары һәм характеры үзгәрә. «Бердәм хезмәт мәктәбе турындагы закон», төп һәм мәҗбүри таләп төсендә, укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү мәсьәләсен куя. Хезмәт эшчәнлеге, аны оештыру эше укытучыларның һәм халык мәгарифе җитәкчеләренең төп игътибар үзәгенә куела.

Революциягә хәтле, гомуми белем бирү дигәндә, укучыларның мәгълүм бер даирә фәннәрне, нигездә гуманитар фәннәрне, үзләштерүләре күздә тотылган. Совет мәктәбе гомумән грамоталы кеше тәрбияләп чыгару белән генә канәгатьләнә алмый иде. Ул кеше белән табигать, шәхес белән җәмгыять, экономика, политика белән культура, үткән белән бүгенге арасындагы катлаулы мәсьәләләрне дөрес аңларлык гражданин тәрбияләргә тиеш иде. Бу исә укучыларда дөньяга материалистик караш, тирә-юнь тормышка яңа мөнәсәбәт, яңа кешелек сыйфатлары тәрбияләү дигән сүз. Укучыларның белемнәрне үзләштерүләре генә җитми, аларны үзбаш фикер йөртергә, мөстәкыйльлеккә өйрәтергә кирәк иде. Шуның белән бергә үк, аларга социаль, политик, хезмәт тәрбиясе, эстетик, физик тәрбия бирү мәсьәләләре көн тәртибенә куелды.

Мәктәпне үзгәртеп кору юлындагы аеруча актуаль мәсьәләләрнең берсе дәреслекләр чыгару белән бәйләнгән иде. Шул мәсьәләне уңай хәл итми торып, совет мәктәбе яши дә, үсә дә алмаячак иде. Дәреслекләр басып чыгару иң үзәк мәсьәләләрнең берсенә әйләнә.

Патша Россиясеннән аермалы буларак, совет педагогикасы баштан ук төрле милли мәктәпләр, шулай ук шәһәр һәм авыл мәктәпләре өчен аерым дәреслекләр булдыру политикасын алга сөрә. Баштарак дәреслекләр чыгару эше белән Халык Мәгариф Комиссариатының әдәбият-нәшрият бүлеге, эшче, крестьян һәм солдат депутатлары җирле советларының нәшриятлары шөгыльләнә. Дәүләт нәшрияты оешкач, дәреслекләр чыгару аның карамагына күчә, һәм бу дәүләт нәшрияты башкарырга тиешле иң төп эшләрнең берсе булып кала.

Революциядән соң азчылык милләтләргә уку-укыту эшләрен үз ана телләрендә алып бару хокукы бирелә. Илебез халыклары моны революция нәтиҗәсендә ирешелгән иң зур казанышларның берсе те-

[1] Государственное Издательство за пять лет. Рус телендә. Москва. 1924 ел. 80 бит.

сендә шатланып каршылыйлар. Укытуны ана телендә алып бару, үз чиратында, милли телләрдә дәреслекләр һәм кулланмалар булдыру мәсьәләсен көн тәртибенә куя.

Бездә дәреслекләр чыгару белән башта губерна башкарма комитеты каршындагы матбугат бүлеге шөгыльләнә, аннан бу эш Казгосиздат карамагына күчә. 1919 елда нәшрият, бераз үзгәртеп һәм яңа шартларга яраклаштырып, иске дәреслекләрне чыгарып килә. Беренче чиратта, иң кирәкле дәреслекләр — әлифбалар, уку китаплары басыла.

Казан нәшрияты I һәм II баскыч мәктәпләр өчен татар телендә дәреслекләр яздырту буенча гаять зур эш башкара. Татар телендә дәреслекләр төзү буенча нәшрият каршында өч коллектив оештырыла: беренчесе татар теле һәм әдәбияты буенча дәреслекләр, кулланмалар төзү өчен, икенчесе математика фәне буенча дәреслекләр төзү өчен, өченчесе табигать белеме буенча дәреслекләр һәм кулланмалар төзү өчен. Һәр өч коллективка татарлар арасыннан күренекле галимнәр һәм педагоглар тартыла.

1919 елда барлыгы 75 исемдәге дәреслек бастырып чыгару планлаштырыла. Аларның гомуми күләме 1154 басма табак булып, тиражлары 3 365 000 данәгә җитә. Елның беренче яртысында I баскыч мәктәпләре өчен 28 исемдәге дәреслек чыгару күздә тотыла. Алар арасында татар әдәбияты һәм грамматика дәреслекләре, математика, география, физика, табигать белеме, тарих китаплары бар. II баскыч татар мәктәпләре өчен планлаштырылган дәреслекләр саны иллегә якын. Алар арасында татар әдәбияты тарихы, Көнбатыш Европа әдәбияты тарихы буенча очерклар, борынгы әдәбият тарихы, рус әдәбияты тарихы, Рим әдәбияты тарихы, Көнчыгыш әдәбияты тарихы, социология буенча хрестоматия, социализм тарихы, рус революциясе тарихы, геометрия, алгебра, тригонометрия, физика, математика һәм башка фәннәр буенча дәреслекләр бар.

Дәреслекләр чыгару эше зур кыенлыклар белән бара. Ана телен белүче наборщиклар җитәрлек булмый, кәгазь җитми, барыннан да бигрәк, тулы кыйммәткә ия дәреслекләр язу өчен авторлар коллективы тупланмаган була, программаларның эшләнмәгән булуы җитди кыенлыклар тудыра. Әмма ни генә булмасын, Дәүләт нәшриятының Казан бүлеге үз өстендәге бурычны нигездә уңышлы башкарып чыга. 1919 ел дәвамында татар телендә бик күп дәреслекләр басыла. Комплекслы программаларны күздә тотып эшләнгән байтак кулланмалар дөньяга чыга. Мәсәлән, «Авыл хуҗалыгы», «Умартачылык», «Ветеринария», «Кооперация», «Хезмәт мәктәбе» һ. б.

География, геометрия, табигать белеме кебек фәннәр буенча дәреслекләр, кагыйдә буларак, русчадан тәрҗемә итү юлы белән эшләнә. Әмма тәрҗемәчеләр, җирле шартларга яраклаштыру йөзеннән чыгып, аларның эчтәлекләрен шактый үзгәртәләр, тулыландыралар. Ул дәреслекләр татар халкы тормышыннан алынган иллюстрацияләр белән чыгарыла.

Дәреслекләрнең үз вакытында чыгуы, шулай ук, Татарстан һәм РСФСР Халык Мәгариф Комиссариатларының өлгерлегенә дә бәйле була, алар дәреслекләрне раслауны еш кына тоткарлап киләләр. С. Потапов «Милли телләрдәге дәреслекләрне чыгару эшен яхшыртырга» дигән мәкаләсендә бик хаклы рәвештә болай яза: «Кульъязмалар, производствога тапшырылганчы, тикшерү һәм раслау белән бәйле озын юл узалар. Урыннарда дәреслекләр мәҗбүри төстә рецензияләнә һәм Халык мәгариф органнарында расланганнан соң, РСФСР Халык Мәгариф Комиссариаты карамагына тапшырыла, анда кабат рецензияләнәләр. Дәреслекләр айлар буе чират көтеп яталар. Кагыйдә буларак, бер утырышта 30—40 дәреслек раслана. Дәреслекләрне раслау хокукын урыннардагы органнарга, аерым алганда, автономияле республикаларның Халык Мәгариф Комиссариатларына... тапшыру максатка ярашлырак булыр иде» [1].

Партия һәм Татарстан хөкүмәте дәреслекләрнең эчтәлегенә генә түгел, ә аларның тышкы бизәлешенә дә зур әһәмият бирәләр. Әмма бу эштә кыенлыклар да күп була. Эш монда бер художник белән редакторның нинди кеше булуыннан гына да тормый, ә материалларның (кәгазь, буяу һ. б.) сыйфатына да бәйләнгән була.

Совет властеның беренче елларында Госиздатның Казан бүлеге төрле кулланмалар чыгаруга да зур игътибар бирә, ул шулай ук методика буенча периодик басмалар чыгара. Мәсәлән, «Хезмәт мәктәбенә бару юлында», «Мәгариф хәбәрчесе» һ. б. Татар телендә чыга торган «Мә-

[1] «Резолюция и национальности». Рус телендә. 1937 ел. 9—10 саннар. 58 бит.

гариф» журналының эшчәнлеге аерым хөрмәткә һәм игътибарга лаек.

Госиздатның Казан бүлеге оешуының беренче көннәреннән үк хезмәт иясе массаларын матур әдәбият белән тәэмин итә башлый. Нәшрият чыгара торган бюллетеньда бу хакта түбәндәгечә язылган: «1919 елның ахырыннан башлап Россиядәге бөтен нәшрият эше Дәүләт нәшрияты тарафыннан берләштерелә башлый. Дәүләт нәшрияты, кәгазь кытлыгына һәм башка кыенлыкларга да карамастан, китап басу өлкәсендә сизелерлек уңышларга ирешә. Агитация-пропаганда материалларыннан һәм брошюрадан тыш, марксистик әдәбият күпләп басыла, әдәбиятның барлык тармаклары, сәнгать, төгәл фәннәр һәм башка фәннәр буенча яңа китаплар чыга, искеләре кабат басыла» [1].

Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы еллары — милли әдәбиятлар барлыкка килүнең һәм үсүенең иң мөһим чоры. Бу елларда Г. Ибраһимов, Г. Камал, Ш. Камал, Ф. Әмирхан, һ. Такташ, К. Тинчурин кебек алдынгы татар язучылары революция вакыйгаларына багышланган иң яхшы әсәрләрен иҗат итәләр. Татар язучыларының иҗаты тыгыз тестә яңа чынбарлык белән бәйләнгән иде, алар социализм җәмгыяте төзү юлында ирешкән уңышлар белән илһамланып эшләделәр.

Казан нәшрияты татар язучыларының оригиналь әсәрләрен чыгару, рус һәм дөнья әдәбияты классикларын тәрҗемә итеп бастыру буенча зур эш башкара. Нәшрият М. Горькийның «Фома Гордеев»ын, А. Толстойның «Касатка» комедияләрен татар телендә чыгара. Каринскийның хезмәт ияләренең революцион көрәшенә багышланган «Алар һәм без» исемле драмасы 10 000 данә тираж белән басыла. Казан нәшрияты чыгарган матур әдәбият китаплары арасыннан татар әдәбияты классикларының әсәрләре аеруча зур популярлык белән файдаланыла. 1920 елда Г. Ибраһимовның революция һәм шәхес мәсьәләләрен сурәтләүгә багышланган «Безнең көннәр» драмасы чыга. Революциянең беренче елларында Ф. Бурнашның «Таһир белән Зөһрә» һәм «Яшь йөрәкләр» исемле сәхнә әсәрләре басыла. Шул ук авторның 1919 елда чыккан «Дала каны» поэмасы азатлык көрәше мәсьәләләренә багышланган. Шул ук елларда М. Максуд нәсерләре, Г. Камалның «Декламацияләр» җыентыгы дөньяга чыга, М. Гафури, М. Фәйзи кебек язучыларның әсәрләре еш басыла.

Нәшрият балалар әдәбияты әсәрләрен чыгаруга зур игътибар бирә, татар классикларының әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итү эшен юлга сала. П. Радионов тәрҗемәсендә рус телендә Габдулла Тукайның «Өзелгән өмет» исеме белән шигырьләр җыентыгы, «Кәҗә белән сарык» исемле балалар әкияте чыга.

Революциянең беренче елларында басылган матур әдәбият әсәрләрендә яңа кеше өчен көрәш, хатын-кыз азатлыгы, мәхәббәт мәсьәләләре күтәрелә. Гражданнар сугышы тәмамланып, илне торгызу эшләре башлангач, хезмәт темасы көчәеп китә. Матур әдәбият әсәрләренең чагыштырмача күп басылуы бездә матур әдәбиятның югары дәрәҗәдә булуы һәм нык алга киткәнлеге турында сөйли.

Госиздатның Казан бүлеге чыгарган китап продукциясенә анализ ясау шуны күрсәтә: совет властеның беренче елларында бездә иҗтимагый-политик әдәбият, дәреслекләр һәм матур әдәбият әсәрләре аеруча күп басылган.

Иҗтимагый-политик әдәбиятның тематикасы шул чордагы тормышның ихтыяҗлары белән тыгыз бәйләнгән. Мондый китапларда иҗтимагый яшәешнең аеруча актуаль мәсьәләләре чагылыш таба. Бу — Госиздатның Казан бүлегенең социалистик җәмгыять төзүдә якыннан торып актив катнашуы, партиянең якын ярдәмчесе булуы турында сөйли.

Казан бүлеге дәреслекләр һәм кулланмалар чыгаруга зур игътибар бирә. Ул шулай ук татар теленә дәреслекләр тәрҗемә итү, татарча яңа дәреслекләр язды-ру эшен киң җәелдерә. Нәшрият чыгарган дәреслекләр коммунистик тәрбия бирү, дөньяга марксистик караш тәрбияләү, наданлыкны бетерүдә ныклы таяныч булалар.

Дәүләт нәшриятының Казан бүлеге татар классикларының, шулай ук рус һәм дөнья классикларының иң яхшы әсәрләрен дөньяга чыгару эшенә зур өлеш кертә.

Губернада яшәүче халыкларны барлык төр әдәбият әсәрләре белән тәэмин итеп тору — нәшриятның төп бурычы әнә шул була. Күргәнегезчә, үз өстенә йөкләнгән бу зур эшне ул нигездә уңышлы башкарып чыга.

---

[1] Дәүләт нәшриятының Казан бүлеге бюллетеньнары. 1921 ел. 1 сан. 5 бит.

# ЯЗУЧЫ. ЗАМАН. ГЕРОЙ

**Тәнкыйтьче Мансур Вәлиев белән язучы Аяз Гыйләҗев әңгәмәсе**

**Тәнкыйтьче.** Сез каршы килмәсәгез, мин бу әңгәмәне бүгенге герой мәсьәләсенә багышлау ягында.

**Язучы.** Юк, мин каршы түгел. Кызыклы һәм кирәкле мәсьәлә. Әдәбият мәсьәләләрендә теоретик булмасам да, һәр язучының иҗат практикасында тегеләй яки бу әдәби мәсьәләләр, шул исәптән, заман һәм бүгенге герой турында уйланган чаклары еш була. Әнә шул мәсьәләләрне үзенең иҗат практикасында чишә-чишә, язучының ышанычы, иманы, зәвыгы тәрбияләнә. Минем бу сөйләшүдә катнашуым да, барыннан да бигрәк, үз тәҗрибәмне уртаклашу дип каралырга тиеш, әлбәттә. Ә язучы буларак, герой проблемасы мине төрле яктан, төрле аспектта кызыксындыра.

**Тәнкыйтьче.** Билгеле, бу сөйләшүне дә күп юнәлешләрдә алып барырга мөмкин булыр иде. Чөнки герой проблемасы әдәбиятның иң үткен мәсьәләләренең кисешү ноктасы кебек бит ул, анда әдәбиятның тормышчанлык көче дә, дөньяны танып-белү чарасы буларак әһәмияте дә, идея-эстетик кыйммәте дә чагылыш таба. Ләкин минем үземне барыннан да бигрәк бүгенге геройның тормыш белән бәйләнеше борчый. Чөнки соңгы елларда чыккан күп кенә проза әсәрләрен алсаң, андагы геройларның еш кына тормыштан, бүгенге тормышта чишелә торган иң әһәмиятле конфликтлардан арттa икәнлекләрен, еш кына безнең әдәбият геройларының инде тормышта чишелгән яки чишелү юлы табылган мәсьәләләр белән гомер уздыруларын күрәсең. Бу бигрәк тә хәзерге чорда — тормышның һәрбер өлкәсендә ачыш, табыш, ярыш кайнап торганда үзен нык сиздерә. Нәкъ менә шушы нәрсә безнең әдәбиятны бүгенге укучының гаять югары күтәрелгән рухи дөньясыннан аерырга мөмкин бит.

**Язучы.** Гомумән алганда, сезнең белән килешми мөмкин түгел. Ләкин, минемчә, мәсьәлә монда тагын да катлаулырак тора. Мәсәлән, мин язучының үзен әсәрнең төп һәм иң мөһим герое дип исәплим. Әгәр автор үз халкының улы икән, үз чорының гражданины икән, үзе яшәгән вакытның каршылыкларын, тирәнлеген тулаем аңлап, тормыштагы көрәшләргә җанытәне белән катнаша ала икән, бу авторның әсәрләре кызыклы һәм файдалы булып чыга. Дөрес, монда талант дәрәҗәсен дә, ул талантның кемгә, ничек хезмәт итүен дә онытып җибәрергә ярамас. Сүзне талантлы кешеләр турында, чын язучылар турында алып барыйк. Кабатлап әйтәм, әсәрнең бөтен тукымасы, уңышы-уңышсызлыгы, уты-ялкыны, мәхәббәте-нәфрәте язучының үз шәхесенә бәйләнгән. Язучы кәгазь-каләм тотып тумый, әлбәттә. Ул тормышның төрле юлларын уза, хезмәтнең ачысын-төчесен татый. Кемнәрдер аның рухи дөньясын баеталар, кемнәрдер киметәләр. Язучының биографиясе — аның иҗатын билгеләүче төп факторларның берсе. Кеше буларак кайда, нинди шартларда чыныккан ул, тормышта һәм әдәбиятта аның рухи юлдашлары кемнәр, болар барысы да иҗат процессында зур урын тота торган факт-

лар. Әгәр дә без бүгенге кайбер язучыларның «геройлары тормыштагы геройлардан артта калалар» дибез икән, моның тамырына күз салырга мәҗбүрбез. Димәк, безнең ул язучыларыбыз үз юлларыннан үзмаганнар, үз темаларын тапмаганнар, үз йөзләрен эзләмәгәннәр. Үз темасын тапкан икән (ә теманы бары тик ниндидер бер мохиттә яшәп, шунда эшләп, шунда көрәшеп кенә табып була), бу кеше тормышта һәм әдәбиятта үз сүзен әйтә ала! Һәр язучыны тәрбияләгән, аңа язучы һәм гражданин буларак өлгерергә ярдәмләшкән өлкә була. Заводмы бу, колхозмы, фән оешмасымы — барыбер. Әмма билгеле бер урын, өлкә була һәм язучы, кеше буларак, шушы үзе белгән өлкә өчен җавап бирә. Барлык өлкәләрне, темаларны кочарлык, персонажларны иңләрлек язучы булуына шикләнәм мин. Безнең заман — фән заманы. Безнең заманда фән эшчеләре арасында специальләшү көчәйгәннәнкөчәя бара. Язучыга шушы катлаулы, күп белем, эрудиция сорый торган заманда үз урынын таба белү бик авыр. Таба калган очракта бу аның бәхете.

**Тәнкыйтьче.** Ләкин фән өлкәсендәге үзгәрешләр һәм специальләшү турында сөйләгәндә без бу процессның тискәре якларын да истән чыгармаска тиешбез. Мәсәлән, специальләшү галимнәрне гаять күп төрле тармакларга бүлдә һәм аларның аралары торган саен ерагая, бер-берсен аңлау мөмкинлекләре торган саен кыенлаша бара. Шуның кебек, әдәбиятта язучының үз темасын, тормышны өйрәнүдә үз юнәлешен булдыру кебек кирәкле һәм әһәмиятле нәрсә дә язучыларны бер-берсен аңламаслык дәрәҗәгә җиткермәсен иде. Ачыграк итеп әйткәндә, еш кына шундый хәлләр була: теге яки бу язучы (бигрәк тә бу яшьләр белән шулай була бугай) тота да тормышның бер тармагын ала. Бу факт үзе, әлбәттә, без сөйли торган специальләшү дигән сүз. Ләкин аннан еш кына нәрсә килеп чыга соң? Авторның әсәрендә әлеге тармакта бара торган вакыйгалар, бөтен детальләре белән кертелгән эш процесслары һәм, гомумән, бу тармакның бөтен спецификасы була, ә менә шул кешеләрнең башкаларга да бик якын һәм аңлаешлы, аларны да дулкынландырырлык рухи дөньясы, кешенең асыл табигате ачылмаган була. Шуңа күрә алар башкалар өчен кызык та, кирәк тә булмыйлар. Моннан шуны әйтәсем килә: язучы тормышның теге яки бу өлкәсенә кереп чумганчы, аннан нинди нәтиҗә, безнең әдәбиятыбызны баетырлык һәм кешенең яңа бер асыл сыйфатын ачып бирерлек нинди хакыйкать табып чыгачагын алдан уйларга тиеш. Әдәбиятның төп максаты ахыр чиктә тормыш төрлелеген чагылдыру түгел, ә кеше характерын төрле яктан ачу бит. Минемчә, без әле менә шуны ныклап аңлап бетермибез бугай.

**Язучы.** Әйе, язучыга тиз генә теләсә нинди темага барып тотынырга мөмкин дигән караш, кызганычка каршы, әле еш очрый. Безнең тәнкыйтьчеләр еш кына тоталар да Нурихан Фәттах, Әхсән Баян кебек прозаикларга: «Нигә сез сугыш еллларын язасыз да нигә сугыштан соңгы елларны тугылыйсыз?» — дип бәйләнәләр. Минем үземә дә бу сүзне еш ишетергә туры килә. Нурихан белән Әхсән нигә шул чорны иҗат итмәсеннәр?! Алар шул чор кешеләре! Алар шул чордагы тормышны төзүдә катнаштылар! Шул чор геройларының эчке һәм тышкы дөньяларын үзләштерделәр, аларның күңелләрендә шул вакытлардагы уннарча, йөзләрчә вакыйгалар, гыйбрәтләр саклана. Шуның өстенә алар шул чорда яшәгән, көрәшкән совет кешеләре алдында бурычлы: Нурихannар, Әхсәннәр күрде ич аларның авыр, әмма мактаулы көрәшләрен! Алар җиткермәсә, киләчәк буыннарга ул чорны кем җиткерер?..

**Тәнкыйтьче.** Ләкин шул ук вакытта мәсьәләнең икенче ягы да бар бит әле. Заман һәм чор белән тыгыз бәйләнештә яшәгән, аның һәрбер үзгәрешен йөрәге белән сизеп, аның өчен шатланып я борчылып яшәгән язучыны, иң беренче чиратта, бүгенге көн мәсьәләләре борчырга тиеш. Бүген тормышта хәл ителә торган мәсьәләләрдә ул иң актив катнашырга һәм шуны үзе аңлаганча, гаделлек таләп иткәнчә чишү өчен бөтен көчен салырга тиеш. Минемчә, әлеге фикер шундыйрак мәгънәдә куелган булгандыр. Минемчә, талантлы язучыларның бүгенге тормышыбызга игътибарлырак булуларын күрергә теләү һәрберебезнең күңел түрендәге өмет.

**Язучы.** Дөрес, мин Нурихан да, Әхсән дә бары тик шул чорны, шул кешеләрне генә язарга тиешләр дип чикләмим, бу язучылар үзләрен башка юнәлештә дә уңышлы эшли алу сәләтләрен күрсәттеләр. Әмма алар кайсы сукмакларга гына кереп китсәләр дә, нинди олы юлларга гына чыксалар да, үз темаларын чишеп, үз

темаларына турылыклы булып кына мәгълүм уңышка ирешетләр дияр идем мин.

Без байтак еллар «эшчеләр тормышына багышланган хикәя-романнар аз языла» дип зарланып йөрдек. Димәк ки, эшчеләр мохитыннан әдәбиятыбызга кадрлар аз килгән дигән сүзне аңлата бу! Язучыларыбыз корыч белән, тимер белән бергә чыныкмаганнар дигән тәшвишле хәбәрне сөйли! Нефть үзәге Әлмәт шәһәрендә Язучылар союзының бүлекчәсе төзелүнең, бәрәкәтле һәм кирәкле булуы турында берәү дә шикләнмидер хәзер? Әгәр Әлмәт бүлекчәсе булмаса, Шамил Бикчурин романы һәм башка байтак әйбәт китаплар дөнья күрер идеме икән?..

Ә бүгенге әсәрләребездәге геройлардан канәгать түгел икәнбез, бу, барыннан да элек, язучыларыбызның көндәлек яшәешләренә кагыла. Яшьләр туп-турыдан туп-туры язучы булып китә, бик иртә профессиональләшә. Тапталган булса да, «мәктәп-вуз-редакция» схемасын хәтергә төшереп узарга туры килә. Менә мин байтак еллардан бирле Язучылар союзына членлыкка кабул итү комиссиясендә эшлим. Байтак иптәшләр минем күз алдымнан узды. Яшьлек зәңгәрлеген җырлап, дәвылланып бер-ике китап язып ыргыткан кайбер иптәшләр безнең хәтердә үк сүнеп, тукталып калдылар. Ни өчен? Чөнки ил тормышын алар белмиләр, халкыбызның гореф-гадәтләреннән, иҗатыннан, яшәешеннән аерылганнар. Һәр язучының артында үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән мәгълүм бер халык торырга тиеш. Дөрес, безнең яшьләребез иҗат командировкаларында акча туздыралар, кайлардадыр укыйлар, әмма тормыш баскычларын узмаган, шушы тормышны төзүгә актив катнашмаган, хаклык өчен кан яки яшь түкмәгән кешеләрнең күңелләре пассив була. Әдәбият исә күңел пассивлыгын күтәрми, халык күңеле пассив язучыларны яратмый, чөнки аларның иҗат җимешләре салкын, җансыз һәм төссез була.

**Тәнкыйтьче.** Бүгенге укучыга салкын һәм җансыз язучы да, аның роботны хәтерләткән герое да юлдаш була алмый. Ләкин, кызганычка каршы, андый роботлар күп кенә әсәрләрдә күренә әле. Еш кына алар заман өчен, ил өчен иң әһәмиятле темаларга да килеп чыгалар һәм чын кеше, сизгер күңелле, тирән тоемлы кеше була алмаулары аркасында бу теманы җиңел генә ерып та чыгып китәләр. Әдәбиятта ихлас күңел белән ясалмалылыкны аера белмәвебез кайчагында роботларга гашыйк булуга да китерә. Эчләре буш икәнне белмичә, без аларны әдәбиятыбыз ирешкән зур казаныш дип саныйбыз. Ләкин чын кешелеклелек хәзер сәнгатьтә генә түгел, тормышыбызда да кешеләрне роботлардан аера торган төп сыйфатка әверелеп бара.

Безнең әсәрләребездә кешелек көче җиңгән саен, минемчә, геройларыбызның да көче, укучыга һәм тормышка тәэсире арта барачак. Чөнки шундый образлар гына безнең рухи дөньябызны яңа баскычка күтәрәләр, баеталар. Бүгенге укучыга герой белән танышу бер бик мәгънәле һәм зур сабак бирә торган тормыш үтү кебек булса гына ул аның онытылмас һәм аерылмас юлдашына әйләнә.

**Язучы.** Бүгенге көн героена минем мәгълүм таләбем бар: герой икән, аның киләчәге булсын! Теге яки бу герой язучы күңеле аша тормыштан китапка үтеп керә. Кем ул, нинди ул, чорының кадерле һәм онытылмаслык асыл сыйфатларына ияме ул — аның укучы күңелендә озак яши алуы әнә шуларга бәйләнгән. Безнең китапларда еш кына бер көнлек персонажлар гомер итәләр һәм китап үзе тузганчы ук искерәләр, онытылалар. Ә менә бүгенге көн геройларыннан кайсысы киләчәккә атлар? Сафлык, тугрылык, матурлык темасына сүз башласак, без һаман Хәятләргә, Галиябануларга, Нәфисәләргә баш иябез... Ә бүгенге әсәрләребездән кайсы хатын-кыз, яулыгын җилфердәтеп, безне узып китәр икән?.. Бу турыда уйласам, уңайсызланам..

**Тәнкыйтьче.** Әйе, бер карасаң уңайсызланыр урын да бар кебек. Бездә, чыннан да, Галиябанулар, Нәфисәләр кебек, бүгенге көннең якты образлары, уңай геройлары юк. Ләкин «Галиябанулар, Нәфисәләр юк» дигән сүздә, минемчә, соңгы еллар әдәбиятының бер әйбәт тенденциясе дә чагыла сыман. Безнең геройларыбыз хәзер нәрсәнеңдер эталоны булудан битәр, әнә шул дәрәҗәгә күтәрелү юлын ныклап бөтен катлаулылыгында өйрәнәләр шикелле. Ә бу исә әдәбиятка моңарчы күрелмәгән тормышчанлык көче алып килә, геройның тормыш һәм укучы алдына әһәмиятен нык арттыра. Моннан берничә еллар элек матбугатта һәм иҗат практикасында уңай герой турында барган кайнар бәхәсне дә әдәбият үзе шулай хәл итте

бугай: ягъни әдәби процесс «үрнәк» геройдан «гыйбрәтле» геройга күтәрелде, минемчә.

**Язучы.** «Үрнәк» герой дип моннан берничә еллар элек «ташка басып, сөткә коенырга яратучы, затсыз, шадрасыз, шопшома кешене» пропагандаларга тырышучылар да булды. Хәзер бу мәсьәләдә икеле-микеле сөйләшүләр бетте инде. Бүгенге үрнәк герой шул ук гыйбрәтле герой түгелмени?..

Шәхсән, минем үземне «гыйбрәтле» геройлар ныграк кызыксындыра. Мин шундый кешеләрне яратам, үзләре яшәгән чорга битараф булмаган, мәхәббәтне һәм нәфрәтне сиземли торган кешеләр... Уйлана һәм уйландыра торган кешеләр! Коммунизм идеалларына турылыклы кешеләр... Шул ук вакытта үз турылыкларын лозунг итеп күтәреп йөрми торган тыйнак кешеләр!.. Илгә, халыкка чын күңелдән бирелгән кешеләр... Киң күңелле кешеләр... Бу сыйфатларга ия булган кешеләрне үз гомер юлымда күп очраттым мин, алар минем күңелемне нык баеттылар. Ясалмалыктан, төче буяулардан, ярашудан качарга өйрәттеләр.

Гыйбрәтле герой мәсьәләсе дә катлаулы бит ул! Аның бер генә төсмере булмаганга, барыбыз да төрлечә аңлатабыз... Гыйбрәтле геройлар күп төрле булсыннар, уйлансыннар, уйландырсыннар, тик чорыбызга лаек, аның дәрәҗәсендә булсыннар!

Әлбәттә, әзерлекле укучыны җилдә очырган кибәк белән алдый алмассың! Бик күп санлы гади укучыларыбыз турында да уйлыйк, алар бүген гади укучы икән, иртәгә чыныгу үткән, белемле, әзерлекле кеше булып китәчәк бит!

**Тәнкыйтьче.** Гади укучы дигәннән, хәзер безнең ул укучыбыз да нык үзгәрде бит. Язучы яки шагыйрь иҗатына бәя биргәндә безнең кайбер тәнкыйтьчеләр өчен төп терәк булган сыер савучыларның һәм механизаторларның зәвыклары, рухи ихтыяҗлары ул тәнкыйтьчеләр уйлаганга караганда әллә никадәр алга китте хәзер. Алар татар әдәбиятын гына түгел, рус әдәбиятын да, Көнбатыш Европа әдәбиятын да укыйлар. Шуңа күрә берәр әсәрне «сыер савучы аңламый» дияе белән тәнкыйтьче хәзер үзенең заманнан артта калганлыгын гына күрсәтә. Аннан соң үзебезнең әдәбиятыбызда туган Идрис («Урамнар артында яшел болын»), Рушад («Фронтовиклар»), Латиф («Каһарманнар юлы») һәм Габделхак («Сүзсез җыр») кебек бик үк гади булмаган геройларның бүгенге укучы күңеленә бик якын кабул ителүләре үзе үк күп нәрсә сөйли бит. Бу геройлар укучы зәвыгын үстерү буенча байтак эш башкардылар һәм безнең геройны заман дәрәҗәсенә күтәрделәр. Ләкин шулай да, минемчә, бу геройлар да әле күп чагында укучының үз дәрәҗәсендәрәк кенә кебек. Күңел хәзер әсәрләрдән озынрак гомерле булып туган, синең белән тормыш буйлап күбрәк ара барырлык геройлар көтә.

**Язучы.** Образның яшәү көчен, тәэсир итү сәләтен вакыт, заман билгели бит аны. Бүгенге көннең иң уңышлы образы дип әйтү, аны анык һәм ялгышсыз билгеләү өчен, алдан күрүчәнлек кирәк. Әлбәттә, бүгенге көннең чагылышын билгеләүче ягымлы кешеләр байтак әсәрләрдә очрый. Тик алар бер генә кеше түгел, әсәрнең үзе белән, әсәрне иҗат итүче автор белән бергә йөриләр. Соңгы елларда уңышлы әсәрләр дип мин Нурихан Фәттахның «Этил суы ака торур»ын һәм Мөхәммәт Мәһдиев әсәрләрен, бигрәк тә аның «Фронтовиклар» романын санар идем. Әсәрләрнең беренчесе моннан мең ел элеккеге тарихка багышланган, икенчесе сугыштан соңгы елларны чагылдыра, әмма бу ике роман, миңа калса, бүгенге көн югарылыгында язылган иң заманча әсәрләр. Алар бүгенге көн укучысын дулкынландыралар, аны туган илгә бирелгәнлек, патриотизм рухында тәрбиялиләр. Бу романнарның киләчәге бар. «Фронтовиклар» романындагы катлаулы образлар галереясы... Фронтовик егетләр... Ялгыз каз кебек сагышлы кызлар... Сүзсез Галиәхмәт бабайларга кадәр минем күңелгә бик газиз, бик якын кешеләр бар анда!.. Дөрес, «Фронтовиклар» романына карата байтак тәнкыйть сүзләре дә әйтелде, әмма ни генә булмасын, Мөхәммәт Мәһдиев чынлык белән, чын кешеләр аша реаль тормышыбызның тасвирын тапкан. Аның геройлары безнең күңелләргә актив кереп урнашалар, без аларны няртәбезме, алар безне әйдәп алып китәме — моннан соң без алар белән бер вакытта да аерылачак түгел.

**Тәнкыйтьче.** Чыннан да, сез әйткән бу мисалда безнең язучылар өчен бик әһәмиятле күренеш ачыла. Күрәсең, язучы тудырган герой чын мәгънәсендә герой, әдәбиятта бүтәннәрдән бер баш югары торырлык образ булсын өчен, беренче чи-

ратта, язучының тормышта үзен герой итеп тоя алуы, үзенә зур җаваплылык һәм бурыч йөкләнгәнен аңлап, шуны тормышка ашырырга ашкынуы кирәктер.

**Язучы.** Минемчә, барыннан да бигрәк, Нурихан Фәттах өчен дә, Мөхәммәт Мәһдиев өчен дә язу, иҗат итү, әдәбият эше— аларның яшәү дөньясы. Алар бу эшкә фанатикларча бирелгән кешеләр. Инде яшьрәклэрдән Азат Ганиев исемен телгә аласым килә. Аның «Сүзсез җыр» исемле кечкенә генә повестен яшь авторның зур уңышы дип саныйм. Бу да юкка түгел! Нурихан да, Мөхәммәт Мәһдиев тә, Азат Ганиев тә тормышка үз биографияләре булып, олы кешеләрчә җитди килеп кергән кешеләр...

**Тәнкыйтьче.** Азат Ганиевкә җиткәч, безгә, мөгаен, яшь проза турында, аның геройлары турында да сөйләшми булмас. Соңгы елларда әдәбиятка килгән Азат Ганиев белән Диләрә Зөбәерова иҗатларында бүгенге яшь буынны аңлау һәм аны күрсәтү буенча кызыклы гына омтылышлар ясалды. Бигрәк тә сез телгә алган «Сүзсез җыр»да һәм Диләрә Зөбәерованың «Дустым авазы» белән «Куш өянкә шаһит»ында. Ул әсәрләрнең геройлары, минемчә, тирән эзләнүләре һәм тормышларында гаделлек, матурлык өчен көрәшләре белән безнең бүгенге геройлар галереясын яңа төсләргә баеталар, анда ор-яңа сыйфат үзгәрешләре тудыралар. Минемчә, бу ике яшь язучы алып килә торган сыйфат шактый дәрәҗәдә безнең киләчәк прозабызның йөзен билгеләр шикелле тоела. Болар, әлбәттә, берникадәр дәрәҗәдә күрәзәлек итү кебек, ләкин шулай да тормышта тирәнәю, чынбарлыкны эре план белән якыннан өйрәнү тенденциясенең көчәюе әнә шундый нәтиҗәне әдәбият өчен дә дөрес итәр кебек.

**Язучы.** Азат Ганиев белән Диләрә Зөбәерова, чыннан да, соңгы еллар прозасында тансыклап көтеп алынган язучылар булды. Прозага яңа көчләр бик акрын килә. Тагын шунысы да бар: әдәбиятыбызга яшьләр бары тик мәктәп стеналарыннан гына һәм туп-туры әдәбиятка гына киләләр! Офык тарлыгы, адымнарның бәләкәйлеге шигырьдә беренче елларда сиздермәсә дә (монда хисләр кайнарлыгы белән узарга да була!), прозада хис өстенә тагын тормыш материалын конкрет белү зарур нәрсә. Ә тормышны процесс хәлендә бары тик аны тәүдә катнашкан кешеләр генә күрә ала! «Сүзсез җыр» әсәренең авторы Азат Ганиев — художник кеше. Художниклар мәктәбен тәмамлаганчы «тормыш мәктәбенең» байтак классларын узган бу кеше, художник исемен алгач та, кабинетка кереп бикләнми. Ул эшли, укыта, йөри. Хәрәкәтчән кеше Азат Ганиев! Аның язмышы башка язмышлар белән кисешеп уза, аның кичерешләре күп, игелекле. Нәтиҗәдә, чор турында тирәнтен уйланулар... Ниһаять, яхшы әсәр, безне дә уйландыра ала торган әсәр. Укучыны уйландыру көченә ия була алу — язучы өчен иң мөһим сыйфатларның берсе!

Әдәбият эшен нәни-нәни пьесалар, беркадәр төчерәк, пафослырак шигырьләр язудан башлаган талантлы каләмдәшебез Диләрә Зөбәерова да тормышның төрле катлаулы юлларын узды. Район газеталарында эшләде. Заманны, аның кешеләрен тирәнтен белә. Азат Ганиевнең әсәрләре чорыбызның фәлсәфи якларына юнәлдерелгән булса, Диләрә әсәрләре укучыга эмоциональ яктан тәэсир көченә ияләр. Мин сезнең белән килешәм: бу ике автор соңгы еллар әдәбиятыбыз өчен ачыш булды. Сүз уңаеннан, мин бу иптәшләргә тагын бер-ике кешене, әйтик, талантлы яшь язучыбыз Миргазиян Юнысны да кушып сөйли алган булыр идем.

**Тәнкыйтьче.** Әйе, бик өметле яшь прозаикларыбыз бар. Ләкин, гомумән алганда, яшь прозада да әле берникадәр тормышның вак детальләре, сай күренешләре белән мавыгу, тирән һәм аналитик караш җитмәү нык сизелә. Яшьләр әсәрләрендә еш кына геройның характер үсеше әсәрнең тыгыз вакыйгалары эчендә бармый, ул көчсез, йомшак шәхес булып килеп чыга. Кыскасы, әле авторның тормышка, геройга карата үз концепциясе, үз юлы булмавы ачыклана. Монда, күрәсең, авторның шәхес буларак ныгымаганлыгы, үз-үзен тапмаганлыгы да зыян итәдер.

**Язучы.** Минемчә, бары тик чын тормыш, аның бер-берсенә мәңге охшамас кешеләре, шул кешеләрнең иҗат нәтиҗәләрендә туган катлаулы хәрәкәт кенә язучының фантазиясен туендырып, сугарып тора. Бу уңайдан мин үземнең бик яраткан язучыларымнан берсе бөек француз язучысы һәм галиме Антуан де Сент Экзюпери иҗатын телгә алып узар идем. Аның барлык әсәрләре диярлек документаль нигездә иҗат ителгәннәр. Сент Экзюпери үзе якыннан белгән кешеләргә,

тормыш юлында очраган шәхесләргә якты күңел, саф йөрәк белән карый белгән. Ул очраткан шәхесләрне башка кешеләр дә очраткан бит, башкалар да күргән. Ләкин алар берсе дә ул шәхесләрдә Экзюпери күрә алганны күрмәгәннәр, ул тоя алганны тоймаганнар. Гади кешеләрдә бөеклек сыйфатлары таба алу, аны күрә, аера белү, үзеңнең күзәтүләреңне укучы белән уртаклашу — язучының иң гүзәл сыйфатларыннан берсе шул түгелмени? Экзюпери иҗатындагы хәрби очучылар, гражданлык авиациясендә хезмәт итүче искиткеч гадел, саф күңелле батырлар, Мермозлар, Гийомелар безнең хәтерләргә Экзюпери әсәрләре аша сеңеп калмадылармыни? Әгәр язучы алар янында булмаса, без алар белән бер чакта да таныша алмас идек. Димәк, Экзепюри үз геройларын үз мохитыннан таба алган, гомере буе шуларга турылыклы булып яшәгән, иҗат иткән. Шул ук Мермозлар, Гийомелар ахыр чиктә Экзюперине Экзюпери иткән бит! Шуларның батырлыгы, кешелеклелеге язучыга якты маяк, мәңге сүнмәс җылылык булган.

**Тәнкыйтьче.** Максим Горький «тормышта һәр вакыт батырлыкка урын бар» дигән кебек, анда, минемчә, олы геройны да һәр чак табып була. Тик язучы кешенең үзенең генә шул геройны тудырырлык дәрәҗәгә күтәрелә алуы һәм аның пульсларын таба алуы гына кирәк. Мәсәлән, соңгы елларда чыккан әсәрләрдән Атилла Расихның «Каһарманнар юлы»ндагы геройлар, бигрәк тә Латиф, тормыш пульсын бирә алуы белән яшь авторларга һәм башкаларга мисал була ала. Бу образ соңгы еллар прозасының алгы сафына чыккан геройларның берсе дияр идем мин. Ул геройлар гәрчә күп булмасалар да, безнең прозага барып юлны күрсәтеп торалар кебек. һәм шул вакытта алар, алдан баручыга хас булганча, үтеләчәк юлның авырлыкларын, каршыга килеп баскан бөтен каршылыкларны беренче булып үз тормышларында кичерәләр. Ә киңрәк мәгънәдә алганда ул геройлар безнең җәмгыятебезгә «бу юлдан китсәгез, менә шулай буласыз, ә бусыннан китсәгез, менә болай буласыз» дип, үз тормышлары белән гыйбрәт күрсәтәләр кебек. Әнә шундый геройлар арасында без сезнең геройларны да күрәбез. Алар һәр вакыт заманның үткен проблемалары эчендә кайныйлар. Алар — фикер кешеләре, аларны башкалар белән бутап яки алыштырып та булмый. Шушы сөйләшү уңаенда бәлки сез үз геройларыгызның тормыштагы чыганагы, реаль чынбарлыктагы нигезе турында да әйтеп үтәрсез. Бу безнең сөйләшүне тагын да тулырак итәр.

**Язучы.** Мин үзем күргән, тормышлары, яшәешләре, кылган гамәлләре белән мине баеткан бик күп кешеләр алдында зур бурычлы әле. Мин унҗиде яшемә хәтле авылга яшәдем. Сугыш еллары һәм аннан соңгы еллар иде бу. Шул елларның истәлеге минем өчен аерата газиз һәм кадерле. «Бераү», «Дүртәү» повестьларында мин бу истәлекләрнең бер өлешен язарга тырышып та карадым. 1972 елда «Язгы кәраваннар» белән «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» исемле кечкенәрәк күләмдә ике повесть яздым. Бу минем үземнең авылдашларыма, якты шәхесләргә, Югары Баграж кешеләренә, Зәй буйларына бурычымны кайтаруым гына. Әсәрләргә геройлар тормыштагы үз исемнәре белән кермәсәләр дә, географик һәм биографик дөреслеккә ябышып ятмасам да, бу әсәрләр минем яшәешемдә яшәгән авылдашларым турында. Яшәгән саен миңа алар хезмәтенең гадилеге һәм бөеклеге, алар яшәешенең матурлыгы һәм авырлыгы ныграк күренә сыман. Моңарчы язылган әсәрләремдә берникадәр тарлык барын үзем дә сизеп йөри идем, тәнкыйтьчеләрнең дә сүзе урынлы булды, әмма мин үзем белгән, үзем яраткан кешеләр алдында бурычлы булып калмаска тырышырмын.

Хәзер дә тормыш белән бәйләнешне ычкындырмаска тырышам. Ел саен диярлек үз авылыбызга кайтам, башка төбәкләргә чыгам, йөрим. Тормыш көнләп түгел, сәгатьләп яхшыга үзгәрә. Тормыш агышыннан ычкынып, төшеп калмаска кирәк. Барыбыз да шуңа омтылабыз. Тормыштан артта калмас өчен аның хәрәкәтен генә түгел, үзгәрмәс кыйбласын да яхшы белергә кирәк. Туган илеңә, коммунизм төзүче халкыңа бирелгәнлек, туган телеңә сүнмәс мәхәббәт — менә ул язучының үзгәрмәс кыйблалары! Тормыш шартлары, яшәү күренешләре көнләп-сәгатьләп үзгәреп торса да, бу бөек төшенчәләр мәңгелек һәм шушы мәңгелеккә туры кешеләр генә үзгәрешләрне халык белән бергә сиземли алалар.

**Тәнкыйтьче.** Биредә конкретрак күз алдына китерү өчен физикадагы резонанс

күренеше әйбәт мисал. Монда да заманны тоту, аңлау өчен язучы үзенең йөрәгенең тибү ешлыгын тормыш ешлыгына көйли алырга тиеш. Шулай булганда ул йөрәкнең үзеннән чыккан җыр да заман тормышында көчәю, аның алга баручы көчләрендә яклау таба. Менә шушы фикердән чыгып караганда да сезнең кызыксынуыгыз һәм эзләнүләрегезнең туган ягыгыз белән генә чикләнмәве соңгы елларда язылган әсәрләрегездән дә күренә. Бу бик аңлашыла, чөнки туган як темасы никадәр генә якын булса да, ул бүгенге тормышның бөтен тулылыгын үзенә сыйдырып бетерә алмый. «Урамнар артында яшел болын» романы һәм «Урталыкта» повесте укучыны әнә шуңа ышандыра. Минемчә, сез үз иҗатыгызда тоткан бу сызык — заманның үткен проблемаларына игътибар киләчәктә дә дәвам итәр кебек. Тик менә нинди геройлар, кемнәр аша булыр ул?

**Язучы.** Берничә еллардан бирле мин илебездәге нефтьчеләрнең тормышы белән кызыксынып яшим. Шул максат белән ел саен ике-өч тапкыр Әлмәткә барам, озак-озак анда торам. Себердә, Оренбургта булып кайттым, һаман «нефть эзлим!» Роман язам. Ул аерым-аерым өч новелладан торачак. Әсәрнең нигезендә өч буын кешеләре: нефтьчеләр династиясе. Якындагы ике елда әсәрне тәмамларга дип торам. Шулай ук пьесалар, повестьлар, хикәяләр язачакмын. 1970 елда «Мең чакрым юл» исемле повесть язган идем, хәзер шуны акка күчереп утырам. Нури ага Арсланов повесть өчен ике шигырь язды. Шуннан аңлашылса кирәк, повесть шагыйрь турында...

**Тәнкыйтьче.** Әдәби геройларыбызны тикшерә-тикшерә, киләчәккә дә кереп киттек. Ә шулай да кире кайтып яңадан бер күз ташлыйк әле: нәрсә җитми соң безнең әдәбиятыбыздагы бүгенге геройга, ни өчен, аерым әсәрләрне укыгач, геройдан канәгатьсезлек хисе кала әле?

**Язучы.** Мин, аларга заман катлаулылыгы һәм заман ялкыны җитми, дияр идем.

**Тәнкыйтьче.** Ә мин, күрәсең, болай дияр идем: безнең геройларга бүгенге укучының акыл дәрәҗәсенә күтәрелергә һәм аңа нинди дә булса сабак бирә алырлык булу өчен, аны узып та китәргә кирәк.

# Әхмәт Фәйзи—тәнкыйтьче һәм галим

Әхмәт Фәйзи мәдәниятебез тарихына туктаусыз эзләнүчән новатор шагыйрь, талантлы драматург, үзенчәлекле прозаик һәм балалар психологиясен тирән аңлый белүче педагог буларак кереп калды. Әдип яшәгән һәм иҗат иткән еллар бездән ераклашкан саен, аның мирасының кыйммәте, сәнгатьчә көче һәм хәзерге шигъри культурабызга булган тәэсире ныграк сизелә.

Шуңа күрә әдипнең иҗат мирасын җыйнау һәм халыкка җиткерү эшенә дә елдан-ел күбрәк игътибар бирелә бара. 1964—1966 елларда Татарстан китап нәшриятында аның өч томлык «Сайланма әсәрләр»е басылып чыккан иде. 1973 елда язучының тәнкыйть мәкаләләрен, публицистик чыгышларын һәм хатларын туплаган «Әдипнең эрудициясе» исемле китап дөнья күрде[1]. З. Фәйзиева белән Н. Юзиев төзегән, Татарстан китап нәшрияты зәвык белән бастырып чыгарган бу җыентык Әхмәт Фәйзи турындагы мәгълүматыбызны тагын да баета һәм тулыландыра төшә. Дөрес, бу китапка әле Ә. Фәйзинең тәнкыйть өлкәсенә караган материалларының бер өлеше генә тупланган. Ләкин шул хәтлесе дә әдипнең исемен татар әдәбият белеме һәм тәнкыйтенең күренекле галимнәре белән янәшә куярга тулы хокук бирә. «Әдипнең эрудициясе» китабын үтелгән үрләрнең бер сәхифәсе дип кенә бәяләү дөрес булмас иде. Чөнки биредә тупланган материаллар хәзерге әдәбият әһелләрен дә күп нәрсәгә өйрәтә алалар...

Тукай, Такташ, Җәлил турында язылган публицистик мәкаләләрне, яшьрәк буын шагыйрьләр иҗатына багышланган тирән хисле чыгышларны укып карагыз. Аларның нигезендә иҗат кешесенә мәхәббәт һәм хөрмәт хисе ята. Татар совет поэзиясе классиклары турында сүз йөрткәндә, ул, барыннан да элек, революция һәм яңа чынбарлыкның алар иҗатына ясаган савыктыргыч тәэсирен, ягъни шагыйрьнең тарих һәм тирәлек, халык тормышы һәм җәмгыять үсеше белән бәйләнешен ассызымлый. «Муса Җәлил турында шуны әйтергә мөмкин,— дип яза әдип,— ул революция белән бергә туып үсте. Революция аның тормыш юлын, эшен-хезмәтен билгеләде, ихтыяр һәм характерын чыныктырды» (95 бит).

Әхмәт Фәйзи аналитик фикерле тәнкыйтьче була. Ул язучының кабатланмас иҗат йөзен, индивидуальлеген ачып салырга омтыла, мисалларның уңышлыларын һәм ышандырырлыкларын сайлап ала белә. С. Хәким, М. Кәрим, Х. Камалов, Ш. Галиевләр иҗатына багышланган мәкалә-рецензияләре нәкъ әнә шундыйлар.

Ә. Фәйзи яңа бөреләнеп килгән сәләтләргә аерата мәрхәмәтле һәм игътибарлы булган. Х. Камалов белән Ш. Галиев — хәзер поэзиябезне төпкә җигелеп тартучы, танылган шагыйрьләр. Илленче елларда исә алар берәр генә җыентык чыгарган яшь-яшь шагыйрь булалар. Ә. Фәйзи аларны каләм тибрәтүче дистәләрчә яшьләр арасыннан күреп ала, аерып куя, җылы сүзен таба, канатландыра, уйландыра.

Х. Камалов шигырьләре аңа кайсы яклары белән ошыйлар соң? «Камаловның шигырьләрендә самимилек, реалистик ти-

[1] Әхмәт Фәйзи. Әдипнең эрудициясе. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1973 ел. 335 бит.

рәнлек очраклы хәл түгел. Моның нигезендә, гади генә итеп әйткәндә, бер нәрсә ята: шагыйрь үзен яза»,— ди ул (229 бит). Шагыйрь үзен яза... Поэзиянең бу хасиятенә Ә. Фәйзи бик еш игътибар юнәлтә. Тәнкыйть мәкаләләрендә дә, әдәби әсәрләрендә дә. «...Автобиографиягә килсәк, бу инде лирикага чит нәрсә түгел, киресенчә, лириканың тууында ул төп сәбәпләрнең берсе булып тора»,— дип яза ул «Бер тәнкыйть уңае белән» дигән мәкаләсендә (172 бит). «Эзләр», «Флейталар», «Шагыйрь», «Тышта яз», «Кырык яшь» кебек шигырь-поэмаларының үзәгендә нәкъ менә шагыйрьнең үз рухы, үз кичерешләре ята, бу әсәрләрне язганда аңа шәхси биографиясе өлге булып тора. Менә шуңа да Ә. Фәйзи яшь шагыйрь Х. Камалов шигырьләрендә үз иҗатының рухына якынлык таба, үзе инанган принципларның дәвамын күреп сөенә.

Ш. Галиевнең «Яңа көйләр» җыентыгын әдип түбәндәгечә бәяли: бу әсәрләр «местәкыйль уйлый белә торган, индивидуаль йөзе булган шагыйрьнең иҗади омтылышы нәтиҗәләре. Аларда шигырь өчен иң кирәк ике элемент бар: уй һәм тойгы» (203 бит). Ә. Фәйзи яшь авторның аз сүз белән күп мәгънә бирә алу сәләтенә, сүзнең тәмен, кадерен белеп, эчке җегәренә үтеп керә алуына игътибар итә. Ләкин өлкән әдип шагыйрьнең ачыш-эзләнүләрен дәррәү хуплау белән генә чикләнми, киләчәктә Ш. Галиевнең иҗади үсешенә комачаулардай җитешсезлекләрне дә сызык өстенә ала. Ш. Галиевне ул беришә шигырьләрендә ясалма ситуацияләргә өстенлек биргәне, бертөслерәк ритмикага таянып эш итүе өчен дусларча әрли. Хәзерге поэзиябезнең үзәк фигураларының берсе булып күтәрелә килгән Ш. Галиев, мөгаен, үзенең иҗат практикасында Ә. Фәйзинең әлеге искәрмәләрен дә исәпкә алгандыр.

«Әдипнең эрудициясе» китабы Ә. Фәйзине олы җәмәгать эшлеклесе итеп тә күз алдына бастыра. Ул талантлы композиторлар, драматурглар, артистлар турында дәүләт кешесе, гуманист буларак кайгыртучанлык күрсәтә. Бу нисбәттән аның фронттан режиссер Ш. Сарымсаковка язган хаты игътибарга лаеклы. Хат талантлы артист Абдулла Сәгыйтовның вакытсыз үлеме уңае белән языла. Ә. Фәйзи иҗат кешеләрен тәрбияләү, саклау эшен кемгәдер тапшырып, үзен читтә калдырмый. Бу изге эш өчен һәр коммунист, һәр намуслы кеше җаваплы, дип саный: «Сарымсак, егет дус, нидер эшләргә кирәк. Күбрәк ялкын! Калганнарны, терекләрне сакларга кирәк. Тиешле югарылыкка менеп, хөкүмәт трибунасына җитеп! Тиешле шартлар тудырып! Үзгәчә мөмкин түгел. Сугыштан соң сафларны барлаганда бу бездән соралыр. Моның өчен без һичшиксез җавап бирергә тиеш булырбыз. Бәлки мин моннан кайталмый калырмын. Ул хәлдә бу минем васыять булып калсын» (279—280 битләр).

Җыентыкка әдипнең төрле елларда язылган мәкалә-чыгышлары тупланган. Алар буенча аның үсеш юлын күзәтеп була. Утызынчы елларда ук яшь әдип, публицистик характердагы әсәрләр язу белән бергәттән, татар совет әдәбиятының үсеш юллары, аның теоретик мәсьәләләре турында да җитди уйлана. 1933 елда язылган «Иҗат кыюлыгына — юл» мәкаләсендә әдип партиянең 1932 елгы карарын яклап чыга. Яшь тәнкыйтьчә әдәбиятны тормыш таләбеннән, илнең гомуми үсеш перспективасы югарылыгыннан чыгып өйрәнергә чакыра.

Ә. Фәйзинең тәнкыйте — хәрәкәттәге эстетика, ул туктаусыз үсештә. Илленче, алтмышынчы елларда язылган мәкаләләре киң проблемалы, тәпле фикерле, эстетик акланган булулары белән аерылып торалар. «Халык шагыйре», «Әдипнең эрудициясе» (1956), «Остальк мәктәбе» (1950), «Иҗат дуслыгы өчен» (1955) шикелле күп санлы мәкаләләре бу фикергә матур дәлил була алалар. Заманында «Литературная газета»да басылып чыккан «Әдипнең эрудициясе» мәкаләсен алыйк. Ә. Фәйзи фикеренчә, теоретик белемен туктаусыз үстерү, баету өстендә эшләмичә, бары тик шәхси интуициясенә генә таянса, язучы хәзерге укучы таләпләрен канәгатьләндерә алырлык әсәр яза алмаячак. Эрудицияне баету, дөньяга үзенең тәпле карашыны булдыру өчен бөек шәхесләрнең карашларына да төшенергә һәм сәнгатьнең чиктәш төрләрен, андагы ачышларны ныклап үзләштерергә кирәк. Чөнки «сәнгатьнең төрле төрләре бер-берсе белән аерылгысыз бәйләнгәннәр, һәм сәнгать эшлеклеләре бер-берсеннән башка яши дә, иҗат итә дә алмыйлар. Архитектор, скульптор, нәкышче, шагыйрь, композитор, график һәм романист бәрысы-бәрысы бергә иҗат итәләр» (219).

Ә. Фәйзи мәкаләләренең тагын бер сыйфатына игътибарны юнәлтәсе килә.

Ул — полемик дәртле, омтылышлы һәм принципиаль тәнкыйтьче. Бу яктан «Бер тәнкыйть уңае белән» исемле мәкалә аеруча характерлы. Татар поэзиясенең үсешен тоткарлап килгән күләгәле якларга тукталып, Х. Хәйри Ә. Фәйзинең «Флейталар», «Кара таш ник дәшми?», «Туу сулышы» кебек әсәрләрендә идеологик зәгыйфьлек, «совет чынбарлыгыннан, реаль тормыш җирлегеннән аерылган формализм таба» (Хәсән Хәйри. Әдәбият һәм тормыш. Казан. 1953. 128—129 битләр). Сүз дә юк, мисаллар уңышлы сайланмаган, алар тәнкыйтьче әйтергә теләгән фикерне расламыйлар. Ә. Фәйзинең әлеге әсәрләре — татар поэзиясенең горурлыгы. Шагыйрь үзенең җавабында тәнкыйтьченең фикерләре белән килешмәвен әйтеп, үз иҗат практикасын, шигъри принципларын, хезмәтен яклап чыга. Мәкаләнең әһәмияте ике әдип арасындагы аңлашылмаучылыкны ачыклаудан киңрәк. Ә. Фәйзи тәнкыйтьнең бурычы, эчтәлек белән форма арасындагы катлаулы мөнәсәбәт, лириканың чыганаклары турында төпле фикерләр әйтә: «...Формализм бездә никадәр начар мәгънәле сүз булса, форма шул кадәр уңай мәгънәле сүз бит ул. Тик ул безгә ничек хезмәт итә, менә эш нәрсәдә. Әгәр дә ул безнең эчтәлекне оештыручы булып, идеяне ачарга ярдәм итсә, бу яхшы форма була. Әгәр дә ул эчтәлекне ачарга комачауласа, эчтәлек белән исәпләшмәстән форма өчен форма булып калырга теләсә, бу инде зарарлы күренеш, бу формализм булып чыга» (175—176 битләр).

«Әдипнең эрудициясе» китабы тагын бер хакыйкатьне раслый. Тәнкыйтьче мәкаләсен укучысының әзерлек дәрәҗәсен күз алдында тотып язарга тиеш. Ә. Фәйзинең китабы шул ягы белән дә үрнәк була ала. Бер төркем мәкаләләрен ул киң укучы өчен мавыктыргыч, популяр телдә яза («Габдулла Тукай», «Мәхмүт Галәү», «Муса Җәлилнең батырлыгы», «Истәлекле көннәр» һ. б.). Икенчеләрендә Ә. Фәйзи әдәбият-сәнгатькә караган практик мәсьәләләрне күтәрә, замандаш әдипләренең бигрәк тә яшь шагыйрьләрнең, тәүге китапларына рецензияләр яза («Татарча энциклопедик сүзлек кирәк», «Музыканы — көн тәртибенә!», «Уй һәм тойгы», «Шагыйрь биографиясендә — халык биографиясе» һ. б.). Өченчеләрендә фәнни анализ, теоретик юнәлеш өстенлек ала. Әдип совет әдәбияты үсешенең принципиаль мәсьәләләрен калку итеп куя. Үзәктә — социалистик реализмны пропагандалау, әдәби осталык, тәрҗемәгә һәм үз эшенә, профессиягә намус белән карау, тәнкыйтьне яңа югарылыкка күтәрү мәсьәләләре тора («Иҗат кыюлыгына — юл», «Бер тәнкыйть уңае белән», «Такташ — рус телендә», «Осталык мәктәбе», «Әдипнең эрудициясе» һ. б.).

Шул кадәресен дә искәртеп китәсе килә: китапның композициясе дөрес уйланылган. Бүлекләр тематика һәм жанр таләпләреннән чыгып төзелгән. Ә бүлек эчендә хронологик принцип үзәккә алынган. Җентекләп, тәфсилле бирелгән аңлатмалар, комментарийлар белән берлектә, бу принцип язучының эволюциясен, үсеш этапларын күз алдына бастырырга ярдәм итә. «Әдипнең эрудициясе» китабы партиянең әдәби тәнкыйтьнең ролен үстерү турындагы тарихи карары белән бер чорда дөньяга чыгуы белән дә шатлыклы күренеш. Элекке мирасны барлау, культура тарихыбызның мәгълүм казанышларын өйрәнү, аларга таяну — хәзерге тәнкыйть үсешенең, осталыкны һәм фәлсәфи тирәнлекне үстерүнең мөһим бер шарты. Бу мәсьәләгә без әле тиешле әһәмият бирмибез, димәк ки, үзебезнең бай әдәби, киңрәк алганда культура мирасыбызга хуҗа булып, аны тиешенчә бәяли белмибез. Публицистика, әдәби тәнкыйть, хатларны бастырып чыгару киләчәктә дә дәвам итсен иде. Икенчедән, менә бу төр җыентыкларны, тагы бер илек аша уздырып, русча чыгару практикасын да гамәлгә кертәсе иде.

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН,**
**филология фәннәре кандидаты.**

# Романтик омтылышмы, аек акылмы?

Яңа теманы үзләштерүнең классик схемасы шундый: башта «җиңел кавалерия» һөҗүмгә ташлана — очерклар, мәкаләләр, репортажлар языла. Аннан — хикәяләр, поэмалар, күпмедер вакыттан соң повестьлар барлыкка килә. Һәм бары шуннан соң гына «авыр артиллерия» эшкә керешә — романнар күренә башлый. Бездә исә киресенчә булды. КамАЗ турындагы беренче очерклар һәм шигырьләр белән бер үк вакытта Ә. Баяновның «Ут һәм Су»[1] романы басылып чыкты. Аннан соң Б. Камалов һәм М. Хәбибуллиннарның повестьлары басылды. Ә КамАЗ турындагы хикәянең әлегә хәтле күренгәне юк.

Сүз дә юк, Ә. Баянов КамАЗ темасына алынып бераз ашыккан. Ашыгуның эзләре романның үзендә дә сизелә. Әсәр артык озынга сузылган, икенче дәрәҗәдәге сюжет линияләре исәбенә артык калынайган, анда автор күтәргән төп проблемага бәйләнеше булмаган эпизодлар күп. Романга стиль берлеге җитми. Аллегорик манерда язылган бүлекләр публицистик пассажлар белән чуарлаша, таза, нык реализм җирдән сөйрәлә торган натурализм белән килешеп яши. Әсәрне укыганда әледән-әле шул нәрсәләргә сөрлегәсең, күңелдә ризасызлык хисе көчәя. Әмма анда әсәрне ахырга кадәр укып чыгарга мәҗбүр итәрлек ниндидер тылсымлы көч тә бар. Әсәрне укып чыгып, соңгы битен ябып куйгач, кабат автор тасвирлаган күренешләргә әйләнеп кайтасың, аларны үзеңнең шәхси күзәтүләрең белән чагыштырып карыйсың, кайдадыр автор белән килешәсең, ниндидер урыннарда автор белән эчтән генә бәхәсне дәвам иттерәсең.

Авторның укучыга әйтер яңа сүзе бар. Күрәсең, хикмәт шунда булса кирәк. Ул табигатьне саклау кебек мәңгелек мәсьәлә белән дә баш вата (чөнки КамАЗ илебезнең моңарчы кеше кулы тимәгән иң матур урыннарының берсендә корыла), аны кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең катлаулылыгы, КамАЗ төзүчеләрнең тормышкөнкүреше һәм башка күп мәсьәләләр дә борчый.

Тагын анда бөтен әсәр буенча кызыл җеп булып сузылып барган бер үзәк проблема бар. Минем нәкъ аңа шулысына киңрәк тукталасым килә. Чөнки ул — тормыш үзе көн тәртибенә куйган мәсьәлә, һәм аның әһәмияте әлеге төзелеш кысалары белән генә чикләнми төсле.

Романның эчке конфликтын һәм драматик киеренкелеген капма-каршы ике характер, тормышка, дөньяга ике төрле караш билгели. Әсәрнең үзәк геройлары Фәез Насыйбуллин белән Борис Филинов арасында уртак яклар да шактый. Икесе дә төзелеш институтын тәмамлаган дипломлы инженерлар, чагыштырмача яшь булуларына карамастан, икесе дә шактый зур тәҗрибә туплап өлгергән төзүчеләр. КамАЗга хәтле Фәез илебездәге күп кенә төзелешләрдә эшләгән, Борис исә хәтта чит илләрдә үк эшләп кайткан. Әмма әсәрдәге вакыйгалар үскән саен аларны бер-берсеннән аера, ерагайта торган, ут белән су кебек, бер-берсенә капма-каршы куя торган сыйфатлар алгы планга чыга.

Баш инженер, бераз соңрак зур бер төзелеш участогының начальнигы Фәез Насыйбуллин, Борис ярым шаярып, ярым җитди төстә әйткәнчә, энтузиаст, «герой». Таңнан алып кичкә хәтле ул төзелеш буйлап чаба, прораблар белән талаша, дефицит материаллар таба, кичләрен игечиге булмаган киңәшмәләрдә, төрле утырышларда уздыра. Ул тәҗрибәле, белемле, теоретик һәм практик яктан нык әзерлекле инженер. Дөрес, һавадан йолдыз чүпләми, әмма алынган эшне вакытында

[1] Ә. Баянов. Ут һәм Су. Роман. Татарстан китап нәшрияты. 1973 ел.

башкарып чыгу өчен көчен дә, вакытын да кызганмый. Артык зурга үрелми, шул ук вакытта мактауга һәм данга да битараф түгел. Төзелеш җитәкчеләре аны һаман күтәрә торалар, Фәез моңа һич тә каршылык күрсәтми.

Участок начальнигы Борис Филинов исә гудок буенча, фәлән сәгатьтән фәлән сәгатькә эшләргә гадәтләнгән кеше. Сменасы бетүгә ул демонстратив тәстә үз «Волга»сына утыра да өенә китеп бара (хәтта участогына зур начальниклар килгән булса да). Иртәгә хәтле сау булып торыгыз, янәсе. Аны үгетлиләр, тиргиләр, шулай да аңарга таяналар. Чөнки ул талантлы инженер, Фәез әйтмешли, гади кешеләргә пар түгел. Әйтик, Борис Филинов участогына су үткәргеч магистраль сузу эше тапшырыла. Икенче берәү булса, тизрәк эшкә тотынып, аны ничек итеп булса да билгеләнгән срокка үтәп чыгу өчен тыршышыр иде. Ә Борис башта ныклап өйрәнә, тегеләй уйлап карый, болай уйлап карый һәм баштагы проектны үзгәртергә кирәк дигән фикергә килә. Аның бу тәкъдиме магистральнең озынлыгын шактый кыскартырга ярдәм итә. Нәтиҗәдә бик тә дефицит саналган күпме трубага экономия ясала, нихәтле дәүләт акчасы янга кала. Яки башка бер мисалны алыйк. Моңарчы төзелешкә кирәкле комны һәм балчыкны уннарча километр ераклыктан ташыганнар. Машина җиткерә алмый интеккәннәр, шуның аркасында төзелештәге күпме кеше эшсез утырган. Борис төзелешнең үзе янында гына карьер өчен яңа урын таба. Ләкин үзенең бу ачышын берәүгә дә әйтми. Моның өчен аңа башта тиешлесен түләсеннәр, ул аны шул чагында гына әйтәчәк...

Элекке дуслар шәхси тормышларында да бер-берсеннән нык аерылалар. Фәез романтик табигатьле кеше, ул үз идеалын, хыялындагы кызны эзли. Дөресен әйткәндә, аның шәхси тормышы өчен вакыты да калмый. Борис хатын аерган кеше, хәзер үзе теләгәнчә яши: машинасында чибәр кызлар йөртә, мәҗлесләр оештыра, кыскасы, үзен берни белән дә чикләп яшәми.

Шул рәвешчә, романда югары романтик омтылыш белән исәп-хисапка корылган аек акыл бәрелешә. Авторның симпатиясе ачыктан-ачык романтик табигатьле Фәез ягында. Төзелеш, Фәез кебек, вакыт белән дә, кыенлыклар белән дә санашмый торган энтузиастлар җилкәсендә бара. КамАЗ кебек зур төзелеш әле башланып кына килгән чагында бу аңлашыла торган хәл. Монда әле күп нәрсә ачыкланып җитмәгән, күп урыннарда хуҗасызлык хөкем сөрә, иң кирәкле нәрсәләргә хәтле җитешми. Әйтик, Борис Филинов участогына бетонны графикта күрсәтелгәнчә, иртәнге сигездә түгел, кичке алтыда гына китерәләр. Бу вакытта, билгеле инде, Филинов кайтып киткән була. Вибраторлар эшләми. Бетонны ничек эләкте шулай салалар, шуның аркасында буш урыннар кала. Нәтиҗәдә җитди брак килеп чыга. Бу хәлне күреп Фәез нишләргә белми, Борис исә үзен бик тыныч тота. Чөнки үзен гаепле санамый. Гомумән, Борис инженерларны толкач, йомышчы малай ролендә йөртүгә принципиаль рәвештә каршы. Әгәр иң югары инстанцияләрдә расланган график бар икән, дип фикер йөртә Филинов, ул һичшиксез үтәлергә тиеш. Бер яктан, ул, әлбәттә, хаклы. Әмма тормышта кайвакыт башкачарак та килеп чыга бит. Төзелеш материаллары җитешми, график әледән-әле өзелеп килә. Мондый төртипләр хөкем сөргәндә, Борис кебек инженерлар түгел, ә кем өлгер, кем остарак, кем үз-үзен аямый чаба — шулар алга чыга. Борис җитәкчелек иткән участок башкаларга караганда начаррак тәэмин ителә, план даими тәстә үтәлеп җитми, эшчеләр азрак хезмәт хакы ала, нәтиҗәдә алар башка участокларга китә башлыйлар. Борисны түбәнрәк эшкә күчерәләр, ахыр килеп, ул төзелешне бөтенләй ташлап китәргә мәҗбүр була. Миңа калса, язучы үз әсәрендә ифрат тормышчан һәм үткен конфликтны тотып алган, тик шуны ахырга кадәр эзлекле тәстә хәл итеп кенә чыга алмаган. Роман буенча фикер йөрткәндә, бөтен эш Фәез белән Борисның шәхси сыйфатларына кайтып кала. Минемчә, мәсьәләне киңрәк планда алырга кирәк иде.

Автор искиткеч кызыклы социаль-психологик процессны тотып алган. Безнең көннәрдә техника үзе генә үзгәреп калмый, хезмәтне оештыру да, кешеләрнең хезмәткә булган мөнәсәбәте дә үзгәрә икән. Идарә итүнең элекке методларына алмашка тагын да аеграк расчет һәм эшне сигез сәгать вакыт эчендә дә уникә сәгатькә караганда күбрәк итеп башкарырлык итеп оештыра белү килә шикелле. Укучыларда, мәсәлән, Фәез Насыйбуллин симпатия гына уятып калмый, аны күпмедер дәрәҗәдә кызгана да башлыйсың. Аның китап укырга да, тагын да җитдирәк,

зуррак мәсьәләләр хакында уйланырга да, шәхси тормышын рәткә салырга да вакыты калмый. Автор күпме генә ышандырырга тырышмасын, мин аннан зур масштаблы чын житәкче чыгачагына ышанмыйм: гадәткә кергән тәртипләр белән ул артык килешеп яши, булган кадәресеннән артык канәгать күренә. Ә Борис, никадәр генә бармагы үзенә кәкре булмасын, күпме генә башка кимчелекләре булмасын, болай эшләргә ярамый ди, башкача эшләргә кирәклеген раслап тора. Шуңа күрә дә аннан тизрәк котылырга тырышалар. Асылда аннан бик аз нәрсә сорала: «Кыланып йөрмә, башкалар кебек эшлә», янәсе. Аны капиталистик эш алымнарын куллануда гаепилиләр. Ләкин бит Филинов чит илдә дә совет инженерлары белән бергә эшләгән. Һәм шул коллектив тәртипне шундый итеп оештыра алган ки, билгеләнгән сәгатьләрдә генә эшләп, штурмсыз-нисез дә алар мактапган чит ил фирмаларын әллә кайда артта калдырганнар. Нигә менә мондагы зур төзелештә дә эшне шулай оештырып булмый икән, дип аптырый ул.

Мин Фәез кебек үз-үзләрен аямаучы кешеләрнең героизмына аз гына да күләгә төшерергә җыенмыйм. Ләкин хикмәт шунда, еш кына әлеге героизм үзе кемдер эшенә җавапсыз караган өчен, кемдер эшне оештыра белмәгән өчен кирәк була, өстәвенә, әле моның өчен теге бәндә бернинди җавап та бирми. «Сез мине аномалиягә саныйсыз,— ди Борис дусты Фәезгә.— Әмма хезмәтне фәнни яктан дөрес оештырганда мин норма саналыр идем. Эшне оештырудагы, планлаштыру һәм тәэминат өлкәсендәге җитешсезлекләрне сменадан тыш эшләүләр, акыру-бакыру, гадәттән тыш киеренкелек һәм утырышлар ыгызыгысы белән капларга тырышучылар аномалия саналыр иде». Болай ышандыра кебек. Ләкин шул ук сүзләрдә Борисның көчсезлеге дә чагыла. Аның сүзләренең мәгънәсе шуңа кайтып кала: миңа бөтен шартларны тудырыгыз, шунда мин сезгә эшләп күрсәтермен. Ләкин ул шартларны кем тудырырга тиеш икән? Төзелештә хәзергә иң авыр чор, зур эш башланып кына килгән чор. Күрәсең, мәсьәлә шактый четерекле һәм катлаулы икән.

КамАЗда һәм Түбән Кама ГЭСы төзелешендә мин күп кенә инженерлар, мастерлар һәм гади эшчеләр белән очрашып сөйләштем һәм шуңа ышандым: анда хәзер җитәкчелек итүнең яңа стиле туып килә. Кыскача гына аны: энтузиазм плюс расчет дип билгеләргә булыр иде. Дөресрәге, башта расчет, аннан соң энтузиазм. Монда миңа шундый бер мәзәк ишетергә туры килде. (Үзенең очеркында аны язучы А. Злобин да китерә.)

Шулай бер вакыт төзелешкә АСУС дигән машина сатып алалар, гади телгә әйләндерсәң, төзелеш белән автоматик төстә идарә итү системасы була бу. Әлеге ифрат акыллы һәм ифрат кыйммәт машинага бөтен мәгълүматларны салалар: кайда нәрсә төзелә, нәрсә җитми, кая нәрсә ташыла һәм машинадан күрсәтмәләр көтә башлыйлар. Ә машина уфылдый, бөтен лампочкалары белән җемелди, әмма һич кенә дә бер нәрсәне аңлый алмый: ничек инде югары сыйфатлы бетонны юл читенә аударалар, ә йорт төзергә дигән дефицит панельләр белән юл түшиләр? Төзелә генә башланган йорт нигә төгәлләнгән объектлар рәтенә кергән дә, бөтен нормалар буенча тиешле материаллар алган объект аларны нигә тагын сорый? Шундый характердагы мәгълүматлар күбрәк кергән саен, машина ешрак җемелди, күбрәк кызара һәм ахыр килеп бөтенләй янып чыга. Нишләргә? Мәскәүгә, әлеге машинаны уйлап чыгарган академикның үзенә телеграмма сугалар. Килеп җитә бу, озак кына машинасында казына һәм әйтә:

— Машина сездә эшләмәячәк.

— Нигә алай?

— Чөнки тәртипсезлек белән идарә итеп булмый,— ди академик һәм Мәскәүгә кайтып китә.

Бу, әлбәттә, гадәти төзелеш анекдоты. Ләкин ул шул ягы белән игътибарга лаек: хезмәтне фәнни оештыруның кирәклеген хәзер һәр кеше аңлый. Техника үсеше котылгысыз төстә хезмәт культурасы турындагы, шулай ук эшченең үз культурасы турындагы мәсьәләне дә киң тәртибенә куя. Чөнки техник прогресс тегеләйме-болаймы кеше аша, аның социаль-психологик мөнәсәбәтләре аша чагыла.

Менә шуңа күрә дә Ә. Баянов романының, шактый кимчелекләре булуга да карамастан, битараф төстә укый алмыйсың. Әсәр бүгенге тормышның мөһим мәсьәләләрен күтәрә, күп нәрсәләр турында уйландыра. Шул рәвешчә, «Ут һәм Су» романының әһәмияте бер төзелеш картинасын тасвирлау белән генә чикләнми. Ул зур һәм җитди мәсьәләләрне кыю рәвештә күтәрүе белән укучылар күңелен җәлеп итә.

**Рафаэль МОСТАФИН.**

# Бөек гуманист шагыйрь

**Нәсиминең тууына — 600 ел**

Шушы көздә күп милләтле илебез халыклары, барлык прогрессив кешелек дөньясы белән берлектә, бөек Әзербәйҗан шагыйре, философ, Якын Көнчыгыш поэзиясе классигы Имадетдин Нәсиминең тууына 600 ел тулу тантанасын билгеләп үтәләр.

Нәсими — XIV йөз ахыры, XV йөз башларында алдынгы гуманистик идеяләрне алга сөрүчеләрнең берсе. Ул Көнчыгыш халыклары арасында хөр фикерле, югары культуралы, көчле рухлы булуы белән шөһрәт казанган.

Нәсими әсәрләренең күбесе аның үз туган телендә язылганнар. Ләкин аның фарсы һәм гарәп телендә язылган шигырьләре дә байтак.

Көнчыгыш поэзиясенең бөтен нечкәлекләренә төшенеп, бөтен катлаулы формаларын үзләштереп иҗат иткән Нәсими поэзиясенең төп үзенчәлеге — тематик яктан гаҗәеп киң диапазонлы булуында, тирән мәгънәле фәлсәфи шигырьләрнең мәхәббәт лирикасы белән тыгыз үрелеп баруында.

Имадетдин Нәсими 1370 елда борынгы Әзербәйҗан каласы Шемахта туа. Озак еллар Әзербәйҗанда яшәп дин белеме ала. Соңрак фәнни китаплар укый башлый. Ул математиканы, астрономияне, философияне, табигать белемен тирәнтен өйрәнә. Аның әзербәйҗан, фарсы, гарәп телләрендә язылган шигырь җыентыклары (диваннары) безнең көннәргә кадәр килеп җиткән.

Шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты Аксак Тимер эпохасы, ягъни әзербәйҗан халкының азатлык өчен көрәш еллары белән бәйләнгән. Нәкъ менә шушы чорда Әзербәйҗанда ислам догмасына һәм Тимеридләр хакимлегенә каршы сектантлар хәрәкәте (хуруфизм) җәелеп китә. Бу хәрәкәтнең башында торган талантлы әзербәйҗан язучысы Фәзлуллах Наими күпләргә мәгълүм. Аның тәгълиматы, күпмедер дәрәҗәдә чикләнгән булуына карамастан, халык дошманнарына каршы көрәштә сизелерлек роль уйный. Бу хәрәкәткә катнашучыларны илбасарлар рәхимсез эзәрлеклиләр. Фәзлуллах Наими 1402 елда Тамерлан малае Мираншах боерыгы буенча үтерелә.

Нәсими Шемахта яшәгән чакта ук инде Наими белән таныш була. Аның дөньяга карашы да Наими тәгълиматы тәэсирендә формалаша. Фәзлуллах үтерелгәннән соң Нәсими, остазының кыю фикерләрен киң катлау халыкка җиткерү нияте белән, Якын Көнчыгышка сәяхәт ясый. Төркиядә була, Сүриягә килә һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр Алеппо шәһәрендә яши. Шагыйрьнең ирек өчен, хаклык өчен көрәшкә өндәүче, кайнар дәрт белән сугарылган шигырьләре җәмгыятьнең барлык катлаулары арасында киң яклау таба. Хакимлек итүче даирәләр арасында исә Нәсими динсез һәм фетнәче дип игълан ителә. 1417 елны, динчеләрнең гаепләүләре нигезендә, Нәсимине кулга алалар һәм җәзалап үтерәләр. Шагыйрьнең нәселдәшләрен Алеппода әле бүген дә очратырга мөмкин. Алар Нәсиминең төрбәсен күз карасы кебек саклыйлар.

Борынгы гарәп чыганаклары Нәсиминең фаҗигале үleme хакында шактый ук тулы мәгълүмат бирә. Ничектер бер көнне Алеппо урамында бунтарь шигырьләр укып

торучы егет, Нәсиминең бер шәкерте тотыла. Кара фикерле мөселман руханилары егеттән әлеге шигырьләрнең авторын сорыйлар. Ләкин егет Нәсими исемен атаудан катгый рәвештә баш тарта, шигырьләрне үзем яздым, ди. Дини фанатиклар егетне үлем җәзасына хөкем итәләр. Тик хөкем алдыннан мәйданда Нәсиминең: «Җибәрегез аны, ул шигырьләрне мин яздым!» — дигән горур тавышы яңгырый. Җәлладлар егетне азат итәләр һәм, руханилар фәрманы буенча, Нәсимине тереләй тиресен тунап үтерәләр. Риваятьләр сөйләвенә карагында, хөкем вакытында зәһидлардан (изгеләрдән) берәү болай ди: «Әгәр дә Нәсими каны кемгә булса да чәчрәсә, тәнегезнең шул өлешен кисеп ташларга туры килә. Чөнки ул кан — динсез каны. Бөтенләй очраклы рәвештә Нәсими каны әлеге зәһидның үз бармагына чәчри. Тегенең йөзе көл кебек агара. «Изге» әле генә әйткән сүзләреннән ваз кичәргә тырыша. Шул чагында канга баткан Нәсими хәлсез тавыш белән:

Кисә башла син зәһидның бер бармагын гына, бар,
Хакыйкатьтән ваз кичәр ул, рәхим вә шәфкать сорар.
Бак, зәһидлар тере килеш туный минем тиремне,
Тик мин гашыйк — җәза, үлем куркытмый һич тә мине,—

дип, «изге» руханиларның икейөзлелеген фаш итә.

Озакламый Нәсиминең фаҗигале үлеме батырлык җыры булып әзербәйҗан һәм бөтен Якын Көнчыгыш шагыйрьләре, ашуглары тарафыннан җырлана башлый. Нәсими исеме исә тугрылык һәм ныклык символына әверелә.

Нәсиминең шигъри мирасы искиткеч бай. Аның шигырьләре укучыны бигрәк тә фәлсәфи тирәнлеге, чын йөрәктән язылуы, акыл һәм матурлык тантанасына чакыруы белән җәлеп итә. Нәсими шигырьләрендә матурлык идеалы кешене олылау, аның куәтенә ышану кебек гуманистик концепцияләр белән бер бөтен булып сентизлашып бара. Нәсими карашынча, мәхәббәт — рухи җиңү. «Гашыйк,— ди Нәсими,— кешенең чиксез куәтен, көчен раслап, эшафот күперчегеннән «мин — алла» дип кычкыручы Мансур[1] кебек, теләсә нинди газапларга да түзәргә, һәм, әгәр дә кирәк икән, сөюе хакына үз-үзен корбан итәргә тиеш».

Саф мәхәббәтлеләр генә мәхәббәт серен аңлый,
Мәхәббәттән мәхрүм мәхлук моны ничек аңласын?
Җәлладлар килгәч каршыңа, мин үзем — алла, диген,
Мәңгелек тормыш хакына җир җәзасын ал, Мансур.

Бу шигыре белән Нәсими гашыйкларга һәм мәхәббәте хакына үлемгә барырга әзер торучыларга эндәшә.

Сектантлар идеологиясен пропагандалап, матурлыкны бөтен җаның-тәнең белән аңласаң гына кешелек идеалларына турылыклы була аласың, дип фикер йөртүче Нәсими, сөйгәнен «җәннәт бакчасы» белән чагыштыра һәм кыямәт көнендә алла хозурына бару турындагы дини абстракт мифнең нигезен җимерә.

Җәннәт вәгъдә итте дәрвиш барча багылары белән,
Җәннәт бакчасын таптым мин тик синең күзләреңнән.

Нәсими идеяләре, әлбәттә, сектантлар идеологиясе рамкаларына гына сыймый. Ул күп кенә шигырьләрендә җир тормышын, гади җир кешесенең уй-фикерен, омтылышларын сурәтли, еш кына табигать күренешләренең реаль мохит, кеше хисләре белән гармоник бәйләнешен чагылдырырга тырыша.

Нәсиминең кеше белән алланы тәңгәлләштерү рухында язылган әсәрләре ислам догмасын тамырыннан какшата. Нәсими карашынча, бөтен дөньяның, бөтен галәмнең хикмәте — кешедә, фәкать кеше акылында.

---

[1] Мансур — динчеләр тарафыннан җәзалап үтерелгән күренекле пантеист (858—922).

Ике дөнья сыйган миңа, мин сыймыйм
берсенә дә,
Мин — чынбарлык — чынбарлыкта
урынсыз-җирсез бәндә.

Нәсиминең көчле хәр тавышы кешеләрне наданлык доньясыннан яктылыкка чакыра. Урта гасыр караңгылыгында яңгыраган бу авазны шагыйрьнең бик күп замандашлары шатланып тыңлаганнар.

Хакыйкатьне яклаганы өчен шагыйрь бөтен гомере буе коточкыч әзәрлекләүләргә дучар ителсә дә, Нәсими үз фикерендә, үз карашында нык торган, гомере буе корычтай нык ихтыярлы, кыю, саф күңелле һәм итагатьле кеше булып калган.

Нәсими иҗаты әзербайҗан поэзиясенең үсешенә искиткеч зур йогынты ясый. Аның шигырь диваннары бүген көнбатыш һәм көнчыгыш илләренең мәдәният үзәкләрендә саклана һәм җентекләп өйрәнелә.

Үз вакытында Нәсими Төркиядә, Сүриядә, Урта Азиядә, Әрмәнстанда шөһрәт казана. Соңрак аның әсәрләре бөтен Иранга билгеле була.

Нәсиминең фидакарь тормышы һәм иҗаты — шагыйрьнең халык белән бер җан, бер тән булып яшәү үрнәге ул. Йөрәк ялкынын һәм гомерен Нәсими кешеләргә бирә, гомере буе кешелек һәм шагыйрьлек миссиясенә тугрылыклы булып яши.

Нәсими юбилеен бәйрәм итү шагыйрь яшәгән һәм иҗат иткән чорның тулы картинасын күз алдына китерергә, Нәсими иҗатының матурлыгын, байлыгын тагын да киңрәк аңларга ярдәм итә.

Нәсими шигырьләре СССРда яшәүче бик күп тугандаш халыклар теленә һәм шулай ук чит телләргә тәрҗемә ителгән.

Бөек гуманист шагыйрь Нәсиминең 600 еллыгы — шигърият һәм дуслык бәйрәме, азатлык һәм тынычлык өчен көрәшүче миллионнарча кешеләргә кадерле бәйрәм.

Заид АКПЕРОВ,
филология фәннәре кандидаты.
БАКУ.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## САЛКЫН ЯКЛАР ҖЫЛЫСЫ

Укучылар хәтерлидер, инде өченче ел рәттән илебезнең Төмән өлкәсендә совет әдәбияты атналыклары уздырылып килә.

Быелгы иҗат бәйрәме аеруча истәлекле һәм киң колачлы булды. Өлкәнең нефтьчеләре, газ чыгаручылары, игенчеләре һәм урман кисүчеләре белән очрашуларда Мәскәүдән, союздаш һәм автономияле республикалардан килгән 70 тән артык әдип катнашты. Бирегә шулай ук Болгария, Польша, Венгрия, Румыния һәм Югославиядән күп кенә язучылар килгән иде.

Совет һәм чит ил язучылары, Төмән өлкәсенең төрле почмакларында булып, 120 әдәби кичә уздырдылар. Аларның чыгышын 50 меңнән артык укучы тыңлады.

Себер якларында уздырылган әдәбият атналыгында Татарстан язучыларыннан Зәки Нури, Мөхәммәт Садри, Галимҗан Латыйп, Ләбибә Ихсанова, Хәсән Сарьян һәм Шамил Рәкыйповлар катнашты.

## ЯЗУЧЫЛАР ВОЛГА АВТОМОБИЛЬ ЗАВОДЫНДА

8—12 августларда Куйбышев өлкәсенең Тольятти шәһәрендә РСФСР язучылар союзы секретариатының күчмә утырышы булды. Секретариат утырышына катнашу өчен Тольятти шәһәренә РСФСР язучылар союзы идарәсенең секретарьлары, әшче темасына язучы күренекле әдипләр килде. Алар арасында РСФСР язучылар союзы идарәсе секретаре, М. Горький премиясе лауреаты, шагыйрь С. Хәким белән «Казан утлары» журналының баш редакторы Г. Ахунов та бар иде.

Берничә көн буена язучылар шәһәрнең эре промышленность предприятиеләрендә булдылар, Волга автомобиль заводы белән таныштылар.

10 августта Тольятти шәһәренең культура сараенда әдәбиятта эшче образы дигән темага зур сөйләшү булды. Утырышны, кыскача кереш сүз сөйләп, РСФСР язучылар союзы идарәсе секретаре Ю. Бондарев ачты. Фикер алышуларда Ф. Кузнецов, А. Кешоков, И. Ростовцева, Г. Ахунов, В. Чивилихин, В. Панков һәм башка әдипләр катнашты. Ахырдан язучылар шәһәр хезмәт ияләренең ял йортларында булдылар, аларның тормышлары, ничек ял итүләре белән таныштылар, аларга үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Кама тамагы районында уздырылган әдәби-музыкаль кичәләрдә татар шагыйрьләреннән Г. Латыйп, Р. Гәрәй, Ә. Рәшитов, Татарстанның атказанган артисты С. Йосыпов һәм Татарстан язучылар союзы каршындагы матур әдәбиятны пропагандалау бюросы хезмәткәре М. Шиһапов катнашты.

* * *

Яшь татар шагыйрьләре Т. Камалиев, З. Маликов, М. Әгъләмов, пропаганда бюросының председателе М. Шәймөхәммәтов һәм Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артисты Х. Җәләлов республикабызның Тәтеш районында йөреп кайттылар. Алар, районның күп кенә авылларында булып, колхозчылар, укучылар белән очраштылар.

## ТИХОН ЖУРАВЛЕВКА — 60 ЯШЬ

«Комбат», «Комбайнчылар», «Курган», «Рядовой Антипов» кебек популяр әсәрләр авторы Тихон Кононович Журавлевка 60 яшь тулды.

Язучының иҗат бәйрәмен республикабыз хезмәт ияләре зурлап билгеләп уздылар. Газеталарда аның иҗатына багышланган мәкаләләр басылды. Казан радиосы һәм телевидениесе язучының тормыш һәм иҗат юлы турында тапшырулар оештырды.

## КамАЗга БАГЫШЛАП

Пермь шәһәренең сәнгать галереясында союздаш һәм автономияле республикалар художникларының КамАЗ төзелешенә багышланган әсәрләреннән төзелгән күргәзмә ачылды. Анда Мәскәү, Рига, Казан, Ереван, Фрунзе һәм башка шәһәрләрдә яшәүче художникларның 150 ләп яңа әсәре куелган. Ул әсәрләр бөтен халык төзелешендә барган киеренке хезмәт сәхифәләрен чагылдыралар.

## СӘНГАТЬ — ХАЛЫККА

20 августа Казан елга портыннан «Грузия» теплоходы 230 лап сәнгать остасын Идел һәм Кама елгалары буйлап сәяхәткә алып чыгып китте. Артистлар республикабызның унлап шәһәрендә һәм район үзәкләрендә концертлар бирделәр, хезмәт ияләре белән, ярышучы коллективлар белән очраштылар.

Музыка бәйрәмендә Татарстанның иң күренекле сәнгать осталары катнашты. СССРның халык артисты Н. Рахлин житәкчелегендәге ТАССРның дәүләт симфоник оркестры, Татарстан АССРның җыр һәм бию ансамбле кебек коллективларны республикабызның һәр почмагында яхшы беләләр. Хезмәт ияләре арасында шулай ук РСФСРның халык артисткасы В. Шәрипова, Татарстанның халык артистлары И. Шакиров һәм Ә. Афзалова, Татарстанның халык артисты, композитор З. Хәбибуллин, Татарстан АССРның атказанган артистлары Г. Рәхимкулов, Э. Җәләлетдинов, эстрада артистларының бөтен Союз конкурсы дипломанты З. Нурмөхәммәтов, җыр һәм бию ансамбле солисты Т. Якупов, җырчы Ф. Сөләймановалар чыгыш ясады.

Татарстан артистларыннан тыш, концерт-фестивальдә Мәскәү шәһәренең күп кенә күренекле сәнгать осталары катнашты. Алар арасында СССРның халык артисты П. Лисициан, РСФСРның халык артистлары И. Переверзев, С. Мартинсон, РСФСРның атказанган артистлары Н. Фатеева, Н. Чередниченко кебек популяр артистлар бар иде.

## СӘНГАТЬ ОСТАЛАРЫ ЛЕНИНГРАДТА

РСФСРның халык артисты В. Шәрипова, РСФСРның халык артисты, Г. Тукай премиясе лауреаты Р. Садыйков, ТАССРның халык артисты, Г. Тукай премиясе лауреаты И. Шакиров, ТАССРның атказанган артисты, Г. Тукай премиясе лауреаты А. Арсланов, Татарстанның атказанган артистлары Ф. Абдуллина һәм Э. Җәләлетдинов составындагы сәнгать осталары бригадасы Ленинградта булып, шәһәрнең күп санлы хезмәт ияләре белән очраштылар, тамашачыларны татар композиторларының җырлары, опера арияләре, балетлардан өзекләр, биюләр, татар язучыларының әсәрләре белән таныштырдылар. Аларның концертларына Ленинград тамашачылары һәм җәмәгатьчелек зур бәя бирде.

## КОМПОЗИТОРНЫҢ ИҖАТ КОНЦЕРТЫ

Саба районы культура йортында СССРның халык артисты, өч тапкыр Дәүләт премиясе лауреаты композитор Нәҗип Җиһанов иҗатына багышланган концерт булды. Концертта СССРның халык артисты профессор Натан Рахлин житәкчелегендәге Татарстан дәүләт симфоник оркестры композиторның «Сабан туе» симфониясен, «Кырлай» симфоник поэмасын, «Нәфисә» увертюрасын һәм башка әсәрләрен башкарды. РСФСРның халык артисткасы З. Хисмәтуллина, Татарстанның халык артисты И. Шибүләков, яшь башкаручыларның бөтен Россия конкурсы лауреаты В. Гыйззәтуллина тамашачыларны «Алтынчәч», «Илдар», «Җәлил» операларыннан арияләр, дуэтлар, җыры күренешләр белән таныштырдылар. Концертны музыка белгече Зәйнәп Хәйруллина алып барды.

## КОМПОЗИТОР ИСТӘЛЕГЕНӘ БАГЫШЛАП


16 майда Казан авыл хуҗалыгы институтының икенче фермадагы актлар залында студентлар РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Тукай премиясе лауреаты, Татарстанның халык артисты композитор Җәүдәт Фәйзи истәлегенә багышланган музыкаль кичә уздырдылар. Кичәдә З. Хәйруллина мәрхүмнең күп яклы иҗаты, җәмәгать эшчәнлеге турында сөйләде. Яшь скрипкачы, Мәскәү консерваториясен тәмамлаган Рөстәм Кирдан Җәүдәт Фәйзинең скрипка һәм фортепьяно өчен язган «Яшьлек хатирәсе» әсәрен, яшь җырчы М. Галиев композиторның соңгы елларда язган җырларын башкарды.

* * *

Күренекле татар совет композиторы Җәүдәт Фәйзинең иҗат мирасын өйрәнү комиссиясе төзелде. Комиссия составына композиторлардан Исмай Шәмсетдинов, Бату Мулюков, музыка белгечләреннән Галина Касаткина, Зәйнәп Хәйруллина, Миләүшә Үтәй һәм язучы Габдрахман Минский кертелде.

## «КОРЪӘН СЕРЛӘРЕ»НЕҢ ЯҢА БАСМАСЫ

Китап магазиннарында Г. Гобәйнең «Коръән серләре» исемле әсәренең өченче басмасы сатыла башлады. Автор китапны элекке басмаларына караганда байтак тулыландырган, китапның ахырына «Социалистик Татарстан», «Казан утлары»



битләрендә укучыларга биргән җавапла-рын урнаштырган.

Татарстаннан читтә яшәүчеләр бу ки-тапны «Книга-почтой» аша урында түләп алу шарты белән соратып ала алалар.

Хатларны түбәндәге адреслар белән җибәрергә мөмкин:

г. Казань — 57,
Октябрьская, 18,
Магазин № 14, «Книга-почтой».

г. Казань, ул. Баумана, 19,
книжный магазин № 1,
«Книга-почтой».

## ҚАЗАН ҚУНАГЫ

Август урталарында башкалабыз Казан-да күренекле Мәскәү тәнкыйтьчесе, фи-лология фәннәре докторы, профессор В. К. Панков булып китте. Ул бөек юл-башчыбыз В. И. Ленин һәм М. Горький исеме белән бәйле урыннарда булды, шә-һәребезнең борынгы архитектура истәлек-ләре белән танышты.

## ХЕЗМӘТКӘ ХӨРМӘТ

Совет кино сәнгате өлкәсендәге хезмәт-ләре өчен, Казан кинохроника студиясе режиссеры Фатих Миңлехан улы Шәрә-фиевка **Татарстан АССРның халык арти-сты** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

1973 елгы гастрольләр вакытында рес-публикабыз хезмәт ияләренә культура хез-мәте күрсәтү өлкәсендәге зур эшләре һәм ирешкән иҗади уңышлары өчен Иркутск шәһәренең музыкаль комедия театры һәм М. Горький исемендәге Волгоград драма театры коллективлары Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамоталары белән бүләкләнделәр.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Шушы елның июль аенда татар ша-гыйрьләре Г. Афзал, Ә. Маликов, С. Сөләй-манова һәм башкорт шагыйре, Г. Сәлам исемендәге премия лауреаты Ә. Атнабаев Башкортстан АССРның Тәтешле районында үткәрелгән әдәбият-сәнгать атналыгында катнаштылар. Алар Бул-Қайпан, Бәдрәш, Курдем, Әрибаш, Аксаәт, Югары Тәтешле авылларының культура сарайларында һәм клубларында, җәйләүләрдә, хезмәт бригада-ларында чыгышлар ясадылар.

Татар һәм башкорт әдәбиятларын про-пагандалауда күрсәткән хезмәтләре өчен, КПССның Тәтешле райкомы һәм хезмәт ияләре депутатларының район башкарма комитеты Г. Афзал, Ә. Маликов, С. Сө-ләйманова һәм Ә. Атнабаев иптәшләрне Мактау грамоталары белән бүләкләде.


* * *

Лениногорск шәһәренең Калинин исе-мендәге культура сараенда Шамил Бик-чуринның «Қаты токым» романы буенча укучылар конференциясе үткәрелде. Әсәр буенча фикер алышуларда нефтьче-инже-нер, очеркист Ж. Рәхимов, бораулау ида-рәсенең баш инженеры В. Кәримов, татар әдәбияты укытучылары Ш. Таһирова, Ф. Гәрәева һәм башка иптәшләр катнаш-ты. Аларның һәркайсы «Қаты токым» ро-манын яратып, мавыгып укуларын әйтте-ләр.

* * *

Драматург С. Кальметов, Азнакай рай-онының күп кенә колхозларында булып, әдәбият сөючеләр белән очрашты. Аларга ул үзенең сатира-юмор әсәрләрен һәм фронт язмаларын укыды, бүгенге татар әдәбиятындагы яңалыклар турында сөй-ләде.

Яз житте



Август



## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫБЫЗ!

«Казан утлары» журналының 1974 елдагы беренче санында Рафаил Төхфәтуллинның «АКБУЗ АТ» һәм Гариф Ахуновның «АРДУАН БАТЫР» дигән повестьлары басыла.

Гамил Афзал, Сәҗидә Сөләйманова, Фәния Чанышева, Рөстәм Мингалимов һәм Госман Садә шигырьләрен дә сез бу саннан укырсыз.

Очерклар, әдәби тәнкыйть, сәнгать, яңа китаплар һ. б. бүлекләрдән дә ятарып укырлык материаллар табарсыз.

«КАЗАН УТЛАРЫ» журналына язылу дәвам итә. Нинди дә сәбәпләр аркасында әлегә кадәр журналга язылa алмый калсагыз, борчылмагыз. «Казан утлары»н сез теләсә кайсы айдан башлап яздыра һәм алдыра аласыз. Тик һәр нәрсәнең вакытында эшләнүе яхшы. Әгәр сез ноябрь аенда журналга язылып куйсагыз, аны ел буе тоткарлыксыз укып барырсыз.

«КАЗАН УТЛАРЫ» журналына илебезнең теләсә кайсы почта бүлегендә язылырга мөмкин. Аның өчен 73210 номерлы индексны әйтергә онытмагыз. Язылу бәясе елга 6 сум.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ